
ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2010





Хәсән Туфан
(1900—1981)

# Казан утлары
# Qazan utları

2010

**12**
**(1058)**

***ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:***

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

***НАШИРЕ:***

***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***
*Казан, Академия ур.; 2*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Хәсән ТУФАН. Ә йолдызлар дәшми. *Шигырьләр.* ........ 5
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Лотфулла солдат. *Бәян.* ........ 8
Гәрәй РӘХИМ. Менә шундый хәлләр... *Шигырьләр.* ........ 38
Әхәт МУШИНСКИЙ. Һаваларда–ак күгәрчен... *Роман.* ........ 42
Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Дөнья буйлап. *Шигырьләр.* ........ 53
Розалина ШАҺИ. Шигърият–тереклек суы... *Шигырьләр.* ........ 57
МӨҖӘҺИТ. Матур кешеләр бар. *Шигырьләр.* ........ 83

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Ләбиб ЛЕРОН. Кычыткан чыпчыгы. *Моңсу комедия.* ........ 60

**ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Бөеклек баскычлары ........ 85

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Марс АХУНОВ. Кычыткан телне сүз кашыр. ........ 88

**СӘНГАТЬ**

«Әни...» күп театрларга килде. *(СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров белән Рәйсә Юсупова әңгәмәсе).* ........ 90
Әзһәр ШАКИРОВ. Булмас димә, дөнья бу! ........ 100

**САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ**

Аида АЛМАЗОВА. Кабатланмас Сәйдәш. ........ 107
Аның турында замандашлары. ........ 109

**ТАРИХ**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Далада–татар курганнары. ........ 112

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 136

**ХӘТЕР**

Фирдәвес ХУЖИН. Күкләр шаһит. *Документаль бәян.* ........ 139

**ТӨРЛЕСЕННӘН**

Сәйдәш ГАРИФУЛЛИН. Европаны аркылыга-буйга. *Сәяхәтнамә.* ........ 160

**АК ҖИЛКӘН**

Зилә СӨНГАТУЛЛИНА. Бәләкәй Зилә. ........ 169

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Хөсәен ӘХМӘТ-ВӘЛИ. Комач хатирәләр. ........ 164
Рәфикъ ЮНЫС. Фәүзия Бәйрәмова татарга кем тия ул? ........ 178

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман А. МУШИНСКОГО «Шейх и звездочет»; повесть З. ЗАЙНУЛЛИНА «Солдат Лутфулла»; стихи Х. ТУФАНА, Г. РАХИМА, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ, Р. ШАГИЕВОЙ, МУЗАГИТА.
«Драматургия»: Л. ЛЕРОН. Мелодрама «Крапивник».
«К 125-летию Г. Тукая»: хронология жизни поэта.
«Искусство»: интервью Р. ЮСУПОВОЙ с народным артистом СССР Ш. Биктимеровым; притчи А. ШАКИРОВА (прод.).
«К 110-летию С. Сайдашова»: А. АЛМАЗОВА. Неповторимый Сайдаш; современники о Сайдашове.
«История»: Ф. БАЙРАМОВА «В степи—татарские курганы».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: Ф. ХУЗИН. «И небо тому свидетель».
«Юбилеи»: Р. ЮНУСОВ. «Кем приходится нам Байрамова?»; воспоминания Х. ВАЛИАХМЕТОВА.
«Белый парус»: З. СУНГАТУЛЛИНА. «Маленькая Зиля»; стихи Л. ИСХАКОВОЙ.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2010 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимний лес; поэт Музагит АХМЕТЗЯНОВ.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by A. MUSHINSKY «Sheikh and astrologer»; story by Z. ZAYNULLIN «Soldier Lutfullah; poems by H. TUFAN, G. RAHIM, SH. ZIGANGIROVA, R. SHAGIEVA, MUZAGIT.
«Drama»: L. LERON. Melodrama «Wren».
«To 125th anniversary of G. Tukay»: chronology of poet's life.
«Art»: interview of R. YUSUPOVA with People's Artist of USSR Sh. Biktimerov; parables by A. SHAKIROV (continuation).
«To 110th anniversary of S. Saydashov»: A. ALMAZOVA. Unique Saidash; contemporaries about Saydashov.
«History»: F. BAYRAMOVA «In steppe there are Tatar mounds».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuatoin).
Pages from Tatar Encyclopaedia.
«Memory»: F. HUZIN. «And heaven is witness.»
«Jubilee»: R. YUNUSOV. «Who is Bayramova for us?»;
memories by H. VALIAHMETOV.
«White Sail»: Z. SUNGATULLINA. «Little Zilya; verses by L. ISKAKOVA.
Bibliography of works published in 2010.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Winter forest; poet Muzagit AHMETZYANOV.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.12.2010, график буенча 1.12.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–1695. Тираж 4096.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.

# Хәсән Туфан

## Ә йолдызлар дәшми

Ваемсыз җил килеп керде кырдан.
Туздыра җил
Кибән түбәсен.
Иләс җилгә дәвер, күпмегәдер,
Тулы ирек биргән, күрәсең...

Кайда соң сез
Шундый җилле төндә,
Кайларда сез, изге дусларым?..
Яңа яра сала йөрәкләргә
Илебезнең иске дошманы.

Дене түгел, көне өчен генә
Яшәп илнең кайбер кибәге
Дегетли дә, дөмгә сөйри бүген
Иң кадерле эре ирләрне...

Ил йөрәге матәм кичергәндә,
Бәйрәм итә кемдер типтереп.
Дозорлыкны—гадел изге эшне
Явызлыкка сугым иттереп.

Кояшка син, йөрәк, йолдызларга:
—Бу ни хәл?—дип сорау бирәсең.
Алар дәшми...
Гамьсезлекнең дәвер, күпмегәдер,
Бәйле кулын чишкән, күрәсең...

*1937*

## Агыла да болыт агыла

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Нәрсә әйтсен: берни белми ул,
Хәбәре юк минем йөрәктән.
Мине бары чылатып үтте
Кукурузлар белән берррәттән...
Нәрсә әйтсен: берни белми ул.

Роман кебек күңелле син, юл!
Азмы синдә гомер уздырдым,
Ничә кием чабата синдә,
Ничә кием итек туздырдым!
Роман кебек күңелле син, юл!

Ә син, яңгыр, искә төшермә
Итегемнең ничек икәнен...
Яланаяк килдем дөньяга,
Шулай гына, бәлки, китәрмен.
Ә син, яңгыр, искә төшермә!

Зират бит ул сабантуй түгел,
Нигә анда киенеп китәргә?
Бу дөньяның бер пар итеген
Нигә юкка әрәм итәргә?
Зират бит ул сабантуй түгел.

Агыла да болыт агыла
Таулар аша Казан ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
...Агыла да болыт агыла...

*1951*

## Кайсыгызның кулы җылы?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы?—
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:
—Кайт!..—дип хатлар килделәр.
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
—Бусы алкалары,
Бусы—кабере...—диделәр.

Әгәр тагын килсәләр,
—Сау!—дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?—
Бәйлисе бар йөрәкне...

*1956*

## Кулын канга батырса да...

*А. С. Пушкинга*

Хәтердәдер, бәлки, сезнең
Казан аша узган чаклар?
Пугачевлар эзен иснәп,
Кешнәп җилгән аргамаклар
Хәтердәдер, бәлки, сезнең...

Азамат ир—башкортны да,
Дала улын—калмыкны да,
Европада беренче кат
Чуен койган халыкны да—
Татарны да күргәнсездер...

Күргәнсездер царизмның
Казандагы бакчаларын:
«Татар һәм эт кертелми!..»—дип
Өреп торган такталарын
Сез дә, бәлки, күргәнсездер...

Тиран шундый «этика»дан
Эт кадәр дә оялмады...
Ләкин сезнен иҗатка ул
Андый такта куялмады,
Кулын канга батырса да...

...Уральски кырларында
Күтәрелде юлда тузан:
Тукай кайтты Казанына
Пугачевлар узган юлдан,
Тугры Тукай кайтты илгә.

Төкерде дә илбасарның
Капкасына, тактасына,
Алып керде Туган илен
Сезнең иҗат бакчасына,
Алып керде безне Тукай.

..Аннан бирле азмы инде
Җилләр искән... комнар күчкән...
Әмма Тукай ачкан капка
Исән әле, һаман исән!—
Исә бирсен әйдә җилләр...

Хәтердәдер сезнең, бәлки,
Безнең яктан узган чаклар,
Каннар юлын кешнәп иснәп,
Ярсып җилгән җирән атлар
Хәтердәдер, бәлки, сезнең...

1968

## Бакчаларга ниләр булган?

*Фәридә Кудашевага*

Бакчаларга ниләр булган:
Сандугачлар сайрамый?..
Бу Казанның шушы ягы
Йөрәгемә ярамый.

Сайрамый ла сандугачлар
Ни каенда, ни талда:
Уфаларга киткән алар,
Уфаларда сез барга.

Шундадыр шул сандугачлар,
Сезнең тирәдәдер шул;
Сезнең җырны бездән элек
Шулар өйрәнәдер шул...

Безнең хәлне сорасагыз,
Безнең хәлләр «Уф!» инде:
Сез киткәннән бирле бездә
Сандугачлар юк инде.

Халык әйтә:
—Бакчаларны
Харап итте шул гына!
—Нишләп безнең Казан,—диләр,—
Чара күрми соң моңа?

Сайрамый ла сандугачлар
Ни каенда, ни талда:
Уфаларга киткән алар,
Уфаларда сез барга.

1959

Зәки
Зәйнуллин

# ЛОТФУЛЛА СОЛДАТ

БӘЯН

Иртәнге сәгать җиде тирәсендә каравыл начальнигы поручик камерага кереп аны уятты:

—Йоклый, каналья! Азрак кайгыра да белми, йоклый! У-у, татар мордасы!

Лотфуллага карады да, ачулы итеп сорады:

—Нәрсәгә елмаясың син, ә?

—Мин дә синең турыда: «У-у, русская морда»,—дип уйладым. Шуңа елмаям.

Поручик йодрыкланган кулын күтәрә биреп, солдатка якынлашты:

—Русия армиясе офицеры турында син, татарин, ничек шулай уйлый аласың. Мин сине хәзер...

Лотфулла кабаланмый гына торып аягына басты.

Поручикның күзенә туп-туры карап әйтте:

—Бармагың белән генә тисәң дә, мин синең хәзер башыңны өзеп ыргытам. Тиеп кенә кара миңа...

Поручик атлаган җиреннән шып туктады. Ул ачуын басарга тырыша иде.

—Атла! Сине полк командиры чакырды. Анда уйларсың кем башын өзәргә! Атла! Мамай калдыгы!

Командир кабинетына җиттеләр. Поручик бөгелгән бармагы белән ишек шакыды. Эчтән тавыш ишетелде:

—Әйе! Керегез!

Солдатны ишек төбендә калдырып, поручик алгарак үтте, доклад ясады:

—Ваше Благородие! Сезнең боерык буенча сакчы, арестованный рядовой Зәйнуллин китерелде. Каравыл башлыгы поручик Демин.

Полковник кулы белән өстәл яныннан урын күрсәтте:

—Узыгыз болайрак, Зәйнуллин. Менә шунда басыгыз.

Лотфулла полковник утырган өстәл янына килеп басты.

—Н-нусь!—диде полковник.—Нәрсә булды, төнлә син торган постта?

Лотфулла полковник сүзләрендә бернинди ачу да, үч алу теләген дә сизмәде. Курыкмаса да, сакланып кына, башын күтәреп полковникның күзенә карады. Һәм... тетрәнеп китте. Полковникның күзендә көлү

*Ахыры. Башы узган санда.*

чаткылары уйный иде.

Кыскача гына төнлә белән үзе торган постта нәрсә килеп чыкканын сөйләде. Полковник сорау бирде:

—Стой! Стрелять буду!—дип кычкырдыңмы?

—Так точно! Ике мәртәбә!

—Ә ни өчен ике мәртәбә, бер генә түгел. Устав бит кабатлауны таләп итми?

Лотфулла, аз гына уйлангандай итеп, үзенең төнге хәлен исенә төшерде дә, җавап бирде:

—Мин аны ишетмәде, ахрысы, бер кычкырганда дип уйладым. Аннан...

Туктады.

Полковник тыныч кына сорады:

—Нәрсә «аннан»...

—Кем генә булса да, атып үтерәсем килмәде.

—Ала-ай!

Поручикка борылды.

—Сакчыны разводящий посттан алган һәм дөрес эшләгән. Аны атылган сыер янында калдырырга ярамый иде. Ә нигә дип аны гауптвахта камерасына яптыгыз? Нинди ярамаган эш өчен, яисә Уставның кайсы статьясын бозган өчен?

—Господин полковник! Ул бит сезнең сыерны аткан.

—Шуннан, атса ни булган?

—Ул бит сезнең сыер. Полк командирының сыеры.

—Әйдә, болайрак уйлыйк поручик. Әйтик, ул полк командиры сыеры урынында шәхсән сезнең сыер булды ди? Поручик сыеры. Һәм часовой Зәйнуллин сезнең, поручикның сыерын, төнлә, караңгыда пост чиген бозып кереп килгәндә атып үтерде ди. Һәм мин сезне бүген, монда, ни өчен господин поручик сезнең сыер төнлә белән снарядлар складына керергә тырышкан дип, аңлатма бирергә дип чакырган булсам, сез миңа нәрсә дип җавап бирәсез бу очракта?

Поручик нәрсә дип тә җавап бирергә белмичә басып тора иде:

—Ну, господин поручик?!

—Минем сыерым юк, господин полковник!

—Дөрес, сыерың юк. Һәм сез әле генә Зәйнуллинны барлык хәрби һәм тормыш уставларын, законнарын бозып гауптвахтага гаепсезгә утыртканыгызны аңламадыгыз.

Полковникның тавышы кискенләнде:

—Полк командирының шәхси сыерының төнен каралмыйча, ябылмыйча иректә йөрүенә полк командиры һәм аның сыерын карарга тиешле деньщигы гаепле. Ә снаряд складына караңгыда керергә тырышкан пост бозучыны атып үтергән часовой Зәйнуллин түгел. Зәйнуллин тулысы белән дөрес эшләгән. Ә сез аны гауптвахтага утырткансыз! Полк командирының ачуыннан куркып шундый эш эшләп ташлагансыз сез төнлә белән.

Лотфуллага якын килде полковник.

—Үз-үземне мин гауптвахтага утырта алмыйм, Зәйнуллин. Ә деньщик кичә кичен лаякыл исерек булган. Асрау хатын сыерны саугач, деньщик япмаган. Сыер бәйләгән бавын өзгән дә, постны эзләп чыгып киткән... Һәм... тапкан! Поручикның курку күрсәтеп ясаган гамәле өчен мин, Зәйнуллин, синнән, полк командиры буларак, гафу үтенәм. Молодец син.

Кыска гына көлеп куйды:

—Бер пуля белән нәкъ маңгаена чәпәгәнсең бит сыерның. Илләмә шәп аткансың икән тавышка да! Синең, Зәйнуллин, бер гаебең дә юк. Бик шәп

сакчы икән син! Рәхмәт.

Ике көннән барлык полкны крепость плацында тезеп, полк командирының боерыгын укыдылар:

—Рядовой Зәйнуллин... постта уяу торган, төнлә караңгыда адашып йөргән сыер постка керә башлагач, часовой Зәйнуллин караңгыда сыерны күрмичә, Устав кушканча командалар кычкырып, аны кертмәскә тырышкан. Сыер керүеннән туктамагач, бер пуля белән атып, аны үтергән. Яхшы хезмәт итеп, снаряд складында постта уяу торганы өчен рядовой Зәйнуллинны 5 сум акча белән бүләкләргә һәм рәхмәт белдерергә!

«Сыер атылганга» бөтен полк шаулашып фикер алышты. Үзенең сыерын аткан часовойга биш тәнкә бүләк биргән полк командирына күпчелек сокланды. Тик, исереп сыерны «карарга онытккан», унбиш тәүлеккә гауптвахтага утыртылган деньщик-солдат кына риза түгел иде:

—Унбиш тәүлек! Тәүлегенә ярты чиләк сөт бирмәгән сыерны ябарга онытканга, унбиш тәүлек гауптвахта миңа?! Өстәвенә, гауптвахтада көләләр миннән: «Сине, урыс солдатын, сыерны япмаган өчен генә полковник унбиш тәүлеккә утыртып куйды, ә татар солдатына, шул сыерны атып үтергән өчен биш сум бүләк бирде». Нигә ул шулай? Алтын Урда заманымыни инде бүген? Татарлык өстенлек итә башлады тагын!

Унбиш тәүлек узгач, гауптвахтадан чыккан хәмергә ихлас урыс солдатын, полк чучкаларын карарга тәгаенләделәр.

Батарея командиры капитан Бульонның наводчик рядовой Зәйнуллинга мөнәсәбәте көннән-көн әйбәтләнә барды. Ул Зәйнуллинга гына түгел, батареядагы башка солдатларга да сугудан туктады. Тик, табигатьтән килгән ялкаулыгы белән, солдатлар арасында «Пермяк соленые уши» дип кушамат алган солдатка һаман да «эләккәли» иде. Йодрык белән түгел, сүз белән, урыс маты белән. Атнага ике-өч тапкыр батареяның төрле урыннарында капитан Бульонның яңгыравыклы баритон тавышы ишетелә.

—... твою мать! Пермяк е..., соленые уши! Тагын итекләреңне тазартмагансың бит. Кырынмагансың!

Берничә көн узгач:

—Что за чорт?! Кая кереп йоклап ятасың син, ә? Тагын качып йоклап ята! Ну и ну! «Соленые уши!»

Укыту төркеме өчен капитан Ростунов атулар уздырды. Ул атулар беркем көтмәгән нәтиҗә бирде. Прицельдә иң тиз эшләгәне, тиз атканы һәм ун снәрәднең алтысын тидерүче яңа наводчик рядовой... Зәйнуллин булып чыкты. Һәм полк командиры исеменә бирелгән рапортка ату нәтиҗәләренә йомгак ясап, капитан Ростунов түбәндәге сүзләрне язды.

«... яңа наводчик солдатлар арасында рядовой Зәйнуллин үзенең тиз исәпли белү сәләте белән яхшы якка аерылып тора. Артиллерия приборларын тиз үзләштерде һәм аларны аңлап, төпле итеп эшли. Табигать тарафыннан бирелгән сәләте зурдан, шуның өстәвенә чыдамлыгы, эшли белүе, тырышлыгы бик тә нигезле һәм ныклы. Күнегүләрдә, атуларда, маневрларда аны ешрак кулланcак, минем уемча, яңа наводчик рядовой Зәйнуллин безнең крепостьның иң шәп белгечләреннән берсенә әйләнәчәк...»

Капитан Ростунов команда буенча тапшырган рапорттан соң икенче көнне рядовой Зәйнуллинны капитан Бульон полк командирына алып керде.

Рөхсәт сорап кабинетка керделәр. Капитан доклад ясады:

—Ваше Высокоблагородие! Сезнең боерык буенча капитан Бульон һәм рядовой Зәйнуллин килделәр. Доклад бирде капитан Бульон.

—Утырыгыз икегез дә!—дип өстәле алдында торган артлы урындыкларга күрсәтте полковник. Елмаеп икесенә дә жылы итеп карап алды.

—Сезнең тыныч, көләч йөзләрегезне күрүгә мин бик тә шат. Бигрәк тә сезне, господин капитан Бульон. Сезнең исәнлек-саулык көннән-көн әйбәтләнә бара, бала-чагаларыгыз да әйбәт булып үсәләр. Тазалар. Гимназистыгыз бик әйбәт укый икән.

Капитан аптырабрак сорады:

—Ул турыда да беләсезмени?

—Беләм. Гимназиядә минем таныш, дус укытучылар бар. Инде рядовой Зәйнуллин синең турыда капитан Ростунов бик нык мактап, сине бик сәләтле наводчик булачак дип зур өмет белән рапорт язган. Капитан Бульон да сезне бик мактый, тырыш, тәртипле солдат, ди.

Алдында утырганнарга карашын ташлап, битен тоташ балкытып елмайды:

—Мин дә, полк командиры полковник Тимофеев, син сакчы Зәйнуллин, төнлә белән постка килеп кергән пост бозучыны (минем сыерны димәде) бер атуда тәгәрәткәч, синең бик тә яхшы солдат икәнеңне аңладым... Эһем, эһһем!

Керчьтә, минем күршедә генә бик зур сәүдәгәр татарин яши. Мамедов фамилияле. Чын татарин. Мин анардан полк солдатларын ашатырга ризык сатып алам. Ашарга дуңгыз итеннән башка ризык бар да бар. Кырым татарларыннан ала, Кавказдан китертә. Һәрвакыт гадел итеп акчаны исәпли белә, беркайчан да алдамый. Полктагы халыкны ашатырга безгә бит управлениедән акчалата бирәләр, азык белән түгел. Һәм без азык-төлекне сәүдәгәрләрдән үзебез сатып алабыз. Өч көннән минем ризык алырга сатулашырга барасым бар иде. «Сатулашырга ярдәм ит!»—дип Мамедовны чакырган идем. Бара алмыйм, безнең мөселман бәйрәме, ди. Лотфуллага карады:

—Өч көннән сезнең, мөселманнарның, Корбан бәйрәмегез була икән. Дөресме ул?

Лотфулла тиз генә исәпләп алды.

—Әйе, дөрес. Һәр елны ул бәйрәм ун көнгә алданрак килә. Мин солдатка алынганда, узган ел диюем, Корбан бәйрәме сентябрь азагында булырга тиеш иде. Мин китеп өлгердем.

Полковник өстәл тартмасын ачты.

—Без, капитан Бульон белән киңәшләштек тә, сине Зәйнуллин Корбан бәйрәмендә биш көнлек ялга җибәрергә булдык. Керчь каласына. Анда мәчетләр күп. Татарлар гына яшәгән урамнарда икешәр, өчәр мәчет бар.

Елмайды:

—Сәүдәгәр Мамедов әйтә, һәр байның үз мәчете бар Керчьтә, ди. Ә татар байлары Керчь каласында ун татарның берсе, ди. Булыр сездән! Бик тырыш бит сез!

Иртәгә иртән киен, киемнәреңне тазарт. Парад форманы ки, и шагом марш в Керчь! Мамедов әйтә, үзенә ошаган мәчеткә керсен, намаз укысын шунда, ди. Шул мәчеттәге картларның берсе алып кайтып китә аны үз өенә, ди. Кунак итеп үзендә тота ул аны, ди. Хуҗа эшләргә чыкса, синең солдатың да аңа ияреп чыксын, эшләсен, ди.

—Сиңа язган кәгазь «Увольнительная» дип атала. Биш көнгә яздым мин сиңа увольнительнаяны. Әгәр инде, сине чакырып үзләрендә кунак итсәләр дә, алай-болай кырынрак караш сизсәң, крепостька кайтып кит. Әгәр инде яхшы каршы алсалар, тор биш көнен дә. Казармадан, солдатлардан, без командирлардан азрак ял ит. Казарма һавасыннан да. Аңладыңмы?

Лотфулла урыныннан тиз генә торып аякларына басты.

—Так точно.

Командирлары ягыннан үзенә карата мондый җылылык һәм игътибар

көтмәгән иде ул. Сигез яшеннән бирле төрле кешеләр тарафыннан кимсетелгән, изелгән ялчы бәндә бит ул. Ә монда мактыйлар, инде сәләтле дип, увольнениега җибәреп ял бирәләр.

Полковник Лотфулланың уйларын бүлде:

—Онытa язганмын. Минем урынбасарны—капитан Мироновны беләсеңме?

—Беләм.

Шуны тап һәм ял итә торган биш көнеңә акча ал. Шул биш көн ашау хакын сиңа акчалата бирергә тиеш ул. Бар! Ял ит!

Икенче көнне иртәнге аштан соң, Лотфулла увольнительныйны капка саклаучы жандармга күрсәтеп, крепостьтан чыкты да, Керчь каласы тарафына сузылган юл белән, башта диңгез яры буйлап калага юнәлде. «Солдат хезмәтендә булу, Гапкадыйр Мәгъзүмгә ялчылыкта йөрүдән әйбәтрәк тә икән әле. Полк командиры да әйбәт, капитан Бульон да әйбәт, инде сугышмый да соңгы айларда... Яшәп була монда.»

Керчь каласы тоташы белән җиләк-җимеш, алма, армут, хөрмә, йөзем бакчаларына күмелеп утыра икән. Шул бакчаларга өстәп һавага ничегрәк кенә булса да биегрәк менәргә тырышып үскән күпсанлы озынча тупыллар һәм алар белән биеклеккә таба ярышып үскән кипарислар. Алар барлык урамнарны тутырып күпләп үскәннәр. Шул тупыллар, кипарислар яныннан үтә башласаң, аларның үзенә генә хас исе сине уратып ала. Теләсәң—теләмәсәң дә синең үпкәләреңне, һавага күпләп чыгарган кипарис, пирамида тупыллары исе белән тутыралар һәм синдә яшәү теләген тагын да ныграк арттыралар. Каланың читеннән, кояш чыгышы ягыннан килеп кереп, Лотфулла кабаланмый гына атлап Керчь урамнарын, өйләрен, кешеләрен карап бара башлады. Һәм бер матур урамны бетәр-бетмәс үтеп, нәтиҗә дә ясап алды: «Җир өстендәге оҗмах бит монда!»

Уралып-үрелеп, үрмәләп үскән йөзем агачлары, ямь-яшел яфраклы төз булып күкне тишеп күтәрелгән кипарис, тупыллар, урамнарда җыйнак, ыспай киенгән чибәр татар кешеләренең йөзләре! Солдат бер нәрсәгә игътибар итте: каршы килгән татар хатын-кызларының берсенең дә йөзе ябык түгел. Тик каршы килгән солдатны күрү белән ул хатын-кызлар урамның икенче ягына чыгып, башларын азрак читкәрәк борып үтеп китәләр. Хет берсе карасын солдатка! Инсафлык, тәртиплелек, әчке торышның, тәрбиянең асыллыгы ул хатын-кызның киеменнән дә, төсеннән дә, атлавыннан да күренеп тора. Татар хатын-кызларыннан нур сибелеп бара.

Лотфулла Кырым ташыннан салынган уртача зурлыктагы мәчет янында тукталды. Матур челтәрле итеп ясалган тимер капка, таш койма. Мәчет ишегалдында ике иярләнгән ат һәм кечкенә гәүдәле бер ишәк бәйләүдә тора. Лотфулла кабаланмый гына мәчет ишегалдына үтте дә, мәчеткә керергә дип аның ишегенә килде. Авыз эченнән генә «бисмилла»ны укып, мәчет ишеген ачты. Ишекне ачкан унайга аны мәчет эчендәге җылы, саф һава каршы алып кочаклады. Мөселман солдатының эченә нииндидер кешеләргә сыенып утыру теләге тарала башлады. Ул, татар баласы—мөселман мәчете эчендә! Ишек төбендә итеген салды. Ике чолгавын да итекләре эченә тыкты да, итекләрен башка аяк киемнәре янына башларын тигезләп бастырып куйды. Белә ул: мәчет эчендә бар да тигезләп тезелгән булырга тиеш, тәртип вә пөхтәлек булырга тиеш! Ходай белән сөйләшү йорты бит бу һәм Ходайга Җир йөзендәге иң якын урын!

Алдан уйланылганча, ак чолгаулары эченнән соры төстәге ике оекбаш киеп куйган иде. Аларны салмады. Иртән бик җентекләп казарманың юыну бүлмәсендә, шешәгә су тутырып, тәһарәт алып килгән иде.

Мәчет эчендә идәнгә җәелгән калын, кул белән суккан йон паласлар өстендә утызлап кеше намазда утыра. Араларында җиде-сигез яшьлек һәм азрак зуррак берничә малай да бар. Ул түбәтәйле татар малайлары мәчеттә намазда утыручыларга ямь биреп, агачлар арасында үскән матур аллы-гөлле чәчәкләрне хәтерләтәләр иде.

Урыс казармасында бердәнбер мөселман булып яшәп, Лотфулланың йөрәге чит-ят мохиттән яхшы гына талчыгып, арыган икән. Ул мәчеттәге ислам диненең рухы белән сугарылган һавадан иркен итеп тын ала, күзенә ирексездән килгән яшьләрне көчкә генә тыеп тора. Борын тишекләре киңәеп китеп, үпкәләр иркен итеп сулыйлар. Күз аллары яктырып китте,җанында барлык вөҗүден үзенең мөселман булганлыгы шатлыгы биләп ала.

—Кай яклардан килеп чыктың безнең мәхәлләгә солдат аркадаш?

—Керчь крепостеннан мин. Шунда артиллериядa хезмәт итәм.

Барысы да җанлана төштеләр.

—Ә-ә, Ак Борын кальгасыннан икән.

Берсе сорады:

—Төрек кальгасыннанмы?.

—Үзең кайсы яктан?

—Урал тауларының көньягыннан. Ырымбур далалары башланган җирләрдән.

—Күптән мондамы?

—Ел тулып үтте инде.

Иң беренче булып кулларын биреп танышкан чалмалы ир тагын ике кулын сузды:

—Тагын бер күрешик әле. Ибраһим минем атым. Ибраһим булам. Син кем?

—Минем исемем Лотфулла.

—Алай икән. Чын мөселман исеме икән. Сине кальгадан командир хуҗаларың җибәрдеме?

—Әйе. Ялга, биш көнгә.

—Ә-ә! Биш көнгә икән. Әйбәт, әйбәт.

Уратып алган мәхәллә халкына караштырып алды да, Лотфуллага мөрәҗәгать итте:

—Аркадаш Лотфулла! Әйдә, рәхим итеп минем йортыма кайтыйк. Кунак булырсың биш көн. Бездә торырсың, яшәрсең, йокларсың, ашарсың, ял итәрсең.

Кыска гына көлде:

—Урыс казармасы исеннән арынып, мөселман булып яшәрсең биш көн булса да. Киттек, әйдә.

Лотфулла дәшмичә елмаеп, нәрсә әйтергә дә белмичә басып тора иде.

Тирә-яктагылар шаулаштылар:

—Бар, бар! Ибраһим бик әйбәт, кунакчыл мөселман ул. Бар!

Ибраһим белән Лотфулла ашыкмый гына урам буйлап атлыйлар. Каршы очраганнар да, бакчаларында эшләгәннәр дә Ибраһимга елмаеп, ачык йөз белән дәшеп исәнләшәләр. Дәрәҗәсе зурдан Ибраһимның мәхәлләдә—күренеп тора.

Кайтып җиттеләр.

Ибраһимның йорты таштан, ике катлы итеп салынган зур бина икән. Лотфулланың йортны кызыксынып караганын чамалап алды хуҗа.

—Бабамнан калган йорт бу. Борынгы дип тә әйтеп була. Анарга да бабасыннан калган булган.

Хуҗаны тыңлап аңлады Урал татары:

—Ибраһим ага! «Әти»не Кырым татарлары «баба» диләрме?

—Шулай диләр, «баба»! Әйдә, өйгә керик. Мин сине карчыгыма күрсәтим.

Беренче катта зур гына аш пешерү бүлмәсе икән. Илле яшьләр чамасындагы чибәр вә дә бик мөлаем йөзле ханым елмаеп каршы алды аларны:

—И-и, Ибраһим! Рәхмәтләр төшкере, кунак алып кайтып киләсең түгелме соң?

—Әйе. Менә Ак патша хезмәтчесе булган татар егете Лотфулланы алып кайттым. Берничә көн бездә торыр. Ашат безне, эчерт яхшылап. Савабы сиңа Ходайдан күп булыр. Бу апаңның исеме Хәсбиямал булыр. Ә бу кунак егетнең аты—Лотфулла.

—Әйдә, өске катка меник. Безнең анда иң зур бүлмә бар, диванлык дип атала. Диңгез ягына һәм ишегалдына караган тәрәзәләре. Аста гына зур бакча. Агачлардан, гөлләрдән хуш ис агыла тәрәзә ачсаң.

Көлде:

—Рәхәтләнеп иснәп йокла хуш исләрне. Кырым чәчәкләренең, кипарис-тупылларның исләрен...

Өйләдә өчәүләшеп ашарга утырдылар.

Кунак тартынып кына сорады:

—Балаларыгыз бармы?

Ибраһимның йөзе яктырды:

—Аллага шөкер! Биш балабыз бар. Өчесе малай, икесе—кечкенәләре—кыз балалар. Улларыбыз башка чыктылар, аерым яшиләр. Берсе монда—Керчьтә. Бодай белән сәүдә итә, Италиягә сата. Бер улым, олысы, Севастопольдә яши. Сәүдәгәр анысы да. Төркия белән мәшгуль. Өченчесе—кече улыбыз Ак Мәчеттә. Анысы Алла хезмәтчесе—мулла. Өчесенә сигез оныгыбыз бар...

Шатланып көлде:

—Малайлар шәпләр ул якка. Киленнәрдән малайлар гына таптыралар.

Хуҗабикә хатын-кыз буларак түзмәде, киленнәрен яклап үзенекен әйтеп куйды:

—Киленнәр шәп диген син. Алар таба бит сиңа малай оныкларны, синең улларың түгел. Аллага шөкер, өчесе дә бик инсафлы балалар. Безгә баба-ана дип үлепләр торалар. Ул оныклар асыллар—чын татар балалары инде. Тупырдап үсеп киләләр. Бисмилла алдан йөри барысының да.

Ибраһим ага күңелле итеп елмая иде:

—Менә, Лотфулла, күр инде син үзең. Бабайлар әйткәннәр: «Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска»,—дип. Үзеңнең, ир-егетнең мәддәтең, ирлегең, көч-гайрәтең вә һәм дә малың булмаса, хатын-кыз гаиләдә хәзер өстенлекне алып, хуҗа була башлый. Чөнки син тапканнан пешереп-төшереп, сине ашатып-эчереп, ул уйлый башлый үзенең кыска акылы белән: «Мин ашатам иремне, мин эчерәм иремне. Һәм ул мине тыңлап яшәргә тиеш тә инде!», дип. Менә, мә! Киленнәр шәп, имеш. Берләштереп алды өч киленне—мине дә, малайларны да бөгеп, безне үз асларына тыгарга маташалар...

Хәсбиямал апа йөзен балкытып елмая иде:

—Ки-и-ит инде! Сөйләмә юкны! Кеше ышандырырсың! Сине бөгеп буламы да, мин шулай эшләргә тырышаммы? Берүк үзең баш бул, үзең хуҗа бул, үзең генә хан бул. Сигез оныгым бар, шул житкән миңа. Аллага шөкер! Ике кызым житеп килә. Кияүгә биргәч, кыз оныкларым да булыр әле. Иншалла. Менә, Алла кушып, кыз оныклар бөгәчәкләр инде сине, ә мин түгел! Хи-и син-не-е!

Кич бакчада, матур итеп ясалган кыек астында кичке ашка утырдылар. Хуҗа өсте таш һәм жир белән ябылган, баскычы кыеклап жир астына

төшерелеп ясалган урынга төшеп, кире чыкты. Кулында озын муенлы бер чирек чамалы, балчыктан ясалган кызыл чүлмәк. Өстәлдә пары чыгып торган кисәк-кисәк итеп туралган кабыргалы симез сарык ите. Зур табакта пилмәннән эрерәк, ясалышы белән шуңа охшаган, Лотфулла өчен таныш түгел ризык. Һәм тагын бер табак... нәкъ үзләре авылындагыча ясалган вак бәлешләр.

Хужа, азрак күзләрен мутлатып, елтыратып, «алачыктан» (теге подвалга охшаган җир астын хужа шулай дип атады) алып чыккан озын муенлы балчык чүлмәктән ап-ак фарфор матур, тирән чәшкеләргә кып-кызыл эчемлек сала башлады. Өстәл өстенә авыз суларын китереп тәмле ис таралды:

—Үзем ясаган шәраб бу. Авыз итик азрак.

Матур ирennәрен бөрештерә биреп, ризасызлыгын сиздермәскә тырышкан Хәсбиямалына елмайган күзләрен текәп әйтте:

—Коръән Шәриф мәй эчәргә рөхсәт итми дип, минем Хәсбиямалым һәрчак каршы төшә. Ә Коръәнне җентекләп аңлап укып, шуны Коръәндә язганны әйтүне аңларга теләми...

—Шулайдыр, аңламыйдыр әллә кая! Син генә инде акыллы башлы.

Ибраһим абый, кабаланмый гына ике чәшкегә яртылаш итеп шәраб салды да, Лотфулладан сорады:

—Хәмер эчкәнең бармы синең?

—Койган ачы балны эчкәнем бар.

—Мин аны белмим. Нәрсә була ул?

—Умарта балыннан, кирәгенчә оеткы салып, мич башында җылыда тотып әчетәләр. Соры төстәге, ачыган бал—хәмер була.

—Сездә дә бездәге кебектер инде. Безнең муллалар да хәмер эчү Коръән буенча тыелган, диләр. Чын сүзме икән, белмим, тик мулла булсалар да, укымышлы булсалар да аңлап бетермиләр. Коръән Хафизда хәмер эчү турында нәрсә диелгән? Анда: «Тамчысын да эчәргә ярамый»,—диелгән. Нинди «тамчысын» диелгән анда? Беренче «тамчысын» диелгән! Бе-ерен-чене, диелгән. Шуңа күрә мөселман шәраб эчәргә ниятләсә, беренче тамчыны менә болай итеп чәшке эченнән алып, селкеп ташларга тиеш. Лотфулла, кара һәм өйрән!

Ибраһим абый «бисмилласын» әйтеп, уң кулының имән бармагын алдында утырган чәшке эчендәге шәрабка тыкты. Кулын аннан алды да, өстәл өстенә селкеде. Бармагыннан бер зур тамчы шәраб шуып өстәл тактасына килеп төште.

—Менә булды. Әчәбез вә һәм дә гөнаһы да юк. Беренче тамчысы өстәл тактасында. Тык, әйдә, солдат, бармагыңны! Урыс хезмәтендә чакта сиңа шәраб эчү дә рөхсәт ителә. Тамчысын селкемичә дә. Чит кешеләр хозурында, аларга буйсынып яшисең бит син. Эч, әйдә!

Мин сиңа тагын бер «һөнәр» күрсәтермен әле бүген.

Лотфулла тыңлады хужа абзыйны. Авызын ерып, бармагын шәрабка тыгып алды да, бармакка эләккән шәраб тамчысын өстәл тактасына селкеде. Ибраһим абзый кебек итәргә тырышып азлап-азлап кына йотып, таныш булмаган эчемлекне эчә башлады. Тәме, исе бик тә нәзакәтле иде. Мондый асыл исле тәмле эчемлекне моңа кадәр аның әле эчкәне юк иде.

—Үзем үстергән кызыл йөземнән ясалган шәраб бу. Миндә җитәрлек, күп ясалган. Мичкә-мичкә алачыкта утыралар. Бабам мәрхүмнән калганы да бар. Өч мичкә. Бабамны искә алганда эчәм ул мичкәдән шәрабне. Аз-азлап кына инде...

Кояш баеп караңгы төшкәч, йокларга яттылар. Лотфуллага, хужа әйткәнчә, өйнең икенче катыннан иң зур бүлмәне бирделәр.

Икенче көнне иртән капка төбендә кемнәрнеңдер мыдыр-мыдыр сөйләшкәненә уянып китте кунак. Ишегалдына, тау ягына чыккан тәрәзәдән карады. Капка төбендә ике зур тәгәрмәчле арбага җигелгән таза гәүдәле алаша тора. Анда хуҗа белән таныш түгел тагын ике кеше баскан килеш сөйләшә. Берсенең кулында каеш чыбыркы. Лотфулла чалбарын, гимнастеркасын киде дә, аскы катта, ишек төбендәге итеген киеп, тегеләр янына капка төбенә чыкты. Якын барып сәлам бирде. Тегеләр сәламне алдылар. Әңгәмәдәшләренең сораулы күзләренә хуҗа җавап бирде:

—Кунагым минем. Лотфулла исемле егет. Керчь кальгасы солдаты. Сез бара торыгыз. Кисә башлагыз. Мин барып озын арба җигәм дә, хәзер барып җитәрмен.

Лотфулланы татарлар белән таныштырды.

—Монысы минем бертуган энекәш. Ә менә монысы апаның улы. Берсе—Әмәтулла, икенчесе—Саматулла. Без Әче Мөшкәгә таш кисеп алып кайтырга барабыз. Мин сарай салам бит.

Көлде берсенең аркасыннан сугып:

—Илләмә эшкә шәпләр инде. Җенен өзәләр эшнең. Барыгыз, егетләр!

Өйгә керделәр.

—Син, Лотфулла, аша-эч тә, калага чыгып йөреп кер. Базар бик шәп безнең—анда йөр. Аннан кайтып ашагач, кичә кич утырган урынга чыгып йокла. Ял ит!

—Хуҗа эш майтарып йөргәндә, мин нишләп кала базарында, эт эчереп йөрим, ди. Аннан йоклап ятыйм, ди инде. Синең белән барам мин.

—Кызы-ык! Эт эчереп йөрим ди мин? Кызык. Сезнең якларда эшләмичә йөрүне шулай эт эчерү диләрмени?

—Шулай диләр. Син миңа, Ибраһим абзый, берәр иске чалбар бир, бер иске күлмәгеңне бир. Мин шуларны киим. Минем өстәге киемнәр парадный формалар бит. Алай-болай ертылса-нитсә эләгер миңа.

—Кунакны эшләтү ошап бетәрме икән? Күршеләрнең дә әйтүләре бар, мәчеттән Ибраһим үзенә солдат-ялчы алып кайткан дип.

—Кеше авызын томалап булмый инде ул. Әйтмәгәйләре лә! Сөйли бирсеннәр. Аннан, мин, синең ул Әче Мөшкәне дә күрәсем килә. Керчь кальгасын шул таштан салганнар бит. Син, хуҗа киткәч, мин ни эшләп монда хатын-кыз янында калыйм, ди?!

—Курыкма син алардан.

—Эш куркуда түгел. Мин дә барам синең белән Әче Мөшкәгә.

Хуҗа аз гына уйланып торды да:

—Синеке дөрестер, Лотфулла. Бар аша, чәй эч. Мин ат җигеп, озын арба алып кайтыйм әле. Чәй эчеп өлгерерсең мин кайтканчы.

—Миннән башка китмә.

—Юк инде, нинди китү ди тагын.

Ярты сәгать вакыт үтмәгәндер, икәүләшеп озын арбага утырып юлга чыктылар. Арбага җигелгән кып-кызыл төстәге, чем-кара койрыклы-яллы таза алаша, кабаланмый гына ырымлы адымнар белән салмак кына юырта. Таш ташыр өчен махсус ясалган арбаның тәгәрмәчләре киң итеп, тимерләп ясалган. Арба нык (таш төяргә бит!), атның дирбияләре барысы да каештан һәм җиз тәңкәләр белән бизәкләп эшләнгән.

Керчь якларында урманнар бөтенләй юк диярлек. Җире дә соры туфрак белән балчык катыш икән.

Ибраһим абый ашыкмый гына сөйли.

—Безнең җирдә үлән бик шәптән үсми. Шулай булса да, һәр йортта 10—15 сарык, 2—3 сыер, 2—3 ат тотабыз. Елга буйларын, күл ярларын чабабыз. Анда җәен мал кертмибез. Мал—далада. Яңгырлар бик еш яумаса

да, атнага бер йәисә ике мәртәбә коеп, тоташ дивар кебек явып китә. Барлык елгаларны чакрым саен ике-өч урыннан буабыз. Төн эчендә шуларга су җыела. Бодай басуларына да, җиләк-җимеш бакчаларына да, алма-хөрмә-армут агачлары төпләренә дә шул буалардан төн эчендә җыелган суны сибәбез. Иртән иртүк кояш кыздыра башлаганчы сипкән су җиргә сенсен! Кайда агызып, кайда чиләкләп ташып. Эше күп инде. Илләмә эшли белсән, нәтиҗәсе дә бик зур уңышлы була. Урыслар Кырымны басып кергәч, күп җирдә безнең авылларга тerәп урысларны утырттылар. Яхшы су буена утырган татарларны авылларыннан кудылар. Татарлар салган йортларга кереп тулдылар. Хуҗалар бит!

Эшләмиләр урыслар. Татарлардан калган йорт-куралар барысы да җимерелеп, череп ята. Эш вакыты—ә капка төбе саен исерек урыс утыра. Күз житсә безнең яландагы бакчалардан алма, армут, йөзем урлыйлар. Урлаган өчен аларны тотып кыйнасак, урыс үрәднигы килеп безгә арест ясап алып китә. Урыс хуҗа Кырымга бүген...

Бераз дәшми барды да өстәде:

—Менә хәзер элекке татар авылы Кызыл Таш аша үтәчәкбез. Бүгенге исеме—Красная Каменка.

Авыл зур гына. Көн яңа гына башланган булса да, чыннан да, салмыш урыслар капка төбе саен, чучка кебек юан маржалары кычкырып сөйләшеп, кычкырып-көлешеп көнбагыш чиртеп утыра иде.

Авылны сөйләшмичә генә уздылар.

Тугарып арбага бәйләнгән ат янына барып туктадылар. Үзләренең атын тугарып тормадылар. Башына солы салган капчык бәйләделәр дә, ике аркан алып җир астына төшеп киттеләр.

—Исемен Әче Мөшкә дисез. Нилектән кушканнар бу урынга шулай дип?

—Төшеп, ярты сәгать таш кисә торган пычкыны тарткач, үзең үк аңларсың.

—Аңлармын ла ул. Шулай да, ни өчен, әйт инде?

—Пычкы тартканда тир бик нык ага. Күлмәкләрне салып ташлап тартабыз без аста пычкыны. Әче тир чыга тәннән. Һава авыр, җитми, җир асты бит. Дымлы да, эшләгән кешегә һава җитми.

Җир астында Әмәт белән Саматның сөйләшкән тавышларына чамалап бардылар. Бик ерак та, һәм тирән дә түгел икән. Кулына керосин белән яна торган куыклы фонарь тоткан Ибраһим абзый атлый, аның артыннан җилкәсе аша ике аркан салган Лотфулла килә. Барып җиттеләр. Алдан килгәннәр кырлары берәр метр чамасы булган ике ташны кисеп, читкә этеп куйганнар. Пычкылары ике төрле икән. Берсе сыңар саплы, икенче очы өскә таба каратып түгәрәкләнеп киселгән. Күбрәк шул пычкы белән эшләп кисәләр икән. Икенчесе, агач кисә торган аркылы пычкы кебек, ике саплы икән. Үткер балта белән каты балчыкка чапкалап кисә торган якка азрак эз салып чыгалар да, шул эздән пычкы белән кисә башлыйлар. Пычкы үткен, балчык күзгә күренеп киселә—эш шуннлыктан бик күңелле бара. Уңлап ташны кисеп читкәрәк куйгач, Әмәт җир өстенә менеп теге ике тәгәрмәчле арбага алашаны җигеп алып төште. Җир астына казып төшә башлаганда ук шул ике тәгәрмәчле җигүле арба төшәрлек-менәрлек итеп, юл сала-сала төшәләр икән. Ибраһим абый йорты янында Лотфулла әһәмият бирмәгән икән—ике тәгәрмәчле арбага җигелгән атның дирбиясенең дугасы бөтенләй юк икән. Чокырга төшеп-менеп йөри торган юлның биеклеген ат башы түшәмгә тимәслек итеп чокыйлар икән. Ат та бик акыллы хайван бит—җир астына төшә башлагач, ул башын иеп атларга

өйрәтелгән. Ат тоягы астындагы юлны яктыртып барырга, уң яктан тәртә башына янып торган фонарь элэләр икән.

Ике пычкы белән икешәр булып бүленеп эшләделәр. Туктамыйча 15—20 минут чамасы бер пычкычы кисә дә, ул гыжлап тын ала башлагач, аны икенче пычкычы алмаштыра. Ике сәгать чамасы алмашлап пычкы белән эшләгәч, Лотфулла ни өчен бу таш кискән урынны Әче Мөшкә дип атаганнарын аңлады. Жир астында һава житми, өстәвенә ул бик дымлы. Кисә башлаган унайга ук тын кысыла, барлык тән буйлап тир бәреп чыга һәм арка, күкрәк буйлап култык астыннан, бот буйлап аска тир ага башлый. Бер сәгать, сәгать ярым тирәсе пычкы белән эшләп, ярымташны кискәннән соң, жир өстенә чыгып, яшел үләнгә утырып ял итәләр, «һава алмаштыралар». Эш каты, шунлыктан әллә ни сөйләшү дә юк. Әмәт кенә икенче чыгып утыруда Лотфулладан сорады:

—Сезнең якларда жир астында таш бармы?

—Бар таш бездә дә. Тау ташы. Аны бездә шихан таш диләр. Жир астында калын катлам булып ята. Өчәр-дүртәр метрга житкән урыннары бар. Кәйлә белән суксаң, уч калынлыгы булып яссы ташка әйләнеп ярыла катлауланып. Шул ташны балчык белән бер-берсенә ябыштырып, келәт, сарайлар, хәтта өй дә салалар. Аннан таш коймалар бик күп безнең авылда. Ул таш койманы салганда ташлар арасына туфрак салып өяләр.

—Ә мондый, бездәге кебек жир астыннан кисеп ала торган, таш юкмыни?

—Бар. Бер урында гына. Яшерган исемле авыл янындагы тауда. Тик безнең бабайлар аңардан кабер ташы гына ясарга рөхсәт итәләр. Бик маһир осталар бар, өтерге, пычак белән кисеп шул ташка язалар, бизәкләр төшерәләр. Ерак-ерак жирләрдән килеп, казып алып китәләр ул ташны.

—Алай икән. Бик күп булмаса да, сезнең якларда да бар икән мондый, бездәге кебек таш.

Егерме дүрт данә кисеп куйгач, ташларны теге ике тәгәрмәчле арба белән өскә ташый башладылар. Арбаның кырыйлары ачыла икән. Жигүле арбаны арты белән биреп, яткан ташларга терәтә язып туктаттылар. Арбаның артын ачып төшерделәр дә, аскы очын жиргә сөяп, арба артына өч калын исән такта сөяделәр. Аркан белән ташны уртасыннан уратып ике очын ат койрыгы ягына бирделәр. Арканның бер очына Самат ябышты, икенче очын, авызын ерып, Әмәт Лотфуллага тоттырды:

—Кәжүнни ипи ашап тазаргансың, көчең ташып тора. Әйдә, тарт арканнан, без арттан этәрбез.

Ибраһим абзый белән Әмәт кулларындагы күсәкләрне рычаг итеп ташны арттан эттеләр. Аркан белән тартып, арттан рычаг белән этеп, артык нык көчәнмичә, әзер ташларны арбага төйи башладылар. Арбаны бик оста ясаганнар—арба идәненә түшәлгән такталар ике катлы итеп салынганнар. Һәм өске кат такталар арасына рычаг башы сыярлык ара калдырылган. Бер чыгаруда дүрт ташны төяп кузгалдылар. Атны алдан йөгәненнән тотып житәкләп Әмәт атлый. Ат, бу эштә элек тә булганы күренеп тора, ашыкмый гына жир асты юлы белән тышкы, якты якка атлый. Пошкыргалап куя—аңа да жир астында һава житми, ахрысы...

Сигез ташны арбаларга терәп куйган калын такталардан шудырып, озын арбага төяделәр. Эшләнгән эшкә нәтижә ясагандай, Ибраһим абзый арба тирәли йөреп чыкты да, чирәмгә тезләнде:

—Йәгез, бер тәмәке көйрәтик тә, ике кеше авылга ташый башларбыз ташны. Икебез монда калып кисә торыр.

Башкаларга ияреп Лотфулла да жиргә чүгәләде. Ибраһим ага арбадан кәзәкиен алды да, аның кесәсеннән янчык белән тәмәке, дүрткелләп

бөкләнгән гәжит кисәге һәм чакматаш чыгарды. Өчәүләшеп тәмәке төрә башладылар. Ибраһим ага Лотфуллага дәште:

—Син тәмәке тартмыйсынмы әллә?

—Юк. Тартмыйм.

—Сәбәп нәрсәдә?

—Безнең мәчет муллалары тәмәкене нәмәхарам диләр. Гөнаһ диләр.

—Дөрес түгел. Тәмәке ул Ходай тарафыннан кеше затына, авыр чакта шуны көйрәтеп-тартып, тынычланыр өчен бирелгән. Мөхәммәт Галиәссәлам, безнең бөек пәйгамбәребез, ислам динен Ходайдан алып безгә индергәндә, адәм затлары тәмәкенең ни өчен яратылганын әле белмәгәннәр. Тәмәкене Колумб исемле диңгез гизүче, Әмирикә жирен ачкач, шуннан алып кайткан. Коръән Кәримдә тәмәке хакында бернәрсә дә юк һәм тәмәке тарту гөнаһ саналмый. Төрек солтаны кальян да суыра, тәмәке дә тарта. Төркестан илендә төрекләрнең күпчелеге тәмәке тарталар. Кырым татарлары да күпчелек тарта.

Елмайды:

—Тартып кара син дә. Ошамаса, ташларсың.

Ибраһим ага сөйләгән чакта, Самат тәмәкене Лотфуллага дип урап та куйган. Чакмагыш таш сугып, көлле филтәгә ут кабыздылар да, шуңардан тәмәкеләрен кабызып тарта башладылар.

Лотфулла Самат урап кабызып биргән тәмәкене иплән кенә алып ике бармак арасына кыстырды да, ике ирен арасына утсыз очын кабып, акрын гына суырды. Тәмәке төтене тын алу юлы белән эчкә кереп китте. Азрак башына бәрде дә, аннары эчкә ниндидер тынычлану ләззәте таралды...

Шул көннән башлап Лотфулла тәмәке тарта башлады. Һәм ул авылы Эстәрлегә, Түбән очта яшәүче Заһит таз дигән бәндәдән соң, солдаттан икенче тәмәке тартучы булып кайтты.

Кисеп, төяп ике көн эчендә 42 таш кисәге ташып куйдылар Ибраһим абзыйның йорт эченә...

Лотфулла өчне кунгач, Керчь каласында яшәгән мөселманнар иртән Корбан бәйрәмен уздырдылар. Ибраһим ага, Әмәт белән Самат, өчесе бер булып, Корбанга диеп ике яшьлек симез тана чалды. Ана кадәр—Корбан чалганчы, мәчеткә Корбан намазына киттеләр. Ир-егетләр һәм аталарына тотынган, ияргән төрле зурлыктагы малай-шалай мәчетләргә агылдылар. Керчь каласында 30—40 йорт бер мәхәллә тәшкил итә икән. Шунлыктан Керчь каласында мәчетләр бик күп, татарлар бик тә диниләр икән.

Мәчеттә, Ибраһим абзый эргәсендә оеп утырган Лотфулла жаны-тәне белән бирелеп, мулла укыган намазны тыңлый. Елга якын казармада урыс, хохол арасында яшәп, шунда йоклап, алар белән бергә хәрби хезмәттә булып, Лотфулланың инсафлы, тәртип ярата торган мөселман рухы ярыйсы гына арыган икән. Кырымдагы Керчь каласының мөселман мәчетендә, ислам догасы сүзләре көйләп укыган мулла тавышы аша солдат Лотфулланың жанына, йөрәк турына, баш миенә барып житәләр һәм рухи азык булып аның вөжүденә, табигый яшәвенә көч булып, аңына сеңәләр иде. Эстәрледә, аның мәчете эчендә намазда утырганда, мәчет идәнендә, аның келәмендә утырган авылдашлары, дус-ишләре, танышлары янында Лотфулла намазның асыллыгын, нечкәлеген, кирәклеген аңлап та бетермәгән. Чөнки ул үз авылында, үзләренең авыл мәчетендә, үзенең дус-ишләре арасында булган, утырган. Ә инде менә, жен-пәриләр иле булган Каф тавының да аръягындагы Кырым жирендә, япа-ялгызы казармада урыс арасында яшәгәч, ул үзенең татар теленең дә, татар гореф-гадәтләренең дә, ислам диненең дә матурлыгын, төпле-нигезле икәнен, гасырлар буена жыйналган тәжрибәсен дә, акыллылыгын да һәм ныклы нигезле икәнен

дә аңлады. Һәм үзе өчен нәтиҗә ясады: без—татар телле, татар гореф-гадәтле, ислам динле, белемле татар халкы башка халыклардан аңлы да, пакъ та һәм иң эшчән халык та! Тик ... без урыс астында! Һәм шунлыктан үзебезчә асыл итеп, матур итеп яши алмыйбыз. Урыс ирек бирми! Без эшләп тапканны тартып алып, бетерә тора һәм һаман да безне телебездән, динебездән мәхрүм итәргә омтыла...

Намаздан кайткач, Саматлар ишегалдында корбан чалдылар. Корбан итеннән әзерләгән кичке ашка туган-тумачаны, дус-ишне һәм күрше-күләнне чакырдылар. Корбан бәйрәме булганда мәй турында сүз дә кузгатмадылар. Гөрләшеп, гәп корып, думбрага охшаган музыка коралында уйнап җырладылар, парлашып биеделәр. Парлы биюләр арасында иң матуры сигез яшьлек чем-кара күзле бер малай белән алты яшьләр чамасындагы бик тә чибәр, шушы яшеннән үк зифа буйлы бер кыз баланың биюе булды...

Дүртне кунгач, кояш офыкка авыша башлагач, Лотфулла хуҗага казармага кайтасын белдерде.

—Алай итмә инде син, солдат!—диде хуҗа.—Бик күңелле егетсең. Бар яктан да ачык йөзлесең. Иртәгә китәрсең.

—Кунакның вакыты өч көн. Ә мин сездә дүртне кунып, озакладым. Булды, житте. Кунакта рәхәт ул—күпме сузсаң да туйдырмый да, китәсе дә килми. Рәхмәт сезгә, мине кунак итүегез өчен. Рәхмәт. Китим мин.

—Ярар, алайса, Лотфулла. Гаепләштән булмасын. Хуш иттек. Ярдәмең дә тиде, тимәде түгел. Бик уңган, эшчән егетсең. Тагын кил, чыгарсалар. Туп-туры үземә кил. Йортка. Ошадың син безгә.

Кул кысышып хушлаштылар. Хуҗа хатын да, алъяпкычына сөрткәннән соң, тартынып кына кулларын солдат-кунакка сузды:

—Исән-имин йөр, туганым. Ул солдат хезмәтендә юк-бар җирләргә тыгылма, йә шартлап куярсың бумбылары белән шунда, Ходай сакласын.

Корбан бәйрәменнән кайткач, Лотфулла ике көннән снарядлар саклый торган Цейхгаузны сакларга каравылга китте. Цейхгауз җир астында 6—7 метр тирәнлектә. Җир казып, таш кисеп, алты бүлектән торган аерым, эче таш белән диварлап алынган зур бүлмәләр. Алты ишек, алтысы да—икешәр. Түбәтәй кадәрле зур йозаклар белән бикләнеп, шуның өстенә һәр ишектә балавызга сугылган мөһерле такта кисәге асылынып тора. Һәр ишекне бергәләшеп ике унтер-офицер ача. Болар инде сверхсрочная службага калган, шушы ук крепостьта элегрәк елларда солдатлар булып хезмәт иткән бәндәләр.

Төнге икедә рядовой Зәйнуллин икенче мәртәбә сакка басты. Постны кабул итәр алдыннан ишектә асылынып торган алты мөһернең бозылмаганлыгын карап чыкты. Йозакларны тотып тарткалады. Тимер ишекләр алтысы да бөтен һәм бикле иде. Постны кабул иткәненә доклад ясагач, разводящий солдатлар белән чыгып китте. Лотфулла аларның баскычтан күтәрелгәндәге аяк тавышларын тыңлап озатып калды да, ашыкмый гына атлап, коридорның аргы башына китте. Постта вакыт һәрчак озак үтә. Чөнки беркем дә юк, җай атласаң да, тизрәк атласаң да шул ук пост, шул ук йозак-мөһерләр, шул ук коридор дивары...

Тыныч кына атлап барган уңайга Лотфулла шып туктады. Чөнки... идәндә, аның ике аягы арасында яшь бала үксеп-үксеп елый иде. Иелеп аяк астына карады. Анда цемент таш идән һәм бернинди елаган сабый бала юк иде. Ә елаган тавыш килә. Эченә салкын булып курку йөгерде. Шинеле эчендәге тәненең аркасыннан, күкрәгеннән салкын тир бәреп чыгып аска таба ага башлады. Ә бала елапмы елый һәм аның илереп-илереп үксеп елавы көчәйгәннән-көчәя бара иде. Лотфулла туктаган икән. Сакланып кына аякларын кузгатты—елау көчәйде. Иелебрәк тагын

карады—итекләре арасында бернәрсә дә юк иде. Ә баланың елаган тавышы үзәкләргә үтеп бара. Куркуыннан калтырый ук башлаган аягының сулын кузгатып артка шудырды. Аның артыннан уңын өстерәде. Берничә адым артка биреп шудыргач, баланың елавы өзелә башлады һәм ул сулкылдауга күчте. Тагын ике адым аякларын артка шудыргач, елау туктады, башкача ишетелми башлады. Ике куллап карабинын кысып тоткан хәлдә, бала елаган урыннан курыккан күзләрен алмыйча, часовой солдат артка чигенә-чигенә, коридор очындагы диварга аркасы белән барып төртелде. Бала тавышы башкача ишетелмәде. Бик озак басып торды солдат аркасы белән диварга сөялеп. Шинель җиңе белән битен сөртте, түгәрәк баш киемен салып лычма су булган чәчләрен корытты. Куркуы үтте, азрак тынычланды. Нәрсә булганын аңларга тырышып, ни булса, шул булыр дип, Аллага тапшырды да, «бисмилла»сын укый-укый, аякларын тавыш чыгармаска тырышып шудыра-шудыра, теге бала елаган урынга тагын якынлаша башлады. Колаклар үрә торган, ике куллап артиллерия карабинын кысып тоткан, йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып шашып тибә, ә Лотфулла, туктата алмаслык үҗәтлек белән, әле генә бала елаган урынга аякларын шудыра-шудыра якынлаша башлады... «Үзе курка, үзе йолка!»—дигәнрәк кебек булды. Җен-пәриләр, шүрәлеләр, диюләр барлыгына бала чактан ук ышанып үскән татар баласы, ниндидер борынгы төрек кальгасында, ниндидер сихер бар дөньяга килеп эләкте бит инде..

Бала елаган урынга җитәрәк аз гына ара калгач туктады. Һәм белгән догаларын кычкырып укып (җен-пәриләр ишетсеннәр!) байтак басып торды. Алга атларга теләге дә, мәдәте дә юк иде. Соңгысы итеп өченче мәртәбәгә «Әлхәм» догасын укыды да, аякларын шудырып алга китте. Һәм ике итек арасында... ачыргаланып ять-яшь бала тагын елый башлады. Лотфулла коридор буйлап артка ташланды һәм... алмаш килеп җиткәнче, аркасын диварга терәп коридор очында кузгалмыйча, басып торды...

Баскычтан алмаштырырга төшеп килгәннәрнең аяк тавышлары ишетелгәч, тоныкланган, карлыккан тавыш белән уставча кычкырып дәшергә тырышты:

—Стой! Кто идет?!

—Алмаш белән разводящий.

Разводящий часовойга текәлеп карады да, шомлангандай сорады:

—Нәрсә булды, Зәйнуллин? Йөзеннең нуры юк—ап-ак бит.

Тыныч булырга тырышып җавап бирде:

—Бернәрсә дә булмады. Порядок бар җирдә дә.

«Пермяк соленые уши»ны постка куйдылар да, баскычтан өскә менеп киттеләр... Баскычтан өскә менеп, һавага чыктылар. Шулчак астан, сакчы калган посттан карабин атты. Ике-өч секунд үтүгә, икенче ату ишетелде. Разводящий, өч солдатны ияртеп, кирегә, пост ягына йөгерде. Аска төшә торган баскычның яртысына да җитмәделәр, каршыларына, үзен-үзе белештермичә баскычтан йөгереп менеп килгән «Пермяк соленые уши» очрады. Бачкычка абынып егылды да, торып каршы килгәннәр янында туктамастан акырып баскычтан сикереп-сикереп менеп китте. «Пермяк ...» тан... бер генә аваз чыга иде:

—А-а-а-а-а!!!

—Тотыгыз куып! Егыгыз!

«Пермяк...»ны крепость астыннан чыккач кына җир өстендә тотып ектылар. Ул еккач та, акылын җуйган кеше кебек, күтәрелеп бәрелә һәм акыра иде. Разводящий карабинын Лотфуллага тоттырды да, куллары белән «чалт-чолт» китереп акырган «пермяк...»ның ике яңагын «чәбәкли» башлады. Яңагына сукканнан айныды ахрысы, акыруыннан туктап,

уратып алган иптәшләрен карап чыкты да... елый башлады. Тик башкача акырмады:

—Нәрсә булды, Пермяк? Ә, нәрсә булды?

Куркынган күзләре белән әле генә йөгереп чыккан ягына карады да, калтырап куйды, телгә килергә азаплана башлады:

—Ан... анда... постта...

—Нәрсә постта? Нәрсә?

—Анда... постта... яшь бала елый.

—Яшь бала? Елый?

—Әйе! Елый! Үзе күренми. Аяк астында, җир астында елый.

—Син нәрсә инде, Пермяк?! Нинди бала ди җир астында? Син аны күрдеңме?

—Юк! Юк ул үзе! Күренми. Илләмә елый инде, үксеп-үксеп елый.

—Һм! Бала елый?! Постта бит әле ул. Елый!

Разводящий, бераз уйланып торды да, урыныннан кузгалды:

—Әйдәгез, төшик, карыйк, тынлыйк.

«Пермяк соленые уши» артка чигенде.

—Ю-уук! Мин төшмим анда. Минем башым ике түгел.

Лотфулла разводящийга карап әйтте:

—Ул бала мин постта чакта да елады. Нәкъ коридор уртасына җитсәң елый.

—Ә нигә постны тапшырганда доложить итмәдең?

—Кеше ышанмаслык бит: җир астында снаряд саклаган саклагычта бала елый! Мин әйтсәм, ышанмассыз дип уйладым.

—Ышанмассыз дип уйлаган? Ә постта ЧП—яшь бала елый. Әйдә, син Зәйнуллин алдан атла, ә без синең арттан төшик. Син постта торганда елаган бит инде. Һәм сиңа ул «елак» тимәгән. Атла! Бу—боерык сиңа!

—Тынлыйм, господин унтер-офицер!

Карабинын ике куллап тотты да төшә торган баскыч янына кереп китте. Аңа разводящий белән ике солдат иярделәр. «Пермяк соленые уши» урыныннан кузгалмады да.

—Мин төшмим!—диде ул курыккан тавыш белән.—Атыгыз шушы урында—төшмим мин. Атыгыз!

Разводящийның йөзенә, кыйшаеп, елмаю чыкты.

—Без төшеп киткәч, җеннәр чыгып сине җир астына алып төшеп китсәләр? Әйдә, төшик. Бетсәк, бергә бетәрбез!

—Юк!—диде «Пермяк Соленые Уши».—Юк! Барыбер төшмим. Бер ишеттем, шул җитте миңа. Юк!

Карабинын каешына тыгып аркасына асты да, кырт борылып, каравыл бинасы ягына, бөтен көченә йөгереп, караңгыга кереп югалды.

—Юк! Барыбер төшмим!—дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

—М-да-а! Ни эшлибез инде?!—диде разводящий. Аның да склад коридорына төшәсе килми иде ахрысы.

—Төшик!—диде Зәйнуллин.—Без төшик. Кем генә тикшерергә килсә дә, алдан безне төшерәчәкләр. Мине һәм «Пермяк»ны. Без бит беренче бала елаганны ишеткән солдатлар. Без! Төшик, тикшерик. Без дүртәү бит.

—Әйдә, син алдан алайса. Карабиның корулымы?

—Корулы.

—Ул елаган нәстә җен булса, аңа атуның файдасы тими инде. Шулай да шул якка ат син.

—Ат!? «Пермяк» ике мәртәбә аткан бит инде.

—Син тагын ат! Бу сиңа боерык.

—Есть, атарга!

Диварга ясалган зур тишеккә атлады. Анда керде. Тонык кына янган электр уты яктысында, бормалы баскычтан төшә башлады. Куркуыннан бөрешкән ике солдат белән разводящий Лотфуллага иярде. Төшеп життеләр. Коридорга керер урында туктап тынлый башладылар. «Шылт» иткән тавыш та юк.

—Атла!—диде разводящий Лотфуллага.—Атла коридор буйлап.

Лотфулла карабинын кысып тоткан хәлдә, коридорга керде дә, сулга борылып коридор буйлап атлады. Лотфулланың 2—3 метрга киткәнен разводящий карап торды да, үзе дә коридорга кереп, акрын гына, алдан атлаган солдат артыннан китте. Ике солдат разводящийга иярде. Акрын гына атлаган Лотфулла, коридор уртасына, бала елаган урынга житә башлады. Якынлашкан саен эчендәге курку, шомлану көчәйгәннән-көчәя иде. Атларга күтәргән аягын таш идәнгә куюы булды... аяк астында яшь бала елаган тавыш янгырады:

—Уа-а! Уа-а-а! Уа-а-а!

Лотфулла артында күмәкләшеп йөгергән аяк тавышлары ишетелде. Ул борылып карады: разводящий унтер-офицер белән ике солдат коридор буйлап чыгу ягына йөгерәләр, качалар иде. Куркуыннан Лотфулла коридорда япа-ялгызы басып калды. Ә анын ике аягы арасында, өзелеп-өзелеп сабый бала елый иде... Лотфулла, аякларын шудырып, артка чигенде. Бала елаудан туктады. Борылды да чыга торган баскыч башланган урынга барып басты. Баш киемен салып, тирләгән башын, мангаен, жилкәсен бәреп чыккан тирдән сөртте. Йөзе белән бала елаган якка карап көтә башлдады. Разводящий белән ике солдатнын кире борылып төшкәнен озак көтмәде. Өстән разводящийнын пышылдаган тавышы ишетелде:

—Зәйнулли-ин!

—Мин!

—Син исәнме?

—Әйе! Исән!

—Кычкырыбрак жавап бир. Начар ишетелә. Куркудан колак тонган.

—Мин исән! Төшегез! Туктады елаудан.

Өчесе дә, гаепле кешеләр кебек, тавыш-тынсыз гына төштеләр.

Разводящий, куркуыннан күзләре белән коридор буйлап, бала елаган якка карап алды да, Лотфуллага буйсынган тавыш белән сорады:

—Рядовой Зәйнуллин, нәрсә эшлибез инде хәзер?

Лотфулланың жавабы озын булмады:

—Син разводящий, син начальник! Син уйла нәрсә эшләргә икәнен.

—Һм! Жаваплылыкны минем өскә ташларга чамалыйсың.

—Ташламыйм. Мин постны саклап алмашынган сакчы. Устав буенча мин хәзер ике сәгать ятып йоклап ял итәргә тиешмен. Ә пост белән нәрсә эшләргә дип уйлау синең һәм каравыл башлыгы вазифасы. Уйлагыз.

Разводящий бераз уйлап торды да «юлын» тапты:

—Менә син хәзерге моментта разводящий булсаң нәрсә эшләр идең, ә?

—Минме?

—Син! Син!

—Ике солдатны пост сакларга часовой итеп калдырыр идем, каравыл башлыгына доклад ясар идем. Ул чишсен бу мәсьәләне. Поручик бит.

Баскыч ягыннан:

—Дөрес, Зәйнуллин!—дигән тавыш ишетелде.

Анда «Пермяк соленые уши»ны ияртеп килгән каравыл башлыгы Никонов басып тора иде. Куркуыннан каравыл бинасына хәтле йөгергән «Пермяк соленые уши»дан снарядлар саклау постында булган хәлне ул инде хәбәрдар икән.

Кабаланмый гына аска төште. Тыныч кына сорады:

—Кая елак балагыз? Миңа да тынлатыгыз! Мин аны еламас инде дип уйлыйм.

Разводящий Лотфуллага боерык бирде:

—Рядовой Зәйнуллин! Алга! Күрсәт господин поручикка бала елаган урынны.

Рядовой Зәйнуллин алга атлады. Бала елый торган урынга житте. Атлап ул урынны үтеп китте. Борылып тагын басты... Бала елаган тавыш ишетелмәде.

Коридор эче тып-тын. Бала елаудан туктаган иде. Поручик акрын гына сөйләп китте.

—Төрекләр бу крепостьны салганга ике йөз ел тулып килә. Төркия белән Русиянең 1768—74 елларда барган сугышлар вакытында бу Керчь крепостенда Төрек гарнизоны булган. Рус гаскәрләре дә төрекләрнең шушы крепосте өчен бик күп кан койган. Төрекләр крепостьны бирмичә сугышканнар, ә рус гаскәрләре бик каты штурмга йөргән. Солдатлар уйлап чыгарган легенда буенча менә шул сугышларда коелган рус һәм төрек каны яшь бала тавышы белән елый икән. Сез шул елауны ишеткәнсез инде.

Солдатларны җитди күзләре белән карап чыкты да, карашын «Пермяк соленые уши»да туктатты:

—Ну, господин часовой! Бас постка!

«Пермяк соленые уши» кулындагы карабинны саклап кына идәнгә куйды да, ике аягын да бергә бөгеп, поручик алдына идәнгә тезләнде:

—Господин поручи-ик! Ходай хакы өчен харап итмәгез мине. Сез мине монда калдырып китсәгез, минем йөрәгем шартлап ярылачак. Ходай хакы өчен!

«Пермяк» маңгаен таш идәнгә бәреп үкереп елый иде.

Нәрсәдер әйтергә җыенган офицерга рядовой Зәйнуллин мөрәҗәгать итте:

—Рөхсәт итегез миңа әйтергә, господин поручик.

—Тынлыйм, Зәйнуллин.

—Господин поручик. Мине таң атканчы, яктырганчы постны сакларга куеп калдырыгыз. Миннән башка барысы да куркалар. Ә мин яхшы итеп саклармын.

—Таң атканчы байтак вакыт бар бит әле. Дүрт сәгатьтән артык.

—Мин бит, господин поручик, татар егете. Кирәк чакта икешәр, өчәр тәүлек йокламыйча эшли алабыз—без бит татарлар. Рөхсәт булса, миңа ике чәшке каты чәй китереп эчерсен разводящий. Йокы килмәскә.

Поручик аз гына уйланды:

—Яхшы. Рядовой Зәйнуллинны постка куябыз. Разводящий!

—Йә, господин поручик.

—Караулкада шәп итеп, куе итеп кайнар чәй әзерләт, монда алып килеп Зәйнуллинга эчер. Берүзең йөрмә, бер солдат иярт.

Лотфулланың кулбашына акрын гына зур кулы белән сукты:

—Сине капитан Бульон һәрчак мактый. Дөрес мактый икән, тәккә генә түгел. Син эшләгән бер бөтен подвиг бу. Мин иртән полк командирына бу турыда доклад ясармын. Бас постка!

Елмайды:

—Без киткәч, син теге баланы тагын елата башлый күрмә...

«Пермяк соленые уши»га тиз генә карап алды.

—Син татариннан башка, үзләрен бөек урыс милләтеннән дип санаганнар да, бу постка басачаклар бит әле.

Берничә ай узгач, Кырым татары Ибраһим ага Лотфуллага Керчь

кальгасыннан бер тарих сөйләде:

—Төркия белән Русия арасында 1768—74 елларда бик каты сугышлар барган. Урыслар басып алган Харьков, Хотмыжск, алар Белгород, Воронеж дип йөрткән калаларга кадәр барысы да мөселман жирләре булган. Менә шул алты-жиде ел барган сугыш вакытында, безнең Кырым ханы урыслар түләгән алтынга алданып, урыс гаскәрен үзе теләп, урыслар белән солых төзеп Кырымга керткән. Ә Кырымда берничә кальга булган: Керчь, Феодосия, Яңа Кала һәм Севастополь урынында. Исемен онытканмын анысының. Ак Кала бугай. Һәм шул кальгаларда төрек гаскәрләре торган. Дингезгә каратып ата торган пушкалары бик күп булган. Азык-төлек берничә елга житәрлек итеп әзерләнеп, жир астында салкын урында сакланган. Һәр кальга эчендә жир астыннан агып чыккан, суы эчәргә яраклы берничә чишмә булган. Күп итеп ризык-фураж әзерләп, кальга эчендә, кирәк чакта суеп ашый торган сыер-сарык тотканнар.

Урыслар Кырымга гаскәр белән кергәннәр. Ә кальгаларда—төрек гаскәре. Кораллары житәрлек, сан ягыннан да байтак. Дингез кораблары да төрекләрдә күбрәк. Диңгездән килеп кальгаларга ярдәм итеп торалар.

Керчь кальгасы белән Салман Паша дигән солтаннның, бүгенгечә әйткәндә, бер генералы житәкчелек иткән. Төрекләрдә, урыслардагы кебек генерал димиләр, паша диләр. Керчь кальгасы өчен сугышлар елдан артык барган—уныш юк. Шуннан бер көнне Пашаның евнухы урыс лагерена чыккан. Һәм урыс генералының колагына гына пышылдаган:

—Менә Паша сиңа балчык чүлмәк жибәрде. Шуңа эретеп алтын белән тутырсаң, кальга капкаларын ача сиңа...

Һәм бер чиләк су сыешлы түгәрәк корсаклы чүлмәк күрсәткән. Урыс генералы чүлмәкне алып калган. Ә ул бик тә акыллы кеше булган. Яхшы итеп уйлаган һәм шундый нәтижәгә килгән: «Әгәр дә падиша Екатерина IIдән шул чүлмәкне тутырырга алтын сорасаң, ул бирер бирүен. Тик крепостьны сатып алдык дип мина дәрәжә дә, алтын-көмеш тә, орден да эләкмәячәк бит инде. Нәрсә эшләргә?»

Генерал акыллы булган, уйлап тапкан. Сугышлар барган чакта ул һәрбер солдатта, офицерда сугышып йөргән урыннарда талап алынган алтын барлыгын яхшы белгән. Һәм үз гаскәрендә игълан итеп, бирмәгәннәргә тентү ясап байтак алтын жыйган. Тик чүлмәкне яртылаш та тутырырлык юк икән. Монда да хәйлә юлын тапканнар. Чүлмәккә, яртысыннан күп итеп юеш кызыл балчык тутырганнар. Авырлыгы алтынга туры килсен дип тутырганнар ул юеш балчыкны. Чүлмәкнең яртысыннан күбесен юеш балчык белән тутыргач, шуның өстенә эретеп сыек алтын салганнар. Ул суынып каткан һәм чүлмәк Паша Салман теләгәнчә... алтын белән тул-тулы булган да куйган... «Алтын белән тулы чүлмәкне» евнухка биреп, Паша тарафына жибәргәннәр. Икенче көнне Паша боерыгы белән Керчь кальгасының дүрт капкасын да ачканнар. Һәм кальгага урыс гаскәре кергән.

Сөйләшенгән буенча, төрек гаскәре карабларга төялеп, Төркиягә кайтып киткән.

Тик Салман Паша үзенең комсызлыгы аркасында һәлак булган.

Евнухын урыс генералына жибәргәндә, әгәр дә аның белән сөйләшү уңай нәтижә биреп, чүлмәк алтын белән тулып кире кайтса, ул евнухка күп итеп алтынлата түләргә сүз биргән. Чүлмәк алтын белән тулып Паша кулына килеп кергән. Тик Паша евнухына сөйләшкән, килешкән алтынның яртысын гына түләгән. Евнух ризасызлыгын белдергәч, Паша алтын турында түгел, башыңны сакла дип, аны бик тиз туктаткан. Паша үзенең гаремы, евнухлары, тән сакчылары белән Төркиягә кайтып, тагын кәеф-сафа корып

яши башлаган. Кальганы урыслар алуны Солтанга көч көчне сындыра дип аңлаткан. Тик евнух, үзенә сөйләшкәнне түләмәгән Паша Салманнан үч алу нияте белән Керчь кальгасын, Паша Салман бер чүлмәк алтын бәрабәренә урысларга сатканны Төрек солтанына җентекләп сөйләп биргән. Солтан боерыгын үтәп, Салман Пашада теге алтын тулы чүлмәкне тентеп тапканнар. Салманны Солтан алдына тезләндереп куеп, сугып чүлмәкне ватканнар: «Ах!» иткәннәр. Чүлмәкнең өсте генә, өчтән бер өлеше генә алтын белән тутырылган булган. Солтанның боерыгы кыска булган: «Салман Пашаны Керчь кальгасын урысларга алтынга саткан өчен, канын агызмыйча, җанын алырга!» Солтан боерыгы төгәл үтәлгән—Салман Пашаның тамчы да каны чыгарылмаган. Чүлмәкне ваткач чыккан алтынны эретеп Салман Пашаның авызына коеп, эченә тутырганнар, канын коймыйча үлемгә дучар иткәннәр. Алтын тутырылган Салман Паша гәүдәсен, Керчь крепосте янына диңгезгә ташларга боерган һәм Солтан боерыгы төгәл үтәлгән. Салман Паша гәүдәсе бүген дә, алтын тутырылган хәлдә Керчь кальгасына каршы диңгез төбендә черегән хәлдә ята икән...

Төркия белән Русия арасында 1768—74 елларда барган сугышлар тәмамлангач, Төркия җинелә. Рус гаскәрләре Суворов җитәкчелегендә Кара диңгезнең көнбатыш ярларындагы Измаил, Очаков крепостьларын штурм белән ала.

Берничә гасыр буена хан биләмәләрендә яшәп, Кырым ханына буйсынып, аңа налог түләп яшәгән әрмәннәрне, грекларны—сез мөселман түгел, ә христиан динендәсез, дип татар-мөселманнарына каршы котырту башлана. Русия хакимияте экономик яктан Кырым ханын йомшарту өчен әрмән, грекларны Кырым ярымутравыннан төньякта урнашкан Таврия далаларына мәҗбүри рәвештә Кырымнан күчереп утыртырга тотына. Казан ханлыгының башкаласы булган Бакчасарайдан 7—8 чакрым көнчыгышка таба Мелитополь исемле, күпчелеге греклар һәм әрмәннәр яшәгән, христианнар каласы булган. Мөселман ханнары бервакытта да башка диннәрне кысрыклап, аларга басым ясау һәм тыю сәясәтен үткәрмәгәннәр, бер халыкны да көчләп мөселман итмәгәннәр. Башка дингә хөрмәт белән карау бөек Чыңгыз ханнан калган һәм киләчәк буын ханнарга мирас булып килгән. Кырым ханына ясак түләүче, Европа һәм Азия белән сәүдә итүче грек һәм әрмәннәрне Әби патша әмере белән көчләп Таврияга күчерәләр. Аларга яңа кала салырга шунда урын күрсәтәләр. Һәм тарихта исеме югалмасын дип Тавриядагы шул яңа калага... Тагын Мелитополь дип исем кушалар. Кырымдагы Мелитополь утырган җирдә әле дә аның бик зур кала булганы сизелә, күренә. Күченеп киткән әрмәннәр, греклар арасында бала-чагасын төяп күченгән бик күп татарлар да була...

Хезмәт итүенә ел ярым тулып үтүгә, рядовой Лотфулла Зәйнуллин, капитан Ростунов оештырган курсларны үтте дә, сынау бирде.

Сынау бирү гади ату итеп оештырылган иде. Тәүге биш снарядны Кавказ ярында кырын яткан иске бер корабка аттылар. Ераклыкны, уң яктан искән җилнең тизлеген төзәүчегә хәбәр иттеләр. Ә Зәйнуллин кирәк цифрларны җентекләп прицельның тиешле урыннарын борып кертте дә, пушка шнурында торган «фейерверкерга» боерык бирде:

—Пли!

Керчь бугазы аша дүрт потлы снаряд очып барып теге як ярда шартлады. Азрак «недолет» булып, снаряд ярда яткан иске карабтан унгарак төшкән иде. Калган дүрт снарядны Лотфулла «карабка салды».

—Ну, Зәйнуллин, молодец! Син бит «вилка» да алып тормадың.

—«Вилка»ның кирәге юк! Тәүге снаряд күрсәтте бит инде нинди

«төзәтмә» кертергә кирәкне.

«Вилка»ны бит махсус кулланалар. Тәүгесе «перелет булса», ераклыкны үзгәртәләр. Икенче снаряд барып житмәсә, «недолет» була бит инде. «Перелет»тан «недолет»ны алып ташлап, калдыкны урталай бүлеп, өченчесен аталар.

—«Недолет»тан йәисә «перелет»тан мин прицельны күпмегә төзәтергә кирәк икәнлеген исәпли беләм.

—Ничек итеп исәплисең, сөйлә!

—Атулар беткәч сөйләргә рөхсәт итегез, господин капитан. Бүген кич яисә иртәгә.

—Ну, ярар! Кичен тек кичен, иртәгә тек, иртәгә. Тик сереңне ачасың барыбер.

—Сер түгел инде ул. Уйлап чыгарган ысул гына.

—Яхшы! Килештек, Зәйнуллин!

Ике айдан Керчь каласы кальгасында Русиянең алты крепостеннан жыелган «яшь төзүчеләр» ярышы үткәрелде. Ул ярышта бер елдан кимрәк вакыт төзәүче булган солдатларны катнаштырдылар. Һәр крепостьтан икешәр төзәүче иде.

Керчь крепостеннан ярышта наводчик рядовой Зәйнуллин да катнашты. Атарга ике көн кала, яшь төзәүчеләр полк командиры кабинетында, аның өстәле каршында «Во фронт» булып, үрә катып басып торалар иде. Командирның сүзе кыска булды:

—Әгәр атып беренче, яисә икенче, өченче урыннарны алсагыз, сезгә унбишәр сум акчалата бүләк бирәчәкмен. Һәм...

Икесенә дә сынап карады.

—... һәм, барырга урыныгыз булса, Керчь каласына ун көнлек ялга жибәрәм. Анладыгызмы?

—Так точно! Тырышачакбыз, господин полковник!

Ярышлар үтеп, бар да гарнизоннарына кайтып киткәч, кичкә таба гарнизон плацында полкны тезделәр. Штаб начальнигы командасын бирде:

—По-оо-олк, смирно-о! Равнени-ие-е на середину-у!

Аннары ул уртага таба атлап килгән полк командирына каршы атлады. Барып житте, доклад ясады:

—Ваше Высокоблагородие! Полк сезнең боерык буенча тезелде. Штаб начальнигы полковник Акимов.

—Вольно!

—Волно-о-о!

Тигез итеп, батальон-батальон булып, сафта басып торган полкка карап борылды:

—Господа солдаты, унтер-офицеры һәм господа офицеры! Балаларым минем: мин командалык иткән полкта шатлыклы вакыйга булды. Алты яр крепостеннан килгән яшь төзәүчеләр ярышында безнең крепостьның яшь төзәүчесе рядовой Лотфулла Зәйнуллин беренче урынны алды. Биш снарядның дүртесен тигезде ул...

Бульон батареясы ягына карады:

—Рядовой Зәйнуллин, сафтан чыгыгыз һәм минем янга килегез!

Лотфулла, солдатлар сафыннан чыкты да, саф адымы белән каты-каты басып, полк командиры янына килеп, үкчәләрен бер-берсенә каты бәреп туктады. Сафка йөзе белән карап борылды.

—Кем белми рядовой Зәйнуллинны, менә карагыз инде. Бу солдат рядовой Зәйнуллин була.

Түш кесәсенә тыгылып, берничә кәгазь акча чыгарды.

—Яхшы атып беренче урынны алган өчен мин аңа акчалата унбиш сум бүләк бирәм.

Акчаларны Лотфуллага бирде.

—Шушы акчалар өстенә рядовой Зәйнуллинга Керчь каласына барып ял итәргә ун көнгә увольнение бирелә.

Рядовой Зәйнуллинга борылды:

—Бүген кереп канцеляриядан увольнительный ал. Ун көнгә ял сиңа.

—Слушаюсь!

—Бир кулыңны, кысыйм, Зәйнуллин. Рәхмәт сиңа. Беренче урынны сез икәү алдыгыз. Икенчегез Красная Горка крепостеннан. Тик синең бишенче «недолет» снарядың аныкыннан кыскарак. Синеке 23 метр, ә Красная Горканыкы—31 метр. Син—беренче. Рәхмәт сиңа, Зәйнуллин.

—Рад стараться, Ваше Высокородие!

—Бар, сафка бас!

Лотфулла, саф таралгач, канцеляриягә кереп «увольнительная записка» алып түш кесәсенә салып куйды...

Икенче көнне ул Керчь каласына, яхшы танышы Ибраһим абыйсына кунакка китте...

Ибраһим яңа-пешә сарай салып йөри иде. Лотфулла да чишенеп, Ибраһим ага биргән иске күлмәк, чалбар киде дә, аңа кушылып эшли башлады.

Пычкы белән таш кисеп, аны агач улакта әзерләнгән балчык измәгә утыртып, алты көн эчендә сарай диварларын күтәреп куйдылар. Соңгы көнне, кичке аш вакытында, Ибраһим үзалдына гына зарлангандай сөйләнеп куйды:

—Кыекка бәпкәләр утыртырга күрше урамдагы балта остасы урыс Никодим белән килешкән идек. Хакын да сөйләшеп, кул сугышкан идек. Бүген өйләдән соң өенә барып килдем. Лаякыл исерек. Хатынын да танымый ята йоклап. Ишегалдына керерлек түгел—хырылдый. Өй эче сасы, түзәрлек түгел. Коскан, ахрысы. Эшнең кызу чагы, каян табасың инде хәзер останы?

—Әйдә, икәү тотыныйк. Мин яхшы беләм бәпкә утыртуны. Әллә нәрсәсе юк инде. Минем бабай Әбү Нәгыйм әйтмешли: «Аңа кирәк кешесе, ышкыйсы да ышкыйсы!» Утыртабыз ул бәпкәләрне—ике көнлек эш инде ул. Бәпкәлек агачларың бармы?

—Бар, бар! Абзар артында, такта койма буенда ята. Шуңа дип кисеп алып кайткан кипарис агачлар бар.

—Кипарислар?

—Әйе. Нәрсәсенә гаҗәпләнәсең—кипарислар.

—Бик затлы агачтыр бит ул кипарислар?

—Затлы, әлбәттә. Урманнан кисеп алган агачлар бит алар. Елга ярыннан. Зур арбага, пар үгез җигеп, шул арбаны тутырып төяп, монда китереп саталар ул кипарисларны.

—Татарлармы?

—Әлбәттә. Урыс шулкадәр араны үгез җае белән уза аламы? Һич юк. Үлә бит ул шундый араны узганчы. Инде килеп җитеп сатып кулына акча керсә—бетте урыс. Керчь каласы читендә тугарылмаган үгезләре янында исереп йоклаган була. Әле өстәвенә, озак ятса, үгезләре аны калдырып кайтып та китә әле аның... Ала-ай! Син бәпкә утырта беләсең инде алайса?

—Беләм. Әйдә әзерләгән агачларыңны карыйк.

—Әйдә.

Ибраһим абзар артына китте. Лотфулла аңа иярде. Анда байтак озын, төз кипарислар һәм тагын берничә, Лотфулла белмәгән карама агачына

тартымрак, кара кайрылы юан гына агач ята иде. Шуларга күзе төште.

—Менә болар өрлеккә бара инде. Башын нәрсә белән ябарга уйлыйсың?

—Безнең елга буйларында чакан дигән үлән үсә. Шуның белән ябарбыз дип уйлаган идем. Тимер белән, такта белән япсаң да була. Акча бар. Тик мин ул сарайда сарык тотарга уйлыйм. Сарык абзары итеп. Башы тимер, йәисә такта булса, суык була бит.

Лотфулла салынган сарайга карады:

—Дивары сарык сарае өчен биегрәк түгелме?

—Түгел. Түшәмгә такта, һич югы киртә тезәм дә, печән тутырам кыек астына.

Ике көндә кыек бәпкәләрен юнып, урыннарына күтәрделәр, нығытып куйдылар. Ибраһим телен шартлатып сокланды:

—Илләмә кулларың оста икән синең, Лотфулла. Кайда өйрәндең болай оста итеп балта белән, өтерге белән эшләргә?

—Әтидән. Сезнеңчә бабамнан. Бик шәп, матур итеп өйләр, абзар-сарайлар, мунчалар сала белә ул. Ат арбалары да ясый. Кыш көне анын белән балта эшендә йөрим мин. Күрше авылларга да чыгабыз. Малайлары алтау минем бабамның. Өй салырга сөйләшеп ала. Дүртәүләшеп, бишәүләшеп барабыз—10—12 көндә бураны эшләп куябыз. Шәп утыра—көзен күтәреп куябыз. Кышын идән-түшәмнәрен хужа йә бездән, йә башка осталардан эшләтә.

Увольнениедәге ун көнен Лотфулла Ибраһимга сарай салып үткәрде. Ике көндә дүрт пар бәпкәне күтәреп куеп нығыттылар. Абзар артында өелеп яткан беләктән азрак нечкәрәк, яшь тупыл агачыннан киселгән киртәләр ята иде. Ибраһим шуларны бәпкәләр өстенә нығытып куярга кушты Лотфуллага.

—Кулың оста, кадак житәрлек. Мин чакан урырга китәм хатын-кыз белән.

—Ярар. Бәлки мин дә барыйм синең белән?

—Юк. Без—өч урак. Иртән тотынсак, кичкә кадәр кирәк кадәрлене урып алырбыз дип уйлыйм. Кече кыз Әминәт сине ашатыр, эшлә дә эшлә!

—Кече кыз дисең, Ибраһим абзый. Нишләп күренмиләр, кызларың бармыни синең?

Ибраһим да елмайды:

—Бар, икәү. Сине, егет кешене ярык-йорыклардан гына күренмичә күзлиләр булыр. Мин шулайрак дип сизенәм. Кызлар бит—алар да тере җан ияләре. Кечесе бәләкәй әле—Әминәте. Ә зуррагы— Фатыймасы буй житеп килә. Әнкәләренә ошап чибәрләр икесе дә. Чапан үрергә алып китәм зурысын...

Өч урак тотып келәттән чыгып килгән чибәр, яшь кызны күргәч, сарай башында соңгы пар бәпкәне утыртып бетереп маташкан оста Лотфулла өнсез калды. Башын каплап, ап-ак юка гына ефәк шәлне муенына ураган, зур төстәге төрле матур чәчкәләр төшкән киң күлмәге аяк йөзенә кадәр төшереп тегелгән. Киң күлмәк тә, үзенең эчендәге зифа кыз гәүдәсен тоташ яшереп тота алмый. Алда, түгәрәкләнеп өскә таба күтәрелеп торган матур түшләре, дулкынланып тын алганга, күлмәк эчендә хәрәкәт итәләр, кузгалалар. Озын керфекле, шомырт кебек чем-кара күзләр, келәт болдырыннан төшкәч, тиз генә, кыек башында чүкеч, өтерге тотып катып калган солдат абыйга, сирпеп кенә күз карашын ташлап алдылар да, аска төшерелгән куе кара керфекләр артына кереп яшеренделәр...

Өйдән хужабикә чыкты. Өчәүләшеп чакан урырга, кечкенә елга ягына, җәяүләп китеп югалдылар. Керчь каласы читендә, урам-урам булып оешып

татарлар авылча, мал асрап, туган-тумача булып, ярәшеп кыз биреп, кыз алып, үзләренең гореф-гадәтләренчә тормыш итү өчен татар кануннарын үтәп яшиләр иде. Урыс ничек кенә басып алса да, татар өстеннән үзен «господин» дип санап яшәргә тырышса да, татарлар тик татарча гына яшиләр иде.

Ике көн чакан урды Ибраһим абзый хатыны һәм зур кызы Фатыйма белән. Буй җитеп килгән Фатыйманың гәүдә торышы хатын-кызга хас, бар нәрсәсе дә урынында, кирәгенчә булып җитешеп килә иде. Кергәндә, чыкканда егет күзләре Фатыйманы сагаладылар, күрергә тырыштылар, сокландылар. Берничә мәртәбә күргәч, тал чыбыктай нечкә, чибәр гәүдәне, киң күлмәк эчендә булса да чамалагач, чама белән уйлады: «Унөч, ундүрт яшьләр тирәседер бу кызга». Азрак уфтанып та куйгандай булды:

—Мин аның өчен карт егеттер инде?!

Бер көн урылган чаканны ташып үтте. Аннан ике көн, Ибраһим абзыйның дусты Насретдин җитәкчелегендә чакан белән абзар башын яптылар. Дусты бик оста итеп чаканны, сузган киртәгә өске очыннан бәйләп нygытып, яба белә икән. Ул нygытып узган чаканны бәйләгән бау тышкы яктан күренми дә, ә чакан бәйләнгән, нygытылган, искән җилгә кубып бирешерлек түгел.

Ун көн буена бик тырышып эшләп, Ибраһим һәм Насретдин салынып беткән сарай башын чакан белән ябып куйдылар. Соңгы көн сарайга яхшы такталардан калын, киң ишек ясап үтте.

Унынчы көн бетеп барганда солдат Лотфулла Керчь крепостена кайтты. Капитан Бульон кабинетына кереп доклад ясады:

—Господин капитан. Рядовой Зәйнуллин увольнениедан кайтты. Бар да тәртиптә.

Бульон торып «честь» бирде. Өстәле артыннан чыкмады, кәефе юк иде ахрысы. Сорады:

—Сине, Зәйнуллин, увольнениега ничә тәүлеккә җибәрделәр?

—Ун тәүлеккә.

—Бир әле увольнительныеңны, карыйм.

Алды, карады. Кире суздьы.

—Дөрес, полк командиры сине ун тәүлеккә җибәрергә кушкан. Сине мөселман бәйрәмнәренә биш тәүлеккә җибәреп өйрәнгән писарьлар, сиңа биш кенә тәүлек язганнар. Синең уңышларга, яхшы хезмәт иткәнеңә алар бик тә көнләшәләр. Писарьлар—солдат аристократлары бит алар. Син өч көн кайтмагач, дезертир саналасың. Ә син биш көн юк. Штаб начальнигына рядовой Зәйнуллин увольнительныен тапшырмаган дип старший писарь доложить иткән. Начальник полк командирына. Язма рәвештә синең өстән рапорт: дезертир!

Полк командиры, исән-имин кайтсаң, сине дезертир дип түгел, аңламыйча увольнениедан соңга калган дип санарга карар кылды.

—Минем гаебем бар, господин капитан. Полковник ун тәүлеккә увольнение дип, полк алдында игълан иткәч, мин увольнительныйга язганны карап та тормадым. Ун тәүлек дип уйлап, алдым да кесәгә салдым. Минем гаеп, язганны карамауда гына...

—Ярар, Зәйнуллин. Озын сүзнең кыскасы: полк командиры, үз имзасы белән сине биш тәүлеккә гауптвахтага утыртырга дип «Записка об аресте»га кул куеп, сине утыртырга боерык бирде. Мә, тот «записка» сиңа...

Кулына язулы кәгазь бирде дә, өстәде:

—Батальон фейерверкерына бар, күрсәт бу «записка»ны, сине гауптвахтага, начальнигына алып барып тапшырсын. Утыр, биш суткага. Өч суткадан артык бит юк булуыңа. Сине дезертир дип трибуналга бирергә

дә була иде. Командир анлый синең ничек увольнениедан сонга калганны. Бар, кайгырма, утыр! Күнеленне юат: «Только тот настоящий солдат, кто прошел через солдатскую губу». Бар, чын солдат. Утыр гауптвахтага!

Күнелсез генә көлде.

Гауптвахта крепостьның төньяк почмагында, яртылаш жиргә кертеп салынган таш капчык иде. Ул дүрт аерым бүлмәдән тора. Һәр бүлмәнең дингез ягында ишегалдына карап торган тимер рәшәткәле тишек бар. Өч бүлмә одиночкалар, дүртенчесе сигез сәкеле гомум бүлмә. Гомум бүлмәдә утырган солдатларны көндез эшкә алып чыгалар. Ә аерым утырганнарга эш юк—күпмегә утырган, шул вакытны арест ясалган солдат шул үзен бикләгән бүлмәдә япа-ялгызы үткәрә инде. Утырганның икенче кичендә урамдагы бәдрәфкә алып чыктылар. Сакка күрше батарея солдатлары куелган. Лотфулла «эшен» бетереп бәдрәфтән чыккач, карабин тотып аны бәдрәфкә алып килгән, устав буенча «выводной» дип аталган солдат тирә-ягына, артына карап алды да, пышылдап сорады:

—Син, Зәйнуллин, тәмәке тартасың икән.

—Тартам.

—Камераңа кергәч, тәрәзә форточкасын ач та, кулыңны аска төшер. Астарак, рәшәткәгә бәйләгән каеш бау булыр. Шуның очына күн янчык бәйләнгән. Эчендә тәмәке, кәгазь һәм шырпы. Бер урарлык кына тәмәке чеметеп ал, кәгазь бер урарга. Шырпы кабының кырыеннан, шырпы сыза торган урының бәләкәй генә итеп сындырып ал. Бер шырпы. Тәмәке урап кабызгач шырпыны, теге кап кисәген урамга ыргыт. Синең тартканны разводящий йәисә каравыл начальнигы күреп калса, тентергә керерләр. Шул чакта син форточкага якынрак бас.

—Кем китергән ул янчыкны.

—Крепость бар булганнан бирле килә инде ул күн янчык белән эчендәге тәмәке, шырпылар. Йөз елдан артык инде аны крепостьта хезмәт иткән урыс солдатлары уйлап чыгарганнар. «Пермяк соленые уши» кичә кич килеп тутырып китте. Синең дус»,—ди.

Лотфулла калган дүрт көнне гауптвахтада тәмәке тарткалап уздырды. Тәмәке исе ишек ярыкларыннан гауптвахта коридорына чыга икән. Рядовой Зәйнуллин гауптвахтада утырган берләнбер солдат булганлыктан, тәмәке исе чыгу белән каравыл начальнигы үзе камерага кереп тентү ясады. Берничә мәртәбә. Соңгысында «килешү» тәкъдим итеп карады:

—Тәмәке, шырпы каян аласың син?

—Яшергән жирдән.

—Әйт ул жирне. Бүген үк чыгасың моннан.

—Монда начар түгел. Минем чыгасым килми.

—Әйтмәсәң, мин тагын биш көн өстим сиңа арестны.

—Өстәгез. Бер чыкмасам, бер чыгармын әле.

Каравыл башлыгы кызып китте:

—Тфу, ты, е... татарин! Тагын бер тартканыңны күрсәм, ун тәүлекне өстим мин сиңа...

«Выводной» Лотфулланы бәдрәфкә алып барганда акрын гына артыннан пышылдады:

—Кич алмашына бу башлык! Түз син ул киткәнче.

Өстәде:

—«Пермяк соленые уши» сиңа бер «Мерзавчик» аракы куям кисет эченә, ди. Куйсынмы?

—Юк. Кирәкми. Эчмим бит мин.

—Шулаймыни?

—Шулай.

Гауптвахтадан чыгып, ай чамасы вакыт узгач, крепостьта суд булды.

Россия социал-демократлары 1905 елның җәендә Кара дингезнен хәрби флотында һәм яр артиллериясе гарнизоннарында патша самодержавиесенә каршы гомум хәрби фетнә оештырганнар. Шул план буенча 1905 елның август аеның тәүге көннәрендә барлык Кара дингездә бер көнне фетнә башланырга тиеш булган. Тик броненосец «Потемкин» көтмәгәндә июнь аенда, күтәрелгән. Эченнән кортлар чыккан ашны ашаудан броненосецның эчендә билгеләнгән хәрби каравыл ашаудан баш тарткан. Броненосец командиры каравылны атарга боерык биргән. Матрослар каравылны атудан баш тартып, коралга тотынганнар...

1911 елның җәендә яр артиллериясенең бөтен Рәсәй күләмендә маневрлары үткәрелде. Керчь крепостеннан торып, аның каршыннан дүрт чакрым ераклыкта зур тизлек белән барган баржага тидерергә кирәк иде. Бу вазифаны, Кара дингез яр крепостьлары төзәүчеләре арасында иң тиз атучы булып даны чыккан, погонына инде аркылыга ике ак лычка таккан унтер-офицер Лотфулла Зәйнуллинга тапшырдылар...

Буксир өстерәгән, якынлашып килгән баржага өченче снарядны чәпәде Лотфулла. Тидерүе дә гадәти түгел иде. Баржаның алдына—буксирга таккан трос ныгытылган өлешенә—барып тиеп шартлады снаряд. Пушка, Керчь крепостеның 12 дюймлы иң зур калибрлы пушкасы иде. Бүгенге исәпкә шул 12 дюймны исәпләп чыгарсаң, пушка торбасенең снаряд чыга торган түгәрәк тишегенең диаметры 30,48 см. Снарядның авырлыгы 331,3 килограмм. Шул снаряд китереп бәреп шартлап, баржаның алгы өлешен һавага алып очырды. Тарта торган тросттан котылган баржа барышы акрынаеп, инерция белән генә алга йөзә иде. Икенче снарядны, ашыкмый гына, Лотфулла баржаның уртасына—ватерлиния сызыгы янына утыртты. Уртасында шартлаган зур снарядтан баржа азрак өскә күтәрелгәндәй итте дә бата башлады. Артта дулкынланып басып торган капитан Бульон түзмәде, кычкырып җибәрде:

—Ну и Зәйнуллин! Джигит—шайтан татарский. Болай беркем дә атканы юк иде әле моңарчы. Ну и молодец же!

Төз һәм шәп аткан өчен акчалата бүләк илле тәңкә иде.

Казармага кайткач дус солдатлары Лотфулланы кочаклап алдылар. «Пермяк соленые уши» сорамыйча түзмәде:

—Баедың инде син, Зәйнуллин. Синнән мәгәрич дусларыңа!

—Ярар, куярмын. Кайтып киткәндә.

Бер атна узгач, Керчь крепостеның иң шәп төзәүчесен полк командиры чакырды. Кул биреп күреште дә, Лотфулла һич көтмәгән сүзне башлады:

—Син инде, Зәйнуллин, ике ай элек үк срогыңны тутырып, солдат хезмәтеннән китәргә тиеш идең. Мин сине шушы соңгы маневрлар үтмичә җибәрмәскә булдым. Син дә бүләк алдың, мин дә алдым. Сиңа караганда биш мәртәбә артык—250 тәңкә. Капитан Бульон һәм капитан Ростунов 150 шәр тәңкә алды. Синең төз атуың аркасында. Сиңа сәләтне мөселман Аллаң бик күпләп биргән... Инде бер сорау сиңа.

—Тыңлыйм, господин полковник.

—Солдат хезмәтең синең дүрт ел иде. Шул срок тулганга өченче ай китте, ә син мине нигә кайтарып җибәрмисең дип тавыш күтәрмәдең. Шауласаң, җибәрә идем мин сине.

—Маневрлар ноябрь башында буласын без барыбыз да белә идек. Һәм мин, сез мине җибәрергә бик теләмәгәнегезне, минем маневрларда атуымны теләгәнегезне аңладым. Шунлыктан дәшмәдем. Нәрсә ул миңа ике-өч ай! Дүрт ел иптәшләр-дуслар арасында үткән казармада яшәве күнелле бит.

Полковник дәшмичә байтак уйланып утырды. Ул бик тә житди сүзне

ничек башларга дип уйлый иде.

—Менә нәрсә, Лотфулла Зәйнетдинович!

Исеме, әтисенең исеме белән дәште.

—Син демобилизация документларын ал иртәгә. Һәм мин сиңа тәкъдим итәм: бездә сверхсрочник булып кал. Оклад яхшы, фатир бирәбез Керчь каласыннан. Ай ярым ял бирәбез, ай ярымга шул сверхсрочник акчасын бирәбез, юлына түлибез. Кайтып кил. Бер ел хезмәт иткәч, Тулага ун айлык курсларга җибәреп, сине артиллерия офицеры итәбез.

Мыек астыннан елмаеп, әйтте:

—Синнән, Зәйнуллин, бик шәп ата торган урыс офицеры ясыйбыз киләчәктә.

Лотфулланың татар табигатен аңлап бетермичә, уйламыйчарак әйтеп куйды бу җөмләне полковник.

—Ну, нәрсә әйтәсен, господин унтер-офицер.

—Рәхмәт Сезгә барысы өчен дә. Дүрт ел буена миңа тик яхшылык кына эшләдегез. Минем, господин полковник, урыс офицеры буласым килми. Сезнең крепостьта хәрби хезмәтне үттем мин. Миннән бик яхшы төзәүче ясадыгыз. Белем ягы бик артмаса да, мин замананың иң алдынгы техникасы—яр артиллериясе пушкаларын—күрдем, өйрәндем, аттым. Офицер булсам минем тормышым яхшылана, ач-ялангач булмыйм. Тик минем урыс кешеләре кебек буласым килми...

Полковникнын йөзе каралып чыкты:

—Ә кайсы яклары белән ошамыйлар сиңа урыслар, Зәйнуллин?

—Господин полковник! Сез урыс кешесе, урыс полковнигы. Мин сезнең бу сорауга җавап бирмәс идем.

Полковник күзен Лотфуллага текәде:

—Син, Зәйнуллин, миңа курыкмыйча урыслар турында уйлаганыңны әйт. Мин бит уйлый белеп яши торган кеше. Башка милләтнең—өстәвенә татарның—без, урыс турында, нәрсә уйлаганын беләсем килә.

—Курыкмыйм мин сездән. Мин һич тә курка белмим. Курыксам, аяк астында бала елаган постта үзем теләп калыр идемме мин?! Үземнең смена беткәннән соң да.

—Дөрес. Курка белмисең син. Шунлыктан ни өчен урыс офицеры буласың килми, әйт миңа. Димәк, син үзеңне урыслардан югары куясың. Шулаймы?

—Мин, господин полковник, сезнең белән бәхәсләшергә теләмим. Белемем, аңым җитми. Ачуланмасагыз, сезнең сорауга үз фикеремне әйтәм.

—Ачуланмыйм, әйт, Зәйнуллин.

—Урыс кешеләренең күбесе аракы эчә, сөйләшкәндә бертуктаусыз мат куллана һәм иң куркынычы, сез—урыслар, ялкаулар, эшләргә яратмыйсыз.

—М-да-а!—диде полковник. Бераз дәшми торгач сорады:

—Күптән шулай уйлыйсыңмы?

—Алты ел элек мин бояр немец Мердерда елдан артык батрак булып эшләгән идем. Шунда ике ай Безгин авылы урыслары белән урман кискән идек. Шунда аларның эшләмәскә тырышып, әллә нинди хәйләләр уйлап, эштән качарга тырышуларына исем киткән иде. Монда инде, казармада, урыс солдатлары белән дүрт ел бергә яшәп, минем урыслар ялкау халык дигән фикерем ныгыды, төпле уй булып ныгыды.

—Авылда тагын батраклык көтә бит сине.

—Шулай икәнен аңлыйм мин. Ләкин тук булып, урыс булып яшәгәнче, үземнең ачлы-туклы татар халкы арасында яшәп, күпчелек татар нәрсә

күрсә, мин дә шуны күреп, татар булып калырга тиеш мин дип уйлыйм. Китим мин кайтып, господин полковник. Җибәрегез мине.

Полковник учы белән акрын гына өстәлгә сукты:

—Синең әле генә әйткәннәреңдә, өстән генә караганда дөреслек бәлки бар кебектер. Татар күзе белән караганда. Ә бит мин чын урыс кешесе. Һәм урыс милләте—минем милләтем. Минем өчен минем милләтем—бөек урыс милләте. Син армиядә калсаң, белемле, культуралы, оста атучы урыс офицеры булып китәр идең...

Туктады. Сүзе юк иде сөйләргә... Бу татар егетенең фикер йөртүе, татар булып калырга теләве бик тә дөрес иде. Тик бөек милләт вәкиле булып, башкалар өстенә басып яшәргә өйрәнгән урысның бер вәкиле буларак, татар егете сөйләгән белән ул килешә алмый иде. Шулай да татар солдатына карата эчке бертөрле каршы торуны урыс полковнигы җиңә алды.

—Иртәгә иртәнге тугызда миңа кер. Кабинетка. Мин капитан Бульон белән капитан Ростуновны да чакырырмын. Бездә синең кебек чын, асыл солдат моңарчы булганы юк иде. Сиңа җитмәсә дә, бик шәп төзәүче Спирин дигән берәү булган иде. Алтынчы елны кайтып китте. Эчә иде. Акчалата бүләк алып Керчька увольнениегә китсә, Керчь комендатурасы безгә аны исерек килеш китереп китә иде. Өлешчә синең әйтүеңдә дөреслек бар—урыс халкы эчә... Ярар. Иртәгә иртән монда кереп документларыңны аласың. Сиңа байтак кына акча да чыкты әле.

—Нәрсә өчен, господин полковник?

—Син көтмәгән яктан. Иртәгә биргәндә әйтермен. Бар, Бульоннан рөхсәт алып, бүген дус-ишләреңне эчер казармада. Мин рөхсәт итте диген Бульонга.

—Слушаюсь, господин полковник.

—Бар, бар!

Икенче көнне иртән полковник үзенең яраткан төзәүчесе унтер-офицер Лотфулла Зәйнуллинга кабинетында хушлашу оештырды. Башта ул Лотфулланың кулына акча тапшырды:

—Менә сиңа, Зәйнуллин, сиксән җиде сум да илле алты тиен акча. Солдат хезмәтен башлап алып киткән алтынчы елның көзендә сез, яшь солдатлар, үзегезгә бер тәүлеккә тиеш булган өч кадак ипине ашап бетерә идегез. Шуннан норма белән ашауга күнегә башладыгыз һәм яңа елның гыйнвар азагында ипине ике кадак кына ашауга күнектегез. Мин сездән калган ипине үлчәтә барырга куштым. Ике кадак та сигез йөз граммда туктадыгыз киметүне. Димәк, һәр тәүлеккә синең бер кадак ипиең кала килде. Өч ел да ун айга шул көн саен бер кадак торып калган ипидән җыйналган акча бу. Господин полковникта калмасын солдат хакы. Ал, кирәгеңә тотарсың!

Өстәл янында басып торган ике капитанга мөрәҗәгать итте:

—Утырыгыз, господа! Хушлашыйк яхшы кеше белән. Хәрби хезмәттә калырга риза булмады безнең төзәүче, татарин Зәйнуллин.

Өстәл артында торган сейфны ачып бер шешә коньяк, дүрт кечкенә рюмка, өч лимон чыгарды. Кесәсеннән пәке чыгарып Бульонга сузды:

—Кис лимоннарны, Николай Николаевич!

Үзе коньяк шешәсен ачып рюмкаларга коньяк салды.

—Хушлашыр алдыннан хәзер мин әйткәнне исеңдә калдыр, Зәйнуллин. Әгәр авылыңда яшәү начар булса, кире кил монда. Бер елга кадәр сине килер дип өметләнеп калабыз.

—Рәхмәт, господин полковник. Тик мин килмәм инде.

—Ну, Зәйнуллин! Монысын әйтмәсәң дә була иде инде, ләкин син монда да үзең булып кала беләсең.

Рюмкасын күтәрде:

—Чын татар джигиты өчен эчәбез. Һәм ана яхшы, бай тормыш телибез Туган илендә.

Бер шешә коньякны өч мәртәбә рюмкаларга салып эчтеләр. Соңгы рюмканы кулына алгач, Лотфулла китәсе кеше буларак әйтте:

—Офицер әфәнделәр! Өчегезгә дә зур рәхмәт. Мин сезнең кул астында хезмәт итеп, дөньяда бик яхшы һәм кин күңелле урыслар барын белдем.

Бульон елмаеп өстәде:

—... һәм хохоллар барын да белдең.

—Әйе, хохол офицерны да белдем. Хушыгыз! Тагын бер кат зур рәхсәт сезгә.

Казармадан крепость капкасына кадәр барлык батарея солдатлары үзләренең яраткан унтер-офицерын, оста төзәүчесен озатырга чыкты. Капка төбендә кочаклашып саубуллаштылар.

—Хуш, Зәйнуллин!

«Пермяк соленые уши» аны кысып кочаклады.

—Рәхмәт сиңа! Сиңа карап эшләп, бу соңгы өч елда мин үземнән ялкаулыкны җинеп бетә яздым инде. Син эшләр өчен һәрчак миңа үрнәк булачаксың!

Ибраһим абзыйга кереп берне кунды.

Кич утырып азрак шәраб эчтеләр, хуш ис бөркелеп торган тәмәке тарттылар. Бераз эчкәч, Ибраһим ага сакланып кына сүз башлады:

—Исәбең булса, кал бездә—Кырымда. Туган-тумача җыелып сиңа йорт салырга ярдәм итәрбез. Түләрсең җайлап. Өйләнеп җибәрерсең, бала-чага... Кырымда төпләнерсең.

Лотфулла кулына тоткан шәрабле чәшкене әйләндерә-әйләндерә уйланды да, җавап бирде:

—Булмас миннән, Ибраһим абый. Кырымыгыз миңа бик ошап та бетми. Урманнар юк монда, эссе. Үләннәр дә бездәге кебек яшел түгел. Көйгәннәр димме шунда... Кайтасым килә, бик сагындым үзебезнең якларны.

—Ай, үзең беләсеңдер инде. Тик, сөйләвеңә караганда, сине анда ялчылык көтә бит инде.

—Гомер буена ялчы булмам әле. Эшли беләм, көч күп, балта эшен дә беләм. Берәр җае чыгар әле...

Икенче көнне Ибраһим ага кара биясен тарантаска җигеп, Лотфулланы Керчьның тимер юл вокзалына озатып куйды. Вагонга утырыр алдыннан улы кебек итеп кочаклады:

—Хуш, Лотфулла. Эшләрең бик барып бетмәсә, өч елдан да соңлама, кил безгә. Фатыйма үсеп буй җитә, сиңа бирермен, киявем булырсың, йорт салырбыз. Монда ошамаса, Ялта янында әнинең энесе яши авылда. Шунда төпләнерсез.

—Ярар, уйлармын. Хуш, Ибраһим абзый! Гаепләп калма.

—Нинди гаепләү ди. Ат урынына эшләп, миңа күпме ярдәмең тиде. Ходай сине ташламасын, ярдәм итсен. Мин монда фатихада торырмын. Мин әйткәнне исеңдә тот.

...Декабрь аеның беренче көннәре иде. Уфа—Чиләбе юлының тау-таш арасында утырган Шафран тимер юл стансасында поездан таза гәүдәле бер унтер-офицер төште. Кара төстәге погоннарына аркылыга икешәр ак тасмалычка тагылган. Егет алсу кызыл йөзле, зәңгәр күзле иде. Уң кулына кечкенә сандык күтәргән, сул кулбашына солдат капчыгы аскан. Ул вокзалга керде. Бу егет Керчь каласы янындагы крепостьта солдат хезмәтен тутырып, туган авылы Эстәрлебашка кайтып баручы унтер-офицер Лотфулла Зәйнуллин иде. Вокзалга керүгә сул якта ишек башына эленгән «Трактиръ» дигән язуны

укыды да, шунда юнәлде. Аш, тәмәке, аракы исе аны кочып алды. Почмакта торган бер буш өстәлгә барып утырды. Сандыгын идәнгә куйды, капчыгын сандык өстенә салды. Сандыкта да, капчыкта да әти-әнисенә, энеләренә, абыйсы Хәйруллага һәм туган-тумачаларына алган бүләкләр, күчтәнәчләр иде. Шинелен, папахасын салып дивардагы чөйгә элде. Утырып тирә-ягына карана гына башлаган иде, «половой» килеп җитте. Урысчалап:

—Чего, Ваше Благородие изволяет?

Шәп бу «половой» дип уйлады Лотфулла. Урыс сүзләре бар да татарча әйтелә иде. Татарчалап сорады:

—Токмач бармы?

—Так точно!

—Сөйләш үзебезчә. Тагын ит-фәләннән нәрсә бар?

—Сарык ите, пилмән, сыер бавыры, казылык.

—Миңа токмач, сарык ите. Булса, кабыргалысын китер. Ике чәй.

Китә башлаган «половой»ны туктатып:

—Өстәлләр арасында йөргәндә белеш әле, Эстәрлебаш ягына барәр олау юкмы икән.

Ашны ашап бетереп, сарык кабыргасын кимерә башлаган иде. Чикмәнле, чабаталы, чыбыркылы бер агай килде өстәл янына. Күзләре елмая иде:

—Гаспадинга олау кирәк икән Эстәрле ягына. Эстәрлегә хәтле түгел, вә ләкин мин шул якка. Матур, Каен Үзәк исемле авылны ишеткәнең бармы?

—Бар. Яхшы беләм мин ул авылны. Булганым да бар.

—Алай икән. Булгач, бик әйбәт. Мин үзем шул авылныкы. Чыпчык Габдрахман исемле Алла бәндәсе. Егерме биш тиен түләсәң, алып кайтам Каен Үзәккә. Сиңа инде аннан 18 чакрым гына кала. Солдат дип мин сине бушка да алып кайтыр идем. Тик ел коры килде, игенне бик аз җыйдык. Гаепләмә, энем, азрак түлә инде син. Атым әйбәт кенә, чана эче тулы печәнем. Тик болай килешик: «Мин чанага утырганда син төшәрсең, син төшкәндә мин утырырмын!» Текәрәк үрләргә менгәндә тәпиләрсең диюем инде бу минем. Шаяртам.

Лотфулла елмайды:

—Бик мәзәк абзый булдың бит әле син.

—Соң шуңа күрә исемне дә такканнар бит инде: «Чыпчык Габдрахман» дип. Юкка-букка, күп чыркылдаганга инде ул, нәрсә өчен дип беләсең..

Өстәлгә карап алды:

—Әйдә, сөягеңне кимер дә, чәеңне эч тә, киттек чыгып. Үземдә туктарсың. Эстәрле ягына баручыны иртәгә иртән табарбыз. Мәдрәсә шәкертләре кайтканнар иде өчәү Эстәрледән. Шуларны әтиләренең берәрсе илтер, мөгаен.

Җыйналып китәргә чыктылар. Лотфулла олаучыдан сорады:

—Син, Габдрахман абзый, Каен Үзәктә Фәхрислам исемле кешене беләсеңме?

—Кайсысы икән—алар өчәү бит. Бисмилла Фәхрислам, Чәкүшкә Фәхрислам, аннан соң Кәккүк Фәхрислам. Хатынының исеме кем?

—Зөһрә исемле. Эстәрледән төшкән килен ул. Минем әтинең бертуган сеңлесе.

Каеш чыбыркысын тоткан хәлдә абзый басып каткан иде.

—И-и, әннә кем булып чыктың бит әле син. Балта Зәйнетдин улы бит син. И-и-и! Син бит минем кода буласың болай булгач. «Бисмилла» Фәхрисламның әтисе белән минем әни бертуганнар бит. Алл-лай икән, кода икән син. Әйтәм аны күргән көенә ошаттым мин сине. Уйлап та куйдым, әллә күргәнем бар инде мин бу гуардин егетне дип.

—Бардыр. Бәләкәй чакта Каен Үзәктә мин ике тапкыр булган идем.

—Ал-лай булгач, күргәнмен инде мин сине. Зәйнетдин абзый килгән саен кунак итеп алам мин аны. Шунда ияреп кунакка килгән булгансыңдыр.

—Анысы булган эш түгел инде. Әти-әни безне кунакка ияртеп йөрми. Чит авылда түгел, үзебездә дә йөртмиләр.

—Ярар, шулайдыр.

—Фәхрислам җизнинең бала-чагасы күпме?

—Ай, күпме дип, кем санаган инде аларны. Малайлары дүртәү. Барысы да Исламнар. Нурислам, Гайнислам, Динислам, Бикислам. Кызлары икәүме, өчәүме шунда. Санын белмим аларының... Нәстәгә дип бала-чагасын санау кирәк сиңа? Баргач күрерсең.

—Күчтәнәч алырга иде. Күпме алырга икән?

—Ы-ы, шул. Солдат абзыйлары исләрендә калсын. Туганнар бит. Ал икеөч кадак суыра торган кәнфит, прәнник, шушки. Апаңа бер матур яулык ал, акчаң булса. Җизнәңә бер кадаклы тәмәке ал, катыргы тартма эчендә. Тарта, каһәр, минем кебек. Мин дә барырмын аның тәмәкесенә...

Юл уңаена вокзалдан ерак түгел кибеткә кереп бүләк яулык алдылар. Лотфулла уйланып торды да, дүрт матур түбәтәй һәм өч матур яулык алды. Түтәенә, малайларына, кызларына... Җизнәсе Каен Үзәк авылы мәчетеннән ерак тормый икән. Зур өенең эче тулы эреле-ваклы кызлар, малайлар. Сандыкны күтәргән Габдрахман абзый ишекне ача башлаган көенә сөрән салды:

—Каршы алыгыз хуҗалар вә һәм дә бала-чагалар. Сезкиләргә кадерле, бүләкле, күчтәнәчле кунак алып кайттым Шафран стансаларыннан. Зәйнетдин балтаның патша хезмәтеннән кайтып баручы улы Лотфулла була ул кунак...

Лотфулла аларда ике кич кунгач, өченче көнне иртән иртүк торды да, өч шәкерт белән бергә Эстәрлегә кайтып китте. Өйлә якынлашканда инде ул авыл читендәге урамда утырган өенең ишеген ачып керде. Шулай итеп кайтып житте туган авылына Лотфулла...



Гәрәй
Рәхим

# МЕНӘ ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР...

## Ходавәндә

*Менә шундый хәлләр бездә,*
*Ходавәндә...*

**Син булмасаң бу Җир шары**
**Оҗмах багы булыр иде.**
**Бөтен кыйтта, урман, болын**
**Чәчәк белән тулыр иде—**
**Ходавәндә!..**
**Җирдәге һәр җан иясе—**
**Фил, куян һәм хәтта бете**
**Бөек ирек яулар иде,**
**Булмас иде үрчү чите—**
**Ходавәндә!..**
**Син булмасаң дәүләтләр дә,**
**Сугышлар да булмас иде,**
**Җир йөзенә кара каһәр,**
**Кайгы-хәсрәт тулмас иде—**
**Ходавәндә!..**
**Мәхәббәт тә, көндәшләр дә,**
**Сөяркә дә булмас иде...**
**Хәләли йә уйнаш аша**
**Бәбиләр дә тумас иде—**
**Ходавәндә!..**
**Син булмасаң булмас хәтта**
**Ходай барын танучы да.**
**(Кичер, Ходам, булмас иде**
**Тәмугыңда янучы да!..)**
**Ходавәндә!..**
**...Әй кем соң син, илаһи зат,**
**Уең белән Җирне юган!?.**
**Ходавәндә мин үзем бит,**
**Сихер белән җиргә туган...**

**Менә шундый хәлләр, туган...**
**Ходавәндә!..**

Гәрәй РӘХИМ (1941) — *шагыйрь, прозаик, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар («Вәгъдә», «Зирек бөдрәләре», «Моңнарым» һ. б.), шул исәптән ике томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Бездәгечә түгел

Мин хыялый бер төш күрдем—
Сәер төшнең һәр төше.
Бездәгечә түгел монда—
Үзгә яшәү рәвеше.
Бездәгечә түгел монда—
Һәркем үзгә эш кыра:
Алашалар канат кага,
Фәрештәләр пошкыра.
Бездәгечә түгел монда—
Алларыңны алмыйлар.
Сиңа гашыйк булган этләр
Иренеңне ялмыйлар.
Бездәгечә түгел монда—
Йөди безнең ишеләр:
Андый-мондый кеше түгел—
Чып-чын монда кешеләр.
Бездәгечә түгел монда—
Замана монда зирәк.
Бездәйләр буа буарлык,
Шагыйрьләр генә сирәк...

Шагыйрьләр гаять сирәк...

## Каен суы

*2007 елның 19 апрелендә Язучылар берлеге идарәсе утырышы алдыннан шагыйрь Равил Фәйзуллин миңа татар әдипләренең «Аккош күле» Иҗат йорты урманыннан җыйган каен суы бүләк итте.*

Каен суы... Сине бер йотуга
Сулкылдады күңелем, елады.
Бөтен тәнем буйлап каным булып
Агып китте каен сулары.
Йөрәгемә барып җиткәч, кинәт
Йөрәк ярсу аттай дулады.
Искә төшеп яшьлек хатирәсе
Үпкәләрем авыр сулады...
Каен суы гына түгел шул син—
Кайгы, шатлык, бәхет сулары...

## Ике ашкыну

*Ерак-еракларга*
*Торналар очып бара*

Ркаил Зәйдулла

*МАЛАЙ:*
—Хыялым булып
Болытлар оча,
Җилләр дә оча,
Кошлар да оча
Сихри якларга.
Шулар шикелле
Очар идем лә
Мин шул якларга,
Ерак-еракларга!..

*БАБАЙ:*
—Хәтерем булып
Болытлар оча,
Җилләр дә оча,
Кошлар да оча
Сихри якларга.
Шулар шикелле
Очар идем лә
Туган якларга,
Ерак-еераклардан...

## Әгәр... Мәгәр...

Белер идем мин нишләргә—
Алтынга манар идем лә
Һәр тумыш көнне, мәгәр—
Бу гомерне өр-яңадан
Кайтарып булса әгәр...
Яшьлегемдә сөйгән кызны
Бәхеткә күмәр идем мин
Ятка бирмичә, мәгәр—
Яшьлегемне өр-яңадан
Кайтарып булса әгәр...
Чит-ят җирләргә китмичә
Яшәр идем туып-үскән
Авылда гына, мәгәр—
Язмышымны өр-яңадан
Кайтарып булса әгәр...
Матур итеп киендереп,
Тәмле ашка тиендереп
Яшәтер идем, мәгәр—
Әти-әни исән чакны
Кайтарып булса әгәр...
Көне-төне шигырь язып,
Шигырь белән генә азып
Яшәр идем мин, мәгәр—
Гомеркәйне, асылкайны
Кайтарып булса әгәр...

## Теләк

*...га*

Язның соңгы көне—
Минем туган көнем.
Язның китү көне—
Минем килү көнем.
Гомер итәм шулай
Гел ымсынып язга.
Бәйрәм итәм язны
Тик бер көнгә... азга...
Бөтен гомер язым
Шул бер көнгә сыя.
Шул бер көндә җаным
Мәңгелек яз тоя.
Язгы соңгы көндә
Мин дөньяга индем...
...Яз киткәндә килсен
Миңа соңгы көнем...

* * *

*70 яшькә киткәндә*

Гомер кояшым баткан да кебек...
Өр-яңа таңым аткан да кебек...

## Безнең ил

1. ЧОРЫБЫЗДАН ИКЕ ЭСКИЗ

*Бер горурлык хисе яна миндә...*
Сибгат Хәким

Кайдадыр көләләр...
Кайдадыр елыйлар...
Кемнәрдер киләчәк тормышны
Бәхеткә юрыйлар—
Шунда ук кул сузып
Хәер дә сорыйлар...
Күп монда галимнәр...
Шулай ук күп юләр...
Үзләре барсы да:

**«Бу—безнең ил!»—диләр...**
**«Бу—безнең ил!»—диләр...**

**Кемнедер суялар...**
**Кемгәдер зур һәйкәл куялар...**
**Төрмәләр,**
**Стадионнар,**
**Кабаклар дыңгычлап тулганнар.**
**Китапханәләр,**
**Музейлар,**
**Күргәзмә заллары**
**Кешесез буш бина булганнар...**
**Чат саен базарлар гөрләшә,**
**Барсы да бер сүзне сөйләшә:**
**«Бу—безнең ил!»—диләр...**
**«Бу—безнең ил!»—диләр...**

**Көн саен арталар ипигә бәяләр...**
**Сөрелми яталар буш җирләр...**
**Эш таба алмыйлар өрлектәй ирләр...**
**Китаплар күптәннән түгәрәк ятимнәр...**
**Кемнәрдер**
**Мәчет башына тәре,**
**Чиркәү башына ярымай**
**Эләргә әзерләр...**
**Гәзитләр, экраннар, эфирлар хор белән:**
**«Бу—безнең ил!»—диләр.**
**«Бу—безнең ил!»—диләр.**

## 2. 2010 ЕЛНЫҢ КАЙНАР ҖӘЕ

*Татарстан—төтенстан...*
Равил Фәйзуллин

**Мәскәү күге—төтенстан,**
**Татарстан—пожарстан,**
**Мари иле—урман көле,**
**Псков—пыскый,**
**Ульянда ут уйный,**
**Новгород Нижний—көйри, чыжлый,**
**Чувашия яна, көя...**
**...Болар бар да**
**Син—Россия...**
**Син—Россия...**
**Син соң бүген халыкларның**
**Туган иле, туган өеме?..**
**Рәсәй, Рәсәй,**
**Син бит бүген—**
**Пыскыган кисәү...**
**Суынган көл...**
**Кара күмер өеме...**
**Шулай да**
**Сәяси зур заллар,**
**Фиркаи съездлар,**
**Хөкүмәт йортлары,**
**Кремльләр**
**Дәррәү горурланып:**
**«Бу—безнең ил!»—диләр...**
**«Бу—безнең ил!!.»—диләр...**
**«Бу—безнең ил!!!»—диләр...**



Әхәт
Мушинский

# ҺАВАЛАРДА—АК КҮГӘРЧЕН...

РОМАН

## I КИСӘК

### 1 БҮЛЕК

#### 1. Күршеләр

Ул үзенең «җәйге резиденция» дип йөрткән кыйшаеп беткән иске сараенда таң беленгәч үк уяна. Аннары озак кына иртәнең стена ярыклары аша ничек эчкә сөзелеп керүен күзәтеп ята. Шунда нindидер соклану белән аерым детальләрен, Плюшкин сыман, төрле чүплектән алып кайтып үз куллары белән җыйган радиосына да карап-карап алгалый. Әлбәттә, түбәдәге күгәрчен кетәгеннән ишетелгән ыгы-зыгы, гөрләшү һәм чыелдау тавышларына да колак сала...

Аннары, әле алма бакчалары артыннан кояш күренеп тә өлгерми, инде ул сарай түбәсенә менеп китә һәм аның ак канатлы күгәрченнәр өере шундук һавага күтәрелә.

Юк, Шәех мондый иртәнге сәгатьләрдә тирә-якны үзенең юлбасарлар шикелле сызгыруы белән яңгыратмый. Бары тик аларның, очарга теләмичә, янадан кетәккә кире кайтырга маташкан кайбер ялкауларын гына куркытып, кетәге янында очына чүпрәк кисәге бәйләгән тал таягын гына селкеп тора. Күгәрченнәр исә, түгәрәкләр ясап оча-оча, һаман югарыга күтәрелә бара. Әле күзгә күренмәгән кояш нурларында, вак-вак ялтыравык тәңкәләр сыман, аларның җилфердәгән канатлары гына ялтырап-ялтырап китә. Бу чакта аларны кулын маңгаена куеп күзәтеп торган Шәех күзләрен кыса төшә, баш артын кашып ала һәм, акыл ирешмәслек нindидер хакыйкать ачкан кеше сыман, югарыдан аска таба төкереп куя да, таягын кетәккә сөяп калдырып, башка эшләрен дәвам итәр өчен гөнаһлы җиргә төшә.

Ә аның алары да санап бетергесез. Барыннан да элек ул үзенең оча торган гвардиясе өчен иртәнге аш әзерләргә керешә. Аннары, тагын кире

Әхәт МУШИНСКИЙ (1951) – *прозаик, публицист; Державин исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Шейх и звездочет», «Адаш малай», «Бер тибүдә гол» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

кетәккә менеп, шул азыкны аларның улакларына салып чыга, кайгыртучан хуҗа шикелле, бу чакта ояларда утырган кайбер күгәрченнәрен кулы белән капшап-капшап карый, куначалары астын чистартып ала... Аннан соң, әледән-әле ниндидер катлаулы схема өстенә иелеп карый-карый, бер-ике сәгать чамасы паяльник белән ниндидер детальләр ябыштырып утыра яисә аның янынннан бер дә өзелеп тормаган чираттагы сораучыга бирер өчен җан өрергә дип, шөрепборгыч белән чираттагы ватык радиоалгыч эчендә казына башлый.

Боларын тәмамлагач, Шәех үзенең мәҗбүри эшләренә тотына. Монда инде—юлның теге ягындагы колонкадан бакчага су ташыймы, сарайда кыш буена шактый кими, җимерелгәли төшкән әрдәнәдәге утыннарны өйгәләп-рәтләп куямы—ул ашыга төшә. Чөнки без икенче сменада укыйбыз, ә мәктәпкә барыр алдыннан беребезгә дә һәм беркайчан да җитмәгән вакыт ягы кыса башлый аны.

Ләкин Шәехне иртәнге кояш еш кына өеннән еракта—Иделдә яисә Казансуда, алай гына да түгел, хәтта уннарча чакрымдагы Мишә елгасының әрәмәлекләр арасындагы берәр тугаенда кармак белән утырган килеш туры китерә. Аның өчен балык тоту да эш булып санала иде.

Белмим, менә хәзер Шәех ничектер, ләкин ул чакта—илленче-алтмышынчы еллар аралыгында, асылда әле үсмер генә килеш тә олыларга охшашлы кыяфәтле булуына карамастан, ачыктан-ачык килбәтсез, ябык, алай да, Хәниф абый әйтмешли, нык сөякле малай иде ул. Моннан да гадирәк итеп шулай бер тапкыр ана: «Син коточкыч ямьсез, ләкин коточкыч кызыксынучан»,—дип Юлия әйтте. Димәк, ул Юлиягә кызыксынучан малай булып тоелган. Беренче «коточкыч»ын кыз, әлбәттә, сүз җилеме итеп кенә кыстырды, ә болай, чынында, Шәехнен тышкы кыяфәте беркемне дә битараф калдырырлык түгел иде. Иген сабагына охшаган муенында зур маңгайлы, кабак сыман нәрсә утыра, чәчен «сыер ялаган»—ничек кенә сыйпама, барыбер тырпаеп тора; чәнечкеле кашы астыннан, беркемне дә аерып тормыйча, бар кешене дә рәттән, кәефенә һәм һава торышына карап йә коңгырт-кара, йә сары төскә керүчән күзләре чәнчеп карый. Аны шунда, беренче очрашуда ук, йә ошаталар, йә озакка яисә бөтенләйгә күралмыйлар иде.

Ә мин үзем исә аны бер үк вакытта ярата да, күралмый идем. Һәм—бу еллар үтә торгач кына ачыкланды—аны яшертен генә, ниндидер үҗәтле кызыксынучанлык белән күзәткәнмен икән. Әйе, күзәткәнмен. Бәлки, ул чакта күзәтүчәнлек минем бердәнбер сәләтем булгандыр. Болай мин бүтәннәрдән башка берни белән дә аерылмый идем бугай. Менә инде ничәмә-ничә еллар үтеп киткәч тә хәтерем миңа һаман-һаман шул дустымны, безнең йортыбызны, кечкенә генә бүлмәсендә инде еракта калган шул тормышыбызның яртысы диярлек узган, ялгызы гына яшәгән галим күршебезне, шулай ук күңелгә якын һәм якын булмаган башка кешеләрне, алар арасыннан хәтта дошман булганнарын да, алардан очраклы рәвештә генә ишеткән кайбер гыйбарәләрне, кул хәрәкәтләрен, ишарәләрне, йөзләрне, тавышларны күз алдыма китереп бастыра... Болар барысы да башымда бөтерелә, шаулый-гөрли, үзләренең иректе тормышлары белән күңелемдә яши бирә һәм мин, бик теләсәм дә, аларның ул тормышына катнаша алмыйм.

Шул чактагы урамыбызда басып торам. Күпме еллар узды! Хәзер ул йорт үзе кайда? Балачакның үзе шикелле үк иксез-чиксез булган аның ишегалды кайда? Күгәрчен кетәге, алма бакчасы кайда? Минем дустым кайда, һәм мин үзем—аның тырпайган чәчле әшнәсе кайда? Аның белән без икебез дә якын күргән, икебез дә аңа гел тартылган, һәрчак кырынмый

йөргән һәм шуңа килешсез күренгән теге галим кеше кайда? Үзенең йөреше белән балеринаны хәтерләткән, аңа барыбыз да акылдан язардай гашыйк булган зәңгәр күзле кызый кайда? Юк, берни дә һәм беркем дә юк инде. Бары тик хәтер генә бар. Әнә, иртәнге тынлыкны ярып, һавага кардай ак почтальон, турман, якобинчы токымлы күгәрченнәр күтәрелде. Ләкин болар теге кошлар, минем дустым кошлары түгел шул инде...

Минем бала акылым анын безнең йортта беренче мәртәбә күренүе белән тәмам уянып житте сыман тоелды. Һәм шуннан соң инде хәтеремдә гадәттә узганың турында үзең берни дә хәтерләмичә, бу турыда сиңа әти-әниең генә сөйли торган кебек нәрсә дә булмады, чөнки барысы да үземнең хәтергә бик яхшы сеңеп калды.

Ул беренче тапкыр безнең йортта бозлы-салкынлы декабрь иртәсендә күренде. Көн суык булуга карамастан, ишегалды тулы халык иде. Кысылып та керерлек түгел! Алар погоннарына кызыл тасмалар тегелгән шинельле кешеләрнең бозланган өйалды болдырына җеназа кабыгын куйганнарын сүзсез генә карап тора. Каралып торган ишек уемы янында яланбашлы, кечкенә гәүдәле бер апа такмаклап елый. Аның яулыгы җилкәсенә сыерылып төшкән, юка гына ситсыдан тегелгән тишек-тошыклы кофтасының ике якка ачылган итәге арасына минем яшьләрдәге малай сыенган.

Бу Шәех иде.

Ул, башын әнисенең итәгенә төртеп, тавышсыз гына елый. Аны күрүче дә юк. Әнә кемнәрдер яннарыннан әтисен, аннары аның артыннан ук зур эскәмияләр, урындыклар күтәреп чыгып киттеләр... Шунда әнисе җеназа артыннан ташланды, малай исә аның артыннан йөгергән иде дә, ләкин икенче катка менә торган текә баскыч янында аннан артка калды да, күңелсезләнеп, чит коридорның караңгы һәм билгесезлеккә чумган почмагына килеп посты.

Минем әни аны безгә—булачак күршеләренә, менә шул чакта алып керде дә инде. Безнең катта барлыгы—дүрт бүлмә һәм аларның һәрберсендә кечкенә мич чыгарылган. Ә гомуми кухняда исә мичнең бик зурысы тора. Бүлмәләрнең берсендә, күзгә ташланмый һәм тавышсыз-тынсыз гына баласыз олы яшьләрдәге бер пар, икенчесендә ялгызы гына галим Николай Сергеевич Новиков яши. Калган икесендә безнең гаилә—әти, әни, абый, апа һәм мин яшәргә тиеш идек, ләкин без анда көчеп тә өлгермәдек, шундук тыгызланырга туры килде. «Бу вакытлыча гына,—дип белдерде безгә башкарма комитет вәкиле,—гадәттән тыш хәл килеп чыкты». Шулай итеп, берсен «гадәттән тыш хәл» аркасында көченеп килергә тиешле яңа күршебезгә калдырып, без яңа фатирыбызның икенче бүлмәсенә кереп урнаштык.

Дөресен дә дөрес икән, хәл чыннан да гадәттән тыш булган. Фатирга чиратта торган янгын сүндерү сугышчысы Исмәгыйль Шакиров бик көткән кадерле ордерын инде суынган кулларына алган, мескен. Ул моңарчы хатыны һәм малае белән берничә ел «вакытлыча» әллә ярым сарайдамы, әллә күгәрчен кетәгендәме яшәгән. Әйе, нииндидер иске склад өстенә, җилләр иркенә әмәлләп куйган ул шыксыз урынны башкача атап та булмый. Аны ягып та җылыта алмаганнар. Җәйнең нинди генә эссе вакытында да аның идәненнән салкын бәреп торган, ә кышын исә ул идән дигәннәре хәтта бозланып каткан. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, малайлары шул «суыткыч»та да исән калган. Тик өлкән Шакиров кына авырып киткән—үпкәсенә салкын тигән. Төннәрен ыңгырашкан, йөткергән, ә хатыны, иртән үк докторларга җибәрәсе урынга, аны шәһәр башлыгы катына куган. Хәер, монда мескен хатынны да гаепләп булмый, чөнки фатир ачкычларын беркайчан да тәлинкәгә салып китереп бирмәделәр бит. Ә сугыштан соң нииндидер биш-

алты ел гына узган ул вакыт турында әйтеп тә торасы юк! Һәм бер дә бер көнне Шакиров, хәле бик начарланып киткәнче дип, авыруына бирешмәскә тырышып, башкарма комитет бусагасын атлап кермәкче булган. Шунда аның хәле бик авыраеп киткән. «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакырганнар чакыруын, тик аны хастаханәгә дә алып барып житкерә алмаганнар...

Шушы кайгыдан акылын югалтыр хәлгә төшкән тол хатын шул ук көнне туп-туры шәһәр башкарма комитетына барып, андагы тере чират һәм «таш йөрәкле» секретарь кызлар аша зур башлык янына ук үтеп кергән дә, аның пинжәк якасыннан эләктереп: «Кеше үтерүче син! Син генә үтерден минем иремне!»—дип, ике кулы белән селкергә тотынган. Ана ордерны шул сәгатьтә үк язып биргәннәр. Ул тиешле мөһере сугылган һәм барлык имзалар да куелган, озак көтеп алынган шул кәгазь кисәген иренен салкын кулларына куйган да: «Менә алдык без көткәнебезне. Иртәгә яна фатирга күчәбез...»—дигән.

Пөхтә итеп обой ябыштырылган такта стена аша күрше хатыннын такмаклап елавы безнен бүлмәгә яхшы ишетелә иде.

Ә минем әни ятим калган малайны ничек булса да юатырга тырыша. Аны минем өстәл янына утыртты да, уенчыкларымны чыгарды. Аннары аннан:

—Синен исемен ничек, бәләкәч?—дип сорады.

—Шәех,—дип үкседе малай һәм, тавышлардан түгел, бары тик күз карашыннан гына саклый ала торган стенанын теге ягында ниләр барын белергә теләп, тынып калды.

—Ә әниеннен исеме ничек?

—Рәшидә.

—Хәзер без сезнен күршеләрегез булабыз инде,—дип әни анын тынлаусыз чәченнән сыйпап алды да мина ишарә ясады:—Менә Ренат белән дуслашырсыз. Сина ничә яшь?

—Алты.

—Бер яшьтә икәнсез, сугыштан сонгылар. Киләсе елда мәктәпкә дә бергә йөрерсез,—диде ана әни. Аннары мина дәште:—Ә син нигә почмакка постын әле? Кунакка уенчыкларынны күрсәт! Йә инде, йә...

Безнен Шәех белән дуслыгыбыз әнә шул көннән башланды. Дөрес, кайберәүләр мәктәптә, дин әһеле шәехкә ишарәләп, аны Шәех дип үчеклиләр иде.

## 2. Хәлдән килмәгәнне...

Мин кичәгедән дә яхшы хәтерләгән ул мен тугыз йөз алтмыш беренче елнын ерак май иртәсендә Шәех мине карангыда ук уятты.

Үзе әмәлләп куйган иркен такта ятагында ул кичен бик тиз йокыга китә. Юрганын башына яба да—вәссәлам! Ә мин ул төнне тәмам торганчы диярлек йоклый алмадым, чөнки мине әти-әнием алай бик еш жибәрми торган балык тотарга бару шатлыгы шулай дулкынландырды. Алай да тан алдыннан йокыга киткәнмен китүен, тик шундук мине инде өстенә дә киенеп алган эшлекле кыяфәттәге Шәех селки башлады. Мин жыенганчы ул балык тота торган әйберләрне барлый, төзәткәли, велосипедларны карый торды...

Төн пәрдәсе чак кына ачылуга, без инде үзебезнен «лисәпит»ләрдә елгага таба жилдерә идек. Безгә һәрвакыт нәкъ менә бу юлы, нәкъ бүген юлыбыз искиткеч унышлы булып чыгар шикелле тоела.

Күркәм май аенын уртасы. Күзгә күренмәс ерак жирләр дә ягымлы жылылык белән сулый. Бөтен көчкә чапкач, иртәнге салкынлык шактый ук

тундырса да, дәртне һич тә сүндерә алмый, чөнки алда—Идел, кояш, ирек, бөтен тормыш! Унбиш яшьтә шулай булмыйча соң! (Ул миннән ярты елга иртәрәк туган, һәм мин аны һәрвакыт куып яшәдем: елына яртышар ел без яшьтәшләр булсак, яртышар ел ул миннән бер яшькә олы була иде.)

Ул чакта без балыкны сал белән агып килгән агачларны кабул итә һәм аннары кирәк җирләргә төяп җибәрә торган база янында тота идек. Бу—безнең күрше Хәниф абыйның яраткан урыны. Аның саманнан ясалган бердәнбер йорты каршыда, урам аша гына агарып күренеп тора. Элеккеге Балтыйк дингезчесе хәзер гражданкада участок милиционеры булып эшли. Аны бөтен тирә-як хөрмәт итә, алдында җирле караклар да калтырап тора. Аның турында газеталарда да яздылар. Ул берүзе алты бандитка каршы чыгып, икесен шундук боргычлап алган, калганнарын соңрак тотканнар. Ә шушы хәлгә бер ел дигәндә, ул, язгы суга ташланып, бата башлаган карчык белән аның овчаркасын үлемнән коткарды. Менә шундый ир-ат ул Хәниф абый. Дөресрәге, егет, чөнки ул чакта аңа егерме дүрт кенә тулган иде әле. Аның ике цилиндрлы, коляскалы трофей «BMW» мотоциклы бар. Әлбәттә, аңлашыла, ул аны сугышта фрицлардан тартып алмаган. Шуның белән ул эшенә дә, балыкка да дыңгырдый, хатыны белән балаларын да утыртып йөри. Аның мотоцикл тавышын без әллә кайдан, хәтта коймалар аша да таный идек.

Мотоцикл, алгы тәгәрмәче бер яккарак авышкан хәлдә, күбеккә баткан яшь айгыр сыман, яр буенда тора. Хуҗасы күренми. Без велосипедларыбызны аның коляскасына сөяп куйдык та сал өстеннән сикерә-сикерә бара башладык. Ә монда аның очы-кырые күренми, әйтерсең кемдер бөтен Иделне бүрәнә белән түшәп чыгарга уйлаган! Суның ачык җирен тапканчы кара тиргә баттык.

...Икебез дә янәшә утырдык. Балык тотканда Шәехкә бәхет гел елмаеп кына тора. Шуңа күрә гадәттә аның янынарак утырам. Кайчагында мин кармагымны суга атканда безнең кармак җепләре бер-берсенә эләгешеп куя. Ләкин Шәех түзә, ачуланмый.

Чиертми иде. Яр буендагы бүрәнәләр тавы артыннан зур булып кызыл кояш күренде һәм, бик тиз кечерәя, агарына барып, бераздан чиста күктә йөзеп китте. Су өсте ялтырый башлады, тирә-якта бөтен нәрсә җанланды, кыска койрыклы яр буе карлыгачлары күренгәләде, ә минем калкавычка энә карагы килеп кунды. Мине басып алган бәйләнчек йокымсырау мәле аркасында аны куып җибәрергә дә көчемнән килмәде.

Инде кояш су өстеннән күзне тәмам көзге сыман чагылдырганда һәм аның яшелле-зәңгәрле булып ялтыраган, кирегә әйләндереп каплаган сыман булган күк йөзе буенча көндезге сирәк болытлар йөзә башлагач кына уянып киттем. Ә Шәех, җиңелчә генә кымшана төшеп һәм калкавычыннан күзен алмыйча, һаман үзенең элеккеге урынында утыра. Әйтерсең менә хәзер кырпы балыгын өстерәп чыгарачак.

Мин икенче ягыма әйләнеп ятарга гына җыенган идем, кинәт ул кармагының җебен эләктереп алды да, тиз-тиз генә тарта башлады. Табыш суда чагылган болытлар арасыннан шашынган кош шикелле очып килеп чыкты. Һәм шунда кинәт кармактан ычкынды да бүрәнәләр өстеннән биеп китте. Инде менә су да якын гына... Шәех, җаен туры китереп, аны эләктереп алды, ләкин балык шундук аның кулыннан шуып төшеп китте. Һәм шунда дустым, яшен тизлеге белән финкасын кулына алып, бер селтәнүдә аны сал бүрәнәсенә кадаклап куйды. Аңа ул финканы кайчандыр—анысын бер Алла гына белә!—күрше Николай Сергеевич Новиков бүләк иткән иде. Финка бик тә күптәнге: инде аның тиредән эшләнгән кыны тетелеп, агач сабы исә череп беткән иде. Шәех аңа яңа сапны үзе ясап куйды.

Пычак йөзе астында карабалык тырпылдый. Ул башта күренгән шикелле әлләни бик зур түгел икән үзе. Шуна күрә бәләкәй сөкә белән сөзеп алмаган ул аны. Ләкин барыбер күзне кыздырырлык, юан, запорожье казакларыныкы сыман мыеклы.

—Чак кына ычкынмады бу шайтан карабалык,—дидем мин.—Шома, хәшәрәт.

—Ә-ә!..—диде Шәех ваемсыз гына. Ул кыланмый иде, чөнки монда кемдер алдында кыланыр кеше дә юк. Аннан соң бу нәрсә анын холкына хас та түгел. Балыкка барган чакта ул, чиертү ничек кенә булмасын, һаман зур балык эләктерү турында уйлый. Ул жаны-тәне белән балыкчы иде.

Хәтерлим әле: без бөтенләй канат чыкмаган кошчыклар гына идек, ишегалдында—кыш, минем әни мичтән өсләре кызарып пешкән өчпочмаклар чыгара... Безнең гомуми кухняда эссе, тәмле ис борынны яра. Белмим, ни сәбәпле булгандыр инде ул бәйрәм? Әллә йөк машинасында шофер булып эшләгән әти командировкадан кайткан идеме, әллә абый стипендия яисә былтыргы жәйдә чирәм жирләрдә эшләгәне өчен акча алган идеме? Хәер, болары әһәмиятле түгел. Иң мөһиме—бүген барыбыз өчен дә бәйрәм! Димәк, бөтен өебез белән сыйланачакбыз.

Ә ул шушындый вакытта балыкка барырга жыена...

Ул чакта безнең шәһәрдә кышын балык тоту шөгыле әле яна гына гадәткә керә башлаган иде. Бу яңа һәвәслеккә шәһәр халкын плотина белән буылган Иделнең кинәт диңгез-океан шикелле жәелүенә һәм Казансуның киң елгага әйләнүенә китергән Куйбышев ГЭСын жибәрү этәрде.

—Син кая киттең әле, Шәех?!—дип гажәпләнде әни.—Өчпочмаклар өлгерде бит.

—Якты чакта суалчаннар казып алырга кирәк.

—Нинди чуалчаннар ди ул кышын?!

—Гадәтиләр. Тик хәзер алар тирәндәрәк кенә ята.

—Утырып аша әле башта.

—Аннары.

Ул әтисенең бүреген батырып киде дә, өстендәге сырмасын йолдыз төшерелгән жиз тәнкәле каеш белән шалт итеп буып куйды һәм чыгып китте.

Ул чакта суалчаннарны мәктәп ишегалды артындагы, без Уйсулык дип йөрткән гаять зур, бормалы-бормалы елгадан казып ала идек. Анда жәй көне тирә-якта яшәүчеләр бәрәңге дә утырта, шунда ук, анын якынрак итәгендә, чүплеккә дә урын табылган, ә арырак, борылыш артында, Уйсулыкның аргы өлешендә күл өсте ялтырап тора. Анда исә язын—зур боз кисәкләре өстендә, жәй көннәрендә кулга ни эләгә, шунын белән—ауган коймалардан ясалган сал өсләрендә, мичкәләрдән торган «флотилия»ләрдә, автомобиль шиннарында менә дигән диңгез сугышлары оештырыла иде. Кайчак кайбер «крейсер»дан суга берьюлы унлап кеше очып төшә.

Кышын күл хоккей мәйданнарына әверелә, ә Уйсулык итәкләре чаңгычылар өчен чын хөррият үзәгенә әйләнә. Монда иелә-сыгыла слалом да шуалар, трамплиннан да сикерәләр һәм арты киселгән бер генә чаңгыда шундый крендельләр ясыйлар—карап туймассын!

Бары тик якын Уйсулыкның кар күмеп киткән чүплеге генә тапталмаган килеш кала бирә. Шәех әнә шунда юнәлгән. (Бу турыда аннары үзе сөйләде ул).

Көн бик салкын иде. Ә бәлки, алай ук салкын да булмагандыр. Без бит, вакытлар уза торгач, балачактагы хәлләрне бераз күпертебрәк сөйләргә яратабыз. Ләкин андагы кар өемнәре чыннан да гаять зур иде, батсаң, колакларың да күренмәслек.

Шәех кыргыч белән кар азрак яуган, ләкин үзенә бертөрле калфак сыман, дөресрәге, текә ярның маңгаендагы козырек шикелле асылынып торган төньяк итәгендә казына башлаган. Башта эше яхшы гына барган, ә менә жиргә тикле казып төшеп кулына лом алгач һәм аның белән туң жиргә суккан саен ул аның кулында янгырый башлагач, шунда ул өчпочмаклар белән жылы мичне исенә төшергәндер, мөгаен. Хәер, ул андый нәселдән түгел, бик үҗәт малай. Чокый торгач, лом кызып чыга. Әйтерсең жир түгел, ә бетон. Тик алай да әкренләп, теләмичә генә булса да, сантиметр артыннан сантиметрлап жир бирешә башлый. Ә менә көрәктә озак көттергән суалчан хәрәкәтләнеп куйгач кына ... кар козырегы ишелеп төшә. Тышта Шәехтән әтисе бүрегенең күбәләк сыман итеп элмәкләп бәйләнгән бавы гына күренеп кала... Башка берәү булса, мөгаен, тереләй күмелгән килеш шунда язга тикле катып яткан булыр иде. Ә ул ничек итсә итә, карны ерып чыга һәм... кабат үз эшенә тотына. Кыскасы, барыбер алып кайтты ул суалчаннарны. Дөрес, алар сүлпәннәр иде, ләкин тереләр.

Икенче көнне иртән үк, сап-салкын өйалды суыгыннан бөрешеп, мин аңа уныш теләп калдым һәм ул салкын караңгылыкта эреп югалды.

Ул, Казансуга, Бөкре күпер тирәсенә барам, диде. Ул тирәдә балык бик яхшы чиертә, дип әйтәләр иде. Ул өстенә бераз кар сибәләгән элеккеге кечкенә бәке-чокырчыкны сайлап ала да, сөмән бавын кулына чорнап, боз вата башлый. Чокырчык бозы әле алай бик катып ук житмәгән икән, ә сөмән бавы черек булган. Бозга икенче мәртәбә китереп сукканда, ул, өзелеп, суга төшкән дә киткән! Кулында бары тик черек бау кисәге калган да су өстендә куыклар гына пәйда булган. Нишлисең, шул тимер аркасында батып үләргә димәгән, Шәех бүреген тагын да батырыбрак кия дә, кулына метр ярымлы бамбук кармак сабын ала... Аңа—Биектау районының коры жирле авыл кешесенә, шундый балыкчы дәрте кайдан килгәндер? Кармагына ярым тере, ярым үле суалчанны кигезеп, салкын суга батыра һәм, туңган бармакларын өреп жылыта-жылыта, күзе белән бозлы суда селкенеп алганнан соң кабат хәрәкәтсез калган калкавычына текәлә. Шәех чокырчыкны чистартып ала, ә анда бозлы ботка кабат барлыкка килә. Шәех аны тагын чистарта, ул яңадан боз белән каплана...

Дустым ничек кенә үҗәт булмасын, суык үзенекен итә: ул туңа башлый. Шәех, хәзер нишләргә инде дип уйлап, хәрәкәтсез яткан калкавычы белән кармагын судан чыгара. Ерак түгел генә балыкчылар төркеме каралып күренеп тора икән, ул шулар янына таба китә. Килсә, аларның кулында— мәктәп линейкасы озынлыгында гына, башларына велосипед ниппельләре куелган гажәеп кармак саплары! Ә кармакларына исә ачык мүк жиләге төсендәге бик-бик кечкенә сәер суалчаннар кигезелгән. Бер балыкчы карт, Шәехнең зарын тыңлап торганнан соң көлеп куя да, аңа бер чеметем озынборын личинкасы бирә, ә артык ниппеле юк икән менә.

Ләкин монысы да бик житә кала Шәехкә. Ул үзенең килбәтсез озын кармак сабын читкә куя да, кармагының очы белән берьюлы ике кечкенә суалчанны эләктереп ала. Ә кармак жебенең кыска өлешен бармагына чолгый һәм... китә шуннан балык тоту! Боз өстендә чабак, алабуга балыклары сикерешә башлый... Шәех аларны, күгәрченнәрен кетәгенә куып керткәндәге шикелле: «Чи-чи-чи»,—дип сөйләнә-сөйләнә тартып чыгара. Әйтерсең балыкларның котырынып чиртүләре һәм боз астыннан бертуктаусыз очып чыгып торулары аның өчен гадәти эш. Мавыгуы шулхәтле куәтле була, хәтта аркасы тирләп чыга. Тик кулы гына бик туңа да, аннан читтәрәк утырган карт кына, аның ягына күз салгалап, ачуыннан сүгенгәләп куйгалый...

Ләкин без гыйнвар бозыннан май салларына кайтыйк әле.

Финка очыннан карабалыкны алып, Шәех бүген минем йокым туютуймавы белән кызыксынды.

—Рәтле йокы да булмады,—дип җавап бирдем мин,—балык та чиертми. Ярый ла сина бәхет елмаеп тора.

Ул дәшмәде, балыкларын тезгән җепне генә тарта төште. Шулчак суда күзгә күренмәс җепкә тезелгән кара сыртлы балыклар селкенә башлады. Шунда хәтерем калды, чөнки минем өчен әллә ниткән уңышсыз көн булды бу. Һәм мин, киерелеп иснәнеп алдым да ана, яр буена коенырга киттем, дидем. Ерак түгел генә сай, ачык урын сарыланып күренеп тора иде. Бүрәнәләр өстеннән сикерә-сикерә шунда таба киттем.

...Шәех түземлелек белән үзенең патша балыгын көтә калды. Ә мин, йөзә белмәгән малай, шатланып, рәхәтләнеп сай суда тыпырчына башладым. Мина мондый рәхәт минутлар алай бик еш тәтеми, чөнки гадәттә мин усал телле яшьтәшләремнән оялам һәм аларның суда куркыныч шаяруларыннан куркам. Ә монда мине бөтен яктан бик яхшы белгән дустымнан башка беркем дә юк, мине беркем дә күрми.

Хәзер гомерем белән чак кына хушлашмый калган ул мизгелне тулысы белән хәтерли дә алмыйм инде. Башта барысы да бик әйбәт һәм күңелле генә булды. Салкынча су күңелне күтәреп, дәртләндереп җибәрде, комлы, тигез су төбе ышаныч тудырды. Хәтерлим, куллар белән «брасс» стилендә эшли-эшли һәм, гәүдәмнең кайчан җиңеләеп, авырлыкны сизмичә аяклар ярдәменнән башка гына йөзә башлавын көтеп, су муенга җиткәнче кердем. Һәм инде кире борылырга гына җыенган идем, шунда кинәт аяк астымдагы җир убылып юкка чыкты.

Шуннан соң хәтеремә шул гына сеңеп калды: үзем су йотам, үзем бар булган көчем белән тыпырчынам, кычкырам, тагын тончыгам, батам... Шушы хәлемнән, батмаска тырышып тыпырчынуымнан ничек, кайчан туктавымны хәтерләмим инде. Яр буенда татлы уяну белән тәмамланган нindидер яшькелт-болганчык төш сыман иде ул мизгел. Гадәттә кичен ничек йокыга киткәнеңне белми-сизми каласың, аның каруы ничек уянып китүеңне яхшы хәтерлисең. Һәрвакыт якты һәм чиста булып истә кала ул. Күземне ачып җибәрсәм, минем өстемә Шәех белән Хәниф абыйның болытсыз май күгенә һичничек тә тәңгәл килмәгән сытык чырайлары карап баккан иде.

—У-уф!—диде Шәех һәм, җиңел сулап, тураеп басты.

—Тинтәк!—диде Хәниф абый.

Шулчак мин барысын да аңладым. Әйе, батуымны, мине судан алып чыкканнарын, һушка китергәннәрен аңлап алдым, тик моны кем һәм ничек эшләгәнен генә белми идем. Соңыннан гына Шәех сөйләде...

Мин тыпырчына һәм акыра башлагач, кармак җимен алыштырып маташкан Шәех, башын күтәреп, минем якка борылып караган. Янәсе, мин чынлап батаммы, әллә шаярам гынамы? Ул үзе минем якка карый, ә куллары инде үзләреннән-үзләре аяк киемен, чалбарын салдыра икән... Мин, су өстеннән югалып, гадәттәгедән озаграк кире чыкмый торгач кына ул бүрәнәләр өстеннән мина таба ташлана.

Комлы су төбендә ул мине шундук эзләп тапкан. Аннары аягымнан тотып ярга өстерәгән. Хәтта сулышы капкан. Шулай аяктан өстерәп чыгарган да. Шуннан соң аның ни эшләгәне ачык аңлашыла инде: кулларымны бер тапкыр—ян-якка аерып җибәрә дә аннан соң күкрәккә куя, ян-якка, тагын күкрәккә... Шул чакта Хәниф абый да йөгереп килеп җиткән. Ул ерак түгел генә, бүрәнәләр өеме артында, балык тотып утырган булган. Ачы итеп кычкырганымны ишеткән дә йөгереп килгән, ләкин инде минем, бу якты дөньяга янадан кайтып, яр буенда яткан мәлемә тап булган.

Аннан икебезгә дә эләкте. Миңа—бозау хәтле булып та йөзә белмәвем һәм хәлемнән килмәгәнне эшләвем өчен. Ә Шәехкә, гади генә әйткәндә, болай, куркыту өчен генә. Ләкин мин Балтыйк диңгезчесенең бу вакытта дустыма ничек җылы итеп каравын, аның көчле кулының әле менә яңа гына барлыкка килгән коткаручының ябык иңнәренә аның бу кыюлыгын ничек хуплап каккалап алуын күрдем.

Шәех сал өстенә мине коткарырга дип сикергәндә чыланган күлмәген сыгып җәйде, янәшәдә кояшта оекбашлары да кибә иде. Мин, акланып:

—Шундый сай җирдә чокырлар бар дип кем уйлаган!—дидем.

—Прокурор алдында акланырсың,—диде ул, трусигын сыга-сыга.

Шулчак яр буенда мотоцикл дырылдады. Бүгенгә Хәниф абыйның балык тотуы да шуның белән тәмамланды.

## 3. Багдад шәехе, солдат каешы

Ул көнне без, икенче сменада укуыбызга карамастан, мәктәпкә соңга калдык.

Мәктәп ишегалдына кердек.

Балачакның иксез-чиксез ирекле, ваемсыз-гамьсез кызыл почмагы—һәркемнең үзенеке ул. Юк, балачакның гына түгел, үсеп җиткәнчегә тикле булган бөтен тормыш анда. Кайчак, юк-юк та, анда кайсыдыр Вася абый да, чалбар балакларын сызганып, футбол тубы куып йөргәли. Үзенең шундый Вася абыйлары безнең чорда да бар иде, алар мәктәп ишегалдын да читләтеп үтмәде, кечкенә балаларны эткәләп-төрткәләп, сәбәп белән дә, сәбәпсез дә карлыкканчы бәхәсләшеп, кайчак бик тә саллы дәлил сыйфатында муен төбенә дә кундырып, туп тибеп йөрделәр. Өлкәнрәк балалар белән кәрттә «очко», «бура», «свара» кебек уеннарда да кисештеләр һәм азарт белән акчага «чика» дигән уен да уйнадылар, бары тик махнушка гына тыпырдатмыйлар иде. «Нәрсә тарта икән аларны монда?—дип уйлый идем мин, аларга карап.—Нәкъ балалар шикелле!» Хәзер исә, вакыт узган саен, миңа аларның ул гамәлләре дә аңлаешлы була бара.

Мәктәп ишегалды үзенең әйләнә-тирәсендә куе булып алма һәм груша агачлары үсеп утырган бакчалар эченә яшеренгән. Безнең йорт та, безнең мәктәп тә, урнашкан урам үзе дә Алмалы дип атала. Юк, хәзер андый урамнарны очрата алмыйсың инде. Бөтен май ае буенча юлны коймалар өстендә кайнаган алмагачлардан коелган ап-ак чәчәкләр каплый, ә июньдә урамның ике ягындагы тротуарлар буйлап тезелгән юкәләр патшалык итә башлый. Киләсең шул сарылы-яшелле юкә түбәсе астыннан—бал кортлары безелди, ә тирә-якта шундый хуш ис, әйтерсең әйләнә-тирәне балга коендырганнар! Соңрак тагын алмагачлар хакимлеге башлана. Аларның алмалары көнен дә, төнен дә шапылдап җиргә коела һәм алсуга манылган ул алмалар бертуктаусыз капка асларыннан тәгәрәп-тәгәрәп чыгалар. Антоновка кирәкме, әнис, алтын ранетмы—җаның теләгәнен сайлап ал! Алмагач белән юкә тик көзен генә, җил бу ике көндәшне һич тә кызганмыйча талкый-талкый соңгы сары яфракларына кадәр чишендереп бетергәч кенә, үзара татуланышып калалар.

Ничек кенә булмасын, тик безнең урам, гәрчә бездәге кебек груша муллыгын башка бер генә шәһәрнең урамы белмәсә дә, Юкәле дә, Грушалы да түгел, ә Алмалы дип йөртелде.

Безнең мәктәп ишегалды бик зур түгел, ләкин унайлы иде. Җиңелчә генә сөзәк футбол кыры, баскетбол-волейбол мәйданы, әллә нинди сарайлар, аулак почмаклар, барып терәлгән тыкрыклар, җиләк-җимеш агачлары. Гаҗәп, ул агачларның җимешләрен дә күреп булмый, без аларны, саранча

шикелле, язын чәчәктә чакта ук диярлек ашап бетерә идек. Чөнки без Алмалы урамы малайлары идек бит, безнең кан тамырларыннан да кан урынына алма суы ага иде бугай.

Җимеш агачлары һәм алар артындагы бәрәңге кырыннан соң Уйсулыклар башлана. Алар турында кыскача гына әйтеп киттем инде.

Ул көнне ишегалдында кысан иде. Баскет та, туп белән сындырылган-сыдырылган куаклар артында чика да уйнадык... Ләкин алай да монда күбрәк футбол патшалык итте. Монда жиденче «А»дан безнең сыйныфташлар—мәктәп ишегалдының иң «абруйлы» малайлары Жбан белән Киләле дә бар иде. Һәрчак яшь булып калган Вася абый да мышный-мышный чаба. Дөрес, тиздән ул юкка чыкты, сиздермичә генә каядыр китеп барды. Капкада гел йомыш белән йөгерүче малай Титя басып тора, шунда ук күп кенә башка балалар да бутала. Шул ыгы-зыгыда, яхшы уен могҗизалары күрсәтеп, унынчы класс укучысы Сашка Пичугин ачык аерылып тора иде. Ул безнең якта әле яңа кеше булуга карамастан, инде абруй казанган егет. Бездә кешегә йә парта артында, йә мәктәп ишегалдында гына танылырга мөмкин. Ә ул, профессор малае, анда да, монда да өлгерде. Мәктәпнең беренче математигы, биш минуттан медаль иясе, район күрке һәм мактанычы Сашка Пичугин укытучылар һәм кызлар мәхәббәтен генә түгел, ә бөтен ишегалды халкының яратуын да яулап алды. Ул стильле пинжәктән һәм һәрвакыт тубык турысы уелган (башкача сыймый) тар балаклы чалбардан, уен өчен уңайсыз булган крокодил тиресеннән тегелгән очлы башлы туфлидән, туп белән шундый оста итеп, әллә ниткән хәрәкәтләр ясый! Ул үзе йөгерми дә диярлек, алай да аннан тупны алу бик тә авыр иде. Ул аларны капкага тибеп тә кертми, ә ничектер нәфис итеп, капкачыны урап, тәгәрәтеп кенә кертә шикелле. Ул еш кына монда, мәктәп ишегалдында, кәрт тә уйнады һәм мин: «Ул дәресләрен кайчан укый, җинәргә дә өлгерә торган олимпиадаларга кайчан әзерләнә икән соң?»—дип гаҗәпләнә идем. Мине Сашканың бик тиз алмашына торган мавыгулары белән сәләте дә гаҗәпләндерә иде. Ә менә бу егетнең тагын бер мавыгуы барын, аның иске открыткалар җыючы коллекционер икәнен мин ул көнгә хәтле белми дә идем.

Хәер, барысын да тәртип белән сөйлим әле.

—Шәех, капкага бас әле!—дип кычкырды Титя, безне күреп.—Миңа өйгә кайтырга кирәк.

Ишегалдында Шәехкә мөнәсәбәт катлаулы иде. Хәер, мин хәзер, инде күп вакытлар үткәч кенә, шулай дип уйлыйм. Чынында, киресенчә, гади, бер күзәнәкле, ниндидер туры сызыклы, хәйләле-мыскыллы һәм мәкерле мөнәсәбәт иде ул. Әйтерсең аңа тию-кагылуны, анда үзенең тапкыр сүзлелеген сынап карауны, кыскасы, аны җае чыккан саен кыерсытуны һәркем үзенең бурычы итеп санады шикелле. Хәтта еш кына кулларын да эшкә кушалар иде. Ни өчен, нигә алаймы? Шуның өчен, чөнки анда безнең барыбызга да хас булган өер белән яшәү хисе юк. Ул башкалардан аерылып торды, күп кенә очракларда калганнарга караганда бөтенләй бүтәнчә эшләп куя һәм шул ук вакытта, тыштан үзсүзле, үҗәт булса да, йомшак табигатьле һәм яшьтәшләренең «явызлыгы»на җавапсыз иде. Аларның юк-бар, буш нәрсә икәннәрен күреп, ул аларга җавап кайтарасы урынга башын гына югары күтәреп куя, аннары, аскы иренен турсайта төшеп, маңгай чәченә өреп ала да, борылып китеп тә бара. Аның бу гадәте һавалы, тәкәбберлек сыман килеп чыга. Әйтерсең ул бәйләнчек чебенне куалый. Борыны—югарыда, карашы—еракта, җавап та биреп тормый, ялагайлану, ярарга тырышу да юк ул караштa. Менә нәрсә чыгырларыннан чыгара җирле азгын малайларны һәм бу аларны аңа карата янадан-яңа һөҗүмнәргә этәрә иде.

«Кем булып кыланган буласың соң син?»—дип бәйләнәләр аңа. Һәм артыннан башлангыч классларда ук туйдырып бетергән сүзләр оча:

*Багдад шәехе—*
*Солдат каешы,*
*Тутык кайсар,*
*Тишек кесә.*

Бу куплетның үз дөреслеге дә бар иде. Илленче елларда һәм алтмышынчы еллар башында да урам себерүче хатын малаеның башкалар, әйтик, профессор малае белән, бертигез киенерлек мөмкинлеге һич тә юк иде. Бүген генә барысы да буталды, хәзер тышкы кыяфәте буенча пыяла савытлар, буш шешәләр кабул итүчене университет доцентыннан, яисә аларның балаларын бер-берсеннән аерып кара! Безнең хәзерге урам себерүче хатынның малае синең яннан шытырдаган-шыгырдаган өр-яңа киемнән узып китә һәм үзенең төтен сыман күзлеге белән сиңа шундый ваемсыз итеп карап ала ки, нигә икәнен үзең дә белмичә, тиктомалдан югалып ук каласың.

Шәех кырыкмаса кырык ямау салынган, аны һаман аска табарак тартып-тартып маташкан, ләкин шулай да барыбер кыска булып калган чалбарларыннан да оялмый иде. Юк, ул беркем булып та кыланмады, фәкать гел үзе генә булып кала бирде. Моны мин бик яхшы белә идем, бәлки, шуңа күрә дә якын күргәнмендер дә аны. Башкалар исә аны нәкъ менә шуңа күрә дә мыскыл итәләр иде. Ничек инде урам себерүче, кечкенә генә буйлы, очраганда сүз кушарга да оят булган—акыра башлар!—үзенең тупас авыл гадәтләре аркасында бөтен Алмалы көлгән бер псих апаның малае шундый горур булып кылана?! Хәтта Титя—шулай ук әтисе булмаган, ә әнисе завод ашханәсендә савыт-саба юучы булып эшләгән Николай Титенко да—аннан көләргә, аны уңайсыз хәлдә калдырырга җай гына эзли, ул моны күзәтеп торучы балалар алдында эшләргә ярата иде. Ә бит бу Титя болай юаш, басынкы малай. Ничектер соңыннан газетада фотографиясен күрдем—хезмәт алдынгысы, оста мехчы икән. Ничек борылмалы бу тормыш дигән нәрсә һәм анда яшәгәндә пычранмыйча калуы да авыр. Мин—Шәехнең беренче дусты Ренат Әһлиуллин да, вакыты-вакыты белән аның миңа тәкәбберлек һәм үҗәтлек булып күренгән эчке бәйсезлеген бик өнәп бетерми идем. Мин башкалардан бары тик аның аркасында үземне күтәрергә, алга чыгарырга тырышмавым һәм аның белән ачыктан-ачык дуслашуымнан оялмавым белән генә аерыла идем бугай. Бары шул гына. Яшьтәшләрем арасыннан аңа мин бердәнбер якын кеше идем һәм аңарга гел яхшылык кына теләдем.

Менә хәзер, инде ничәмә-ничә еллар узгач, кайчак үтеп киткән шул тормышны яңадан акка күчереп язасы, ягъни яңабаштан, дөрес итеп яшәп үткәрәсе килә! Чөнки анда күпме ялгышлар—әһәмиятсез вак-төяге дә, хәзер искә алуы да чиркану тудырган, күңелдә төзәтеп булмаслык төер калдырган хурлыклылары да калды бит.

*Дәвамы киләсе саннарда*



## Шәмсия Җиһангирова

# ДӨНЬЯ БУЙЛАП

***

Йоклый кеше. Мендәрдә таралып
Ята чәче, аяк-куллары...
Үлгән дияр идең, ишетелмәсә
Аның тыныч, тигез сулавы.

Йоклый кеше—дөнья мәшәкатен,
Моң-зарларын, гамен онытып;
Төшләрендә җәннәт бакчасыннан
«Бәхет» атлы сәмруг-кош тотып.

Йоклый кеше. Аның иң бәхетле,
Иң илаһи мәле—шул чакта!
Дошманыңмы синең, дусыңмы ул—
Читтән генә соклан. Уятма!

***

Уңга карыйм—җаным киселеп төшә,
Сулга карыйм—икеләтә авыр...
Әллә нинди генә мәхәббәтсез,
Мәрхәмәтсез, кешелексез дәвер!

Барып сыенырлык кеше тапмыйм...—
Йөрим үзем кеше арасында.
Явызларга һич тә ярап булмый,
Яхшысына (бәлкем!) ярарсың да.

Алу-сату тәхет тота бүген,
Ходай йортыннан да иман качкан.
«Хаталарны таныдык!» дип кенә,
Башлап булмастыр шул яңабаштан.

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА—*шагыйрә, прозаик; «Төсле моң», «Җирсу», «Якты сагыш» һ. б. китаплар, популяр җырлар авторы. Казанда яши.*

Кеше хәзер иман җыю түгел,
Акча-байлык җыю белән мәшгуль,
Һәр адәмнән соңра калыр нәрсә
Каберең өстенә куйган таш ул.

Ул байлыкны күпме җыеп була?!
Нәфес казаннары һаман тулмый.
...Оҗмахны да бүлешерләр иде,—
Ярый әле сатып алып булмый!

***

Кинәт кенә дөнья тынып калды...
Әйтерсең лә утын сүндереп,
Карт әбиләр кебек кыштыр-кыштыр
Караватка ятты сүрелеп...

Әле кичә генә шау-шу иде—
Дирижерсыз оркестр кебек
Сайрый иде җирдәге бар кошлар
Берсен-берсе узып, бүлдереп...

Әйтерсең лә кара мөһер сугып,
Кемдер яңа боерык чыгарды:
Дөньяларын онытып сайрамасын,
Туктатыгыз, диеп, шуларны!

...Онытылмаган иде! Киресенчә,
Гөрләп тора иде бу дөнья.—
Мәет чыккан йортка охшап калды
Кинәт, кошлар тавышы тынуга...

***

Бала чакта, әле һаман истә,
Бәйләгәндә әнкәм кырда көлтә,
«Кул арама керер» диптер инде,
Ала иде үзе белән эшкә.—
Ай урагын салып иңнәренә,
Итәген кыстырып билләренә;
Кулмәгенең бәби итәкләре
Җилфер-җилфер иде җилдә генә...
Кулы белән гел төзәтер иде
Яулык читендәге бөдрәләрен...
Саф-саф булып тезелеп ятар иде
Ул бәйләгән киндер көлтәләре.
Көлтәләрне тезәр иде аннан
Гаскәр-гаскәр итеп чүмәләгә...
«Гөлҗа-а-ма-а-а-л» дип җырлар сузар иде,
Елап алыр иде күрмәгәндә...
Мин дә әнкәм кебек тезеп-тезеп
Сала идем киндер учмаларын...
Ашамый да йоклап китә идем,
Өйгә кайткач, көне буе арып.
Әнкәм һаман мактап торыр иде:
«Кулың, диеп, ятып тора эшкә...
Көлтә генә түгел, гомереңне
Яшә шулай тезеп бер тәртипкә».

...Гомер үтә торды. Язмыш миңа
Сынауларны бирде көлтә-көлтә...
Һәр учмасын йөрәгемә тезеп,
Яшәп ятам шулай бер тәртиптә...

***

Бала чактан килә бер сүз,
Ник әйтелгән, кем белә:
«Имән астына кермә, дип,
Имәнгә яшен тия».

Имәннән дә чыдамрак
Агач юктыр югыйсә!
Кая барып сөяләсең,
Имәнгә сөялмичә?!

«Яшен» дигән сүз куркыта,
Аңа сөялү кая!
Яңгыр астыннан чабасың
Йөгерә-атлый-тая...

Имәннәрне ирләр белән
Чагыштырам мин шуңа:
Барып сөялүең була,
Тота да яшен суга...

«Яшен» дигән сүз куркыта,—
Иргә сөялү кая!
Дөнья буйлап йөгерәсең
Йөгерә-атлый-тая...

***

Бала чакта, күбәләктәй канатланып,
Оча идем кунып гөлдән-гөлгә...
Бик сак кына карап тора иде хәят:
Тия күрмә берүк, тия күрмә!

Канатлары ныгып җитмәс борын
Егылмасын диеп гөл таҗыннан,
Үз канат астына сыендырып,
Әнкәм килә иде гел алдымнан.

Үскәч, очар коштай канатланып,
Гөл таҗыннан күчтем зәңгәр күккә...
Сөйгән ярым миңа иңен куйды:
Болытлардан, диеп, егылып төшмә!

...Инде хәзер очар канат талган,
Гөл дә ымсындырмый, зәңгәр күк тә...
Иң дә куймый беркем һәм әйтми дә:
Егылып китмә, диеп, егылып китмә!..

## Әй, сөю!..

**Бу дөньяга бакканым син,**
**Ялганым вә хакларым син,**
**Җаным телгән утларым син,**
**«Әйе»ләрем, «юк»ларым син,**
**Туры кыйбла тотканым син,**
**Оттырганым, отканым син,**
**Чәчемдәге бәсләрем син,**
**Күземдәге яшьләрем син,**
**Яшәү тәме, әчесе син,—**
**Минем белән мәңге бергә яшисе син!**
**Тот кулымнан, китик әйдә дөнья буйлап!**

***

*Бик күңелсез җирдә яшәүләре*
*Күңеле катып калган кеше белән...*
Нияз Акмал

**Мактаналар күпләр, «мин, дип, шөкер,**
**Бу дөньяда дөрес яши беләм,—**
**Кулым биреп күрешмим дә хәтта**
**Файдасы тимәстәй кеше белән...»**

**Шактый яшәп, мин дә әйтә алам**
**Бу дөньяда, диеп, дөрес яшим,—**
**Җитәклим дә китәм кулларыннан**
**Тамганнарны күзләреннән яшен...**

**Дөнья кыйммәтләре гел акчага**
**Салып үлчәнгән бу заманада**
**Онытабыз кеше күңеленең**
**Байлыкларын үлчәп карарга да...**

**Мин мөкиббән нечкә күңелләргә,**
**Иманы—саф, җаны—ап-акларга!**
**Бу кыйммәтләр тәтеми күпләргә,**
**Сатып алып булмый акчаларга.**

**Авыр булыр иде яшәү җирдә**
**Күңеле катканнар арасында,—**
**Ярый ла бар әз-мәз шатлыкка да**
**Сөенә белүчеләр—бала сыман.**



Розалина
Шаһи

## Шигъри́ят—тереклек суы...

**Шигърият—тереклек суы,
тәлгәш-тәлгәш милли сүз,
кош булып оча түбәмнән—
күләме белән йолдыз!
Шигырь булса, җан тыгыз!..
Кайсы гасыр, нинди кавем
табынмаган шигырьгә?
Күңел койган чикләвек сүз
үтеп кергән бәгырьгә—
шулай арткан моңыбыз!...
Шигырьле, аһәңле милләт
Нинди хәсрәт төшмәсен—
шигырь манарасы иткән—
халкым тойгы чишмәсен!
Дошман алалса, алсын?!.**

**Илдән—илгә, йөздән—йөзгә
барган шигырь шуышып,
яраланган солдатсыман—
әйтергә мәхәббәт сүзен,
кушып соңгы сулышын...
Компьютерлар заманында,
бүгенге көн чатында,
шигырь ялгыз бәргәләнә,
бөтен дөнья каршында,
ләкин калмассың ялгыз!
Күңелдән тамган бу сүзләр—
йөрәк-бәгырь эзләре,
әйе, тормыш үзгәрер,
ләкин чәчәк, икмәк кебек,
шигырь калыр югары...
Киләчәккә юнәлер!**

Розалина ШАҺИ (ШАҺИЕВА)—*шагыйрә, сәнгать белгече; «Кара мәрҗән», «Ниса» исемле шигырь китаплары, күпсанлы монографияләр авторы. Казанда яши.*

Яңага, киләсе көнгә,
без бергә барасыбыз!
Алтын җепле—хикмәтле сүз—
Син—йөрәк парәсебез.
Иң татлы мирасыбыз...
Шигырьдә янасыбыз!

## Урамым

Авылым!... Ур—р—амым!... Мин синдә туганмын!
Егыла-егыла, әниемнең чабуына ябышып,
Басуың таптады беренче адымым!
Нәкъ Казан юлында, Көл тавы астында
Куралар эчендә башланды гомерем!
Нәкъ менә шул илдә, карурман җирендә,
Сызылды беренче шигырем.
Әле дә кулымда, йодрыкта, алтындай,
Кадерле, бер бөртек тузаның!

Шәһәрем! Урамым!
Ахрысы, мин синдә туганмын!
Йолдызларга ябыша-ябыша, хуш исле мамыклы
Язгы юкә исләренә умартадай чорналып,
Көяз кибетләрең, ертык тротуарларың, мәктәп,
Театрлар,
Черек күлләрең аша,
Мин сине мең кабат у-р-радым!!!
Урадым, яратып туймадым!
Оямны йортыңда корганым!
Эчендә җилферди таганым!
Йотлыгып ни эзли бәйрәмдә патефон көенә
Беренче танголар ишеткән колагым?

Авылым, шәһәрем! Бер хәтер авазым!
Икегез тазартты күңелем ярасын!
Иңдерде күңелгә—язасын,
Читләрдә болганып, йөрәкнең янасын!
Илемне сагынып, яңадан кайтасын!
Шигырьгә табынып, суфыйдай яшәсен!
Иң татлы шәрабтай авылы, каласы,
Урамы, таллары,
Илемнең һавасы!
Шуларны алтынга, көмешкә язасы!
Язмышым урамы! Мәңгегә каласы!

***

Күбектәй очалар...
Кадерле исемнәр,
Коела өстемә
Матдәләр, җисемнәр...
Күзләрен акайткан
Тәкәббер балыклар,
Аларның эчендә йотылган
Халыклар...

Әйтерсең җан бирә
Сүз колы милләтләр,
Сүтелә тирә-як—
Акчалар чиләкләп!
Балкымый йөзләрдә
Илаһи өметләр—
Аяклы товарлар,
Мөкатдәс кибетләр!

Күптөрле матдәләр,
Соп-соры йөрәкләр,
Очалар урамнан
Көпчәкле өрәкләр!...

Кайда сез атларым,
Җилләрем, тугаем,
Ташкойма артында
Яшәеш, туганлык!

Матдәләр, җисемнәр,—
Бер дәүләт төзерлек...
Килмешәк, сәрхушләр,
Бер буа бөярлек.
Телефон шаукымы
Үзәкне өзәрлек:

Талкына карт рәссам:
—Калмады яшәрлек!
Буяулар өстенә—
Арбага төярлек—
Коела матдәләр,
Вак-төяк, тәкәрлек!

Бир, Ходам, сабырлык,
Сәяси уяулык!...
Шифалы үләнең
Хисләрне юарлык!
Төшимме суларга,
Кояшка тоташып?!
...Ашыйлар матдәләр
Рухымны, башымны!

## Тыгыз шәһәрләрдә тын кысыла...

Тимер тормыш, ызгыш, башны бәреш,
Бөҗра-бөҗра туыш-чуалыш.
Ялтыравык кара машиналар
Баш өстеннән оча: «чыж» да «чыж»!
Бәхет вәгъдә иткән заман үтте.
Таш бинадай катты вәгъдәләр.
Җил очырган кебек шуышалар
Башын бөккән агач бәндәләр...
Көн арбасын тарта...
Тәртәләре
Кабыргага кергән.
Бил бөгә....
Рух тормышы тамам сыеклана..
Байлар аза... Кулда дилбегә.
Диләр:—Шигырь—хилаф, белем—шикле,
сәүдә хәләл,
Сәүдә—никахлы!
Ярый әле мәйданнарга чыгып,
өеп яндырмыйлар китапны!
Мин оямны ташлап, илгә чыгам—
Җылап-тырнап шигырь язарга.
«Мәңге язам».
Сүзнең мәңгелеген, һич шөбһәм юк,
Кирәк акларга.

Хыял чигенгәндә, сәнгать шулай
Йомылып, шомга батканда,
Коралым—сүз; кальбем—корыч каләм,
Илгә барлык казып тапканым!

Тыгыз шәһәрләрдә тын кысыла...
Җир селкенә...телеп йөрәкне...
Күңел эзли ышанычлы бер йөз—
Тапшырырга өмет-теләкне.



Ләбиб
Лерон

# КЫЧЫТКАН ЧЫПЧЫГЫ

МОҢСУ КОМЕДИЯ

**Ике пәрдәдә**

**Катнашалар:**
Гөлсинә
Рәүф
Фирая
Азат
Рәшидә
Сукбай

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Шәһәр фатиры. Бүлмәдәге заманча җиһазларга карап, хуҗаларның бай тормыш алып баруын чамаларга мөмкин. Пәрдә ачылганда бер почмакта, ноутбук янында, өстәл лампасы яктысында Рәүф утыра. Шактый зур савытлы бик матур гөл күтәреп, Гөлсинә керә.*

Гөлсинә *(«АББА» җырын көйләп)*. «Мани, мани, мани-и-и... Деньги гони-и-и... Аhа-а-а...Оhо-о-о...» Менәтрәк! *(Гөлне өстәлгә куя)*. Бигрәкләр дә яратам инде шушы гөлне... *(Яфраклардагы тузанны сөрткәндәй итә, җырлый)*.

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана
Бәгыръкәем, мине күрде исә...

Хәерле көн, матуркаем, гөлкәем! Сагындым да инде үзеңне, бәгыръкәем!? Хәзер, хәзер... *(Такмаклап көйли)*.«Йөгереп чыктым бакчага, бастым алтын акчага... Гомер буе хезмәт итте-е-ем... Үзебезнен патшага... *(Сабагыннан тотып, кинәт гөлне савыттан чыгара)*. Менәтрәк! *(Савыт төбеннән ниндидер төргәк алып, йөрәгенә якын китерә)*. Исәнгенәмесез, җанкисәккәйләрем?

Рәүф *(пәйда була)*. Дурдом! Ычкынасың бугай инде.

Гөлсинә. Җә инде, һаман-һаман чәпченмә! Утыр әле! Акча санаганны ярата ул! *(Төргәкне сүтә)*. Синең эшләгәнең ашарга да җитми, мин тапканны рәхәтләнеп санап була ичмасам. *(Тәмләп, акча санарга керешә)*. Берәү, икәү, өчәү...

Рәүф. Нәрсә, язуымны, рухи ризыгымны ташлап, синең белән бергә ба-

Ләбиб ЛЕРОН (1961)—*шагыйрь, прозаик, драматург; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил исемендәге премия лауреаты, «Күрше тавыгы», «Сине генә сөям», «Чыктым аркылы күпер», «Сөяксез тел» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

зарга чыгыйммыни инде?

Гөлсинә. Синең ул язган-сызганың... синең ул рухи ризыгың духилык та акча бирә алмый... Сигез, тугыз, ун... Чык базарга! Чәпчергә вакытың калмас... Тугыз.. ун... Ун булды түгелме соң инде?! Ялгыштырдың бит!

Рәуф. Эһ, нәданым!.. нәданым!.. Мин базарда чиләнер өчен тумаган!

Гөлсинә. ...биш, алты... Мин... мин... җиде, сигез... Эшлим бит әле... Тугыз, ун...

Рәуф. Сина ярый... Син... *(Туктаaлып кала).*

Гөлсинә. «Син—җүләр!» дисеңме?! Көләргә булдырасың син... Петросян! Шамкай сыңары! Эш-мазар дисән, ни теләгең, ни рәтең юк... Тугыз, ун...

Рәуф. Сагынам Парижны! Дюма! Мопассан! Эйфель манарасы... Их, дөньясы!..

Гөлсинә. Кит әле, ачуымны китереп тормале! Бер күрмәгән Парижны сагыналар димени, җүләр! *(Кыңгырау тавышы яңгырый).* Бер тынгы юк. Тагын кем инде бу? *(Рәуфкә).* Кая чабасың? Акчаны яшермәдем бит әле! *(Кабаланган вакытта бер кәгазь акчаны идәнгә төшерә).* Булды бугай инде. Бар, ач ишекне! Уф, акчага карап ләззәтләнергә дә ирек бирмиләр...

*Азат керә.*

Азат. Ник озак ачмый торасыз? Качып кына акча саныйсыз мәллә?

Гөлсинә. И-хи-хи... Азат кергән икән! *(Читкә карап).* Акча саныйсыз мәллә, ди... Әүлия! Рәуф, исәнләшергә кайчан өйрәтәсең инде син бу... баламутны?

Азат. Тел туздырып, һаман-һаман исәнләшеп тормыйлар инде, Гөлсинә апа! Рәуф абый белән кичә кич кенә исәнләштем. Шулай бит, Рәуф абый, әйеме?! Менә! Рәуф абый раслады. Синең белән дә, Гөлсинә апа, исәнләшкән идем... өченче көн!

Гөлсинә. Җүнләп исәнләшә дә белмисең... Бүтән кертмим мин сине!

Азат. Кертмим, дигәннән... Тыңлагыз... Бер анекдот сөйлим... Ике бабайның кызлар янына аулак өйгә барышы икән. Берсе икенчесенә әйтә: «Баруын барабыз инде, кертмәсәләр нишләрбез?»—ди. Икенче бабай: «Кертмәсәләр, кайтырбыз да китәрбез... Менә кертсәләр, нишләрбез?!»—ди икән. Ха-ха-ха!... *(Азатка кушылып, Рәуф тә көлә).*

Гөлсинә. Алдан ук әйтеп куям: акча юк! Үзебез дә коргаксыдык. Ипи алырлык та рәт калмады. Бирмиләр бит, Азат җаным, вакытында түләми интектерәләр... И бу кемнәрне... нәчәлестеваны... хуҗаларны әйтәм... Кеше акчасыз ничек яшәргә тиештер...

Азат *(идәндәге акчаны күреп ала, күргәнен сиздерми).* Мине әлегә... әлеге... бу акча дигәнең... кызыксындырмый... Гөлсинә апа. Өйләнәм мин! Котлый аласыз. Туйдым буйдак тормышта-а-ан... Үзем генә белəм хәлкәйләремне!

Гөлсинә. *(Көлеп).* Берүк өйләнә күрмә! Менә мин дә ашыгып өйләнгәнемә үкенеп бетә алмыйм...

Азат. Ә?! Әһә! Әйтсән, каты әйтәсең дә инде, Гөлсинә апа...

Рәуф. Тыңлама син аны, Азат. Син мине тыңла. Менә мин...

Гөлсинә. Азат, кесәндә кулъяулыгың юкмы? Сөртергә әзерлән Рәуф абыеңның күз яшьләрен... Мин—бәхетсез, дип хәзер жылап җибәрәчәк. *(Такмаклый).*

«Әминә елый үкереп,
Тубым суга төште, дип.
Рәуф абыең елый,
Авызкаем пеште, дип...

Рәуф. Менә, менә, күрдеңме инде, Азат? Өйләнмә. Өйләнсәң—бетәсең. Өйләнгәнче, син болай ит... Путевка ал да, Парижга барып кайт! Өйләнгәч, Парижны түгел, Мамадышны да барып күрә алмаячаксың! Их, сагындым Парижны!

Азат. Аңламадым, Рәуф абый... Ничек инде... *(Ижекләп).* Са-гын-дым, Па-риж-ны...

Гөлсинә. Игътибар итмә Рәуф абыена. Вакыт-вакыт шулай тиле-миләләнеп ала ул. Кызың үзе беләме соң әле?

Азат. Ә? Нәрсә ?

Гөлсинә. Кәбестә! Йөргән кызың үзе беләме, дим?

Рәуф. Азатка—азатлык! Тыңлале... Париж турында минем дустым Марсель Галиев ни дип әйтә... «Париж—Европаның таҗы. Аны күргәч, күзгә яшь килде: сокланудан, их, без дә яшибез икән, дигән нәүмизлектән...»

Гөлсинә. Житте инде, шамакайланма! Чистый бер французский Шамкай булдың!

Азат. Өйләнәсе кызны мин кичә генә күрдем әле. Ну матур да инде! Искиткеч! Супер! Фәрештә! Нефертити кебек гүзәл!

Гөлсинә. Ни... ни... нинди Кефир түти кебек?

Азат. Син үзең... Кефир түти! Борынгы Мисыр патшабикәсе ул—Нефертити! Бик чибәр булган... Кичә мин күргән кыз шикелле!

Гөлсинә. Аңлашылды. *(Шаярып)*. Кызыңның исеме ничек сун, Азат бәбкәм?

Азат. Белмим әле, Гөлсинәттәй. Танышырга өлгермәдем.

Рәүф. Мин беләм... Өйләнгәнче Сылу Гүзәлева да Сылу Фәрештәева... Өйләнгәч, барысының да исем-фамилиясе бер—Змея Иблисова!

Азат. Көлмә, көлмә, Рәүф абый. Син күрсәң, үзең дә гашыйк булыр идең аңа! Во! Ммм-а!

Гөлсинә *(Рәүфкә)*. Хәзер! Гашыйк булып кына карасын! Күр әле, күзләрен мутландырып, аяк өсте изри башлады. Оҗмахтагы хур кызлары кочагына кереп бара диярсең... Күрсәтермен мин сиңа матур кызларны! *(Азатка)*. Бар, бар, әллүр моннан! Теләнә салынып торма. Сыптыр! Җә, тумаган тайның билен сындырырсың... Танышмаган-сөйләшмәгән үзе... Мужыт сәвсим телсездер ул синең Ниффер титең?! Мужыт күзләре кылыйдыр... *(Күзләрен кылыйландырып күрсәтә)*. Менә мондый булса, кереп качар тишек тапмыйча йөрерсең... Атлап йөргәнен күрдеңме? *(Титаклап күрсәтә)*. Мужыт аксактыр ул? Өйләнәм-өйләнәм, имеш!

Азат. Ышанмыйсыз мәллә?! Менә күрерсез әле!

Гөлсинә. Туеңа чакырырга онытма. Бөтенесенә дә барабыз!

Рәүф. Мин барысына да баралмам, ахры. Язасым бар! Туй мәҗлесләрендә фикерләрем чуалучан минем...

Азат. Әй... сезнең шуткагыз! Бер генә мәртәбә өйләнәм мин, Алла теләсә!

Гөлсинә. Чистый башны катырдың син безнең! Чыгып китәсеңме инде, юкмы? Элек шундый тыныч яшәп ята идек. Әллә каян күченеп килдегез дә... Авыртмаган башка тимер тарак булдың тәки! Киләсең дә керәсең, киләсең дә керәсең... Керәсең дә акча сорыйсың... Син бит безнең уллыкка алган үги балабыз түгел!

Азат. Ярый әле искә төшердең, Гөлсинә апа. *(Идәндәге акчага текәлә)*. Акча дигәннән... Акча сорар алдыннан бер анекдот! Бер ир хатынына әйтә икән: «Карале, безнең газиз улыбыз минем пыртманиттан акча чәлдергән бит!» Хатыны әйтә:»Нишләп улыбыз алган дип уйлыйсың? Бәлки мин алганмындыр?!»—ди. Ире әйтә: «Юк, син алмагансың... Син тиенәнә чаклы кырып, себереп алган булыр идең... Ә монда бераз калган әле...» Ха-ха-ха!.. Гөлсинә апа, акча биреп тор инде...

Рәүф. Биреп торыгыз инде, диген, агач тел!

Азат. Әйе, биреп торыгыз инде... идәнгә төшкән әнә шул акчагызны!

Гөлсинә. Очлы күз булырсың икән! *(Җәһәт кенә акчаны алып, учына яшерә)*. Безнеке түгел ул! Монда ни... кем әле... шул кергәние... *(Рәүфкә)*. Әйт инде, син дә бар идең лә?!

Рәүф. Әйттең бит үзең... Шул кергәние!

Азат. Әртистләр дә инде сез, кадерле вә гыйззәтле күршекәйләр. Хәтта мине, татарның булачак Райкинын да уздырасыз!

Гөлсинә. Нинди Райкин, нинди Райкин... Карт студент син! Мәңгелек студент! Син артист булганчы, татар театрлары ябылып бетмәгәе... Беләсенме кем кергәние безгә? Рәшидә кергәние, вәйт! Уф! *(Иркен сулыш алып, акчаны халат кесәсенә тыга)*. Шул сорап керер... шуңа бирерсең әле, диде.

Азат. Сорап кердем бит инде менә! Бирегез...

Гөлсинә. Сиңа бирергә димәде ул. Кемгә әле...

Азат. Рәшидәгәме?

Гөлсинә. Әйе. Рәшидәгә. Туктале, Рәшидәгә түгел инде... Нишләп Рәшидә үз акчасын үзенә калдырсын!

Азат. Аңлашылды, бирмисез инде?!

Рәүф. Миндә—юк. Булмагач—бирәлмим.

Гөлсинә. Кеше акчасын бирәлмибез шул, Азат энем.

Азат. Алайса, биш ярым бәрәңге биреп торыгыз. Тагын—полтора суган. Бер стакан тулар-тулмас сыек май да бирсәгез...

Гөлсинә. Күптән шулай диләр

аны. Тулар-тулмас! Баядан бирле—акча, акча... *(Аш бүлмәсе тарафына атлый).* Кредит бирә торган банк түгел лә без...

Азат. Әнинең авылга кайтып китүе—бер дә минем файдага булмады әле, Рәуф абый. Акча житкереп булмый... Гөлсинә апа жаным! Бер-ике... өч-дүрт телем ипи дә эләктер инде! Колбаса белән...

Гөлсинә *(чыга).* Каклаган каз ите дә кирәкмиме?

Азат. Әллә бармы? И-и-и... Каклаган каз итен үлеп-ләр яратам инде мин! Рәхмәт инде, Гөлсинә апа. Күп кирәкми, ике лезвие калынлыгы житә, җәме?!...

Гөлсинә. Сиңа житәдер дә... Ни бит... Ачуланма инде, Азат үскәнем. Кичә, бик каты эч эзләнгәч, сиңа гына дип саклап торткан каз итен чәйнәп-чәйнәп... менә болай иттерреп... суыррып-суыррып... ашап бетердек.

Рәуф. Җә инде, Гөлсинә, ашказаның котыртып сөйләмә. Аның югалтып егыла бит хәзер Азат.

Азат. Садистлар сез! Ярар, хәзергә болары да житеп торыр... Икенче юлы кергәч, берәр тәмле әйбер бирерсез! Кара икра! Кызыл икра! Гөбәдия! Мантый! Алдан ук рәхмәт! Бик зур рәхмәт! Утерический шәп күршеләр сез! Болай булгач, ачтан үлмибез! Чыгып китәр алдыннан тагын бер анекдот! Психиатр кабинетына мүкәләп бер ир заты килеп керә. Авызына нидер капкан бу. Психиатр әйтә: «Ой, безгә мәче килгән түгелме соң?»—ди. Ир заты бер сүз дә әйтмичә, почмакка таба мүкәли. Психиатр аны күзәтә-күзәтә: «Ялгышканмын, маэмай икән ич бу!»—ди.

Ир заты, бер сүз дәшмичә, икенче почмакка таба мүкәли. Психиатр, аңа текәлеп карап тора-тора да, янә әйтеп куя: «Ә-ә, белдем-белдем, керпе икән бит син! Юк, ташбака!»—ди. Ир заты авызындагы электр үткәргеч чыбыкны кулына ала да болай ди: «Мужик, син миңа тыныч кына интернет кертергә мөмкинлек бирәсеңме инде, юкмы?!» Ха-ха-ха!...

Гөлсинә. Нәрсә, безгә психиатр дип төрттермәкчеме инде син?!

Рәуф. Азатка—азык!

Азат. Ә-әй... Кызык түгел сезнең белән! *(Чыгып китә).*

Гөлсинә. Азаттан—гарык! Азат түгел бу—газап! *(Кесәсендәге акчасын башкалары янына куя).* И-и, жанкисәккәйләрем, берегез күрше малаена чүт кенә корбан булмыйча калды. Акча сорап безгә керәләр димени, жүләр! Рәшидәдән сорарга кирәк иде сиңа. Үзе ялгыз, үзе бай! Ә без кем? Без кем, ә?

Рәуф. Мескеннәр без, Гөлсинә, мескеннәр... Акча колына әйләнгән вак бәндәләр... Менә кем без!

Гөлсинә. Әйдә, әйдә, акыллы сүзләр сөйләгән булып кылан... Каян килгән... кем әле... философ сынары! Платон! Сократ! Домкрат!

Рәуф. Домкрат түгел, Демокрит!

Гөлсинә. Тагын кемнәр бар әле? Шопенгауэр! Кант!

Рәуф. Ә син—Плюшкин! Акча! Акча! Акча колына әйләнеп беттең инде. Шул акча дип, байлык артыннан куам дип... Туганнарың белән дә аралашмый башладың... Абыеңның, эненнең хәлләрен белешмәгәнеңә дә ничә ел бардыр инде. Сеңлеңне дә... балдызны әйтәм... тәмам оныттың.

Гөлсинә. Мин түгел, алар мине оныттылар. Онытсалар тагы. Кирәкләре бер тиен! Алардан башка дөньяга киллем, алардан башка да яши алам, шөкер!

Рәуф. Алай димә, алар синең якын туганнарың. Тормышта төрле чак була. Жәл, минем туганнарым юк. Алар булса, минем тормыш бөтенләй икенче төс алыр иде.

Гөлсинә. Мин—бар. Шул житмимени сиңа? Мин синең атаң да, анаң да, балаң да!

Рәуф. Син бит—минем туган түгел. Хатын гына бары! Гап-гади хатын! Үзең беләсең, без бербөтен түгел. Бәхетебезнең бер чите китек. Безне туган итә торган...

Гөлсинә. Торасың да шулай дисең, торасың да шулай дисең...

Рәуф. Бәлки безгә... аерылышыргадыр, ә?! Детдомнан бала алыйк, дидем... Кирәкми, дисең. Болай яшәп булмый бит инде. Һәрхәлдә, мин бүтән болай яши алмыйм. Яшәүнең кызыгы юк. Мәгънәсе бөтенләй калмады. Киләчәк турында уйлыйсы да килми хәтта. Инде кырыкны тутырып киләбез бит. Әле ярый язуым бар да, бердәнбер хыялым бар...

Гөлсинә. Тагын шул Парижмы?

Рәуф. Бала турында хыял...

Гөлсинә. Бала, бала... Нишлим соң, Ходай Тәгалә бирмәгәч?! Бармаган

врач, күренмәгән им-томчы калмады... Гаилә үзегеннән дә хәбәр юк! Бәдбәхетләр! Анда туккән акча...

**Рәуф**. Тагын акча... Шул акча дип уйлаганга балабыз юк безнең... Инде мин ул гаилә үзегенә дә өметләнмим... Дөньядан тәмам читләштек. Матурлыкны күреп, тоеп яшәүдән мәхрүм булып гомер чигәбез. Кем әйтмешли, кырыктан сон—шырыкка... Ә яшисе килә адәмчә итеп, шайтан алгыры!

**Гөлсинә** *(кинәт ярсып)*. Яшә! Бар, башканы тап! Кем сиңа комачаулый!? *(Үксергә тотына)*. И бәхетсез башкайларым...

*Кыңгырау тавышы ишетелә. Рәуф ишек ачарга дип китә.*

**Гөлсинә**. Ачмый тор! *(Акчаны яшерә. Күз яшьләрен сөртә)*. Тагын кем йөри инде... Хәерсез! Ач хәзер!

*Музыка.*

**Рәуф** *(тавышы ишетелә)*. О-о! Кем килгән безгә!? Кычыткан чыпчыгы! Кер әйдә, балдыз, уз түрдән! Какраз сине искә төшереп тора идек. Апаң күз яшьләрен түгеп утыра иде... кадерле вә газиз туганнарын бик сагынып..

*Рәуфтән алда Фирая күренә.*

**Фирая** *(көмәнле)*. Сәлам! Көтмәгән идегезме?

**Гөлсинә** *(Фираяның корсагын күреп)*. Аба-ау! Полный пакет субсидии! Моңа гаилә үзеге дә, акча да кирәкми. Базарга барып, карбыз йотып кайттың мәллә?

**Фирая** *(кочаклашып күрешә)*. Исәнме, апа? Нихәл, жизни! Уф, ардым! Расих абыйлардан килеш. Сезгә кү-ү-үп итеп сәлам тапшырырга куштылар. Расих абый суткалы эштә икән. Минем белән килә алмады. Сезгә диган күчтәнәчләрне жизни белән барып алырбыз инде. Име, жизни?! Абау, апа, ник жылыйсың? Жылама! Мине күрдем дигәч тә... И-и, сагынгансыздыр шул. Мин дә бик сагындым үзегезне!

**Гөлсинә**. Жизнәң... аерылышабыз, ди.

**Рәуф**. Егерме ел бергә торабыз, аерылышып булмый. Шуңа жылый.

**Фирая**. Ничәнче тапкырын аерылышасыз инде сез, апа? Йөзгә тулдымы әле, жизни? И күнелледер ул аерылышабыз дип жылап яшәүләре! Кияүгә чыксам, мин дә сезнең кебек яшәр идем, Алла теләсә! Аерылышасын—кавышасын, аерылышасын—кочаклашасың... Идиллия!

**Гөлсинә**. Ә сиңа кавышырга да, аерылышырга да кирәкми. Син... Абау... Ирсез бала табарга жыенасың мәллә?

**Фирая**. Ә нигә?! Барыбер табак-савытны юасы бит әнигә! Кызык әйттемме? Минем сүзләр түгел... Бер балалар шагыйре шулай дип язган... Борчылма, апа. *(Көмәненә ишарәли)*. Моны... төшерергә килдем мин!

**Рәуф, Гөлсинә** *(икесе бергә)*. Нәрсә дип әтисез бала үстерергә...

**Рәуф**. Син нәрсә, Фирая! Үз акылыңдамы син, кычыткан чыпчыгы?

**Фирая**. Жизни! Мин кычыткан чыпчыгы түгел... (*Корсагын сыйпап*). Мин хәзер—сумкалы кенгеру! *(Кенгеру кебек сикергәләп йөри.)*

**Рәуф**. Карале, кенгеру, зоопарктан качмагансыңдыр бит?!

**Фирая**. Юк, циркта качтым мин, жизни. Сез белмәгәч тә, безнең авыл циркка әйләнде бит хәзер. Алкаш клоуннар, жонглер хатыннар, ләмдә йөзүче дуңгызлар күрәсегез килсә, безнең авылга кайтыгыз. Билет бәясе—бушлай. Рәхим итегез! *(Кәнәфигә утыра)*. Эш юк, бәйрәм күп. Чәй урынына—аракы... Диңгез—тубыктан... Пир на весь мир!

**Гөлсинә**. Әткәй-әнкәй булмагач, тәмам юлдан язгансың икән, сеңлем. *(Фираяның көмәненә ымлап)*. Атасы кем? Безнең авылныкымы? Мин беләммме ул кешене?

**Фирая**. Син түгел, үзем дә белмим, апа. Караңгы иде. Әллә Касыйм, әллә Вәсим... Әллә урыс, әллә әрмән... Туктагыз әле, сорау яудырып тинтерәтмәгез! Ашарга бирәр нәрсә бирегез! Безнең ашыйсы килә!

**Рәуф**. Карале, Фирая, әрмән дигәннән... Бездә әрмәннәр ашый торган ризык юк бит. Корсагыңдагы әрмәнчик, Ашотикны әйтәм, безнең токмачлы ашны яратыр микән? Бәлки ана шашлык белән коньяк кирәктер?!

**Фирая**. Жизни, борчылма, ни бирсәгез, шуны ашыйбыз, шуны эчәбез. Талымлап тормыйбыз—үзбәк пылавын

да яратабыз, грузин хачапуриен да сыптырабыз, украин салосыннан да баш тартмыйбыз. Урысның тозлы кәбестәсен урабыз гына! Мариның гөмбәсен, чуашның самагунын, башкортның балын...

**Гөлсинә.** Гүләйт итеп тә карагансың икән, ыштыр бит! Авылга кайтырбыз дип кенә торадырыек... Кеше күзенә күренерлегем калмаган икән... Булсаң да булырсың икән адәм гыйбрәте! Дружба народов! Тефү!

**Фирая.** Ашатасызмы сез кадерле туган-тумачагызны, әллә юкмы?

**Рәүф.** Хәзер, балдыз. *(Фираяның корсагына карап елмая).* Хәзер, хәзер, хөрмәтле вә гыйззәтле төрле милләт вәкилләре... *(Аш бүлмәсенә китә).*

**Фирая** *(кычкырып).* Кичәге аш булса да ярый!

**Гөлсинә.** Кичәге ашны ашыйсың килсә, иртәгә килергә иде, дивана. Тибәме?

**Фирая.** Кем?

**Гөлсинә.** Балаң кыймылдыймы, дим?

**Фирая.** Ә-ә, моны әйтәсең икән... Тибә. Кушаяклап тибә! Эчне тишеп, күлмәкне ертып чыкмаса ярый инде. Грузин булса, алар шундый халык... *(Лезгинка биеп ала).* Ярар, булды... Цирк тәмам!

**Гөлсинә.** Төшерәм, дип ялгышмыйсыңмы, Фирая сеңлем?

**Фирая.** Апа, атасына... аталарына кирәкмәгән бала белән кая барыйм мин? *(Тирә-ягына карап).* Ярый сезнең бөтен җирегез җитеш. Минем бит шушы күлмәгемнән башка бүтән яңа киемем дә юк. Кышкы сапожки бар икән тагы! Жизни кухняга кереп батты. Иртән ашамаган иде мәллә?

**Гөлсинә.** Рәүф! Газ плитәсен табалмыйсың мәллә, тинтәгем минем? Акылсызкаем!

**Фирая.** Шундый яратып әйттең жизнигә. Рәхәтләнеп спектакль карармын, дигән идем... Аерылышып уйнамыйсыз инде болай булгач...

**Гөлсинә.** Кем белә, кем белә...

**Рәүф** *(тәлинкә күтәреп чыга).* Бер Ходай белә! Микроволновкада жылыттым. У-ух, исе дә исе... Специфический!

**Фирая.** Жизни, апа, ачуланмагыз инде. Миңа аш кәстрүле белән кирәк!

**Гөлсинә.** Казаны белән түгелме?! Бу сиңа ресторан мәллә? Бездә Әндри казнасы юк!

**Рәүф.** Әйе шул, шул арада бөтенләй истән чыккан. Сез күбәү бит әле—бер ясле! *(Кире кереп китә).*

**Гөлсинә.** Фирая, акыл өйрәтергә җыенмыйм, име. Тагын бер кат уйла. Уйла, сеңлем!

**Фирая.** Уйласы уйланган инде, апа... Временное увлечение, кесерева сечение и... гуляй, Фираюшка! Пролетарий всех стран, соединяйтесь! Мама, чаю, мама, чаю, мама, чаю не хочу...

**Гөлсинә.** Әллә нәрсәләр беләсең син, сеңлем.

**Фирая.** Замана җимеше мин, апа, замана җимеше! Гламур кыз! Шундый сүз дә беләм әле мин!

**Гөлсинә.** Гыламур... Корсаклы кыз дигән сүзме инде ул?

**Фирая.** Безнеңчә тәти кыз була инде ул, апа. *(Урыныннан тора).* Аш җылынганчы, әйләнеп керим әле. Мин хәзер! *(Чыгып китә).*

**Рәүф** *(аш бүлмәсеннән чыга).* Прошу к столу!

**Азат** *(керә).* Рәхмәт, рәхмәт! Әле генә ашаган идем... Сез бик кыстагач, тагын ашамый булмас...

**Рәүф.** Туктале, күрше, сиңа түгел әле бу!

**Гөлсинә.** Бар, бар, чык... Безнең бернәрсәбез дә юк! *(Азатны куа).*

**Азат.** Чыгам, чыгам... Карагыз әле, нәрсәгә кергән идем әле мин? Ярар, исемә төшкәч, тагын керермен... *(Чыга).*

**Рәүф.** Кая китте, балдыз?

**Гөлсинә.** Ашың да җитмәс бу гыламурга, акчаң да... Чыгып китте әле. Хәзер керәм, диде.

**Рәүф** *(ишек тарафына карап).* Да-а... Исәнме, кода-а... Авыл яшьләренә дә шәһәр чире йокты. Бетте авыл, бетерделәр! Пычракка батты дөньясы! Их, сагындым Парижны! Шундый сагындым!

**Фирая** *(керә).* Тагын бер кат—сәлам!

**Рәүф** *(Гөлсинәгә).* Миңа ичмасам балдыз—ике мәртәбә исәнләште!? Азат түгел инде, әйеме?

**Фирая** *(артына борылып).* Заходи, дядя Коля! Заходи, гостем будешь! Тут все свои!

*Тартынып кына, Сукбай керә. Гөл-*

*синә, авызын ачкан килеш, катып кала. Рәүф тә шок хәлендә басып тора.*

Сукбай. Здрасте!

Фирая. Дядя Коля, болар—минем бик якын кешеләрем! Таныш бул, бу—минем кадерле апам Гөлсинә, ә монысы—минем бик шәп жизнәм! Рәүф исемле. Ә бу, таныш булыгыз—дядя Коля. Мин—Фирая булам инде, дядя Коля, бая әйткән идем бугай. Ашың жылындымы, жизни? Без ашарга әзер!

Гөлсинә. Ме... ме... менәтрәк! Нишләвең бу, Фи... Фи... Фирая? *(Кашына башлый).* Кемне алып кердең син? Бетләтеп үтерәсең бит безне!

Рәүф. Балдыз... Кычыткан... чып... чып... *(Үзе дә сизмәстән, кашына).*

Сукбай. Может мне лучше уйти... Я потом... зайду...

Фирая. Дядя Коля! Потом суп с котом... Ашагач китәрсең! Сине куып чыгарган кеше юк монда. Шулай бит, жизни?! Име, апа?!

Гөлсинә. Китәм, ди бит. Ник үтереп кыстыйсың кешене. Китсен!

Азат *(керә).* Тук, тук! Ишегегез ачык... *(Сукбайны күреп).* Гөлсинә апа әйтмешли, менәтрәк! Кунакларыгыз бар икән... *(Рәүфкә).* Туганнарыгыз мәллә, Рәүф абый?

Гөлсинә. Әһә, туганнан туганнар... Әтиләр бер—бабай башка!

Азат *(Сукбайга карап).* Әтиегез мени? Исәнмесез, бабай! *(Күрешә).* Ә бу матур кыз-хатынны кем дип белик? Исемең ничек синең, туташ-ханым?

Фирая. Думбыра! Сез дип сөйләш, деревня!

Азат. Сез... исәнмесез, Думбыра апа... жаным? Исемегез бик оригиналь! Таныш булыйк: минеке—Барабан!

Рәүф. Полный квартет. Азат, син нәрсәгә кердең?

Азат. Ашарга! Матур гына сөйләшә идегез бугай... бүлдердем, ахры?!

Гөлсинә. Азат! *(Пауза.)* Акча юк!

Азат. Кирәкми миңа акча. Миңа тоз кирәк! Бер кашык... чүмәкәем!

Гөлсинә. Рәүф, биреп чыгар инде шуңа. Кабы белән тоттыр—ашасын туйганчы! Лавр яфракларын да бир!

Рәүф. Анысы нигә тагы?

Гөлсинә. Бүтән кереп йөдәтмәс өчен!

Рәүф *(кухнядан җәһәт кенә әйләнеп чыга).* Мә! Башка вакытта иркенләп сөйләшербез, яме.

Азат. Рәхмәт, Рәүф абый! Рәхмәт, Гөлсинә апа! Баегач, кертермен. Чыгып киткәнче, бер анекдот!

Гөлсинә. Анекдот капчыгы булдың инде тәки... Житте, сөйләмә!

Рәүф. Сөйләсен инде әйдә... Янадан тиз генә кермәс бәлкем...

Азат. *(Китешли, Фираяга).* Карале, Мандолина, ошадың син миңа... Гутбай, мерсимадам! Чао! *(Чыгып китә).*

Сукбай. Давайте-ка, я тоже уйду...

Рәүф. Давай, давай... Әллүр иттек!

Фирая. Нет! Апа! Жизни! Бу бит—дядя Коля! Дя-дя Ко-ля бу!

Гөлсинә. Сеңлем, чат саен алар—дядя Колялар, дядя Ванялар! Әйдә, ташы барысын да безнең өйгә! Сыйла, кунак ит! Урын иркен! Зал зур—бетләр сугыштырырга... Баланың атасы да бу түгелдер бит?!

Фирая. Ни булды сиңа, апа? Син элек мондый түгел идең! Минем кебек, сезнең кебек үк кеше бит ул дядя Коля!

Рәүф. Әйдә, ярар, ашасын инде...

Азат *(керә. Нәрсәдер сорамакчы була, исенә төшерә алмый).* Әй, оныттым! *(Чыгып китә).*

Сукбай. Дорогуша... Фираюшка... Может не надо...

Гөлсинә. Дөрес! Не надо!

Фирая. Дядя Коля, дим! Ашыксаң, әнә кресло, утырып садись! Сине мин кунакка чакырдым. Жизни аш жылытты—безнең өчен. Шулай бит, жизни?! Минем апа ашны тәмле итеп пешерә белә ул! Әйдә, дядя Коля, мактап ашыйк әле апаның ашын...

Рәүф. Апаң түгел, мин пешердем.

Фирая. Ах, да, жизни пешергән!

Сукбай. Как скажешь, как скажешь... Вообще-то, мне торопиться некуда... Так вкусно пахнет, а ложки у вас есть?

Рәүф. Есть аш чүмече, то есть половник. Надо?

Гөлсинә. Барыгыз җәтрәк кухняга! Башым әйләнә, күнелем болгана башлады...

Фирая *(Гөлсинәне кочаклап ала).* Апа жаным, син дә балага узмагансындыр бит?!

Гөлсинә. Вон кухняга! Барыгыз,

дим, кире уйлаганчы! Кулларыгызны юыгыз! Шуннан чыкмагыз!

Фирая. И, апам, кадерлем минем, бик зур рәхмәт сина, яме! Рәхмәт, жизни, сина да! Сезгә дип килә идем... Күрәм—ишегалдыгыздагы эскәмиядә дядя Коля моңаеп утыра... Дядя Коля икәнен белми идем әле очрашканчы... Исәнмесез, минәйтәм... Мин ишегалдыгыздагы бөтен кеше белән дә исәнләштем үзе...

Рәүф. Нәрсә, әле монда бөтен ишегалды да керәчәк мәллә?

Гөлсинә. Фирая! Марш!

Фирая. Аңладым, апа. Без инде ашый башладык. Әйдә, дядя Коля!

Сукбай. Заранее большое спасибо вам! *(Аш бүлмәсенә кереп китешли).* Благодарю. Мир этому дому. Все у вас будет хорошо!

Рәүф. Менә сина—кычыткан чыпчыгы! Һава торышын үзгәртергә жыена бу... Дядя Коля, дип кенә тора—бертуган абыйсы диярсен!

Гөлсинә. Сукбае чыгып киткәч, иманын укытам мин аның! Өйгә килеп керергә өлгермәде—хужа булып алды. Вредитель!..

Азат *(керә).* Исемә төште! Ни... Сезнең...

Гөлсинә *(Азатның өстенә бара).* Террорист!.. Колорадо жугы!..

Азат. Әй, тагын оныттым! *(Чыгып тая).*

Гөлсинә. Безне бөлдерергә килгән... Ә син, туганнарың белән аралашмыйсың, дисең... Әнә, күрдеңме берсен! Дәшми калсак, шәһәрдәге бөтен бомж хәзер безнең туганга әйләнәчәк!

Рәүф. Дядя Коля димәктән... Чырае бер дә урысныкына охшамаган...

Гөлсинә. Таптың сүз... Бомж—бомж инде, аны урыска, татарга аерып карыйсы юк. Аларның барысының да чырае бер үк. Бомж бит ул бывший интеллигентный человек дигәнне аңлата. Бәлки бу адәм дә...

Рәүф. Алай дип кистереп әйтмәс идем...

Гөлсинә *(Аш бүлмәсе ягына ишарәли).* Өеңдә... бардак... Ә син фәлсәфә сатып торасың! Мә-га-нә-сез! Бар лутчы, теге Субсидиягә әйт, табак-савытларны өеп калдырмасын—әйбәтләп юып, сөртеп куйсын! Сукбаена ялгыш ышкыла күрмә—бете йогы бар. Мин ышкылмаган килеш тә кычытына башладым инде. *(Рәүф аш бүлмәсенә кереп китә).*

Рәшидә *(керә).* Сез нәрсә, әллә хәзер ишегегезне бикләмисезме? Шар ачык! Аяк киемнәрегезне караклар, бомжлар чәлдереп китмәсен.

Гөлсинә. Без бомжлардан курыкмыйбыз. *(Аш бүлмәсе ягына карап, кычкырыбрак әйтә).* Хәзер алар безгә туганнардан да кадерлерәк!

Рәшидә. Кунакларыгыз бар мәллә?

Гөлсинә. Синнән бер дә кеше өзелми бит. Менә без дә калышмаска булдык әле.

*Фирая, Сукбай һәм Рәүф аш бүлмәсеннән чыга.*

Рәшидә *(Сукбайны күреп, гажәпләнүе чиктән аша, чиркануы йөзенә чыга, читкә тайпыла).* Ба! Приют ачтыгыз мәллә?!

Гөлсинә. Ишетмәдеңмени, бүген бит бөтендөнья сукбайлар көне! Бездән соң хәзер сина керәләр. Өстәлең әзерме?

Рәшидә. Бәй, сукбайлар көне дә бармыни ул хәзер? Бер дә ишеткәнем юк иде.

Сукбай *(күрешмәкче булып, Рәшидәгә кулларын суза).* Здрасте, мадам!

Рәшидә *(жирәнеп читкә тайпыла).* Бик исән әле! Күрешеп тормыйк! Абзый, воздушный поцелуй гына, яме...

Сукбай. Вы очень красивая женщина! У вас глаза добрые. И вообще, вы—прелесть! Я вас....

Гөлсинә. Үзе бомж булса да, хатын-кызга комплиментлар әйтә белә, мәхлук! Она у нас еще и добрая, и щедрая, и гостеприимная! И квартира у нее большая, и кастрюля... Ой, как она гостей любит! Рәшидә, чакыр инде кунакларны үзенә! Без сыйладык, хәзер синең чират! Первый—бездән, второй—синнән!

Рәшидә. Бомжлар сыйлап ятасым гына калган иде... Аллам сакласын!

Фирая. Сәлам, Рәшидә апа! Мине танымадың мәллә?

Рәшидә. Бәррәч! Фирая түгелме соң син? Котымны алдың! Мин бит сине дә бомж дип торам. Саумы, сеңлем? *(Көмәненә ишарәләп).* Кай арада өл-

герден?

Фирая. Күп сүз... чүп сүз, диләр безнең авылда, Рәшидә апа. Базарда тоттым да карбыз йоттым! Жизни! Кырыну приборларың кайда синең?

Рәүф. Нәрсәләр, дисең? Нәрсәне кырасыз тагы? Кайда дип... Шунда инде—урынында, ваннада! Ә нигә?

Гөлсинә. Әллә, Ходаем...

Фирая. Әйдә, дядя Коля... Гламур егет ясыйбыз хәзер синнән...

Сукбай *(кыенсынып)*. Может не надо... Утром только помылся...

Рәүф. Минем бритва, минем «Жиллет»...

Рәшидә *(йөзен чытып)*. Юынгансыңдыр инде, әйе! Йөз кат юындырсаң да, кеше ясап булмый синнән... Гөлсинә, нәрсә карап торасың, кертмә моны ваннаңа!

Гөлсинә *(Фирая белән Сукбайга каршы төшә)*. А нука, отойди! Только через мой труп! Фирая! Нишләвең бу?! Остановись! Тукта!

Рәшидә *(Гөлсинә янәшәсенә басып)*. Въезд запрещен! Тут—шлагбаум! Дверь там, скатертью дорога1

Сукбай. Да-а... Ничего не поделаешь... В России живем: куда не глянь, везде шлагбаумы. Спасибо за гостиприемство! Живите с Богом! Мир этому дому, все у вас будет хорошо! И дети, и все...

*Сукбай акрын гына чигенә.*

Фирая. Апа! Рәшидә апа! Китегез әле юлдан! Шампуныгыз бармы, жизни?

Азат *(керә)*. Шампунь, дигәннән...

Рәүф. Сиңа нинди шампунь кирәк, Фирая: майлы чәч өченме, әллә кавыклы чәч өченме?

Азат. Шампунь, дигәннән... Авыз чайкарга бирәр стакан шампанскиегыз юкмы?

Рәшидә. Бар, бар! Боларда юк әйбер генә юк!

Гөлсинә *(Азатка)*. Үтерәсең бит инде, теләнче тамак! Нету ничего, нету!

Азат. Күкәегез генә бардыр әле... Күкәй, дигәннән... Бер анекдот! СССР заманы.... Бер авыл карты кибеткә килгән... «Кызым, миңа носки бир әле»,—дигән ул сатучыга. «Күкәйгә генә бирәбез»,—дигән сатучы кыз. «Ә миңа аякка кирәк иде шул!»—дигән карт... Ха-ха-ха!... *(Чигенә-чигенә)*. Ярый, ярый алайса... Күкәйгә бераздан керермен... *(Чыгып китә)*.

Гөлсинә. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорар, диләр... Шушы буладыр инде ул! *(Рәшидәгә)*. Син дә яхшыатланып тормасана! Бомжны үзеңә алып кер дә—юындыр! Безәшаттык, мунча кертү—синнән! С легким паром!

Фирая. Сез ни сөйлисез, ә? Ни әйткәнегезне колагыгыз ишетәме? Безнең кебек үк кеше бит ул дядя Коля! Кемнәрнеңдер газиз баласы! Сездән, миннән аермасы шул: дядя Коля сугышта булган, михнәтләрне күп күргән! Ә сез... Их, әйтер идем инде...

Гөлсинә. Кибет янындагы сугыштамы?! Ну и что! Ул нәрсә сөйләмәс! Сугыштан исән калган икән, шуңа сөенеп яшәсен. Сугышырга кем кушкан—шул ашатсын! Мин кушмадым...

Рәшидә. Дөрес әйттең, Гөлсинә. Яшәсен кешечә, яшәсен безнеңчә! Эшләсен! Ничу шакшыланып йөрергә! Таптылар бер кызык: эчәләр, эчәләр дә урамда яши башлыйлар... Рәхәт, бер кайгысы юк, уйларга кирәкми. Бог дал, Бог взял. Яшәү байдан, үлем Ходайдан!

*Сукбай бүтәннәргә сиздермичә генә чыгып китә.*

Фирая. Сез, сез... Әллә кемнәр сез! Дядя Коля, әйдә, кыенсынып торма... Сугыштагы кебек батыр бул! *(Як-ягына карый, артка борыла)*. Дядя Коля-я-а-а!.. *(Көмәнен тотып, чыгып йөгерә)*.

*Ут сүнеп ала.*

*Шул ук бүлмә. Гөлсинә белән Рәүф.*

Рәүф *(эзләнә)*. Син күрмәдеңме?

Гөлсинә. Ни икәнен әйтеп сөйләш. Нәрсә эзләгәнеңне каян белим мин...

Рәүф *(хатыны янына килеп)*. Бүре башың!

Гөлсинә. Абау! Котымны алдың!

Рәүф. Тукай сарыгы мин... Бүре башың эзлим. Бә-ә-ә-ә!

Гөлсинә. Сарык икәнеңне беләдерием. Әмма Тукай сарыгы икәнеңне

белмидерием монарчы. Бүре башы белән нишлисең? Аш пешерәсең мәллә?

Азат *(керә).* Кеше котыртып, тагын ашау турында сөйләшәсезме?

Гөлсинә. Аза-а-ат! Югал күз алдымнан!

Азат. Хәлегезне белергә генә кергәнием... Кыстамагач, утырып тормыйм инде алайса... Берәр нәрсә кирәк булса, миңа да керегез... Тартынып, кыенсынып тормагыз... Мәрхүм бабай әйтмешли, бары—бергә, югы—уртак! *(Чыга).*

Гөлсинә. Геморройдан да хужы бу мөртәт!

Рәүф. Гөлсинә! Уен-муен түгел... Пинжәкне күрмәдеңме? Бер сәгать буе табалмый интегәм бит инде... Чалбар да юк!

Гөлсинә. Астыма кыстырып утырган идем менә... Каян белим! Башымны катырмале!.. *(Кинәт урыныннан сикереп тора).* Стоп! Пинжәк, дисеңме?! Чалбарың да юкмы? Трусикларың урынындамы? Бар, кара!

Рәүф *(кинәт башына сугып ала).* Һоп-па! *(Ашыгып, күрше бүлмәгә кереп китә).*

Гөлсинә. Менә сиңа—корсаклы Хәйрия фонды! Мать Тереза! Шуның гына эше бу! Чарасын күрмәсәк, таратып бетерәчәк бөтен әйберне...

Рәүф *(кәгазь кисәге тотып чыга).* Послание из космоса! Галәмнән безгә хәбәр бар! *(Укый).* «Жизни! Апа! Жизнинең кайбер киемнәрен алдым. Кем өчен икәнен әйтмим. Борчылмагыз, бурычлы булып калмам. Сезне яратып: Кычыткан чыпчыгы.» Йә, ничек? Аңлашылдымы?

Гөлсинә. И Ходаем! *(Кабаланып, күрше бүлмәгә кереп китә дә, гөл күтәреп, шундук кире чыга. Гөл төбеннән акчаны алып, тиз-тиз санарга керешә).* Бер, ике, өч.... Ярабби, Ходаем!.. ...дүрт, биш... *(Санап бетергәч, лып итеп урындыкка утыра. Бераз паузадан соң).* Исән! *(Башын өскә күтәреп).* Рәхмәт, Ходаем! Яхшылыгыңны мәңге онытмам... *(Рәүфкә карап).* Бу синең трусик-прусик кына түгел... Тагын саныйм әле! Берәү, икәү, өчәү... *(Иреннәре генә кыймылдый).* Аллага шөкер, касса исән!

Рәүф. Банкка салган булсак, бу хәтле өтәләнмәс идең!

Гөлсинә. Яңа машинага җыябыз бит! Иртәгә дөлфәт дисәләр, нишләрсең?!

Рәүф. Дөлфәт түгел, дефолт!

Гөлсинә. Беләм лә! Шул дефолт аркасында банкта ничә тапкыр акчабыз акырып янды. Болай, ичмасам, җан тыныч! Ул-бу килеп чыкса да, хет, берәр нәрсә алып өлгерергә була... Уф, котым ботыма төште пәрәме! Ничек котылырга бу... каламбур... галәмбур... кызыйдан?

Рәүф. Гламур кыз...

Гөлсинә. Беләм лә! Сиңа әйтәм, әй, Тукай сарыгы! Башыңны эшләт бераз. Бетәбез бит!

Рәүф. Карап, тыңлап торам да... тагын бер карап куям. Син бит кайчандыр үзең дә нәкъ Фирая кебек идең!

Гөлсинә. Яшь чагында һәркем яшь була. Картайдыммыни хәзер? Нәрсәм ошамый?

Рәүф. Яшең турында әйтмим лә! Кешелеклерәк идең син элек. Ярдәмчел идең. Хәтереңдәме, бер сәрхуш абзый машина астына чүт эләкми калгач, без, аны култыклап, өенә кадәр озатып куйдык. Мәтрүшкәле чәен дә эчтек әле. Чәй эчкәндә генә белдек: абзыйның хатынына бик катлаулы операция ясаганнар икән... Хатыны исән калу шатлыгыннан бер чүлли эчеп бетергән... Шул чакта башта син әйткән идең—әйдә абзыйга булышыйк, дип... Идәннәрен дә юып йөрдең... Исеңдәме?! Күңелең матур булганга яраттым да инде мин сине...

Гөлсинә. Яши-яши күңел ямьсезләнергә дә мөмкин. Тормыш үзгәртә ул кешене. *(Акчаны кабат гөл төбенә яшерә).* Син дә бит элеккеге Рәүф түгел хәзер... Тукай сарыгы!.. *(Гөлне күтәреп, икенче бүлмәгә кереп китә).*

Рәүф *(ачуы килеп).* Ә син... ә син... шул сарыкның хатыны! Их, дөньясы!.. Башны кая куясы...

*Кыңгырау тавышы. Рәүф ишеккә таба китә. Тынлык.*

Гөлсинә *(икенче бүлмәдән чыгышлый).* Йә теге теләнче тамак бу, йә теге хәйрия фонды... Тагын сукбаен ияртеп кайтмаса ярый инде...

Рәшидә *(керә).* Төне буе төшемә кереп интектерүе җитмәгән, инде тагын ишегалдында очрады .

Рәүф. Кем турында сүз бара, Рәшидә?

Рәшидә. Кем турында булсын инде—дед Мазай турында!

Гөлсинә. Нинди дед Мазай?

Рәшидә. Теге... беркөнне сездә күргән бомж инде—дядя Коля! Фираяның сукбае! Текәлеп карап калды миңа, минсиңайтим... Берәр тәңкә бирим мәллә дигәнием... Әй, минәйтәм, бетмәс монда хәерчеләр. Атлаган саен бит алар хәзер. Бет шикелле бөтен җирне бастылар. Хөкүмәт тә шуларны берәр кая олактырмый ичмасам! *(Үзе дә сизмәстән кашынып куя).*

Гөлсинә. Абау, Ходаем, әллә бет йоктыргансың инде?! Шатыр-шотыр кашына башладың... Бик селкенеп сөйләшмәле. Бетең идәнгә коелмасын тагы. Рәүф, дим, якын торма Рәшидәгә—читкәрәк кит!

Рәүф. Сүзләреңне үлчәп сөйлә инде бераз. Безгә хәзер бет кенә җитмәгәние!

Рәшидә. Ие, ие! Аллам сакласын, диген! Ул арада бет йога димени? Мин бит ул ишегалды карачкысына терәлеп басып тормадым. Ерактан ук күрдем дә, янында выжт итеп үттем дә киттем.

Гөлсинә. Карале, Рәшидә, әллә йортка кертәсеңме үзен? Юындырасың, киендерәсең дә менә дигән кеше итәсең... Эт асраганчы...

Рәшидә. Эт асраганчы, бет асра, дисең мәллә?

Рәүф. Шәп фикер! Берьюлы ике куян атасың, Рәшидә... Җәмгыятькә дә файда, үзеңә дә!

Рәшидә. Миңа нинди файда?

Гөлсинә. Бәй, ирле буласың!

Рәшидә. Сез нәрсә! Көлмәгез әле миннән. Фатирымны приют та, картлар йорты да итәргә җыенмыйм... Башыма тай типмәгән әле! Үзегез кертегез фатирга. Сугышта катнашкан ди бит—льготасы булыр!

Гөлсинә. Безгә мать-одиночка да бик житкән! *(Баш түбәсенә күрсәтә).* Менә моннан льготасы!

Азат *(керә. Хатын-кыз күкрәге төшерелгән алъяпкыч кигән. Башында—повар башлыгы.)* Бик тәмле иттереп төче коймак пешермәкче идем... Он юклыгы исемә төште! Аптырагач, табада ит кыздырырга булдым... Ярты кило гына итегез юкмы? Сыер йә сарык ите булмаса, куян ите дә ярый... Алдан ук әйтеп куям: елан ите кирәкми!

Гөлсинә. Саранча да болай ук куркыныч түгелдер, билләһи... Рәүф! Китереп бир миңа чебен үтергечне. Бәреп үтерә-ә-м мин моны!

Азат. Нервы беткән бит синең, Гөлсинә апа... Ручны бүлнискә барып ят! Рәүф абый, сузмагыз... Кеше бүген бар ул, иртәгә юк, дигәндәй...

Рәүф. Азат, күрше булсаң, күрше бул... Бер ярты сәгать үзеңнән ял иттер безне, зинһар!

Азат. Күрше хакы—Тәңре хакы, диләр... Аңладым! *(Чыгып китешли).* Ярты сәгать, диденме әле?! Пока!

Гөлсинә *(башын тотып).* Ходаем, тыныч тормыш бир!

Рәшидә. Алай икән... Күршегез мут малай икән... Чәй эчеп тормыйм—кыстамагыз! Үзегез парлашып кич утырырга кирәгез. Бер кило көнбагыш алдым. Рәхәтләнеп идән чүпләрбез! Гәп сатарбыз. Таныш-белешләрне чәйнәп алырбыз.

Гөлсинә. Чакыруына рәхмәт. Үзебезнең тузан суырткыч белән керикме?

Рәүф. Мин—кермим! Этеңнән куркам!

Рәшидә. Эттән курыкма син, кешедән курык! Кеше—иң куркыныч җан иясе! Эт нәрсә ул, эт—эт инде... Сатана—друг человека!

Гөлсинә. Алай димә! Кеше—кешегә дус һәм иптәш! Кеше—җирнең чәчәге!

Рәүф. Әйе, кеше—чәчәк кебек: үзе кайда, исе дә шунда.

Рәшидә. Әллә тилерә башладыгыз инде? Сез тәмам диванага әйләнгәнче чыгып китим әле тизрәк! *(Чыгып китә).*

Гөлсинә. Уф! Туйдым бүген кешедән. Беркемне дә күрәсем килми.

Фирая *(керә).* Мине дә күрәсең килмиме, апа?

Гөлсинә. Сине дә.

Фирая. Мин китсәм... сагынырсың әле, апа. Сагынырсыз!

Гөлсинә. Сагынасы килә башлады инде.

Рәүф. Гөлсинә! Җүләр сатып утырма әле. Син нәрсә!

Фирая. Жизни! Апа! Миндә бер яңалык бар: поликлиникада булдым, тагын бер тапкыр анализлар тапшырдым. Иртәгә минем язмыш хәл ителәчәк! *(Ашыгып, икенче бүлмәгә кереп китә).*

*Рәүф белән Гөлсинә, бер-берсенә*

*карашып, Фирая кереп киткән бүлмәгә текәләләр. Ут сүнә.*

*Бераздан ут яна. Шул ук бүлмә күренеше.*

*Фирая бер ялгызы моңланып утыра.*

Фирая *(жырлый, Азат керә, сиздерми генә тыңлап тора).*

Бакчадагы гөлләремнең
Шау чәчәк аткан чагы.
Минем газиз башкаемның
Уйларга баткан чагы...

Йөгрә-йөгрә бара идем
Хыялым каршысына.
Ничекләр генә түзәем
Язмышым ачысына.

Бакчамдагы гөлләремнең
Шинә бит чәчкәләре.
Мөлдерәмә күзләремнән
Ага бит яшькәйләрем...

Йөгрә-йөгрә бара идем
Хыялым каршысына.
Ничекләр генә түзәем
Язмышым ачысына...

И Ходаем, сабырлыклар бир миңа! *(Куллары белән йөзен каплый).*

Азат. Тук-тук! *(Кыңгырау «төймәсенә» баскандай итә).* Челтер-пелтер! Ишек ачык икән... Бигрәк матур итеп жырладың, туташ... ханым... Күптән мондый жыр тыңлаган юк иде!

Фирая *(күз яшьләрен сөртә, кинәт шат күңеллегә әйләнә).* Сәлам, Барабан! Шикәр кирәкме, борычмы? Әйдә, варенье белән сыйлыйм үзеңне!

Азат. Шикәр кирәкми, борыч ашамыйм... Мин Карлсон түгел. Вареньега исем китми. Миңа... син кирәк!

Фирая *(күмәненә ишарәләп).* Без икәү бит!

Азат. Миңа димәгәе! Хет өчәү бул! Корсагыңа караганда, бер көтү булмагае әле!

Фирая. Шаккатасы юк. Безнең нәселдә була торган хәл. Әтинең апасының кызы берьюлы өч бала тапты.

Азат. Әтиеңнең... апасының... кызының... өч баласының... әтиләренә миннән кайнар сәлам тапшыра тор! Туйда әйбәтләп таныштырырсың...

Фирая. Нинди туйда?

Азат. Безнең... синең белән минем туйда!

Фирая. Барабан булса да булырсың икән!

*Шулвакыт телефон шылтырый.*

Фирая *(кабаланып, трубканы ала).* Алло! Әйе! Әйе... Әйе...Ничә сум кирәк дисез? Ничә мең??? *(Трубканы кулыннан төшереп жибәрә яза).* Шулхәтле үк кирәк мени?! Рәх... рәхмәт... сезгә! *(Трубканы куя, башын тотып, лып итеп утыра).* Андый акчаны мин каян табыйм?

Азат. Кем ул? Нинди акча турында сөйләштең син?

Фирая. Ә... юк... ни бу... *(Үзен бик тиз кулга ала).* Карале, күп белмә—тиз картаерсың!

Азат. Картаясы килә бит! Туйдым перспективасыз яшьлегемнән! Әни һаман авылдан кайтмый. Стипендия пачти көнендә бетә.

Фирая. Эшләргә кирәк, эшләргә! Хезмәт кешене бизи, диләрме әле?!

Азат. Бизи... Ике жирдә эшлим инде, барыбер житми.

Фирая. Убыр кебек ашыйсың, ызначит... Диета тот!

Азат. Болай да диетада инде. *(Пауза).* Чык үземә кияүгә! Ошыйсың син миңа. Матур итеп яшәрбез! Баланны бергәләп үстерербез!

Фирая. Стоп, стоп... Тукта! Йөргән кызың юкмыни соң?

Азат. Сиңа охшаган берәү бар барын... Читтән генә яратып йөрим мин аны.

Фирая. Заочно, димәк. Кыюсызланып йөрмә. Беләсеңме, сандугач белән сыерчык бер-берсеннән шулхәтле аерылып тора. Тәк шту, мәхәббәтеңне аңлат та, менә шул кызга өйлән!

Азат. Кызларга бай егет кирәк шул аларга! Машинасы булсын, акчасы чишмә кебек ташып торсын... Минем нәрсәм бар? Фатир бар да инде... Кешелеккә кия торган кәчтүм-чалбар бар, дигәндәй... Пачти һөнәрем бар... Иң мөһиме—мәхәббәткә тугры йөрәгем бар!

Фирая. Мин менә байлыкка карамас идем...

*Гөлсинә белән Рәуф керә.*

Гөлсинә. Без кайттык! *(Азатны күреп).* Менәтрәк! Һо-һо! Теле-теле-тесто, кияү һәм невеста! Бездән чыкканың

юк... Тәки өйләнергә йөрисең бугай син, Азат?!

Азат. Тәкъдим ясаган идем... Миңа сез, вакытсыз кайтып, мишәйт иттегез.

Рәүф. Аңа сина кадәр мишәйт иткәннәр инде... Әрмәннәр!..

Азат. Әрмәннәр, дигәннән... Бер анекдот! Урыс, грузин, әрмән бер самолетта очып баралар икән. Грузия өстеннән очканда грузин: «Безнең кызлар чәчәк ярата!»—дип, чәчәкләр сибә. Әрманстан өстеннән очканда әрмән: «Безнең кызлар акча ярата!»—дип, кәгазь акчалар чәчә. Рәсәй өстеннән очканда урыс: «Безнең кызлар сезне ярата!»—дип тегеләрне самолеттан тибеп төшерә... Ха-ха-ха!...

Рәүф. Бажай, афәрин! Давай, тимерне кызуында сук! Фирая, уйлап торма, ризалаш! Мондый шәп егетне бүтән беркайдан да табалмыйсың...

Фирая. Үтерепләр кыстады инде, уйлап карыйсы булыр!

Гөлсинә. Нәрсә уйлап торырга... Ишекне алып кына куярга кирәк... Азат барыбер гел бездә!

Азат. Алай димә, Гөлсинә апа, менә бит чыгып барам... Фирая, уен-муен түгел, мин чынлап әйттем. Уйла, яме! *(Чыгып китә).*

Гөлсинә. Акчасы булмаса да, чиста күңелле егет!

Рәүф. Бажайлыкка кандидатлар арасында Азат—беренче! Сомнений быть не может!

Фирая. Ташлагыз әле шул шаяруыгызны! Минем үз хәлем хәл!

Гөлсинә. Аңлыйбыз, сеңлем, сукырлар түгел—күреп торабыз! Безнең сиңа бик җитди сүзебез бар.

Рәүф. Утыр әле, Фирая! *(Утырышалар).*

Гөлсинә. Сеңлем... ничек аңлатыйм микән...

Рәүф. Аңлатып торма. Балдыз сабый бала түгел. Тот та әйт!

Гөлсинә. Сеңлем... Төшермә син баланны... Тап!

Фирая. Апа...

Рәүф. Тап та...

Гөлсинә. ...безгә бир!

Фирая *(сикереп тора).* Сез ни сөйлисез, апа? Җизни?

Рәүф. Без күп уйладык. Үзең белеп, күреп торасың... балабыз юк.

Гөлсинә. Бир безгә баланны... сеңлем!

Фирая. Апа! Туктале!

Гөлсинә. Син яшь әле... Тагын табарсың! Аңла инде, хәлебезгә кер... Бу бала безгә бик кирәк!

Рәүф. Баласыз тормыш—тормыш түгел ул. Бөтен ягыбыз җитеш. Бала гына юк! Фирая, балдыз...

Гөлсинә *(ялварып).* Сеңлем...

Фирая. Апа! Җизни! *(Өзгәләнеп).* Сез уйлаганча гына булса икән ул! *(Йөгереп чыгып китә).*

*Музыка.*
*Пәрдә төшә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Беренче пәрдәдәге күренеш.*
*Кыңгырау чылтырый. Бераздан Сукбай керә, кулында пакет-сумка.*

Сукбай. Здрасте! *(Түр ишеккә таба бара).* Хозяева! *(Шикле кеше кебек, анда-монда каранып торганда, Азат керә. Сукбай аны күрми).*

Азат. Әһә! Эләктеңме, карак? *(Сукбайга ташлана).* Нәрсә урладың?

*Икәүләшеп әүмәкләшә башлыйлар.*

Сукбай. Послушай, брат...

Азат. *(Сукбайның аркасына асылынып).* Кем брат? Бомж тебе брат! Заткнись! Сейчас получишь, карак!

Сукбай. Друг, товарищ, отстань, а! Сейчас все объясню...

Азат. Бур син! Нинди дус булыйм мин сиңа! Хәзер милициягә тапшырам!

Сукбай. Ну что ж... Если так не понимаешь... *(Кинәт Азатны идәнгә егып сала, аның кулын каера).*

Азат. А-а-а... авырттырасың бит, бандит... Җибәр кулны!

Сукбай. Тихо! Будешь меня слушать?

Азат. Сындырасың бит кулны... Җибәр, дим! Буду, буду!

Сукбай. Молодец, холодец! *(Азатның кулын ычкындыра).* Запомни навсегда: я—не вор!

Азат. *(Кулларын угалап).* Карак булмагач, ник керәсең чит кеше фатирына? Күрмисеңмени, хуҗалары өйдә юк! Күрсәт, нәрсә ул сумканда? *(Идәндә яткан сумканы алып, аннан пинҗәк белән чалбар тартып чыгара).* Бу бит... бу бит Рәүф абыйның киемнәре! Карак түгел, дип торган буласың... Урлагансың бит!

Сукбай. Воруют ночью, днем берут! Урламадым мин аны...

Азат. Ха! Татарча сайрый башлады! Безнеңчә дә сөйләшә беләсең икән!

Сукбай. Белмәскә! Татар бит мин!

Азат. Нишләмәкче идең Рәүф абыйның киемнәрен урлап?

Сукбай. Слушай... егет... һаман бер сүз чәйнисең дә бит... Син үзеңнең хәзер нинди ситуациядә калганыңны беләсеңме?

Азат. Нинди ситуация? Нәрсә сөйлисең син?

Сукбай. Хәзер аңларсың. Кайда монда телефон? *(Җәһәт кенә телефон янына барып, трубканы кулына ала, сөйләшкән булып кылана).* Алло, милиция! Мин монда карак тоттым!

Азат. Кем карак? Син нәрсә!

Сукбай. Кулыңда кемнең киемнәре ул? Үзеңнекеме? Түгел! *(Трубкага).* Дежурный!

Азат *(каушый төшеп).* Бомж... абый... Абзыкаем, туктале! *(Телефонга килеп тотына).* Мин урламадым... Син нәрсә! *(Киемнәрне идәнгә ташлый).*

Сукбай. Каптың син, бырат! Киемнәрдә бармак эзләрең калды... Ничек диләр әле, все улики против вас, гражданин подсудимый!

Азат. Мин сине прастуй бомж дип кенә белә идем... Хәйләкәр, юк, бик явыз бомж булып чыктың әле... Аферист икән бит син! Авантюрист!

Сукбай *(катгый итеп).* Утыр! Тыңла! Тышкы кыяфәтенә генә карап, кешегә бәя бирергә беркайчан да ашыкма. Миңа син мине бомж дип атадың... Карак, дип тә әйттең... Бәлки мин миллионердыр? Син каян беләсең минем акча юклыкны? Минем хәер сорашканымны, теләнгәнемне күргәнең бармы?

Азат. Юк.

Сукбай. Шулай булгач, сүзләреңне уйлабрак әйт. Бомж бомж инде ул—хәер эстәүче, дисеңдер... Ләкин минем беркайчан да акча теләнгәнем булмады. Гариб-горабә түгел мин, тилемсә дә түгел, Аллага шөкер!

Азат. Нишләп мондый хәлгә төштең соң, абзый?

Сукбай. Үзем төшмәдем мин, бырат... *(Бармагын өскә чөеп).* Төртеп төшерүчеләр булды. Әйт әле, син газитмазар укыйсыңмы?

Азат. «Сәхнә» журналын укыштыргалыйм шунда... Татарның атаклы артисты Азат Әфләтунов турында, ягъни минем турыда да үтереп мактап язмадылар микән, дип кенә...

Сукбай. Утыр. Тыңла. *(Кесәсеннән газит чыгара).* Ә мин көн саен укыйм. Менә кара, газит тышына ат башы чаклы хәрефләр белән ни дип язганнар? «Сукбайлар белән ничек көрәшергә?» дигәннәр! Әйтерсең, нindiдер бер бандит мин! Сукбайлар белән түгел, аларны шундый юлга этәргән сәбәпләр белән көрәшергә кирәк. Син дә кеше, мин дә кеше... Без барыбыз да—кешеләр! Күккә карап, йолдыз санап кына яшәмә син, дускай... Атлаган чакта аяк астына да иелеп кара—анда да җанлы тормыш бара... Аңлаталдыммы, быррат?

Азат. Бу пинҗәк, бу чалбар... Рәүф абыйның киемнәре сезнең кулга ничек килеп керде? Шуны гына аңлый алмый торам...

Сукбай. Ә-ә-ә... боларны әйтәсеңме... *(Киемнәрне пөхтәләп төрә дә кире сумка эченә тыга).* Боларны миңа Фирая... син беләсең бугай Фираяны... киярсең дип биргән иде. Җизнәсеннән алып торган булган. Фираяның күңеле саф, рәхмәт аңа. Нияте изге булса да, мин боларны киялмим. Мин—ир кеше. Мин аякта басып торам. Тормыш төбенә төшеп яшәсәм дә, горурлыгымны югалтмадым әле мин. Шуңа кире китердем мин бу киемнәрне. Фираяны да бик күрәсем килгән иде...

Азат *(урыныннан сикереп тора).* Менә хәзер аңлашылды! Сиңа Фирая кирәк икән. Күзең төштеме? Белеп тор: мин аны сиңа бирмим! Фирая—минеке. Минеке генә булачак!

Сукбай. Әтәчләнмә, егет!

*Күрше бүлмәдә тавышлар ишетелә.*

*Гөлсинә белән Рәшидә күренә.*

Рәшидә. Балконыгыз бик матур булган. Мин дә шулай эшләтәм! Осталарның телефон номерын бирерсең әле, яме?

Гөлсинә. Бирермен, бирермен... *(Азат белән Сукбайны күреп).* Йа Хода! Балконга да чыгар хәл юк, шантрапалар шундук өйне басып ала. Нишлисез монда? Азат, сина әйтәм?! Тагын теге бомж!

Рәшидә. Ишегенне бикләргә кирәк иде, Гөлсинә. Проходной дворга әйләнгән бит фатирыгыз!

Сукбай. Здрасте! Извините...

Азат. Гөлсинә апа, хәзер аңлатам...

Гөлсинә. Кирәкми миңа синең аңлатуың... Барыгыз, икегез дә аттырыгыз моннан! Әллә бездә Әндри казнасы бар дип белдегезме? Югалыгыз күз алдымнан!

Азат. Анладым. Мин... мин... югалам... *(Чыгып китә).*

Сукбай. Еще раз—здрасте! Не скажете, как мне найти Фираю? Бик кирәк иде!

Гөлсинә. Күзең чыкмагандыр бит. Юк монда Фирая. Әттәч-бәттәч! Әллә татарча да белә инде?!

Рәшидә. Нишләп сөйләшмәсен! Үзебезнең Татарстаныбыз сукбае бит ул! Син шуны әйт, хәзер ничек куып чыгарабыз бу жан көеген?

Сукбай. Мин сезне беләм! Вас Рашидой зовут. Так ведь?!

Рәшидә *(мыскыллы елмаеп).* Мине белүеннән би-и-ик үсенеп, очынып киттем инде менә, өтәләнгән үрдәккәем! Перәме летаю менә! Высоко-высоко летаю! Гөлсинә, дим, ник дәшмисең? Отвечай! Куып чыгар бу имгәкне!

Сукбай. Вы о чем? О чем речь, дорогуша моя?

Рәшидә. Дорогуш мой, иманыңны укытканчы, отвались, яме?! Гөлсинә, дим! Куып чыгар җәтрәк!

Гөлсинә. Иди, иди... До свидание! *(Рәшидәгә).* Каты әйттемме?

Рәшидә. Тагы да каты итеп әйт! Бүтән кермәслек булсын!

Сукбай *(урыныннан торып, кулындагы сумканы Гөлсинәгә суза).* Передайте Фирае вот это, пожалуйста. Пожалуйста!

Рәшидә. Ала күрмә берүк! Бомба булмасын тагы!

Сукбай. Не бойтесь, это—не бомба, Рашида жаным. *(Сумканы кәнәфигә куя).*

Рәшидә. Жаным, дип торган була тагы... Хәчтерүш! Много болтаешь, давай, отчаливай по хорошему! А то... милицию вызывем!

Гөлсинә. Точно! Нишләп башта ук әйтмәдең аны. Хәзер позвоним! *(Телефонга таба бара).*

Сукбай. Подождите! Я сейчас уйду.

Рәшидә. Давно пора! Типкәләп чыгарганчы, тизрәк олак!

Сукбай. Такие милые суперженщины, и так грубо обращаются с мужщиной суперменом. И не стыдно вам?

Рәшидә. Уф, үләм! Күр әле моның сөйләшүен... Каян килгән суппер-пуппер мужик! Гөлсинә, звони в милицию!

Гөлсинә. Уже звонить итәм...

Сукбай. Не надо, я сам уйду. Спасибо за гостеприемство! Мир этому дому.

Рәшидә. Давай-давай, быстро шагай, бомж бабай! Иди туда, незнай куда, бүтән килмә сюда.

Сукбай. До свидание, Рашида. До встречи! Покорно изверяюсь. Гафу итегез! *(Чыгып китә).*

Гөлсинә. Үзем генә куып чыгара алмый идем мин моны. Ярый әле син булдың, Рәшидә.

Рәшидә. Сумкасын да биреп чыгарасы калган тегенә. Нәрсә микән эчендә, ачып карарга иде бит.

Гөлсинә *(кинәт).* Не подходи!

Рәшидә. Уф, куркыттың! Урысча кычкырмале. Үзебезчә әйтсәң дә анлыйм бит мин. Ничек беләбез инде моның эчендә ни бар икәнен?

Гөлсинә. Хәзер Рәуфкә әйтәбез. Сумканы аңа актартабыз. Рәуф!

Рәшидә. Әллә Рәуф өйдәме?

Гөлсинә. Өйдә булмыйча, кайда булсын тагы.

Рәшидә. Вәйт тиле син, Гөлсинә. Ник аны башта ук әйтмәдең?

Бомжны куып чыгара алмыйча күпме чиләндек. Кайда соң, нишли соң ул Рәуф? Йоклый мәллә?

Гөлсинә. Юк. Яза. Темнушкада. Темнушканы кабинет итте бит!

Рәшидә. Барыбер анламадым. Рәуф

нишли дисен?

Гөлсинә. Яза, дим!

Рәшидә. Нәрсә яза? Пишетме, әллә май язамы?

Гөлсинә. Опера яза! Нишләп май язсын инде, менәтрәк! Сыер юк бит безнен. Прусты яза, пишет! Кичә дә төнлә язды. Бүген дә темнушкадагы кечкенә өстәленә кадалып утыра. Сөенеп торам әле менә. Язмаганына бер ун ел булган иде бит!

Рәшидә. Яза башлаган, димәк... Бик әйбәт! Атаклы язучы хатыны булып, затлы күлмәкләр генә киеп, кичәләрдә, банкетларда порхать итеп йөриселәрен алда икән әле!

Гөлсинә. Авызына бал да май! Амин! Яза гына күрсен берүк... Юкса, соңгы вакытларда кая бәрелергә-сугылырга белмичә йөридерие... Рәүф! Рәүф, дим! Чык әле монда!

Рәшидә. Бомба бар, диген! Атылып чыксын!

*Кулларын язгалап, киерелеп, Рәүф чыга.*

Рәүф *(кәефе шәп).* Күгәрченнәр гөрләшәләр безнен өйнен түрендә... Серләшәбезме?

Рәшидә. Серләшү генәме! Бомж белән типтерәбез! Әллә син бернәрсә дә ишетмәденме? Көпә-көндез фатирынны талап, хатынынны, мине урлап чыгып китә яздылар бит!

Рәүф. Сине урласалар да ярый... Хатынкаема тия күрмәсеннәр! Нәрсә, берәр чит кеше керде мәллә?

Рәшидә. Рәүф, сручно врачка барып, колагынны күрсәт. Сонга калганчы, атып кал: ишетмисен икән бит син, бәгырькәем! Әле генә бомж булды монда—Фирая сукбае!

Гөлсинә. Ашыйсын килмиме, Рәүф жаным?

Рәшидә. Нинди ашау, ниткән ашау? Өеңдә бомба шартларга тора!

Рәүф. Аңлатып сөйләгез әле, нинди бомба?

Рәшидә. Менә бу сумканы ачып карарга куша сина Гөлсинә. *(Сумканы Рәуфкә китереп тоттыра да читкәрәк китеп колакларын каплый).* Открой давай!

Гөлсинә *(Рәүф артына елышып).* Подожди!

Рәүф. Ачтым. Шуннан?

Гөлсинә. Вытаскивай!

Рәүф. Нишләп икегез берьюлы урысча сөйләшә башладыгыз әле?

Рәшидә. Почему, патамушто, монда бомж булды.

Гөлсинә. Шунын белән гел русча сөйләштек тә, хәзер менә үзебезнен телгә кучәлмичә интегәбез. Әйдә, нәрсә бар анда, чыгар!

Рәүф. Ха! Минем кәчтүм-чалбар түгелме соң бу?

Рәшидә. Урлаткан иден мәллә? Бомж булуы гына житмәгән, карак та икән бит теге иблис!

Гөлсинә. Шул бомжны киендерәм дип, Фирая бездән сорап тормыйча гына алып чыгып киткән иде бу киемнәрне. Сукбае ошатмаган курәсен, кире керткән!

Рәшидә. Сайланган була икән әле, үзенен кем икәнен белмичә!

Рәүф. Ә мин... *(Көлеп жибәрә).* Берәр юньле әйбер дип торам тагы! *(Дәррәү көлеш.)* Йә, ярый... Сезнен сүз бетмәс... Ә мине теге бүлмәдә... темнушкада бөек эшләр көтә! Роман көтә! *(Кереп китешли).* Кирәк булсам, чакырырсыз!

Рәшидә. Баядан бирле сорамакчы булам... Гөлсинә, ниме сон... Гаилә үзгә белән ничек булып бетте сезнен?

Гөлсинә. И, Рәшидә, аптыраган инде... Беренче тапкыр биргән анализлар белән барып чыкмады бит, үзен беләсен... Рәүф «Бала, бала!» дигәнгә генә анализларны икенче тапкыр бирергә ризалаштым... Әле бер хәбәр дә юк! Әллә ни өметләнмим дә инде...

Рәшидә. Алай димәле син... Әнә, Гүзәлияләр... Пробиркада үстереп, балалы булдылар... Хәзер сөенеп бетәлмиләр!

Гөлсинә. Утка керосин сипмә әле, Рәшидә. Ходайдан шулай язгандыр...

*Ут сүнә.*

*Музыка. Ут янганда Фирая бер ялгызы вальс бии (кайда биюе мөһим түгел). Биюдән туктап, залга якынаеп, шигырь сөйли. Азат анын сөйләгәнен бер читтә тынлап тора.*

Фирая.
Мәхәббәтнен канат жиле
Мина да тигән иде.
Яратуыма сөенеп,

Бәхеткәйләргә тиенеп,
Яшисем килгән иде...

Йолдызларның атылганын
Мин дә бит күргән идем.
Теләгем кабул булыр, дип,
Бәхетем ташып торыр, дип,
Куанып йөргән идем.

Насыйп булмас, ахры, яшәү
Ярым өчен җан атып.
Гомер учагым сүрелә,
Өметкәйләрем өзелә—
Сына сабыр канатым...
Сына сабыр канатым...

Азат. Фирая!

Фирая. Азат?!

Азат. Син монда икәнсең. Мин сине көне буе эзләдем. Юк, мин сине гомерем буе эзләдем! Менә... таптым ниһаять! Шигырьне матур сөйлисең икән син... Үзең яздыңмы?

Фирая. Сина барыбер түгелмени?!

Азат. Мин дә шигырь сөйли беләм... Кичә, алма ашый-ашый, төне буе яздым. Менә тынлап карале:

Көч-гайрәтне күрсәтәм, дип
Таулар күчерәсе юк...
Әгәр минеке булмасаң,
Мәнге кичерәсем юк!
Шәпме?

Фирая *(көлеп)*. Бу шедеврыңны язган чакта ничә кило алма ашап бетерден инде?

Азат. Алмадан соң ярты кило груша да ашадым әле мин! Аннары ике әфлисун, өч мандарин, бер киви, ярты лимон...

Фирая. Кыйбатка төшкән икән!

Азат. Иҗат корбан сорый! Бүтән язмам, ахры... Эчем авырта...

Фирая. Жәл. Берәр шәп шагыйрьгә кияүгә чыгармын, дип хыялланган идем... Булмады!

Азат. Андый нәтиҗә ясарга ашыкмале син... Кем белә, эч авыртуы беткәч, бәлки мин тагын шигырьләр яза башлармын...

Фирая. Шагыйрь булуда гына мыни хикмәт! Иң мөһиме—кеше бул син, Азат!

Азат. Мин сине яратам, Фирая!

Фирая. Ә мин сине яратмыйм, Азат... Аңла, зинһар, ярата алмыйм мин сине!

*Ут сүнеп ала.*
*Ут янганда Рәуф «иҗат булмәсендә», өстәл янында ноутбукка текәлеп утыра, ара-тирә клавишларга баскалап ала. Үзүзеннән канәгать түгеллеге сизелә.*

Рәуф. Шайтан алгыры! Тема шәп! Сюжет менә дигән! Нишләп язалмыйм соң мин, ә?

Фирая тавышы *(караңгыдан ишетелә)*. Язалмаячаксың да, иптәш автор! Чөнки син, җизни, ялгыш юлдан киттең!

Рәуф. Ә? Нәрсә? *(Як-ягына карап ала)*. Беркем дә юк.

Фирая *(аерым ут яктысы белән пәйда була)*. Мин монда, җизни, синең күңелеңдә.

Рәуф. Ә? Әллә саташа башладым инде?! Балдыз!? Синең тавыш бит бу?! *(Колак тишекләренә бармакларын тыгып селкетә)*. Гөлсинә читтән карап торса, ычкынган бу, диячәк... Валлаһи! *(Башын тотып, уйга чума)*.

Фирая. Йә, нәрсә яздың инде син, җизни? Авыл кызының мәхәббәт маҗаралары, корсакка узуы, авылдан качып шәһәргә килүе, шәһәрдәге маҗаралары... И вәссәлам! Шул гынамы? Юк, җизни!.. Син мине белмисең әле... Син берни дә белмисең. Син күзаллаганча түгел, бөтенләй бүтән кеше мин! Җанымда—давыл! Йөрәгемдә ут кайный! Роман, дип зурдан купкансың да кубуын... Синең матур ялганың, буш сүзләрең беркемгә дә кирәк түгел, җизни! Моны беркем дә укымаячак. Яз! Җаннарны елатырлык, йөрәкләрне тетрәндерерлек итеп чынбарлыкны яз! *(Ут белән бергә югала)*.

Рәуф. Нәрсә булды бу? *(Кинәт урыныннан торып, уң кулын Ленин кебек алга суза)*. Во! Баш эшли башлады... Дөрес юлдан багасың, иптәш язучы! *(Кабат урынына утыра)*. Дөрес юлдан... атлагыз алга, иптәшләр!

Сукбай тавышы. Юкны бушка аударып, зерәгә ыштан туздырма син, туган... Язсаң яз, курыкмыйча!

Рәуф. Монысы кем тагы? Сукбай?! Дядя Коля, синме бу?

Сукбай *(ут аны да аерым яктырта)*. Язасың икән, тормышчан итеп яз син! Нәрсә, тормыш төбенә төшкән бер мәхлук бәндә генә мени мин? Үзең, бер тамагын гына кайгыртып яшәүче пошмас җанмыни мин? Нәрсә, тормышка, җәмгыятькә карата бер фикерем дә юкмыни минем? Сукбайлыкка төшүемнен

сәбәбен ник язмыйсың? Чөнки белмисең... Минем кебекләр дөньяда миллион! Һәрберсе—үзе бер ачы язмыш! Гәзитләрдә өзлексез чәйниләр: «Сукбайлар белән көрәшергә кирәк! Сукбайларны каядыр олактырырга кирәк!»—диләр... Әйтерсең сукбайлар—илне талаучы, кеше җанын кыючы бандитлар... Сукбайлар белән түгел, аларны тудырган социаль сәбәпләр белән көрәшергә кирәк!

Рәүф. Круто!

Сукбай. Яз! *(Рәүф Сукбай сөйләгән вакытта, ноутбукка текәлеп, клавишларга кызу-кызу баса башлый).* Яз, туган!

...Без частька килер алдыннан гына бик каты бәрелеш булган. Теге яктан да, бу яктан да кырылганнар. Безнекеләр бер дошманны эләктергәннәр. Каршыбызга шуны китерделәр. Аяклары яраланган моның. Куркынган күзләрен мөлдерәтеп җирдә ята бу. Лейтенант Ильичев Рязань егете Роман Шустриковны строй алдына чыгарды. Роман якташы Есенинга охшатып шигырьләр яза иде:

«Россия—великая страна,
Россия—родина моя!
Ты иногда—так многословна,
Как баба немая!»

Менә шул шагыйрь егеткә лейтенант дошманны атып үтерергә боерды. Роман әйтә: «Не могу стреляйть! Он же без оружия!»—ди. «Стреляй!»—ди лейтенант. «Не могу!»—ди Роман. «Ты что, гад, врага жалеешь?»—дип, Ильичев Шустриковның якасыннан эләктереп алды. Мин түзмәдем, араларына барып кердем дә, лейтенантка: «Если тебе так хочеться, сам стреляй!»—дидем. Татарлыгым чыраема чыккан булгандыр... «Ах, ты, чаплашка!»—ди бу миңа. Шуннан соң пистолетын минем чигәгә китереп терәде дә: «Тогда ты стреляй, татарская морда! Приказываю!»—дип акырды. Дошманның күзләре акаеп чыкканын гына хәтерлим... Аттым...

...Шуннан соң күп бәрелешләрдә катнаштым. Илгә исән-сау кайттым. Әмма теге күзләр... Кая гына барсам да, ниләр генә кылсам да, гел мине эзәрлекләделәр. Дөньяның, яшәвемнең ямен, тәмен бетте. Аракы эчеп, онытылмакчы булдым—сазга кереп баттым... Ватанны дошманнан саклагыз, дип безне ут эченә ыргыттылар. Соңыннан барысы да аңлашылды—зерә сугышканбыз икән. Мокыт сәясәтчеләрнең шәхси амбициясен яклап, бер мәгънәсезгә күпме яшь гомер өзелде. Рязань егете Роман Шустриков та һәлак булды... Меңәрләгән егетләр чит җирдә башларын салдылар! *(Сүгенгән сыман итеп).* Родина-мать! Илгә солдатлар һәм эчкечеләр генә кирәк икән! Мать твою! *(Югала).*

*Рәүф дәртләнеп язуын дәвам итә.*
*Ут сүнеп ала.*
*Ут янганда Гөлсинә белән Рәшидә өстәл янында утыра.*

Гөлсинә. Менә шундый хәлләр, Рәшидә... Абыйларда куңды микән? Борчыла башладым инде. Һаман юк!

Рәшидә. Борчылма, Фирая югала торган кыз түгел ул, кайтыр. Бая... күземә генә күренмәде соң... бер песи кухнягызга таба кереп киткән сыман тоелды. Син бит эт-мәче яратмый идең!

Гөлсинә. Ә-ә-ә... аны әйтәсеңме? Бүген иртән подъезд ишеге төбеннән алып кердем. Мине күрде дә аякларыма килеп ышкына башлады. Күзгә карап, үзенчә мырлаган була... Нәрсәсе беләндер яраттырды үзен. Алып кердем әле менә. Ошатса—бездә калыр, урын—иркен!Бер гәзиттә укыган идем, өйдә мәче булса, бала туарга мөмкин икән, дип...

Рәшидә. Элек мондый түгел идең. Әллә сеңлеңә охшый башладың инде?! Фатирыгызга ул сукбай алып кергә, син—мәче, дигәндәй...

Гөлсинә. Бүген дә йоклый алмадым. Әллә нәрсә шунда... Гел уйланып яттым. «Тик икәү без, уй да мин!» дип Габдулла Тукай әйткәнме әле?! Шуның шикелле...

Рәшидә. Кем әйткәнен үзең яхшы беләсеңдер... Син бит—педуниверситет бетергән кеше! Берме-икеме ел укытып йөрдең түгелме соң?!.

Гөлсинә *(авыр сулап).* Әйе-е... Бар иде укытып йөргән чакла-ар... Кешечә түләгән булсалар, әле дә яраткан эшемдә әвәрә килер идем! Балаларны ярата идем...

Рәшидә. Базарыңны ташла да, кайт укытучылык эшенә!

Гөлсинә *(авыр сулап, көйләп).* «Сондыр шул инде, сондыр шул инде...»

Рәшидә. Җүләр сатып утырма! Яраткан эштә эшләүгә ни җитә! Ул яктан минем бәхет булды. Көн саен яна кешеләр, төрле язмышлар белән очрашам. Кешеләр бит безгә паспорт алырга, паспорт алыштырырга дип кенә килмиләр. Эч серләрен бушаталар, кинәшләр сорыйлар, ярдәм өмет итәләр... Булдыралган кадәр хәлләренә керергә тырышасың... Әле менә кичә соцзащита кызлары безгә бер адәмне алып килде. Заманында менә дигән гармунчы булган! Теге... дед Мазай кебек, әй лә, Фираяның дядя Колясы кебек, бомж хәленә калган. Документларын югалткан. Документлары черт с ним! Быел кыш, исерек килеш карда ятып, ике кулын өшеткән, бахыр. Кискәннәр! Яңа паспортка кул куярга кирәк бит инде хәзер... Ничек куйды дип уйлыйсың? Авызы белән! Беркемгә кирәге калмаган үзенең. Исерек белән торасы килмәгәндер инде, хатыны бүтән иргә кияүгә чыккан. Туганнары да моннан баш тарткан. И җәлләдем дә инде үзен!

Гөлсинә. Сәер кеше син, Рәшидә! Әле җәллисең шул бомжларны, әле күрәлмисең...

Рәшидә. Кая бара бу замана? Туганга туган кирәк түгел, аналар балаларын ташлап кача... Аңламассың бу дөньяны!

Гөлсинә. Мин монда үзебезнең Фираяны аңламыйм. Ә син дөнья дисең!

Рәшидә. Фирая кебекләр җитми бугай бу җәмгыятькә! Замана Фираяларга кытлык кичерә... Их, тагын бер-ике... йөз Фирая... Һәм...

Гөлсинә. Син дә Рәүф кебек сөйләшә башладың... Әйдә, бик тәмле пирогым бар. Чәйләп алыйк! *(Кухняга кереп китәләр).*

*Фирая керә. Прическасын үзгәрткән.*

Фирая. Әллә беркем дә өйдә юк инде?

Азат *(артыннан ук кереп).* Мин бар!

Фирая. Абау, котны алдың!

Азат. Кайтканыңны тәрәзәдән күрдем дә кердем әле менә. Сагындым үзеңне! О-о! Прическаңа игътибар итми торам икән! Тагын да чибәрләнгәнсең димме?! Карале, чынлап әйтәм, әйдә, чык миңа кияүгә!

Фирая. Мин бит болай да кияүдә инде, Азат. Ирем бар минем. Үзебезнең районда, зур урында эшли. Бик яратам мин аны. Ул да мине ярата. Уч төбендә генә йөртә.

Азат. Ышанмыйм. Яратса, бу хәлдә ялгызыңны гына чыгарып җибәрмәс иде.

Фирая. Бик мөһим эш белән командировкага китте шул ирем. Мине дә үзе белән алып барырга бик теләгән иде. Эш кешесенә комачау булып йөрисем килмәде. Гел шалтыратып, хәлемне белешеп тора.

Азат. Ну-ну! Ышандыра яздың. Син нәрсә, мине кеше аермый дип беләсең мәллә? Минем абый да—зур урында эшли. Әмма мин җиңгәчәйнең синеке шикелле прастуй күлмәк киеп, Вьетнам базарыннан сатып алган алкалар тагып йөргәнен хәтерләмим.

Фирая. Күзең үткен икән... Мин бит махсус шулай киендем. Алкаларның да очсызлысын тактым. Апаны көнләштерәсем килмәде. Йөрәге янмасын әле, дидем. Иремә дә сүз китерәсем килми.

Азат. Ну-ну!

Фирая. Ышанмасаң ышанмыйсың инде. Акча биреп ышандыра алмыйм. Әйтәсемне әйттем, Азат. Бүтән әйттермә, яме. Матур кызлар белән дөнья тулы. Шулар арасыннан үзеңә тиң яр табасыңа ышанам мин. Бәхетле бул!

Азат. Миңа син кирәк, Фирая. Мин сиңа чынлап гашыйк. Яратам мин сине! Туасы балаңны да, үзеңне дә мәңге яратачакмын! Күңелем алдамый минем, без барыбер бергә булачакбыз!

Фирая. Ха-ха-ха... Ирем ишетсә бу сүзләреңне, икебезне дә... *(Корсагын сыйпап.)* Юк, өчебезне дә харап итәчәк!

Азат. Борчылма, ишетми ул. Командировкада дисең бит.

Фирая. Командировкада булса да, әллә кайда еракта түгел бит ул—Чабаксарда гына!

Азат. Хет күрше бүлмәдә генә булсын—курыкмыйм мин синең иреңнән. Дөресен генә әйткәндә, юк бит синең ирең, шулаймы?! Алдыйсың син. Ялгышып балага узгансың да, хәзер үзеңне үзең юатып, алдашып торган буласың. Юк синең ирең! Сүзләрең белән алдала-

саң да, күзләрең алдамый синең!

**Фирая.** Ирем бармы минем, юкмы, анда синең эшең булмасын. Югал күз алдымнан, бар, чыгып кит! Яратмыйм мин сине!

**Азат.** Чыгып китәм. Пока. Әмма син тынычлангач, кабат керәчәкмен! Белеп тор! Без барыбер бергә булачакбыз! *(Кырт борылып, чыгып китә).*

**Фирая** *(өзгәләнеп).* Их, Азат, Азат... Күңелең саф синең. Нишлим, сине өметләндерә алмыйм бит. Хәлләремне үзем генә беләм... *(Жырлый).*

Аланнарда җиләк җыйган чакта
Күреп алдым бүре баласын.
Белмәдем шул, алда язмышымның
Уттан алып суга саласын...

Аланнарда җиләк җыйган чакта
Никләр күрдем бүре баласын?
Белмәдем шул килер көннәремнең
Сагышларга мине саласын...

Аланнарда җиләк җыйган чакта
Кызарып ла бетте кулларым.
Берәр вакыт сина, бәгырькәем,
Илтер микән гомер юлларым?..

*Телефон шылтырый.*

**Фирая.** *(Трубканы ала).* Алло! Әйе! Әйе! *(Ул сөйләшкән чакта ишек тарафында Рәүф күренә. Аны күреп, Фираяның йөзе тагы да яктыра).* Сәлам, жизни! *(Трубкага).* Рәхмәт! Бик зур рәхмәт! Шундый куанычлы хәбәр әйттегез! Ходай сезгә дә һәрчак мәрхәмәтле булсын! Тагын бер мәртәбә зур рәхмәт сезгә! Жизни, кайттыңмы?!

**Рәүф** *(шаярып).* Сине сагынып кайттым, балдызым-йолдызым...

**Рәшидә** *(кухнядан чыга).* О-о-о! Югалган кеше табылган! Кайларда йөрдең, Фираюшка?

**Гөлсинә.** Кайда йөрсен, сукбайлар янында инде... Белмисеңдер әле син: сукбайларның атаманы бит ул хәзер! Жанна д,Арк!

**Рәшидә.** Бер дә арык түгел... Таза, матур!

**Рәүф** *(киная белән).* Балдыз булдыра ул, молодец! Чибәрлеге бар, үҗәтлеге житәрлек, тәвәккәллеге—хәттин ашкан... Аның өчен ике дөнья—бер моржа... Кая тели—шунда бара. Ни тели—шуны эшли.

**Гөлсинә.** Тормозсыз трактор белән бер—алдында очраган бар нәрсәне жимереп бара...

**Рәшидә.** Баруын тырт-пырт барадыр да бит... *(Күкрәкләрен куллары белән селкеткәләп).* Буферы изелепяньчелеп беткәч, нишләр менә?!

**Рәүф.** Балдыз, тыңлама син боларны. Барыбер акыллы сүз әйтмәсләр!

**Гөлсинә.** Кайлардадыр себерелеп, эшерелеп йөргәнче, туасы балаң турында уйлар идең ичмасам! Артистка!

**Фирая.** Дөрес әйттең, апа. Артистка! Әйе, минем гомер буе артистка буласым килде...

*Азат керә.*

**Азат.** Гафу итегез, тамагым тук... Бер әйбер дә кирәкми...

**Гөлсинә.** Наконец!

**Азат.** ...әлегә кирәкми!

**Рәүф.** Бүлдермәгез әле Фираяны!

**Фирая.** ...Кечкенәдән бирле хыялланам инде мин. Хыялым әллә кайчан ук чынга ашкан да булыр иде бәлки. Әнине карарга кирәк иде... Син бит, апа, чыктың да киттең! Күчтәнәч итеп бер кило конфет-прәннек апкайта идегез дә... Әнкәй шуны ел буе күршеләргә сөйли иде... Ә мин фермада эшлим. Сыерларга, бозауларга Галиябану булып, Сәрвиназ булып уйныйм... Укырга керә алмыйча калдым... Әнине карадым...

**Гөлсинә.** Син нәрсә беләсең соң? Менә син сыерлар, бозаулар, дисең... Минем белән укыган Әлфияләрнең, Санияләрнең, Рәфидәләрнең бер көтү бала-чагасы бар... Ә минем?

**Фирая.** Апа, хәзер кайта аласың... Бала-чагалар юк хәзер. Болын хәтле мәктәптә ике-өч бала селкенеп йөри. Балалар бакчасы ябылды. Хәзер хатыннар авылда да бала тапмый...

**Рәшидә.** Между прочим, рәтле ир булса, мин бүген үк бала табар идем! Берне генә түгел—бишне! Орлыгы юк! Их, яхшы мужик булса!

**Сукбай** *(затлы киемнән керә, бер кулында—ниндидер төргәк, икенче кулында—бик матур чәчәк бәйләме).* Кем әйтте юк дип! Бар ул яхшы мужик!

*Барысы да Сукбайга гаҗәпләнеп карый.*

**Фирая.** Дядя Коля! *(Сукбайның кочагына ташлана).*

Сукбай. Киләчәгең шушы чәчәкләр кебек гүзәл булсын, сеңлем!

Азат. Амин! *(Сукбай кулындагы чәчәкләргә үрелеп).* Кая, китер чәчкәләренне... Үзем бирәм Фираяга!

Сукбай. Минем үземнең кулларым бар... Мә, Фирая!

Фирая *(чәчәк бәйләмен алып).* Рәхмәт, дядя Коля!

Сукбай. Акча алып килдем сиңа, Фирая! *(Төргәктән орден-медальләр чыгара).* Шушыларны сатам!

Азат. Ә нәрсәгә сиңа акча, Фираякаем?

Фирая. И, Азат, ошыйсың син миңа. Бүген үк кияүгә чыгар идем сиңа. Тик сине дә, үземне дә бәхетсез итәсем килми!

Гөлсинә. Нидән бәхетсез? Азат бик шәп егет! Менә дигән кияү!

Азат. Миндәй затлы кияү дөньяда бүтән юк! Әни дә шулай ди... Үзем дә шулай уйлыйм...

Фирая. Аңламыйсыз шул сез... Авырыйм мин... Врачлар үзләре дә нәрсә икәнен төгәл белмиләр... Тикшеренер өчен генә дә бик күп акча кирәк... Бик күп!

Азат. Бик күп акча?! Миндә ничаклы бар икән? *(Чалбар кесәләрен капшаштыра).*

Сукбай. Фирая! Барысы да әйбәт булыр. Бәлки операция кирәк тә булмас. Врачлар да ялгыша. *(Өскә төртеп күрсәтә).* Барысы да « Ин Главный Врач» кулында!.. УЛ беркайчан да ялгышмый! Болар гына җитмәсә, минем банкта да байтак акчам бар... Менә... паспорт белән генә проблема! Әйле-шәйле йөргәндә югалткан идем... Яңа паспорт алалсам...

Рәшидә. Нет проблем! *(Орден-медальләрне тотып карый).* Мин сине үзем паспортлы итәм... Син минем яшьлек мәхәббәтем Кыямны хәтерләттең... Аның да шушындый бүләкләре булгандыр... Ул да сугышта иде... Син кайткансың, ә аны кайтардылар...

Сукбай. Әйе... мин кайттым... к сожалению!

Рәшидә. Ходай гомер биргән икән, куанып яшәргә кирәк, дядя Коля! Син бит герой!

Сукбай. Тормыш төбенә төшкәнгә кадәр минем исемем Камил иде. Камил дип дәш, Рәшидә!

Рәшидә. Хәзер генә аңладым мин сине, Камил... Кемевич?!. Күрсәткәндер сиңа дөнья...

Камил. Күрсәтте, еламаска өйрәтте... *(Орден-медальләрне өстәлгә куя).* Балаларга тел, әдәбият, тарих, милләт турында, шәхеснең асылы, яшәүнең мәгънәсе хакында сөйлисе кеше идем мин. Пединститутта ике ел укып калдым—армиягә алдылар...

Рәуф. Әйе, син күргәннәрне дошманыңа да күрергә язмасын!

Рәшидә *(орден-медальләрне кадерләп тотып, Камил янына килә).* Гафу ит мине, Камил... Гафу итегез, зинһар!

Камил. Нигә? Ни өчен?

Рәшидә. Синнән чирканганым, җирәнгәнем өчен!

Гөлсинә. Мине дә кичерә күр, дядя Коля! Мин ... без... әллә кемнәр без! Адәм баласы шулай гел ялгыша инде ул...

Азат. Камил туган... Миңа үпкә саклама, яме... Теге чакта... Икәү әүмәкләшкәндә... кулыңны каерып авырттырдым бугай...

Камил. Синме?! Минем кулнымы?!

Азат. Ә... юк... Гафу ит... Киресенчә булды бугай шул...

Рәуф. Барыбызны да гафу ит, солдат!

Камил. Сез түгел... башкалар гафу сорарга тиеш... Бездән! Яуда ятып калганнардан да, исән-сау кайта алганнардан да! Кылган гамәлләре өчен халкыннан гафу үтенә алган илнең генә үзен бөек держава дип йөртергә хакы бар! Әлегә мин андый хәлнең булганын хәтерләмим... *(Бераз паузадан соң, Рәшидәгә карап).* Рәшидә! Син чынлап та мине паспортлы итә аласыңмы?

Рәшидә. Итәм, дидем бит!

Азат. Мин беләм, Рәшидә ханым беркайчан да ике сөйләшми... Ул югалткан паспортыңны да табып бирергә мужыт!

Камил. Фираяга бик күп акча кирәк. Һәм бик тиз кирәк!

Фирая. Камил абый, бәлки ул миңа инде кирәк тә булмас... Шулай да... бик зур рәхмәт сиңа!

Азат. Төшенкелеккә бирелмәскә! Ишетәсеңме, Фирая?! Авылда шәп йортыбыз бар безнең. Буш тормасын дип, хәзерге вакытта анда әни яшәп ята. Шул йортны сатабыз! Әни риза булачак. Әнием бик әйбәт минем!

Рәшидә. Ниткән сүз ул? Ул йортны сатканчы күпме вакыт уза... Фираяга үзем бирәм акча!

Гөлсинә. Туктагыз әле сез! Безне бөтенләй оныттыгыз! Без бар бит әле монда. Яраткан жизнәсе булганда, бертуган апасы булганда, нишләп сездән алып торсын инде ул... Шулай бит, Рәүфкәем?!

Рәүф. Әйе, шулай. Без—Фираяның иң якын кешеләре. Без дә булышмасак...

Гөлсинә. Мин хәзер! *(Икенче бүлмәгә кереп китә).*

Фирая. Сез нәрсә инде. Мин сезне борчымаска уйлаган идем, жизни...

Рәүф. Их, син, кычыткан чыпчыгы! Нинди борчу ди ул! *(Килеп кочаклый, үбеп ала).*

*Гөлсинә бүлмәдән гөл күтәреп чыга.*

Гөлсинә. Хәзер, хәзер... *(Гөл төбеннән төргәкне ала).*

Бисмиллаһир рахманир рахим! Файдасы тиярлек булсын бу акчаларның! Мә, сеңлем, син дә бисмилланы әйтеп ал!

Фирая. Апа... нишлисең син... жизни... үзегезгә кирәктер бит...

Гөлсинә. Безгә син кирәк, сеңлем! *(Акчаны биреп, Фираяны кочаклый).* Син кирәк!

Рәүф *(хатыны белән балдызын кочагына ала).* Дөрес әйттең, Гөлсинә! Безгә син кирәк, балдыз!

Азат *(Фирая алдына тезләнә).* Юк, Фирая миңа кирәк... Миңа!

Камил. Фирая барыбызга да кирәк!

*Фирая кинәт апасы белән жизнәсе кочагыннан чыга да, башта Азат белән, аннары Камил, соңыннан Рәүф белән биергә тотына. Башкалар бер үк вакытта сөенеп тә, гаҗәпсенеп тә, сәерсенеп тә аңа карап торалар.*

Фирая *(биюдән туктап).* Балалар жыры! Жырлый—Фирая Әлдермешева! *(Дәртле-күңелле итеп жырлый).*

Учлап-учлап жиргә сиптем
Сары тары ярмасы.
Чырык-чырык чыркылдаша
Ике чыпчык баласы...

Чырык-чырык, чырык-чырык!
Ике чыпчык баласы!..
Миңа—тары сибәсе дә,
Сезгә—чукып аласы...

*Фирая кинәт жырлаудан туктап, Гөлсинә янына килә.*

Фирая. Рәхмәт апа, рәхмәт сезгә! Барыгызга да!.. Тик... Кичерегез мине... Кичерегез! Юк минем бернинди дә балам! Уйнадым гына мин! Мәгез, тотыгыз баланы! *(Күлмәк эченнән мендәр тартып чыгара да өскә чөя, аны Азат тотып ала).*

Рәшидә. Вот артистка, ә! Нәрсә булды инде бу?

Азат. Нәрсә булсын... Выкидыш! Вык-кидыш! Вык-кидыш! *(Шатлыгыннан мендәрне кочып, «Ламбада» биюен бии башлый).* Баласы булмагач, ире дә юк инде аның!

Гөлсинә *(шок хәлендә).* Бала?! Балам!? Син безне алдадың?! Ышанмыйм!

Фирая. Алдамадым, апа. Мин чынлап уйнадым.

Азат. Браво! Браво!! Афәрин!!! Искиткеч шәп уйнадың! *(Мендәрне үбә, сөя).* Талант син, Фирая, талант! *(Мендәрен кочаклаган килеш, Фирая алдына тезләнә, баш ия).* Син, син—иң гүзәл актриса! Булмаган бала өчен рәхмәт сиңа! Рәхмәт сиңа мендәр өчен!

Рәүф. Бармактан суырып язасы да юк... Менә ул тормыш үзе биргән сюжет! Роман геройлары—безнең арада!

Гөлсинә. Ышанмыйм, ышанмыйм!..

Фирая. Апа! Апам! Бәгырь кисәгем!

Гөлсинә. Минем сиңа әйтер сүзем юк!

Фирая *(күз яшьләрен сөртә).* Апа! Жизни! Зинһар... мине... аңларга тырышыгыз... Минем бик тә, бик тә артистка буласым килде!..

Азат. Син хәзер үк артистка инде, Фирая!

Фирая. ...Авылымны да бик яратам мин. Аны яшәтәсем килә! Яшисем килә минем!

Камил. Син яшәячәксең, Фирая!

Азат. Без әле яшибез, Фирая! Дөньяның артына тибеп яшәячәкбез!

Фирая. Сезнең алда уйнап, үземне тагын бер кат сыныйсым килде... Сынаттым!

Рәшидә. Сынатмадың, Фирая...

Азат. Булдырдың!

Фирая. Апа! Син... сез... өйдә юк чакта... Гаилә үзәгеннән шылтыраттылар! Синең балаң булачак, апа! Жизни! Сезнең балагыз булачак!

Гөлсинә. Ә?! Чынлапмы? *(Үзәк өзгеч тавыш белән).* Рәү-е-еф!!!

Рәүф *(Гөлсинәне кочагына алып).* Кадерлем минем, бердәнберем! Гөлсинәм минем!!! Шатлык бер килсә, ишелеп килә ул... Без Парижга барачакбыз! Мине симпозиумга чакыралар. Сине дә үзем белән алам!

Азат. *(Рәүф белән Гөлсинә янына килә).* Сез иң бәхетле кешеләр бүген! Сезнең хөрмәткә миннән бер анекдот!..

Рәүф. Азат, берүк хәзер сөйләмә... Башка вакытка калдыр, яме!

Азат. Ихтыярыгыз...

Гөлсинә. Ашыйсың килмиме, Азат?

Азат *(хисләнеп).* Аһ... ниһаять! Затлы кешедән татлы сүз! Рәхмәт, рәхмәт... Бераздан, ямегез! *(Камил белән Рәшидә янына килә).* Күрәзәлек итү сәләтем юкюгын... Әмма күңелем сизә... Сез бергә булачаксыз, дуслар! Миннән фатыйха!

Рәшидә. Авызыңа бал да май!

Камил. Азат, гел бергә булыйк, аерым торыйк! *(Көлеш).*

Азат *(Фирая янына килә).* Фирая! Фираякай... Син...

Фирая. ...мин риза!

Азат. Кычыткан чыпчыгым мине-е-ем!.. *(Фираяны күтәреп ала).*

*Дәртле, күңелле музыка.*

*Пәрдә.*

---

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЕЛЪЯЗМАСЫ



75 ел элек (1935 ел) «Совет әдәбияты» журналында (12 сан) **Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»** повестеның азагы;

65 ел элек (1945) «Совет әдәбияты»ның 12 санында **Гомәр Бәшировның «Намус»** романыннан өзек;

60 ел элек (1950) «Совет әдәбияты»ның 12 санында **Әхмәт Фәйзинең «Тукай»** романыннан азак өлеше;

50 ел элек (1960) «Совет әдәбияты»ның 12 санында **Зәки Нуриның «Үлгәннәр дә үч алды»** (партизан хикәяләре) әсәре, **Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»** пьесасы;

40 ел элек (1970) «Казан утлары»ның 12 санында **Шамил Рәкыйповның «Таңнар һаман матурмы?»** повесте, **Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур»** тарихи романының азагы;

35 ел элек (1975) «Казан утлары»ның 12 санында **Вакыйф Нуруллинның «Яшьнәп үткән яшьлек»** повестеның азагы;

25 ел элек (1985) «Казан утлары»ның 12 санында **Ибраһим Сәлаховның «Имәннәр тамыр җәйгәндә»** романы дөнья күргән.

Мөҗәһит

## Матур кешеләр бар

Шундый матур кешеләр бар
Арабызда.
Күңел күзегезне ачып
Карагыз ла.

Нурлар балкып тора йөргән
Юлларында
Ут уйната алар гади
Кулларында.

Телләрендә бары күркәм
Сүзләр генә.
Күпне өмет итмәс алар
Үзләренә.

Вәгъдәләре иман булыр,
Ялган булмас.
Беркайчан да алар яман
Гамәл кылмас.

Дәрәҗәгә омтылмаслар,
Тыйнак алар.
Гаделлектә сине кат-кат
Сынар алар.

Туганнарга туганнарча
Мөнәсәбәт.
Көрәшергә чыгып торыр
Һәрчак сәбәп.

Шундый матур кешеләр бар,
Күрәсездер.
...Әле бергәләшеп гомер
Сөрәсездер.

## «Татар» дисеннәр

Исемебез татар безнең,
Татарстан—туган җир.
«Туган тел» не җырлый-җырлый
Гомер итә торган җир.

«Татар барда хәтәр бар»,—дип,
Әйдә, әйтә бирсеннәр.
Хәтәрлек—яуда, тик бүген
Хәтерсез димәсеннәр.

Чакырылмаган кунакны
Тиңләсеннәр татарга.
Татарларча кунакчыл без
Дусларга һәм ятларга.

Татарга тылмач кирәкми,
Без барсыннан хәбәрдар.
Таңга калып карап тора
Тарихи хәрабәләр.

Татар булсак та болгарның
Каны безнең каннарда.
Сынган чакта егылмадык,
Янмадык ялкыннарда.

«Татар барда хәтәр бар»,—дип,
Әйдә, әйтә бирсеннәр.
Дөнья тарихында, ләкин,
Хәтерсез димәсеннәр.

## Илһам Шакировка

Бәхет касәм тулмас иде,
Илһам абый, син булмасаң.
Моңнарыңа сихерләнәм,
Җырларыңны мин тыңласам.

Актарыла бәгырьләрем,
Күзләремне яшьләр баса.

Югыйсә син гап-гади бер
Сарман егете ләбаса.

Ишетсеннәр иде сине
Дөньяда бар кыйтгалар да:
Җирдә татар барлыгына
Ышаныр иде алар да.

## Нигә елап торырга?

Җизни дигән бер абый
Алып китте апаны.
Үзем ачып чыгардым
Үзебезнең капканы.

Апам бездән киткәндә,
Гармуннар уйнадылар.
Әнием дә, әбием дә,
Белмим, ни уйладылар,
Әзрәк еладылар...

Югыйсә җизни апаны
Күтәреп кенә йөртте.
Бөтен кеше алдында,
Оялмыйча, бер үпте.

Шулай булгач, ул апаны
Ярата бит. Ә нигә
Елап торырга ди инде
Әби белән әнигә?..

## Бүген шигырь бәйрәме

Шушы залга җыелган күк
Табигатьнең бар яме.
Бүген хисләр чәчәк ата,
Бүген шигырь бәйрәме.

Чәчәкләрдән ява сыман
Сихри сүзләр бәйләме.

Нинди көн бу? Тукай көне!
Бүген шигырь бәйрәме!

Әллә язгы чәчкәләр дә
Безгә сәлам бирәме?
Алар да пышылдый кебек:
«Бүген шигырь бәйрәме!»

**Редакциядән:**

*Декабрь аенда каләмдәшебез—Мөслимдә яшәүче балалар шагыйре, педагог, Татарстанның атказанган укытучысы, А. Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Мөҗәһит Әхмәтҗанова 60 яшь тула. Аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.*

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1909 ел

**6—24 гыйнвар.** «Вакыт» газетасы берничә санда рәттән түбәндәге игъланны биреп барган:

«Шигырьләр көтепханәсе». 7 нче дәфтәр. Г. Тукай. «Печән базары, яхуд яна Кисекбаш». Үткен телле, милләтемезнең мәшһүр шагыйрьләреннән Габдулла әфәнде Тукаев әсәре. Күпләп соратучыларга адрес: Казан, «Үрнәк» матбагасы.

Назик вә гали хисләр жырлаучы шагыйремезнең иң соңгы гүзәл шигырьләре бу мәжмугададыр.

Казан гавамына мөһим саналган хәбәрләр вә мәсьәләләр бу китапта бик килешле сурәттә жәмигъ ителеп, бик кызык көленмештер».

**14 гыйнвар.** «Габдулла Тукаев диваны» исеме белән шигырьләр жыентыгы дөнья күрә. («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр. 3 нче кыйсем, Казан, «Гасыр» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы, 48 б., 6000 данә.)

**20 гыйнвар.** «Әл-ислах» газетасы хәбәр итә: «Гасыр» көтепханәсе ачылды! Казанда, Екатерининский урамында, Ибраһимовлар йортында.

*Хөрмәтле укучылар!*

Без, ике сәнәгә якын дәвам иткән нәшрият эшемезне тагын да мөкәммәл сурәттә тәрәккый иттерергә ижтиһад итеп, «Гасыр» көтепханәсе исемендә бер китап мәгазәсе ачарга мөвәффәкъ улдык. Нәшриятымызга матди вә мәгънәви ярдәмче булган мөхтәрәм укучыларга тәшәккер итеп, көтепханәмезнең ачылганыны белдерәмез.

Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкәсе».

«Гасыр» көтепханәсе Тукайның китаплары дөнья күрү һәм аның катнашында үткәреләчәк әдәби кичәләр турында игъланнарны еш бастырып торган.

«Әл-ислах» газетасы хәбәр итә: «Габдулла Тукаев диваны» басылып чыгып сатыла башлады. Киләчәк номерда мөхакәмә дәрж ителер».

**3-4 февраль.** Тукай Казанга килгәч аралашкан чордашы, язучы һәм гарәп мәдәнияте тарихы белгече Ш. Шәрәф (1878—1938) белән очраша.

**7—12 февраль.** «Вакыт» газетасы «Печән базары, яхуд яна Кисекбаш» китабы дөньяга «чыгу турында кат-кат хәбәр итә.

**10 февраль.** «Күнел» һәм «Васыятем» исемле шигырьләре дөнья күрә.

**6 март.** «Габдулла Тукаев шигырьләре» жыентыгы басылып чыга. («Шигырь көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. 1 нче кыйсем. Икенче табгысы. Казан, «Үрнәк» матбагасы, 48 б., 4000 данә).

**11 март.** «Габдулла Тукаев шигырьләре» басылып чыга («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. 2 нче кыйсем. Икенче табгы. Казан, «Үрнәк» матбагасы).

**26 март.** «Энже бөртекләре» исемле жыентыгы (Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга.

**29 март.** «Пәйгамбәр» шигыре басылып чыга. «Лермонтовтан үзгәртелгән» дип куелган. М. Ю. Лермонтовның «Пророк» (1841) исемле шигыреннән файдаланыпназыйрә рәвешендә язылган романтик шигырь.

**21 апрель.** «Исемдә» дигән шигыре дөнья күрә.

Астөшермәдә: «Бу шигырьне Габделләтыйф Мостафин тарафыннан телемезгә

*Дәвамы. Башы 8 санда*

тәрҗемә кыйлынган русча бер пьесада күптән түгел генә гыйффәтен җуйган бер кыз үзенең бәхетле заманнарын сагынып җырлый. Пьеса басылып чыккач укылса, тәэсире артыграк булыр»,—дигән искәрмә бирелгән. Бу пьеса «Җинел хезмәттә» дигән исем белән шул ук елда «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан Казанда И. Н. Харитонов матбагасында дөньяга чыгарылган. Тәрҗемәчесе—Ләтыйф Мостафа. «Исемдә»не пьесаның төп герое Гайшә җырлый. Астөшермәдә «Бу шигырьнең мөтәрҗиме мәшһүр шагыйремез Г. Тукаев» дигән сүзләр бар.

**29 апрель.** «Матбугат каһарманнары» дигән фельетоны «Мин язмадым» имзасы белән басылган. Шунда ук «Номерга төшкән искеләр» һәм «Ишан» дигән шигырьләре урнаштырылган.

**26 май.** «Ике кояш» исемле шигырен яза. Шигырь беренче татар профессиональ актриса, Татарстанның атказанган артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга (1892-1974) багышлап язылган. С. Волжскаяның Татарстан Үзәк дәүләт архивында саклана торган альбомында шигырьнең Тукай кулы белән язган кульъязмасы да теркәлгән.

**Җәй.** Московская урамындагы (хәзерге Киров урамы) «Москва» номерына урнаша. Монда Тукай бик аз гына торган булырга тиеш. Ул күбрәк «Болгар», «Амур» кунакханәләрендә яши.

**2 июнь.** «Йолдыз» газетасы хәбәр итә: «Яңа китаплар басылып чыкты. Г. Тукай. «Алтын әтәч».

**21 июнь.** «Эштән чыгарылган татар кызына» шигыре «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

**21 июнь.** «Татарча театр» исеме белән «Хуҗа һәм приказчик» дигән спектакльгә язылган рецензиясе басылып чыга.

Һәвәскәр артистлардан аермалы буларак, «Сәйяр» труппасы артистларының уеннарын мактап, аларның профессионаллар дәрәҗәсендә торуларын әйтә. Бигрәк тә Г. Кариев (1886—1920), Н. Сакаев (1885—1927), В. Мортазин-Иманский (1886—1937), С. Гыйззәтуллина-Волжская (1892—1974) турында сүз алып барып, аларның тамашачы күңелен җәлеп итәрлек, табигый рәвештә уйнауларын ассызыклый. «Галимҗан ролен уйнаучы Кариев үзенең җанлы хәрәкәте вә килешле кыйланышы вә кирәк урыннарда төсен вә сүзнен тонын үзгәртә белүе илә хәзер генә базардан сәхнәгә тамашага тотып кертелгән бер татар бае иде».

**24 июнь.** «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Бәгъзе зыялыларымыз» һәм «Татар бае» дигән шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шунда ук «Милләтче» фельетоны «Шүрәле» имзасы белән һәм «Гөмберт» имзасы белән «Безнең заман вә Сәгъди абзый» исемле фельетоны урын алганнар.

**Җәй.** Мәхмүт Дулат-Алиевнын (1889—1920) чакыруы буенча, Дулат-Алиевлар өендә, Яңа Бистәдә Мехчылар урамындагы (элек Большая Симбирская дип йөртелгән) 37 нче йортта 15—20 көн чамасы кунак була. Мәхмүт һәм иптәшләре белән йортның түрендә—печәнлектә йоклый. Якын дусты Вафа Бәхтияров та берничә мәртәбә аның янына барганы хакында яза.

«1909 елның җәендә шагыйрь Гурьевкада фабрикант Хәсән Акчуриннарда кунакта була. Хәсән бай татарча да, русча да шактый мәгълүматлы кеше булып, милли мәдәниятнең барышы белән кызыксынып торган, аны күтәрү хакына акчалата ярдәм иткән, ара-тирә җәмәгать эшләрендә катнашкан кеше.

Гурьевкада фабрикант Акчуриннарда булып кайтканнан соң, апасы Газизә Зәбировага хат яза. Хатның сәфәргә кагылышлы өзеге вафатына бер ел тулу унае белән басылган мәкалә эчендә китерелгән: «Казаннан бер дә читкә чыкканым юк, диер идем, әле шул арада гына Сембер ягындагы Хәсән Акчурин дигән фабрикантка барып, биш кич куныш кайттым. Бер дә көтмәгәндә, ансыздан хәбәр бирделәр. Мин үзем Казанда да шалапай йөрим. Рәтләп киенергә дә, юынырга да өлгерә алмадым. Алар, әлбәттә, бай кешеләр. Сыйлауларын язудан каләм гаҗиз. Бару-кайту расходы алардан. Шунын өстенә, киткәндә, 50 тәнкә акча һәм киемлекләр биреп җибәрделәр. Бер белмәгән, танымаган кешенең кисәктән шундый хөрмәт күрсәтүе гаҗәп түгелме? Гаҗәп булган өчен яздым».

**22 сентябрь.** «Китап» шигырен яза.

**29 сентябрь.** «Исемдә калганнар» исемле автобиографик хикәясенең кереш өлешен (мөкаддимә) язып тәмамлый.

«Бу «Исемдә калганнар»ны язуыма башлыча сәбәп берничә нәширләрнең миннән тәрҗемәи хәлемне язып бирергә үтенүләре булды.

Мин аларга туганымнан алып хәзерге яшемә кадәрге тәрҗемәи хәлемне кыска гына рәвештә язып бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте.

Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шунын белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарнын һәммәсен язасым килде.

Шунлыктан Уральскига килеп житкәнемә кадәр кичердегем хәлләр илә аннан соң шушы сәтырларны язып утырган вакытыма кадәрле башыма килгәннәрне икесен ике рисалә итеп чыгарырга мәгъкуль күрелде». Керешнең азагында Тукай үз кулы белән «29 нчы сентябрь, 1909 сәнә» дип язып куйган.

**27 октябрь.** «Әдәбият» исемле шигырьләр жыентыгы («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр. Казан, «Үрнәк» матбагасы. Беренче битендә Тукайның рәсеме дә бар) басылып чыга.

**12 ноябрь.** «Исемдә калганнар» исеме белән автобиографик әсәре (Казан, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга. Тышлыкта Тукайнын фоторәсеме бирелгән. 38 б., 4000 данә.

**23 ноябрь.** «Балалар күнеле» исемле китабы (Беренче жөзьэ. Ибтидаи мәктәпләр өчен шигырьләр мәжмугасы. Казан, «Сабах» көтепханәсе, И. Н. Харитонов матбагасы)** «Сабах» ширкәте идарәсеннән кереш сүз белән басылып чыга.

**27 ноябрь.** «Кинәш (Чикмә гамь шул нәрсәгә...)» шигырен яза.

**28 ноябрь.** «Әдәбият» исемле шигырьләр жыентыгы һәм «Исемдә калганнар» әсәренең дөнья күрү уңае белән «Вакыт» газетасы игълан итә: «Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр». Мәшһүр шагыйрьләремездән Габдулла әфәнде Тукаев әсәре, шагыйрьнең рәсеме илә.

«Исемдә калганнар»—шагыйрьнең автобиографиясеннән бер өзек (үз каләме илә язылган тәрҗемәи хәленнән)».

**29 ноябрь.** «Кинәш» шигыре басылып чыга.

**1 декабрь.** «Вакыт» газетасы хәбәр итә: «Сабах» көтепханәсе. Балалар бәхетенә зур бер адым. Шагыйрь Габдулла Тукайның «Балалар күнеле» намендәге әсәреннән беренче жөзьэ басылып чыкты».

**17 декабрь.** «Теләү бетте» шигырен яза.

**19 декабрь.** «Идел» газетасы хәбәр итә: «Яңа әсәрләр. 1. «Исемдә калганнар» Г. Тукаев. 2. «Әдәбият». «Шигырь мәжмугаларыннан 10 нчы китап улан бу әсәре янә Габдулла Тукаевнныкыдыр. Һәр икесе «Юл» көтепханәсе нәшрияты».

**20 декабрь.** «Теләү бетте» шигыре басылып чыга.

**31 декабрь.** Габдулланың бабасы (әнисенең әтисе) Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмиров үлә (1829 елнын 30 декабрендә туган). Өчиле авылы имамы булып торган. Өчиле авылы зиратына жирләнгән.

**1909—1910 еллар.** Тукай вакыт-вакыт Казанның Яңа бистәсендәге Мәхмүт Дулат-Алиевлар йортына килеп чыга, кеше күзеннән югалып торып, иҗат эше белән шөгыльләнә.

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Марс Ахунов

# КЫЧЫТКАН ТЕЛНЕ СҮЗ КАШЫР

**Кызганычка каршы, янында һәрвакыт син алардан ераграк торырга тиешле кешеләр була.**

**Сатучы белән сатып алучы арасында әдәпле мөнәсәбәт бер ертык унлык аркасында бозыла.**

**«Исереккә сәлам бирмә, ул бирсә дә алма!»—диләр... Аекларны каян табасың ди инде хәзер?**

**Телереклама вакытында, шәһәрнең Канализация хезмәтенә көч килә!**

**Әгәр дә син җирдә яткан 10 тиенлек акчаны иелеп ала аласың икән, димәк, табибка «радикулит өчен» биргән өч мең тәңкә акчаң әрәмгә китмәгән...**

**Хәтта колорадо коңгызларына сибә торган агуларны да төрләндереп торырга кирәк.**

**Бокс—шешә авызы белән кеше бугазы арасындагы «киртә».**

**«Алма пеш, авызга төш»,—дип ятучылар бихисап, ә алмагачта сыңар алма да юк.**

**Кеше булып калыйм дисәң һәрвакыт кеше комачаулый.**

**Вак бәлешләр пешергән саен вагая бара.**

**Теше белән шешәне бик оста ачканга күрә, аны үзләре белән шешә ачкычы урынына йөртә башладылар.**

**Кирәкмәгәнгә—кулы озын, кирәккәнгә—кулы җитми.**

**Машина артка чигенгәндә тагылган арба алга чыга.**

**Җырчыга бәйгедә беренче урынны алу өчен бер тавыш җитмәде—үз тавышы.**

**Пляждагы белдерү: «16 июльгә кадәр җылы су булмаячак».**

**Ябыгырга теләсәгез, депутатлыкка кандидатларның вәгъдәләре белән туеныгыз.**


**Ишек алдындагы бөтен өстәлләрне домино сугучы пенсионерлар алып бетергән, безнең мескен балаларга утырып кәрт уйнар җир дә юк.**

**Минемчә, илгә президентлар бөтенләй дә кирәк түгел: Кремльдәгеләр илдәге халыкны, авыл көтүе кебек, чиратлашып көтсеннәр!..**

**Сәхнә теле—тамашачыга чыгарып күрсәткән тел.**

---

## РӘСЕМ БЕЗДӘН, ҖАВАП СЕЗДӘН...



Әлеге фотога иң уңышлы рәсем асты уйлап табучыны журналыбызга ярты еллык бушлай әбунә көтә.

Сездән дә кызыклы вә кәттә фотолар көтеп калабыз...

# «ӘНИ...» КҮП ТЕАТРЛАРГА КИЛДЕ

## (Мәшһүр драманың туу һәм СССР театрларын яулау тарихы)

СССРНЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ
ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

**—Гадәттәгечә, бу юлы да мин сезнең янга, Шәүкәт абый, Галиәсгар Камал исемендәге атаклы театрыбыз һәм даны ерак-еракларга таралган аның бер спектакле хакында сөйләшү нияте белән килдем. Нәкъ кырык ел элек куелган, сез үзегез дә катнашкан «Әни килде» спектакле турында әйтүем.**



—«Әни килде»гә хәтле дә Шәриф Хөсәенов язган пьеса персонажларын уйнаган артист буларак, мин бәләкәй генә чигенеш ясап алыйм әле, алайса. 1949 елда театр училищесын тәмамлап, Татар академия театрында эшли башлавымны, һәм шуннан армиягә алынуымны беләсез инде—бу турыда сезгә сөйләгәнем бар. 1953нең көзендә генә армиядән кайттым. Театрыбызның яңа сезоны исә ул елда «Профессор кияве» дигән спектакль белән ачылды. Һәм спектакль мине хәйран калдырды.

**—Шулай укмыни?! Шәриф Хөсәенов үзе исә 1991 елда Татарстан Фәннәр академиясенә юллаган хатында бу пьесасы хакында бик примитив иде дип язган.**

—Туксан беренче ел күзлегеннән караганда примитив булып тоелуы—бер дә гаҗәп түгел. Кырык ел үткән бит! Әсәр туган вакытында исә һәм яңалыгы, һәм актуальлеге белән бөтен шәһәрне таң калдырды, Татарстанның бөтен авылларын урады. Уйлап кына карагыз: Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Мәхмүт Галәү әсәрләре тыелган, татар сәхнәсе тәрҗемә пьесалар белән чуарланган чор бу. Менә шул чакта туган, татар яшьләренең сугыштан соңгы тормышын сурәтләгән «Профессор кияве»нең әһәмияте һәм дәрәҗәсе бәяләп бетергесез булды. Жәл, сезнең буын аны күрмичә калды. Әсәрнең төп героинясын уйнаучы Рауза Уральская вафатыннан соң спектакль яшәүдән туктады. Рауза, аңа гыйшык тотучы егетне башкаручы Вәкил Закиров, Дэллюс Ильясов, Рәфкать Бикчәнтәевләрнең искиткеч уены әле бүген дә күз алдымда тора. Шушы спектакльдән соң мине Рәфкатькә охшатып, сезнең кайсыгыз Бикчәнтәев тә, кайсыгыз Биктимеров соң дип, безне бик озак бутап та йөрделәр.

**—Бу буталыш Хәй Вахит пьесасы буенча алтмышынчы елларда Рәфкать Бикчәнтәев куйган «Беренче мәхәббәт» спектакленнән соң тагын да көчәйгәндер әле. Чөнки Бикчәнтәев үзе анда Әпсәләмне, ә сез Тәлгатьне уйныйсыз бит. Мин сезне тәүге тапкыр шушы спектакльдә күреп, образга бик табигый керә алуыгызга сокланган идем. Шушы ук чорда (1961) Шәриф Хөсәенов та остазы, режиссер Габдулла Юсупов үтенече белән яза башлаган «Зөбәйдә—адәм баласы» дигән гаҗәеп пьесасын тәмамлый. Икенче тапкыр мин сезне шул спектакльдә күрдем.**

—И-и, Рәйсә ханым, бу чакта инде мин Шәрифнең бер генә пәрдәле «Бирнәле кыз»ында студент егетне уйнап чирканчык алырга, байтак кына спектакльләрдә катнашырга өлгергән идем.

**—«Бирнәле кыз»дан соң ук туган «Чулпан» пьесасының язмышы хакында белмисезме? Шәриф абыйның илле алтынчы елда сөйгәненә язган хатында: «...Менә үземнең соңгы эшем—бичара «Чулпан»ымны да сиңа багышладым. Аһ, минем аны сиңа шундый укыйсым килә!..»—дигән юллар бар.**

—Безнең җәмгыятькә хас булмаган трагик вакыйгалар сурәтләнә дип, аны обком тыйды бугай. Һәрхәлдә, минем хәтергә шулайрак сеңгән.

**—Режиссер ашыктыра-ашыктыра яздырган «Зөбәйдә—адәм баласы»ның Академия театры сәхнәсендә дүрт елдан соң гына пәйда булуы да партия өлкә комитеты белән бәйлеме?**

—Шәрифнең бу әсәренә карата түрәләрнең мөнәсәбәте миңа мәгълүм түгел. Әмма театрыбызда барган хәлләрдә өлкә комитетының турыдан-туры катнашы булуын беләм. Шәрифтән үтенеп сорап, таләп итеп яздырган бу пьесаны театрыбызда кую Габдулла абый Юсуповның үзенә насыйп булмады шул. 1961 елда аның урынына режиссер итеп татарның җан-рухын аңламаган, гореф-гадәтен, телен белмәгән бер рус кешесен китерделәр.

**—Рус кешесен? Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрынамы?! Кем иде инде ул?**

—Александр Михайлов. Өч спектакль куйды, әмма аларның берсен дә татар тамашачысы кабул итмәде. Шуннан соң үзе үк китәргә мәҗбүр булды, бахыр. Ул киткәч кенә Хөсәен абый Уразиков «Зөбәйдә—адәм баласы»н куярга алынды... Ул вакытта без спектакльләребез белән Ульяновскида идек. «Зөбәйдә—адәм баласы»на репетицияләр башланды дип, гастрольләрне өзеп, безне чакырып алдылар.

**—«Без...»—дияегез белән үк Наилә Гәрәева, Гәүһәр Камалова, Хәлим Җәләловлар уены күз алдыма килде. Аһ, Наилә Гәрәеваның ул Зөбәйдәсе! Ялгыша-ялгыша, бәргәләнә-бәргәләнә үз-үзен табуы! Зөбәйдәгә гашыйк Әсхәт-Хәлимнең күгәрченнәре белән мәш килүләре!.. Гәүһәр апа Камалованың уены, аның әле хәзер дә колакта сакланган «әйтеп, әйтеп, әйтеп әйтәм» кебек гыйбарәләре!.. Ә сез... сез бик тә шәп егет—самосвалның шәп шоферы булып хәтергә уелгансыз... Фирдәвес Әхтәмованың озын чәчле Кәримәсе дә, Ирек Баһмановның ялкау Фәрите дә истә. Хөсәен абый Уразиков үзе исә Вера апа Минкина башкарган Җәүһәриягә өйләнергә йөрүче хәйләкәр Сәмигулла картны уйнап, театр эчендә янә бер театр ясаган иде... Яшьлегебезгә тәңгәл килгән ошбу спектакльнең тууына һәм Казаныбызны шаулатуына без—студентлар—бик сөенгән идек.**

—Шәрифнең әсәре... әсәре нинди бит! Казан гына шауладымы соң?! Нәкъ шул вакытта Габдулла абый Юсупов та «Зөбәйдә—адәм баласы»н Әлмәт театрында куеп, нефтьчеләр каласын хәйран калдырды; аннары бу спектакль белән Татарстанның бөтен авылларын шаулатты.

**—1968 елда Шәриф Хөсәенов «Әни килде» драмасын тәмамлый. Һәм аның бу әсәре дә «Зөбәйдә—адәм баласы» язмышына дучар була. Ягъни Камал театры сәхнәсенә 1970 елда гына менә. Шәриф абый белән шул елларда аралашкан Гөлсем ханым Исәнгулова: «Башта «Әни килде»не Празат Исәнбәт куярга тиеш иде, нигәдер озакка сузылды. Менә шул чакны Шәриф борчылудан җиде килога ябыкты» дип искә ала. Театрның эчке тормышы белән генә бәйле идеме бу? «Озакка сузылу»ны әйтүем.**

—Шәрифнең бу әсәренә кагылышлы вакыйгаларны яхшы хәтерлим. Бер мәлне белдерүләр тактасына һәммәбезне сөендергән приказ эленде. Анда театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗановның фәрманы—«Әни килде» спектаклен кую вазифасының Празат Исәнбәткә йөкләнүе, Ана роленә зур шөһрәткә ия атаклы актриса Фатыйма Ильскаяның билгеләнүе игълан ителгән иде.

**—Фатыйма апаның ул рольдән баш тартуын беләм. Бу турыда бер әңгәмәбездә Академия театрының директоры Шамил әфәнде Закиров болай дигән иде: «Режиссерларның Фатыйма Ильскаяны гел баш рольләрдә, гел яшь кызларны гына уйнатуы аның холкына да нык тәэсир иткән булса кирәк. Хатасымы, бәхетсезлегеме дигәндәй, өлкән яшьтәгеләр роленда уйнарга теләми ул. «Әни килде» драмасындагы Ана ролен тәкъдим итәләр. Әмма Ильская: «Мин авыру карчыкларны уйнамыйм!»—дип, бөек Ана роленнән баш тарта. Татар театры тарихында рольдән баш тарту кебек хәлнең бүтән булганы юк...»**



*Шәриф Хәсәенов.*

—Бу хәлне баштарак мин дә Фатыйма апаның горур-кырыс холкы, тәкәбберлеге белән бәйли идем. Хәзер менә бүтәнчәрәк фаразлыйм: олыгаеп килүче, аяклары сызлау белән дә җәфа чигүче Ильская Ватан белән тиңләштерелгән бөек Ана ролен күтәрә алмам, уйный алмам дип курыккандыр, минемчә.

**—Хуш, Празат абыйның спектакль чыгаруны сузуы әлеге хәлгә генә бәйле түгелдер бит.**

—Празатка—затлы, зыялы, сирәк очрый торган интеллигент шәхескә—спектакль тудыру кебек җаваплы иҗат эшенең башында ук мондый хәлгә юлыгуның күпмедер дәрәҗәдә тәэсире булгандыр, мөгаен. Ана роленә искиткеч талантлы Галимә апа Ибраһимова билгеләнгәч тә аның үзгәрмәвенең, һаман сүлпән булуының сәбәбен мин соңрак—Шәриф әсәренең үзеннән таптым. Врач әдип «Әни килде» драмасында дөньякүләм проблема—наркомания афәтенең илебезгә, гаиләләребезгә үтеп керүен күрсәтеп, беренче булып кешеләрне кисәтә, бу фаҗигагә каршы чаң кага... «Совет чынбарлыгына яла ягучы» мондый спектакльне обкомның куйдыртмаячагын белә торып иҗат итү җиңел булмагандыр, билгеле. Ел ярымнан соң, Празатны бу газаптан коткарып, спектакль әзерләү эшенә Марсель үзе тотынды. Һәм әйбәт спектакль тудырды.

**—Һай, ул спектакль! Берьюлы бер составта СССРның өч халык артисты уйнаган бүтән татар спектаклен белмим мин. Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимеров, Фуат Халитовлар исеме ул чакта теллэрдән төшмәде. Ә илаһи нуры белән үк бөтен сәхнәне балкыткан Галимә апа Ибраһимова исә мәгърур Ана булып, тере легендага әйләнде. Язгы ташудай халык агылган бу спектакльне тыярга өлкә комитеты җөрьәт итмәгәндер, шулай бит?!**

—Обком диюгә искә төште менә: спектакль чыккан көннәрдә—аның премьерасы 1970 нең 26 мартында булды—Марсельнең үзен генә дә, шул чактагы директорыбыз Рәшидә апа Җиһаншина белән икесен бергә дә ул оешмага еш чакырып алдылар. Күңелсезләнеп кайткан чакларын да хәтерлим. Югары оешмалар алдында «күндәмлек күрсәтеп», драма авторы Шәрифкә дә, спектакль режиссеры Марсельгә дә—әсәргә артык зыян китермәслек дәрәҗәдә барыбер ташлама ясарга туры килгәндер дип уйлыйм. Спектакльдән «наркотик» эпизодының алынуы да, Ана дисбесенең күлмәк кесәсендә генә калуы да шуны раслый.

**—«Наркотик» эпизодыннан башка да, актерларның искиткеч уены әлеге афәтне гел искәртеп торды. Ринат Таҗетдинов иҗат иткән Инсафның, мәсәлән, «морфий» сүзеннән үк сискәнүе, авыру Анага укол кадаучы шәфкать туташы тарафына ирексездән сузылган кулларын тыярга тырышкан газаплы халәте әле һаман күз алдымда. Сугыштан аяксыз кайткан ошбу ир-егетнең Ватан сугышы китергән афәт турындагы монологы да җаннарны тетрәткән иде... Ә сезнең үзегезгә—тискәрелеге белән тиңдәше булмаган образ иҗат итүегезгә бәйләнмәделәрме соң?**

—«Өстәгеләр»нең мактап та, хурлап та турыдан-туры үземә сүз әйткәннәре

булмады. Ә менә Шәрифне чакырганнар икән. Бермәлне ул мине урамда очратып: «Спектакльдә үзләрен таныган туганнарым минем өстән жалоба белән обкомга барганнар. Миңа каты гына эләкте. Син сакланып йөр! Син башкарган Исламның прототипы—бертуган абыем: «Шәүкәтегезне үтерәм!» дип янады...» кебек сүзләр әйтеп, үземне кисәтте, уяу булырга киңәш итте... Мин башкарган бу персонажга тамашачы мөнәсәбәтен беләсездер инде. Миңа, театрга Марсель Сәлимжанов килгәнче гел социаль геройларны: кызыл галстуклы пионердан алып, комсомолын да, большевик-комиссарын да уйнап, гел алкышлар гына яулаган актерга—бу юлы ул каргыш яудырды. Татарстан гастрольләре вакытында алгы рәтләрдә тезелешеп утырган өлкән яшьтәге апаларның ачулы карашын тоеп уйный идем. Баулы сәхнәсендә бермәлне, мәсәлән, үсмер малай ыргыткан таш бик әздән генә башыма тими калды... Андый чакларда мин, кешеләрнең үзәкләренә үтәрлек итеп уйнаганмын икән дигән канәгатьләнү хисе кичереп, халыкның әхлакый рухы таза булуына сөенә идем. Ананың мещанга әверелгән бу юньсез баласы Исламга карата булган тамашачы нәфрәтен тою миңа алкышлардан кадерлерәк иде.

**—Анның каравы, сезнең уенны, сез башкарган ул тискәре персонажны театр сәнгате белгечләре югары бәяләде. 1970 елның көз айларында «Театр» журналында И. Романович, О. Кайдаловаларның «Әни килде» спектакленә багышланган мәкаләләрен укып, театрыбыз өчен, сез артистларыбыз өчен горурлануым истә.**

—Әнә шул елның июлендә безнең театрны Мәскәүгә гастрольгә җибәргәннәр иде бит. Анда «Әни килде» спектакле зур уңыш казанды. Бу турыда шул вакытта Мәскәүдә чыккан бик күп газета-журналларда яздылар. Әнә, ул стенам буйлап төргәк-төргәк өемнәр ята. Зур бер өемдә—бөтен илгә таралучы «Правда», «Сельская жизнь», «Комсомольская правда» һәм төрле исемдәге Мәскәү газеталары. Аларның һәрберсендә безнең театрга, «Әни килде» спектакленә багышланган мәкаләләр бар. Шул рәвешле бу спектакльнең даны без Казанга кайтып җиткәнче үк бөтен Союзга таралып өлгергән иде инде. Гөрләп узган шул гастрольдән соң труппаны «Әни килде» спектакле белән СССРның иң зур театрлары чакыра башлады.

**—Әүвәл әнә шул өемнәр турында. Ничек җыя алгансыздыр, белмим; бу бит... бу бит—театр тарихы! Ярты гасырны сыйдырган мондый зур байлыкны ник өйдә асрыйсыз, нигә театрга, Луара Шакирҗановага тапшырмыйсыз? Ул сезгә бик рәхмәтле булыр һәм аларны күз карасы кебек саклар иде. Кирәк булганда театр белгечләре дә, журналистлар да файдаланыр иде.**

—Луараның кысан музей бүлмәсендә кәгазь бите сыярлык та урын юк. Театрга тәгаенләнгән музей бинасына Ходай кушып, җитәкчеләр акча биреп, капиталь ремонт ясалса, шундук тапшырыр идем дә бит... Рухи байлыкларга күк капусы ачылганы әлегә бер дә күренми шул. Әле шушы көннәрдә генә театрыбыз директоры Шамил Закиров, үзе белән музей хезмәткәре булачак бер кызны да алып килеп, бу өемнәрдәге байлыкның каталогын төзергә кушты. Иншалла, югалмаслар, киләчәктә театр музее киштәләрендә үз урыннарын алырлар дип өметләник.

**—Инде гастрольләрегез хакында... Шушы көннәрдә генә Камал театрының әдәби бүлек мөхәррире Гөлнур ханым Гыйматова белән компьютер аша «Әни килде» спектакленең гастрольләр маршрутын барлап утырдык. Мәскәү (1970 ел), Уфа (1971 ел), Алма-Ата, Фрунзе, Ташкент (1972 ел), Чиләбе, Оренбург, Свердловск (1973 ел), Куйбышев, Ульяновск (1974 ел), Әстерхан, Баку (1977 ел) шәһәрләре!.. Әлеге шәһәрләрдәге тамашачы «Әни килде»не ничек кабул итте соң? Хәер, бик күп вакыт узды бит—онытылгандыр инде.**

—И, халык рәхмәте—алкышларга уралган «браво», «яшә», «афәрин» сүзләре онытыла димени?! Театр яннары тулы халык!.. Билет табуга өметен әзмәгән кешеләр камалышында калган чакларыбыз булды. Спектакльне караганнан соң хуҗа-режиссерларның «Әни килде» драмасын сорап Марсельне йөдәтүләренә чаклы истә... Кыскасы, «Әни килде» спектакле һәр җирдә ажиотаж тудырды.

**—Үзебезнең Казаныбыздагы кебек булган инде алайса. Камал театрының Горький урамындагы ул чагын хәтерлим. «Әни килде»гә ашыгучыларны һәрчак «артык билетыгыз юкмы?» диюче төркемнәр каршылый иде. Һәм һәр спектакле саен шушындый хәл. Әмма бу спектакль, тамашачыны аптыраштта калдырып, 1977—78 еллар сезоны репертуарына кертелмәде. Сез бу хәлне ничек кабул иттегез?**

—Ялгышты Марсель, ялгышты. Галимә апаны пенсиягә җибәрүе дә, аншлаг белән барган «Әни килде» спектаклен туктатуы да—зур ялгышы булды Марсельнең. «Мәкер вә мәхәббәт»тә Луизаны, «Отелло»да Дездемонаны, «Король Лир»да Корделияне, «Тормыш җыры»нда Фатыйманы, «Татар хатыны ниләр күрми»дә Мәрхәбәне башкарып халык мәхәббәтен яулаган Галимә апа—«Әни килде»дәге мәгърур кыяфәтле Ана образын да милләт Анасы дәрәҗәсенә күтәреп, Ватан Анасы символында башкаруга ирешкән иде. Хәтта Фатыйма Ильская да бу дәрәҗәдә башкара алмаган булыр иде. Чөнки аңарга Галимә ападагы мөлаемлылык, җылы йомшаклык, нәфис горурлык җитенкерәми иде.

Ә нинди шәп партнер иде бит Галимә апа—йә Хода! Матурлыгы, эчке нуры белән үк тамашачыны хәйран калдыра иде. «Әни килде»дә—әниемне, «Ташкыннар» һәм «Хатынны ничек кулга алырга» спектакльләрендә хатыным рольләрендә уйнап, башкарган образларында самими яшь белүе белән нык сокландырган иде.

Театрдан аерылуны ул бик авыр кичерде. Очкан җиреннән аерып, канатларын сындырып җиргә ыргытылган коштай бәргәләнде. Туганнар идек без Галимә апа белән. Минем әтинең бертуган апасының кызы иде ул. Аннары... «Дом обуви» йортында бер үк этажда күрше квартирларда яшәдек бит. Шунлыктан яхшы беләм: соңгы көненә кадәр театрга яңадан кайту турында хыялланды ул. Театр—аның яшәү рәвеше иде шул. Гаиләсендә дә ялгыз булды, аңлау тапмады. Ире—Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының балетмейстеры Гай Таһиров—кырыс холыклы кеше иде. Кызлары Флора да, атасына охшап, каты бәгырьле булды. Ә Галимә апа театрда да, гаиләсендә дә үз-үзен яклап ваклана белми торган, татар хатын-кызларына гына хас булган тыйнаклыкка, итәгатьлелеккә, сабырлыкка ия зыялы зат иде... Ялгышты шул Марсель, ялгышты. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е кебек үк, Шәрифнең «Әни килде» классик әсәре дә безнең сәхнәдән төшәргә тиеш түгел иде.

**—«Зәңгәр шәл» дигәннән... Сез башкарган Ишан образы гына да—үзе бер спектакль! Аның янына шул вакытта сәхнәгә Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ы, Туфан Миңнуллинның бер-бер артлы «Әлдермештән Әлмәндәр», «Дуслар җыелган җирдә» пьесалары менә. Сезнең өчен янә зур-зур өч роль—өч образ! Әлмәндәр үзе генә дә ни тора! «Әни...»нең сәхнәдән алынуына болай ук борчылгансыздыр дип уйламый идем.**

—Нишләп өч кенә роль булсын ди?! Ул чорда аена гына да 10—20 исемдәге спектакль куела иде. Ә минем һәр спектакльдә диярлек ролем булды. Әнә, теге биек өемне күрәсезме? Ул төргәктә үзем уйнаган 400 рольнең программалары саклана. 400 спектакльдә катканмын, димәк.

**—Чынлапмы? Дүрт йөз спектакль, дүрт йөз роль дисезме?! Шәриф абыйның «Әни килде» драмасы гына да Камал сәхнәсендә 400 тапкыр уйнала. Димәк, сез андагы бер ролегез белән генә дә 400 тапкыр сәхнәгә менгәнсез. Тагын 399 роль... Төрле-төрле язмышлы 400 кешенең тормышы белән йөзләрчә, меңнәрчә һәм йөз меңнәрчә тапкыр сәхнәдә яшәү... Гади адәм баласы күтәрә ала торган хәлме бу?!**

—Хәзрәтләр нәселеннән бит инде мин. Программаны кулыма алу белән әүвәл аның өстенә «Лә иләһә илләллаһ: Аллага тапшырдым» дип, үзем генә укырлык итеп язып куям. Шуннан соң гына, Бисмилла әйтеп, ролемне өйрәнергә тотынам. Рольләремнең авыр бирелүен хәтерләмим мин.

**—Шәйхи Маннурның «Муса» романы буенча Казан телевидениесе күп сериялe фильм төшерде. Сез анда Мусаны уйнадыгыз. Ә бераздан Камал театры сәхнәсенә Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр»ы менде. Биредә инде сез Мусаның**

**палачы—Җәллад образын иҗат иттегез. Шәп уеныгызны, «Минем хатын—акушерка, йөкле хатыннарның балаларын кабул итә, ә мин шул баланың башын чабар өчен үсеп җитүен көтәм» дип, тәмләп әйтүегезне хәтерлим.**

—Палачның аны палач иткән философиясе бит инде бу! Кешенең туу кебек тәүге мизгелендә хатыны катнашуына да, кешенең соңгы мизгеле—җанын кыю кебек эшнең үз кулында булуына да бердәй куанмаса—палач була да алмас иде ул. «Тәмләп әйтү», дисез. Палачның бу халәтен аңларга һәм тамашачыга да аңлатырга тиеш бит инде актер. Ә менә «Ат карагы»ндагы Сибгатьнең прототипы Шәкүр каракның каршылыклы табигатен ныграк аңлау өчен ул туган авылга барырга туры килгән иде.

**—Ягез әле, ягез, анда ни күрдегез, нәрсә аңладыгыз инде?**

—Йорт үзе юк, ихата коймасы да таралып беткән, әмма капка... ныклыгы сакланган капка—үз урынында. Ә йорт урынын кычыткан баскан. Нигез ташлары янәшәсендә калган бер шомырт агачы ап-ак чәчәккә күмелеп утыра... Күрше йортның хуҗасы белән аның чоланында төне буе сөйләшеп чыктык. Милләт каһарманы булып легендага әйләнгән Шәкүр агай дин тоткан икән; биш вакыт намазын да калдырмаган, әмма дин буенча харам саналган урлашуны да хуп күргән. Үзе урлашу эшендә катнашмаган, яраннарын гына җибәргән, ә урланган малны ярлыларга өләшкән. Акылы белән дә ул дөнья күләмендә дан тоткан. Аңа кинәшкә тирә-юньнән генә түгел, ерак-ерак илләрнең хөкүмәт башлыклары да, бай түрәләр дә, закон белән эш итүчеләр дә—кыскасы, төрле милләтләрнең төрле дәрәҗәдәге кешеләре килгән имеш. Кемнең кем булуына карамастан, ул аларны якты чырай белән кабул иткән. Шунысы кызык, бер яктан, ул аларның байлыкларын тартып алган (урлаган), ә икенче яктан, шул ук кешеләргә кинәшләре белән ярдәм дә иткән. Һәм һәр очракта да ихлас булган, бу ике гамәлнең һәр икесен чын күңел белән башкарган. Ягъни ни кылса да үз-үзе белән килешеп, һәр гамәленең кирәклегенә инанып эшләгән.



*Г. Камал театры. «Әни килде». Беренче куелыш (1970). Ана—Галимә Ибраһимова, Сәяр—Айдар Хафизов.*

Гәрчә үзләре дә аның янына кинәшкә йөрсәләр дә, татар улы Шәкүрнең көннән-көн үскән дәрәҗәсе хөкүмәт кешеләрен куркыта башлый. Һәм, билгеле инде, ул кулга алына. Ябык үткән суд вакыйгалары да, гаҗәп хәл, авылына кайтып ирешкән. Легендар Шәкүр судта да үзен дәрәҗәле тоткан—бик тыныч булган. Үлем җәзасына хөкем ителгәч, соңгы теләген белешкән судьялардан намаз уку өчен ун минут вакыт сораган...

**—Кешеләр гозерен үтәү, урланган малны үз файдасына тотмыйча ярлыларга өләшү кебек шөгыльләре белән генә түгел, үзенең яшәү рәвеше белән дә үрнәк булуын белеп кайтуыгызның иҗатыгызда һичшиксез файдасы тигәндер, Шәкүр-Сибгатегез шәп иде. Хәер, тамашачыны ышандырмаган ролегезне белмим мин. Тудырган образыгызның тәэсир итү көчен нәфрәт ташы аша үзегезгә дә татырга туры килгән бит, әнә. Әйе, әйе, «Әни килде»дәге Исламыгыз турында искәртүем. Ә бу спектакльнең сәхнәдән алынуына килгәндә исә... мин үзем моны Марсель Сәлимҗановның тыңгы белмәс холкы белән бәйләп карыйм. Марсель әфәнде Шәриф абыйга: «Безнең «Әни...»гә**

**СССРның бөтен театрлары тотынды, ә мин үз әйберемнең үземнеке генә булуын яратам» дип, спектакльне Камал сәхнәсендә туктата да шул ук елда В. И. Качалов исемендәге Казан рус драма театрында куя. «Белое платье матери» исеме белән 1978 елның маенда шаулап үткән премьералардан соң, Качалов театры ошбу спектакль белән гастрольләрен башлап җибәрә. «Белое платье матери» булган шәһәрләрне, еллап-айлап дигәндәй, театрның музей мөдире Юрий Алексеевич Благов санап та күрсәтте: 1978нең июль-август айларында Оренбург, Нижний Тагил; 1979нын июнь-июлендә Череповец, Вологда, Рязань; 1980нең июль-август айларында Белоруссия шәһәрләре; 1981нең май-июне—Ульяновск, июле—Уфа; 1982нең июль-август айларында Харьков, Запорожье, Севастополь; 1983 елда Волгоград...**

—Шәрифнең әсәре... драма үзе нинди бит! Марсель әйткәнчә, нәкъ шул чорда илнең күп кенә режиссерлары «Әни...»не үз театрларында куя башлады бит инде.

**—Әйе, «Әни килде»нең ун телгә тәрҗемә ителеп, СССРның тагын кырыклап театрының куюы хакында рәсми чыганакларда һәм Шәриф Хөсәеновның үз язмаларында да мәгълүмат бар. Бу турыда Шәриф абыйның Казан медицина институтында бергә укыган сабакташы, гомерлек җан дусты Суфия ханым Мифтахова болай ди: «Әни килде» драмасы күп телләргә тәрҗемә ителде һәм СССРның бик күп театрларында куелды. Күбесенең премьераларына Шәриф үзе дә барды. Ә бармаган очракта, спектакль куелган шәһәрләрнең театр директорларына яки «хезмәт күрсәтү» бюроларына акча җибәрә, һәм Ана ролен башкаручы актрисага чәчәк алып тапшыруларын үтенә иде».**



*Г. Камал театры. «Әни килде». Икенче куелыш (1999). Ана—Наилә Гәрәева.*

—Чәчәк дигәч, искә төште менә: әсәренең Мурманскида куелуына, Ана ролен мәшһүр Мөслим Магомаевның әнисе уйнавына Шәрифнең бик тә сөенеп, барырга әзерләнеп йөргәнен хәтерлим.

**—Шул чактагы очрашу бу ике шәхесне гомерлеккә дуслаштырган булса кирәк. Шәриф абый архивында Ана ролен башкаручы Айшет Магомаеваның «Кадерле улым Шәриф» дип башлап, «Хөрмәт белән, әниең» дип тәмамланган гаҗәеп хатлары сакланган. Шуларның берсендә—сиксән алтының декабрендә язылганында—мондый юллар бар: «Белое платье»—Чимкент, Мурманск театрларының бер еллык планын ярты елда үтәгән иде. Гастрольләр вакытында да тамашачыны тетрәндергән спектакль һәрчак шушы булды. Хәзер менә Майкоп театрының директоры мине үзләренә эшкә чакыра. Әлбәттә, «Белое платье» әсәре белән. Ә миңа инде—64. Бәлки, ризалашыргадыр, ә?..»**

—Безнең татар Анасы илдәге төрле милләтләрнең уртак Анасына әверелгән әлеге чорда «Әниемнең ак күлмәге» исеме астында Марсель «Әни...»не яңадан куйды. Әмма үзебезнең Камалда түгел, бу юлы ул драманы Кәрим Тинчурин театры өчен сәхнәләштерде.

**—1988 елда дөнья күргән бу спектакль дә хәтергә сеңгән. Исламия Мәхмүтова уйнаган Ананы да тамашачы яраткан иде. Спектакль караган чакта үзенең кичергән халәтен Шамил әфәнде Закиров, мәсәлән, «Минем тетрәнүем шул хәтле көчле иде—йөрәк даруы кабуым да ярдәм итмәде; күз яшьләремне тыя алмагач, һавага чыгып үкси-үкси еладым», дип искә ала хәзер дә. Ә сезне... Сезне, Шәүкәт абый, «үзебезнең Камалда» диюегездән үк сизеп алдым, 1999 елда «Әни...»нең яңадан кайтуы, ягъни Академия театрында өр-яңадан куелуы сөендергәндер, билгеле. Спектакль сездә ниндирәк тәэсир калдырды?**

—Драма авторы Шәриф авыру сәбәпле спектакль ашык-пошык әзерләнде. Авылдан килгән, тугыз бала әнисе—мәһабәт Ана роленә фактурасы белән үк туры килми торган Наилә Гәрәеваны куеп, Марсель зур ялгышлык эшләде. Шәриф әсәрендәге мәгърур Ананы күрергә теләгән тамашачы бу спектакльне кабул итә алмады. Житмәсә, бу куелышта сәхнә бизәлешенә дә фальш кушылган иде. Мескен хезмәт хакына көн күрүче медсестра фатирын ике этажлыга әйләндерү нигә кирәк булгандыр, аңламадым. Каян килсен инде ул гади медсестрага ике этажлы фатир?!

**—Моны мин үзем, мәсәлән, ике кысан бүлмәне берьюлы күрсәтү өчен алынган символик алым буларак кына кабул иткән идем.**

—Шәриф әсәре бернинди символикаларга мохтаж түгел. Чынбарлыкка хилафлык итә торган мондый йогышсыз «ямаулык» спектакльне бизәми, киресенчә, ямен киметә. Шәриф әсәре—бөек әсәр, классик әсәр. Сирәк туа торган мондый әсәргә вакыт та, заман-гасырлар да тәэсир итә алмый; ничек бар—ул шулай яши. Әдәбиятта да, сәхнәдә дә. Шекспир әсәрләре кебек. Әгәр әсәрне тирәнтен аңлаган режиссер куйса, образларны әсәр үзе таләп иткән актерлар уйнаса!.. Мин, мәсәлән, спектакльнең ул куелышында Ана ролендә Дания Нуруллинаны күрергә теләгән идем.


*Мурманск театры. «Әни килде». Ана—Айшет Магомаева (Мөслим Магомаевның әнисе).*

**—Шәриф абый үзе Алсу Гайнуллинаның уйнавын теләде... Кем эшләми—шул ялгышмый, диләр бит. Титаник хезмәт башкарган режиссер Марсель әфәндене дә ялгышлары булуы—гаҗәп түгел. Әмма «Әни...» әсәренә ул, иманым камил, һәм тирәнтен аңлап, һәм яратып тотынды. Әгәр шулай булмаса, аның беренче куелышы ук Мәскәүне хәйран калдырып, бөтен илне иңләр идемени?! Шулай булмаса—баш режиссер, мәшһүр Сәлимҗанов шәхсән үзе аны дүрт тапкыр куяр идемени?! Мондый хәлнең бүтән бер әсәргә карата да булганы юк бит.**

—Дөрес, Рәйсә ханым, килешәм. Алай да күңелне бер сорау борчый: «Әни...»нең бу соңгы куелышын Шәриф үзе ничек кабул итте икән? Премьерадан соң, театрның икенче катында утырып торуын күреп, янына киллем. Шәриф эндәшмәде. Мин, нык авырый, хәле юктыр, дип уйладым. Спектакльне ошатмаудандыр, бәлки, дигән уй да күңелгә килде.

**—Премьераның уңышлы үтүе турында ишетеп, котлап шалтыраткан Фәнис Яруллинга гәрчә: «Утыз ел элек язылган пьесаңның премьерасын карау—куян шулпасының шулпасын эчү генә инде» дисә дә, Шәриф абый Марсель әфәндегә бу куелыш өчен дә бик рәхмәтле булгандыр дип уйлыйм. Премьерадан соң сәхнә артында: «Мин бәхетле, слушай, сәхнәдә, тамашачы каршында, чәчәкләргә күмелеп китәм бит... Шушылай минем кебек аяк өсте үлүче, йә, тагын кем бар?!»—дип үзенең дусты режиссер Сәлимҗанов алдында шукланып алырлык көч табар идемени Ул, югыйсә. Рәхмәтле булуының Шәрифчә әйтелүе бит инде бу! Әйе, әйе, шул ук төндә Суфия ханымны гаҗизанә калдырып: «Әсәремне тулы килеш, бөтен килеш күрү дә насыйп булды»,—дия-дия елавы да аның Марсель әфәндегә рәхмәтле булуын раслый. «Тулы килеш», «бөтен килеш!..» Сез дә сизгәнсездер, бу куелышта режиссер теге елларда обком тыйган эпизодларны да керткән иде бит.**

—«Дусты Сәлимҗанов алдында...» диюегезгә, хәтердә бер вакыйга яңарды. Бервакыт без Марсель белән Васильево урманына гөмбәгә бардык. Ни хикмәттер, гөмбә юк, беләккә элгән кәрзиннәребез һаман буш. Тинтерәп йөри торгач, Марсель әйтә куйды: «Вакыт әрәм итеп йөрмик болай. Иң яхшысы, кайтабыз да Шәрифкә керәбез. Ул безне кайнар чәе белән дә, затлы шәрабы белән дә сыйлар, кунак итәр ичмасам...» Хуш, кайттык бит инде Шәриф янына сыйланырга. Бусаганы атлау

белән мина әйткән «сыйлану» кебек сүзләрен кабатлады Марсель. «Шәраб эчү урыны түгел бу; минем янга дусларым сәнгать, театр тормышы турында сөйләшү өчен килә; сыйланырга, әнә, ресторанга барыгыз» дип, әле ябылып бетәргә дә өлгермәгән ишекне киереп ачып, Шәриф безне куып чыгарды... Шәриф урынында берәү булса, икейөзлеләнер, елмаеп маташыр, түренә утыртып кунак итәр иде. Баш режиссер Марсель Хәким улын куып чыгарырга берәү дә, кабатлап әйтәм, беркем дә җөрьәт итә алмас иде. Мин шунда Шәрифнең нинди олы шәхес булуына хәйран калдым. Бу икәүнең бәйсез, горур холыклары да охшаш иде шул.

**—Шул ук вакытта, дуслыклары да—чын дуслык—эчкерсез, ихлас, олы дуслык иде. 1998нең көзендә төн уртасында телефоным уятуы, һәм Шәриф абыйның бик тә хәсрәтле тавышын ишетүем хәтердә. «Йокыңнан уятканга ачуланма инде. Үз-үземә тынгы табалмаганга шалтыратам, слушай. Белгечләр киңәше белән—Марсель хәзер Германия хастаханәсендә. Үзебезнең врачлар бик хәвефле диагноз куйдылар бит. Беркемгә дә әйтмә, яме?» дию, үземнең исә: «Алай бик хафаланма әле. Хәвефле булса—җибәрмәсләр иде, дәвалау мөмкин, димәк. Күр дә тор, бер ай да үтмәс, Марсель әфәнде сау-сәламәт кайтып керер, Алла боерса» кебек сүзләр белән юатуым истә. Ә Шәриф абый авыргач... Марсель әфәнде күзендә чагылган кайгы-хәсрәтне яшерү өчен кара күзлек киде, гел кара күзлектән йөрде. Ул бу күзлекне театр бинасы эчендә дә салмый иде. Шамил әфәнде белән икәүләп Шәриф абыйны больницага яткырдылар һәм алып чыктылар. Театры белән Марсель үзе җирләде дә. Һәм гомеренең соңына хәтле Шәриф абыйны сагынып яшәде Марсель әфәнде. Мине күргән саен сүзен театрга килүем өчен рәхмәт әйтүдән башлап, «Шәриф житми жанга, Шәриф житми», дип тәмамлый иде. Ярый әле янында сөйгән хатыны Гөлнар ханым, яраткан театры, дуслары, шәкертләре булды.**

—Бу яктан караганда Марсель Шәрифтән бәхетлерәк икән. Шәриф ялгыз яшәде шул. Әмма теге көнне утырып торган авыру Шәриф янында карарак кына, чибәр генә бер ханымны күрдем. Кем булды икән ул?

**—Премьера көнендә дә, аннан соң да Шәриф абый янында алмаш-тилмәш ике ханым булды, рәхмәт төшкере. Берсе—апасының кызы Наза ханым, икенчесе—сабакташ дусты Суфия ханым. Наза ханымда абыйсының—архивы, ә Суфия ханым хәтерендә дустының серләре саклана. Бу ханымнар сезгә «Казан утлары» журналының 2006, 2007 еллардагы 3нче саннарында чыккан «Ак сагыш иясе». «Күкләрдән иңгән мәхәббәт» дигән очерклар һәм 2006 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Шәриф Хөсәенов» исемле китап аша да—күпмедер дәрәҗәдә таныштыр дип беләм. Серләре дигәннән... «Әни...» әсәренең туу тарихына да Суфия ханым ачыклык кертте. Бу хакта ул: «Нечкә күңелле, миһербанлы-шәфкатьле, намуслы һәм горур Шәриф гаделсезлекне кабул итә алмый иде, һәм гомере буе ул дөньяны, кешеләрне чистарту уе белән янды, шуның өчен көрәште. Туганнарының кимчелекләрен дә гафу итә алмый иде ул. Әнисе авыргач ничек борчылуын белсәгез икән?! Больницага салды, аннан да үзе алып чыкты...» дип сөйләде.**

**Олыгаеп та чибәрлек чалымнарын җуймаган шул ханымнарның берсен күргәнсез инде сез, алайса.**

—Марсель белән Шәрифне әйтәм... икесе дә ноябрьнекеләр икән: берсе—7сендә, ә икенчесе 26сында туган. Театр былтыр Марсельгә—75, Шәрифкә 80 ел тулу даталарын бик зурлап уздырды, шөкер. Яшьләр Шәрифнең «Зөбәйдә—адәм баласы» әсәрен янадан сәхнәгә менгезде. Мин Шәрифне үземнән күпкә кече дип йөри идем. Баксаң, бер яшькә генә кече икән. Шәриф—бик чибәр, яшь кыяфәтле иде бит ул.

**—Шундый кыяфәте аркасында, гәрчә үземнән күп яшькә олы булса да, аңа «абый» дип әйтергә ничектер кыймый идем. Менә сезнең белән сөйләшкәндә генә тәүге тапкыр аны абый дип атадым. Олылыгы, олпатлыгы еллар үткән саен ныграк сизеләдер, мәшһүр әдипләребез бәясе дә аны зурлап, абый дип әйтүгә этәрәдер, күрәсең. Шәриф абыйдан соң үзе дә озак яшәмәгән XX гасырның могтәбәр аксакалы**

**Әмирхан ага Еники, «Юбилей сабаклары» дигән соңгы мәкаләсендә болай дип язды: «Шәриф Хөсәен бик үткен фикерле чын талант иде... Минем өчен ул сугыштан соңгы драматурглар арасында иң көчлесе иде... Аның «Зөбәйдә—адәм баласы» һәм «Әни килде» драмалары иң беренче нәүбәттә Тукай бүләгенә лаек әсәрләр иде. Бу карашымны мин бервакытта да беркемнән дә яшермәдем... Бүләк алганнарның бик күбесе күптән инде онытылып бетте, ә Шәрифнең әнә шул әсәрләре чын мәгънәсендә үлемсез...»[1] Бөек замандашыбыз әдип Фәнис Яруллин исә үзенең «Серле кеше» эссесын болай дип тәмамлый: «Мәңге искерми торган әсәрләр язып, СССР дигән гаять зур илнең бөтен сәхнәләрендә куелган «Әни килде»нең авторы тыйнак каләмдәшебез Шәриф Хөсәеновның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә дә ия булмавы күңелне рәнҗетә. Туктаусыз күкрәгенә бәрелеп торган гаделсезлек аны безнең арабыздан алып китте»[2].**

—Әдипләр хаклы. Торып-торып гаҗәпләндерә, рәнҗетә торган хәл бит бу. Кабатлау булса булыр, бая сөйләшкәннәрне искәртим әле: татар драматургиясендә «Әни килде» кебек Камал театры сәхнәсендә генә дә 400 тапкыр уйналган, ун телгә тәрҗемә ителеп, СССРның кырыклап театры куйган һәм бөтен Союзга танылган әсәр бүтән юк! Марсель Сәлимҗановның да «Әни...»дән башка бүтән бер әсәрне дә дүрт тапкыр куйганы булмады. «Әни...» татар театры сәнгате тарихында феноменаль күренеш ул!

**—Афәрин, Шәүкәт абый, әйбәт әйттегез! Сез үзегез дә театр сәнгатендә феномен шәхес бит... Егерменче гасыр башында бөек Тукай:**

> **Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,**
> **Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.**
> **Театр—яктылыкка, нурга илтә,**
> **Кире юлга җибәрми, уңга илтә,—**

**дип, театрга әнә нинди зур өметләр баглаган. Һәм, шөкер, узган гасыр—Марсель әфәнде, Шәриф абыйлар гасыры бу өметләрне аклады дип нык ышанып әйтә алам. Безнең бу сөйләшү дә шуны ачыклады, рәхмәт Сезгә! Атаклы Камал театрында иҗат иткән СССРның алты халык артистының берсе—соңгы могиканы буларак, егерме беренче гасыр театрының һәм бүгенге хәле, һәм киләчәге турындагы уй-фикерләрегез белән дә уртаклашсагыз иде.**

—«Театр» дигән шул шигырендә Тукай:

Вә ул дарел-голүм, дарел-әдәптер,
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер,—

дип, театрның белем йорты, әдәп йорты, тәрбия урыны булуын искәртә. Узган гасырның икенче яртысында Татар дәүләт академия театрының башында затлы, зыялы актерларыбыз Галия апа-Хәким абыйларның улы—театр ишек алдында сәхнә тузанында аунап үскән, әти-әнисе белән гастрольләрдән гастрольләргә йөреп, татар халкының рухи дөньясын, күңел байлыгын, җаны таләбен аңына тирәнтен сеңдергән Марсель Сәлимҗанов иде. Һәм ошбу шәхес Тукаебыз әйткән әлеге хакыйкатьне, ягъни театрның төп вазифасын бер генә минутка да исеннән чыгармады. Театрның бүгенге хәленә килсәк... мин нык борчылам. Баш режиссер заман шаукымы белән артык мавыга сыман. Әлегә ул эзләнү процессы кичерә булса кирәк. Әгәр заман шаукымына иярмичә, мәгънәсез көлкеле тамашаларга алданмыйча, татар халкының әхлакый традицияләреннән аерылмаган талантлы әсәрләргә таянып эш итсә—театрыбыз академик йөзен җуймас дигән өмет-ышаныч бар. Ахыр килеп, Фәрит Бикчәнтәев—Марсель Сәлимҗановның үз шәкерте бит—сынатмас, иншалла.

**Рәйсә ЮСУПОВА**
*әңгәмәсе.*

---

[1] «Юбилей сабаклары». 24 сентябрь, 1999 ел. «Мәдәни җомга».
[2] «Шәриф Хөсәенов». Татар. кит. нәшр., 2006.

Әзһәр
Шакиров

# БУЛМАС ДИМӘ, ДӨНЬЯ БУ!

## Кара икра тарихы

Безнең Академия театры 1977 елда Әстерхан шәһәренә гастрольгә барган иде. Анда җәйнең иң матур чагына туры килдек: кавын-карбыз өлгергән, помидор кызарган, җиләк-җимеш, балык тулып ята, җаның теләгәнчә аша. Безнең Казан белән чагыштырганда бик очсыз. Казан гомер-гомергә ач-хәерче шәһәр булып халык күнеленә кереп калган. Мондагы әйберләрне бик Казанга алып кайтыр идек, гастрольләрне Бакуда дәвам итәсе бар. Гастрольдә минем янга шактый күп кеше җыйнала, кайбер кирәк кешеләрне үзем дә эзләп табам. Спектакль беткәч, гадәттә кунакханәгә кайтасы килми, күңел әле спектакль белән яши. Бәхетемә, сәхнә артына тәбрик итәргә кергән кешеләр күп вакыт мине үзләре белән кунакка алып китәләр. Күрәсең, «зинһар, мине үзегез белән алып китегез»,–дигән кыяфәт йөземә чыккан булгандыр. Әле дә хәтеремдә, «Сүнгән йолдызлар» спектакле беткәч, бик матур киенгән, бераз гарип кешегә охшаган егет мине үзләренә алып китте. Нишләптер аяк тартмый, әллә аркасында бераз гына бөкресе булганга? Өендә хатыны, ике баласы бар икән, кыз белән малай. Бераз утыргач, бу кеше минем кем икәнемне хатынына аңлата башлады: «Аңлыйсыңмы, бу артист, чын артист, минем әле мондый артистны күргәнем юк! Нәрсә аптырап каттың, Казан артисты–Шакиров! Ул сәхнәдән мине уйнап күрсәтте, мин нинди бәхетсез...»–дип, елый башлады. Ничек тынычландырырга белмим. Хатыны: «Аңа эчәргә ярамый, эчсә, холыксызлана, нигә аны эчертәсез, төне буе нишләп йөрисез монда?!»–дип, мине эт урынына сүгә. Түздем-түздем дә: «Рафис Сабирович үзе алып кайтты, ялынып килмәдем. Мин хәзер үк китәм, мине озатып куегыз!»–дим. Кая барасың, төн уртасы... Ишек алдына чыктым да, шешәне тотып, уйлап утырам: нишләп әле мин шулай эт кебек йөрим, җүнле кеше хәзер түшәгендә рәхәтләнеп йоклап ята. Моннан соң, Алла боерса, гарип кешеләр янына беркайчан да бармас идем. Хайван тек, хайван дип, үз-үземне сүгәм. Иртәнге якта беренче трамвай белән үк кунакханәгә кайтып аудым.

Уянып китсәм, кичке сәгать биш, тиз генә юындым-кырындым да, «Зәңгәр шәл» спектакленә киттем. Уйнап бетергәч, сәхнә артына теге ир кеше, хатынын, балаларын ияртеп тагын килеп керде. Мине кочаклап үк алдылар, хатыны гафу үтенә, кунакка чакыралар. Оятымнан нишләргә белмичә: «Бүген инде башка артистны чакырыгыз!»–дим. Шулвакыт театрыбызның директоры Әзһәр Хөсәенов килеп керде, болар әллә кайчангы дуслар кебек кочаклашып күрештеләр.

–Сез әллә танышлармы?–дим, гаҗәпкә калып.

–Без әллә кайчангы танышлар, Әстерханда Рафис Сабирович кебек татар театрын яраткан кеше юк!»–ди Әзһәр Хөсәенов.

Соңыннан белдем, бу кеше Әстерханның бөтен балык–уылдык складларының хуҗасы икән. Әйтәм аны, табынында җаның ни тели, шул бар иде.

Бакуга китәр алдыннан Рафис Сабирович мина шалтыратты, эшләгән җиренә килергә кушты. Трамвай белән шәһәрнең читенә килеп җиттем. Күрәм, тимер чыбык белән уратып алган складлар тезелеп киткән, кирәргәме-юкмы дип аптырап

*Ахыры. Башы узган санда.*

торганда: «Сезгә кем кирәк?»–дип бер милиционер килеп басты.

–Мин артист Шакиров, Казаннан, Рафис Сабирович чакыруы буенча килдем–дим.

–Әйдәгез,–дип, озатып, кертеп җибәрде бу.

Өстендә склад мөдирләре кия торган гади генә телогрейка, аягында итек, башында бүрек, моны һич тә директор дип уйламассың!

–Мин бит сезгә сәгать бергә килергә куштым, әле сәгать унике генә.

–Гафу итегез, кич белән авылга барасы бар.

Минем үз гомеремдә андый складны күргәнем булмады, җаның ни тели–бар да бар, шаккаттым, безнең төшкә дә кермәгән әйберләр. Тегесен дә аласы килә, монысын да, шулай да күңелне тыеп, бер-ике банка 100 граммлы кара икра, кызыл икра, стерлядь, осетр, говяжий консервалар, индийский чай–(боларны аңлашылсын өчен русча язам, чөнки дефицит! Калганнарын әйтеп тә тормыйм) шактый тутырдым. Хәзер инде, боларның барысын да алырга ярыймы, дигән кыяфәт белән күзенә карап торам. Бу миңа бәясен әйтте.

–Нигә шул хәтле очсыз?!

–Бу складтан продукция Мәскәүгә иң зур түрәләргә заказ белән китә, аның үз бәясе шулай, шуңа күрә очсыз.

Мин, сөенечемнән, акчасын түләп, рәхмәтләр әйткәч:

–Зинһар, мине үзең озата чык, милициядән бик куркам,–дидем.

Чыннан да, бик җентекләп тикшерделәр, артист бит, аңлап алдым, минем алда уен уйныйлар, бу, күрәсең, күптән шулай куелган булган. Кунакханәгә кайтып, бер кешегә дә күрсәтмичә, тиз-тиз генә җыеп куйдым. Миңа, Аллага шөкер, Казанга алып кайтырга күчтәнәч тә булды.

Кич белән Кызыл Яр авылында «Ак калфак» спектаклен уйныйбыз. Авылга килүгә бөтен халык өйдән өйгә йөреп кара икра эзли, мин дә түзмәдем, бер ярты литрлы банка белән кара икра алдым. Спектакль беткәч, колхоз председателе миңа яна гына тоткан чөгә балыгы китерде, бик зур–җиде-сигез кило булыр. «Юлда тикшерәләр, сак бул, беркемгә дә күрсәтмә, декорация арасына яшер»,–ди. Хәвеф-хәтәрсез көчкә кунакханәгә кайтып җиттек, чөнки юлда гел милиция тикшерә. Тиз генә балыкны чистартып, башы белән койрыгыннан уха ясадым, калганын Бакуга алып китәргә дип, әйбәтләп суыткычка тыгып куйдым.

Иртән иртүк Әзһәр Хөсәеновка ике целлофан пакет белән берәр килолы кара икра китерделәр, бик зур рәхмәтләр әйтеп, кешесенә бирермен дип, алып калдым. Әзһәр Хөсәенов Бакуга гастрольләрне оештырырга, безне каршы алырга дип, бераз алдан киткән иде. Диктор Абдулла Дубинның абыйсы бик зур күчтәнәчләр әзерләп, кипкән балык, ысланган җәен, чуртан, сазан, зур-зур чабаклар алып килгән. Минем әйберләр күп җыелды, чемоданга сыймагач, капчыкка тутырдым.

Иртән аэропортка озатырга шактый кеше җыйналган иде. Тиз генә өстәл әзерләдек, администратор чакырганчы рәхәтләнеп җырлашып, көлешеп утырдык. Аңлыйсыздыр, аэропортка шундый кутәренке рухта килеп кердек, чегән таборы диярсең, һәркайсыбызда төрле-төрле төенчекләр җыйналган, әйтерсең, бөтен Әстерханны талап китәләр! Минем әйберләр бар кешенекеннән дә күбрәк. Миңа бервакыт «посадка» игълан иттеләр, барыбыз да ашыга-ашыга, төртешә-төртешә чиратка бастык. Берзаман күтәрелеп карасам: «Кто без разрешения везет килограмм черной икры–штраф 145 рублей!»–дигән язу тора. Минем ике айлык хезмәт хакым... Шушы язуны күрүем булды, эчкән винолар баштан чыкты, бөтенләй айнып киткәндәй булдым. Инде нишләргә? Кемнән ярдәм көтәргә? Хөсәеновның уылдыгы портфельдә, үземнеке чемоданда, әгәр ачтырсалар, барсын да алып калачаклар. Капчыктагы чөгәләрне кая куясың? Бөтен кеше алдында хур булдым, хур булдым. Мине самолетка да утыртмаячаклар. Миңа килеп каптым. Без бит артистлар, беркем дә безне тикшерер дип уйламады.

«Откройте чемоданы!»–дигән тавыш ишетелде. Минем алда бераз кызмача Габдулла абый Шамуков басып тора иде. «У меня там ничего нет, я–народный артист! Я чемодан открывать не буду!»–дип әйтүе генә булды, янына милиционер килеп басты да: «Это ты народный артист?»–дип, чемоданын актарып та атты. Бу хәлне күргәч, мин бөтенләй тораташ булып каттым. Кая барырга белмим, әйберләремне көчкә күтәреп, акрен генә иң арткы рәткә килеп бастым. Бөтен кеше

тып-тын булып калды. Инде хәзер нишләргә? Артистлар берәм-берәм чемоданнарын ачып, әйберләрен күрсәтә башладылар. Шунда театрның баш режиссеры Марсель Сәлимжановның хатыны Гөлнарны күрдем дә: «Зинһар, шушы портфельне алып чыгарга ярдәм ит»,–дим.

–Кил, минем янга бас, бергә чыгарбыз!–ди бу. Ниһаять, мина да чират житте.

–Что там у вас в портфеле?

–У меня там ничего нет, немного вина и закуски.

Ит, балык кисәкләрен чыгарып өстәлгә сала башладым. Портфелем эченнән зур-зур кара чебеннәр очып чыга башлады. Түзмәдем, ачуымнан берсен сугып үтердем. Моны карап торган Гөлнар: «Ну, хватит, что там может быть?!»–дип, мине «сугә» башлады. Мина шул гына кирәк иде. «Если вам надо, возьмите мой портфель, он мне не нужен»,–дип, тикшерүче хатынга портфельне этеп жибәрдем дә, карап торам: теге хатын нишләр икән. Кулына алырга, актарырга жирәнә. Шуннан сон: «У меня еще мешок есть!»–дип, капчыкны актарырга тотындым. Бөтен жирен чебен сырып алган, әллә кичәге балыкнын сүле агып чыккан, әллә сыра түккәннәр.

–Если вам нужен мой мешок, возьмите, возьмите, мне ничего не надо!–дип жылак тавыш белән кычкырам. Көн шундый эссе, бөтен жирдән тир ага, күзләр акайган, аякта көчкә басып торам, «Странный кеше» ролен шундый килештереп уйнадым, безнекеләр читтән карап, асларына сия-сия көлгәннәр. Чемоданны ачтырып та карамадылар. Әйберләрне сөйрәп самолет янына килеп бастым, атларлык хәл юк, чирәмгә утырдым, чебеннәр тагын сырып алды.

Бөтен кеше утырып беткәч кенә самолетка кердем. Янәшәмдә чибәр генә бер маржа хатыны: «Вы видели, какой-то странный человек около трапа сидит, мух гоняет, бывают ведь такие странные люди. Так смешно было, так смешно!»–дип рәхәтләнеп көлә. Мин әйтәм: «Это же был я». Шулай дип әйтүем булды, теге маржа: «Извините ради бога, извините...»–дип миннән гафу үтенә башлады. «Да вы что, не волнуйтесь, бывает...»–дим.

Озак та үтмәде, матур ханым икенче урынга күчеп утырды.

## Артистларны ашатмаска дигән закон бармыни?

Мина театрда гастрольләр оештырырга да туры килгәләде. Шулай бервакыт Хәй Вахит абыйнын «Талак, талак» комедиясе белән Актаныш якларына чыгып киттек. Ай буе гастрольдә йөргәндә төрле хәлләр туа, бәла-каза гына булмасын, калганына түзәргә була. Актанышка килеп төшкәч, бер әйбергә игътибар итмичә калмыйсын. Район үзәген тау башына шундый итеп салганнар, сокланмыйча мөмкин түгел. Бөтенесе бер жирдә урнашкан: Мәдәният сарае, райком, кибетләр, кунакханә, хәтта милиция дә. Аста Агыйдел искиткеч матур булып агып ята, безгә, артистларга ял итәргә, балык тотарга Ходай Тәгалә үзе биргән диярсен. Актаныштa театрны, сәнгатьне яраталар, шуна күрә мине райкомда да бик жылы каршы алдылар. Житмәсә, ул вакытта Хәләф Низамов эшли иде, ул артистларны хөрмәт итә, бик ачык, кин күнелле кеше булып хәтергә кереп калган. Иртәнге сәгать дүрттә торып райкомга керәм дә, без барасы колхоз председателенә шалтыратам. Әгәр сонга калсан, председательне берничек тә тотармын дип уйлама, басуга чыгып китте диләр дә, шунын белән эш бетте, чөнки колхозда бөтен эшне ул гына хәл итә. Шуна күрә, тан тишегеннән торып: «Без кичке сәгать алтыда киләбез, завклуб урынында булсын, ашарга әзерләгез, без кайтканда ресторан эшләми, зинһар, кулыгыздан килгәнчә ярдәм итегез инде!»–дип ялынасын. Гастрольләребез унышлы гына бара, халык театрга йөри, билетлар сатылып бетә, ашау-эчү жайланган, торган урыныбыз искиткеч, аста Агыйдел: артист кешегә тагын ни кирәк!

Шулай беркөнне иртүк торып, без барасы авылга шалтыратам:

–Исәнмесез, бу мин, артист Шакиров, беләсездер, бүген сезнен авылга киләбез, зинһар өчен, спектакль беткәч, артистларга ашарга әзерләсәгез иде, спектакль сон бетә, юл ерак, без кайтуга ресторан эшләми. Сезне бик яхшы, кин күнелле кеше дип тә сөйлиләр...

Берзаман трубкадан карлыккан тавыш ишетелә: «Артистларны бушка ашатырга, дигән закон бармы әллә? Минем бер кешене дә бушка ашатканым юк!»

Аптырап калдым, нәрсә әйтергә белмим. Әле мина мондый сүзне ишетергә туры

килгәне юк иде. Кайвакытта, ник шул хәтле күп кеше алып килден, тегеләй дә болай дип тенкәгә тияләр иде. Бу бит энә нәрсә ди, артистларны бушка ашатырга дигән закон бармыни ди!

Ачуымнан:

–Гафу итегез, ә сез миңа «артистларны ашатмаска» дигән законны күрсәтегез, андый закон бармыни?! Сез нәрсә, Совет властен мәсхәрә итмәкче буласызмы? Партия язучылар, артистлар турында нәрсә әйткәнен исегезгә төшеримме? Сез кем белән сөйләшкәнегезне беләсезме соң? Мин хәзер райкомда утырам, теләсәм, беренченен үзенә керәм!

–Теләсә кая кер, минем үз эшем дә баштан ашкан, артист кайгысы юк әле. Сез киләсез дә китәсез! Минем монда сыерларны карыйсым бар, атна буе үгез эзлим...–дип трубканы куйды.

Мин, аптырап, көтемә утырдым. Инде нишләргә? Хуҗаларга керергә оят, чөнки гел мактап, сезнен аркада безне шундый яраталар, хөрмәт итәләр, без монда ял йортында яшәгән кебек яшибез, дип ялагайланып йөр дә. Сездә шундый мәгънәсез, җүнсез председательләр дә бар икән бит, хәтта ашарга да пешермиләр, дип сүз кузгатсаң, син үзең кешеләр белән сөйләшә белмисен, башта сөйләшергә өйрән, диярләр. Әлбәттә, безне беркем дә бушка ашатырга тиеш түгел, әмма йоласы шундый, артист белән хәерчене һәркем кулыннан килгәнчә ашатып чыгара. Әгәр артистны гастрольдә бушка ашатмасаң, аннан игелек көтмә, хәзер кәефе кырыла. Без бит авылда акча түләп ашарга өйрәнмәгән, шуңа күрә ресторанда да көненә бер генә мәртәбә ашыйбыз, аны да көндез генә. Хәер, безнен 2 сум 60 тиен суточныйга ресторанда көннәр буе рәхәтләнеп ашый алмыйсың шул, зарплатасы турында әйтеп тә тормыйм инде. Бу колхозга иртәрәк барырга туры килер, югыйсә, көне буе ач калуын бар.

Барасы авыл шактый ерак булып чыкты, 20-30 чакрымнар булыр. Клубка килеп кердем, сәхнәсен карап йөрим. Клуб мөдире дә минем янда. Театрыбызнын күренекле артисты Әсхәт Хисмәтовка әйтәм:

–Боларнын сәхнәсе бик бәләкәй, монда безнен декорация сыймаячак, башка авылга китәргә туры килер ахры (Әле декорацияне бушатып та карамаган). Без бит Академия театры, мондый сәхнәдә уйнап булмый. Сез завклуб буласызмы?

–Әйе, мин. Сез Шакиров абый буласыз бит (Исемемне әйтә алмый, чөнки минем исемне театрда да дөрес әйткән кеше бик сирәк). Мин билетларны саттым, безгә зур декорация кирәкми, зинһар, уйнагыз инде, бөтен халык театр көтә.

–Сезгә әйттеләрме соң, спектакль беткәч, артистларны ашатырга тиешләр дип.

–Мин бернәрсә дә белмим, миңа аны-моны әйтүче юк.

–Бар әйт, безгә кичкә ашарга әзерләсеннәр.

Завклуб идарәгә китте. Берзаман бухгалтериядән 7 сум 40 тиен акча түләргә, дигән кәгазь җибәргәннәр.

–Кем бирде бу кәгазьне сезгә?

–Бухгалтер.

–Чакыр үзен, хәзер үк килеп житсен.

Урта яшьләрдәге бер ир-ат килеп керде.

–Мин бухгалтер, нишләп акча түләмисез?

–Әле безнен ашаган юк. Менә мин колхоз председателенә, партия оешмасы секретарена, авыл советына чакыру билетлары җибәрдем, һәрберсенә икешәр билет. Безнен билет бәясе 1 сум 20 тиен тора, 6 билетка 7 сум 20 тиен, кич белән председательгә 20 тиенен үзем бирермен. Безнен Академия театрында мондый кәгазьләрне кабул итмиләр. Мин сезгә үз кесәмнән чыгарып бирә алмыйм бит инде.

Мин анын үз кәгазен үзенә бирдем. Бик үпкәләп чыгып китте. Озак та тормады, тагын кәгазен күтәреп килгән.

–Акчагызны түләгез инде, председатель каршында мин ни дип җавап бирермен?–ди бу.

–Ярар, борчылма, председатель килгәч, үзем түләрмен,–дим.

Әз генә янгыр сибәли башлады. Спектакльне башларга председательне көтәбез. Юк! Каршымда басып торган завклубка болай дидем:

–Менә мин хәзер халык алдына чыгам да әйтәм: «Хөрмәтле тамашачылар! Без сезнең авылга шул хәтле ашкынып килдек, чөнки монда районның иң зур сыер фермасы, ул сарыкларыгыз турында әйтеп тә тормыйм. Бигрәк тә сез, хөрмәтле колхозчылар, Академия театрын карарга тиешле кешеләр! Сезнең хуҗаларыгыз безне шундый кыен хәлгә куйдылар, без бүген спектакльне ничек итеп уйнап чыгарбыз, әйтә алмыйм, артистлар шундый ач...

Завклуб алдында шундый зур монолог сөйләдем, юри кычкырам, артистлар да, тамашачылар да ишетсен дип. Завклуб түзмәде, коеп яуган янгыр астында, ашарга пешкәнме, юкмы икәнен белергә дип, урамга атылып чыгып китте. Председатель килмәсә дә, спектакльне башларга булдык. Бер заман манма суга батып завклуб килеп керде.

–Шакиров абый, зинһар борчылмагыз, бар да булыр, артистларны тынычландырыгыз. Миңа үпкәләмәгез, минем бер гаебем дә юк...–дип тезеп китте бу.

–Исендә тот, энекәш, артист үпкәләми–рәнҗи генә. Председателеңә әйт, минем мондый кешене күргәнем булмады, халкыбызның сөекле артисты Шакиров бик нык рәнҗеде диеп!

Тамашачы спектакльне шундый күтәренке рухта карады, гомергә кул чапмаган урыннарында рәхәтләнеп көлеп, кул чабып утырды. Әллә янгыр яуганга, әллә артистларның ачуы чыгып, үзләренең кем икәнлекләрен тамашачыга күрсәтәсе килгәнгәме, искитмәле шәп уйналды. Спектакль беткәч, безне чыннан да ашарга алып киттеләр. Мин инде өметемне өзгән идем. Шул хәтле мул ризык: аш, ит, бәлеш, өч кешегә бер ярты, кымызына хәтле бар!

–Нишләп шулхәтле мине җәфаладыгыз, мыскыл иттегез? Менә бит нинди матур өстәл әзерләгәнсез!–дим.

–Шакиров абый, мин син сөйләгәннәрне председательгә җылый-җылый сөйләдем! Бөтен авыл белән хур булабыз, барсын да үзем түлим, дидем. Безнең авылда артистларны мондый зур кунак итү беренче мәртәбә, ул да булса сезнең хакка! Кем белә, бәлкем соңгысыдыр. Безнең хуҗа шундый кеше, артистларны яратмый. Кайткач, зинһар, райкомга кермәгез инде!–ди завклуб егет.

Артистлар юл буе бүген булган хәлләрне сөйләп, берсен-берсе көлдереп, рәхәтләнеп күңел ачып кайттылар. Минем күңелдә ниндидер бер төер калды. Хәзер инде безнең артистлар бу вакыйганы мин язганнарга караганда күпкә кызыграк, истә калырлык итеп сөйлиләр.

## Яшьлек җүләрлеге

Без яшь вакытта, ягъни, әле театрда эшли башлаган елларда Урта Азиягә, Алма-Атага, Ташкентка булган гастрольләрне көтеп ала идек. Чөнки Казанда булмаган ризыкларны, җиләк-җимеш, кавын-карбызны бары тик шул якларда гына туйганчы ашап кала идек. Безнең заманда да ул, хәзер дә–Казан–иң ач, иң кыйммәтле шәһәрләрдән саналды, санала. Хәерче артистларга ул бигрәк тә анлашыла, ник дигәндә, без Советлар Союзы дип аталган урыс империясенең иң зур шәһәрләрендә айлар буе гастрольләрдә йөри идек. Шуңа күрә Казанның нинди пычрак, шакшы шәһәр икәнен бүтән калалар белән чагыштырып карарга мөмкинлегебез бар иде. Хәзер генә ул базарларда, кибетләрдә җаның ни тели, шул бар, акчаң гына житсен. Ул вакытларда мондый хәлне күз алдына да китереп булмый иде.

Шулай, Ташкенттагы гастрольләребезнең берсендә минем белән бик кызык, сабак алырлык бер хәл килеп чыкты. Без Ташкент шәһәрендә ай буе гастрольдә булдык, һәркөнне иртән «Алай» базарына җиләк-җимеш, яшелчә алырга барабыз. Базарга кергәч тә, каршыбызда эскерт хәтле кавын, карбыз өелеп ята. Җаның кайсын тели, шунысын ал! Кызык бит ул адәм баласы, башта килгәч тә бик тыйнак кына, сатулашмый гына үзебезгә ошаган кавын-карбызны сатып ала идек. Бер-ике көн узгач, болай да очсыз әйберләрне сатулаша башладык. Күп тә үтмәде, бу кавының бозыла башлаган, бу карбыз өлгермәгән, дип, тавыш куптарган арада, икенче беребез бер кавынны үзенеке итә, ягъни, чәлдерә иде. Бу бит кешенеке түгел, колхозныкы, үзбәкчә әйтсәк, кышлакныкы, шуңа күрә гөнаһысын да сизми идек, чөнки гомер буе колхозныкын урлап яшәдек, канга сеңгән. Житмәсә, тау

кебек өелеп ята. Артист халкы гаҗәп бит ул, түзми, ничек алдаганын башкалар алдында сөйләп, үзенең нинди оста артист икәнлеген күрсәтмәкче була. Бигрәк тә шул сәхнәне уйнап күрсәткәч, күңеле күтәрелеп китә, шуннан тәм таба. Бөтен театр шул турыда кызык итеп сөйли, йә ничек булды, ничек булды, безгә дә сөйлә инде, дип, тенкәнә тиеп бетәләр. Бу бит кесәндә аны алырлык кына акчаң булмаудан түгел, ә үзеңнең артистлыгыңны күрсәтәсе килүдән генә туган бер уен, шаяру гына. Ләкин шуны онытмаска кирәк, үзбәкләр бик кызу канлы халык, бигрәк тә үз илләрендә, җитмәсә, кулларында ат суя торган пычак, алдаганыңны яки чәлдергәнеңне сизсә, чәнчеп алырга да күп сорамас. Безнең бер артистыбыз ит алганда, нигә миңа гел сөяген генә саласың, дип,«ярамый» торган сүз ычкындырган өчен генә дә, «үтерәм, суям мин сине!»–дигән сүзләр белән үзбәк агае пычак тотып бөтен базар буйлап мескен артистны куып йөргән. Шуңа күрә бу эш үзенә күрә бик зур тәвәккәллек сорый. Кайберәүләребезнең мондый хәлләрдә хур булганнары да бар.

Менә гастрольләр бетәргә бер-ике көн калгач, мине Чимкент шәһәренә туйга чакырдылар. Ул Ташкенттан 120 чакрымнар чамасы булыр. Туйлар искиткеч күңелле узды, ике көн кунак булдым, кулларыннан килгәнчә хөрмәт иттеләр, матур итеп озаттылар. Хуҗалары шәһәрнең иң хәлле кешеләре иде. Хәтта безнең театрны кунак иткәннәре дә бар. Үзегез күз алдына китерәсездер яшь артист Шакировның туйдан ничек кайтканын. Уянып китсәм, Ташкентка килеп җиткәнбез. Исемә төште, иртәгә бит Казанга кайтабыз! Ә минем бернинди күчтәнәч тә алынмаган. Гадәттә, андый ерак гастрольләрдән кайтканда, үзең белән күбрәк әйбер алып кайтырга тырышасың, юлда гына да өч тәүлек кайтасы бар. Кунакханәгә кайтып җиткәч, нишләргә белми аптырап тора идем, бездә электрик булып эшләүче Рамил Сабитов басып тора. Ул егет турында үзе бер хикәя язарлык «материал» бар.

–Әйдә әле, Рамил, базарга барыйк, минем бит кайтырга бернәрсә дә алынмаган, әле генә туйдан кайтып төштем Чимкент шәһәреннән!–дим моңа.

–Әйтәм аны, бик затлы коньяк исе килә, өстәге киемнәрең дә... Юк, вакытым юк, бармыйм, үпкәләмә, эшкә барасы бар,–ди бу.

–Курыкма, Рамил, бәхилләрмен, хәзер машина алабыз да китәбез, борчылма, озак тормыйбыз. Бик тиз әйләнеп кайтабыз.

Машина тоттык та, «Алай» базарына киттек. Әле дә хәтеремдә, өр-яңа ак «Волга» иде. Килеп туктагач, шоферга әйтәм: «Безне көт, акча өчен борчылма, түләрбез»,–дим. Белмим, нишләптер "Волга»дан чыгуым булды, үзгәрдем дә куйдым бит, әй, үземне нindидер бер зур кеше итеп хис итә башладым! Рамилгә дә үземнең кем икәнлегемне күрсәтәсем килде, янәсе, артист Шакиров менә шундый була ул. Тукта әле мин әйтәм, базар хуҗасын табыйм, миңа иң яхшы әйберләрне алырга ярдәм итсен, акчам да үземә күрә җитәрлек, чөнки туйдан кайтып килəм. Базар хуҗасының кайда утырган урынын күрсәттеләр. Күрдем, өстәл артында өлкән генә бер үзбәк агае чәй эчеп утыра. «Сез миңа ярдәм итмәссез микән, базардагы затлы әйберләрне алырга»,–дим. Бу миңа бик озак карап торды, өстемдә иң яхшы тройка костюм, башта эшләпә, галстук, ботинкалар турында әйтеп тә тормыйм, туйда ничек киенгән булсам, шул килеш. Бераздан (хәзер инде исемен хәтерләмим, бик озак еллар истә иде) үзе кебек олы яшьтәге бер абзыйны чакырып алды. Нәрсәдер колагына әйтте дә, теге абзый мине үзе белән ияртеп алып китте. Шул арада безнең янга Рамил дә килеп җитте, минем хезмәтче ролен шундый итеп уйный, шаккатырсың. Бу кеше минем зур түрәләр белән эш итүче икәнемне аңласын өчен, үзбәкләрнең билгеле кешеләре турында шундый итеп сөйлим, авызга гына карап бара. «Башта,–мин әйтәм,–кавын-карбыз алабыз, аннан җиләк-җимеш»,–дип санап киттем. Безнең янга ук ак "Волга»килеп туктады, шоферга беркая да ашыкмаска, көтәргә куштым. Кавын сатучылар янына килгәч, менә монысын, менә монысын, дип, бармак белән генә төртеп күрсәтәм. Иң матур, өлгергән зур кавыннарны сайлый башладылар. Үзбәк агае үлчәргә теләгән иде, мин: «кирәкми!»–дидем. Рамил бер зур кавынны күтәреп машина янына китте, аның артыннан ике үзбәк, ун килодан артык булгандыр, шулай ук ике кавынны машина багажнигына китереп салдылар. Шуннан соң бик зур ике карбызны көчкә күтәреп килделәр. Мин базар хуҗасының исемен әйтеп, аның нинди яхшы адәм икәнен үзбәкләргә аңлатам. Бер ящик «дамские пальчики»ны алдыма китереп куйдылар. Шул хәтле матур, эре, пешеп кенә килә

торган шәфталуны, безнеңчә персиклар була инде, зур тартмага бик кадерләп төреп бирделәр. Инде хәзер кипкән җимешләр генә аласы калды. Миндә шундый кураж башланды, хәзер инде үзем базар хуҗасына әвереләдем, мондый чакта мине беркем дә тыя алмас иде. Үзбәк сатучылары аптырап карап торалар, чөнки мине ике-өч кеше обслуживать итә. Үземә кирәк әйберләрне барсын да алдым шикелле, базардагы иң яхшы җимешләрне китерделәр. Рәхмәт әйтеп машинага утырдым, бигрәк тә базар хуҗасына минем рәхмәтемне җиткерергә куштым. Үзбәкләр мине озатып калдылар. Машинага кергәч карасам, Рамилнең йөзе ап-ак, маңгаена салкын тирләр бәреп чыккан, үзе калтырана. Кунакханәгә килеп җиткәч, шоферга акча бирдем дә: «Әгәр берәр нәрсә кирәк булса, базар хуҗасына бар, ул мине белә!»–дидем. Номерга әйберләрне көчкә ташыдык, шулхәтле күп җыелган, ничек алып бетергәнмендер. Шунда Рамил әйтә: «Әзһәр абый, син бит бу әйберләр өчен бер тиен дә түләмәдең! Әгәр синең артист икәнеңне белсәләр, икебезне дә суялар бит. Ник мине анда алып бардың, харап булдым, харап булдым»,–дип өзгәләнә, мине тирги башлады. «Менә күрдеңме инде, артист Шакиров ничек була ул! Әйдә, үпкәләмә, сыйлыйм үзеңне!» дигәч: «Минем эшкә барасым бар, театрга киттем»,–дип шылды бу.

Үзем генә калгач, айнып киткәндәй булдым. Чыннан да, минем кем икәнемне белсәләр, күрмәгәнемне күрсәтерләр иде. Бу турыда уйлау да куркыныч. Менә хәзер дә мин аңлый алмыйм, ничек курыкмыйча шундый эшне эшли алганмын?! Казанда булса бер хәер, кичерегез зинһар, мин шаярдым гына, барысын да түлим, без бит үз кешеләр дисәм, бәлки аңларлар да иде. Монда, Ташкентта, «Алай» базарында дөньяда күрмәгән эшне эшләп кара! Кайсыгызның йөрәге җитә икән?! Юк, аек акыл белән мондый эшне эшләмиләр. Җанны тынычландыру өчен эчеп тә карадым, кая, эчкән саен айныйм гына. Менә хәзер килеп керерләр дә, үтереп ташларлар сыман тоела башлады. Түзмәдем, исән чагында урамга чыгыйм дип, киемнәремне алыштырып, театрга киттем.

Төнге сәгать унберләрдә кайтып керсәм, Ташкенттагы дусларым мине көтеп утыралар. Берсе прокуратурада эшли, икенчесе милициядә, өченчесе, мине бик хөрмәт иткәне, араларында иң юмарты–Мәгъсүм исемлесе–әйтә: «Без сине сәгать уннан бирле көтәбез, кая югалдың?!»–ди.

Мин боларга үзем белән булган хәлне сөйләдем, үземнең шундый зур хата җибәрүемә үкенгәнемә ышандырырга тырыштым. Әлбәттә, ышанмадылар, рәхәтләнеп көлделәр генә. «Нәрсә, ике-өч кавын-карбыздан үзбәкләрнең малы кимер дип уйладыңмы? Алай бик борчылма, Аллаһы Тәгалә аларга уйламаган җирдән бирер. Әйдә, җырла, бүген без сине озатырга килдек, иртәгә эшкә!»–ди болар. Алар да күчтәнәчкә эчемлекләр, тәмле ризыклар алып килгәннәр. Мин үземнең янә дусларымны чакырып, бик матур итеп мәҗлес корып төн уздырдык. Икенче көнне Рамилгә әйтәм: «Кара аны, бу турыда беркемгә дә сөйләмә!»–дим. Кая инде, Казанга кайтуга ук минем белән булган хәлләрне бөтен театр белә иде. Шулкадәр арттырып, кызык итеп сөйлиләр, хәтта, үзем дә ышана башладым. Сез әйтерсез, нигә инде бу турыда язган, бер дә кызык түгел дип. Моны мин кызык булсын өчен язмадым, гыйбрәт вә сабак булсын өчен яздым! Аңлаган кеше аңлар.

# КАБАТЛАНМАС СӘЙДӘШ

XX гасырның 20 нче елларында Татарстанда композиторлык мәктәбе оеша башлый. Солтан Габәши белән Салих Сәйдәшев—әнә шул мәктәпнең башлангыч буынын хасил итәләр. Иҗат эшчәнлеген дә алар икесе бервакытта—С. Габәши Уфада, С. Сәйдәшев Казанда башлап җибәрәләр. Беренчесе—тәүге татар операсын тудырса, хор житәкчесе һәм мөгаллим булса, икенчесе—музыкаль драма авторы, дирижер. Икесе дә халык яратып җырлый торган җырлар язып киң танылалар.

Ятим калгач, Салих Сәйдәшев апасының гаиләсендә тәрбияләнә. Жизнәсе Шиһап Әхмәров Казанда атаклы журналист һәм иҗтимагый эшлекле була. Ул ана фортепиано ала, укытучы итеп композитор Заһидулла Яруллинны чакыра. Әлеге һәм сонгы елларда Салих Сәйдәшев күренекле шәхесләр белән таныша һәм аралаша. Алар арасында Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Һ. Такташ, К. Тинчурин, Г. Ибраһимов, Т. Гыйззәтләр бар. Халкыбызның асыл затлары белән аралашу ана тирән йогынты ясый. Салих Сәйдәшев—махсус музыкаль белем алган беренче татар композиторы. 1915-1918 елларда ул Казан музыкаль училищесында укый. 1918 елдан—гражданнар сугышында, ә 1922 елда Казанга кайткач, татар дәүләт драма театрының дирижеры һәм музыка житәкчесе вазыйфасына керешә. Бу театр исә «Сәйәр» труппасына нигезләнеп оештырыла. Бераздан Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы татар опера студиясендә укый башлый. Композиторның иң зур ачышлар ясаган жанры музыкаль драма, музыкаль-драматик әсәр була.

Салих Сәйдәшев иҗатын өч чорга бүлеп карарга мөмкин.Тәүгесе—1922—1926 елларда куелган спектакльләр. «Галиябану», «Башмагым», «Казан сөлгесе»ндә музыка гаҗәеп дәрәҗәдә фольклор белән тыгыз үрелеп барыла. Иҗатының икенче чоры—20-30 елларда куелган спектакльләр: «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Наемщик», «Кандыр буе». Боларда инде аерым музыкаль номерларга, җыр һәм арияларга, ансамбль вә хор, увертюра вә балет сюиталарына да зур урын бирелгән. Өченче чоры исә Бөек Ватан сугышы һәм аннан сонгы елларда язылган әсәрләрдән гыйбарәт. Болар—«Ил», «Чын мәхәббәт».... Элгәреге казанышлары биредә дә үстерелә. Әмма дә инде музыкаль-театраль жанрда өстенлекле халәткә опера ирешә бара.

Шау-гөр килеп социализм төзегән дәвердәге энергияне, тормыш көчен композитор көйгә кучерә һәм ул яна дөньяга мәдхия булып янгырый. Ничә гасырлык кимсетелүләрдән һәм коллыктан сон татар халкы, ниһаять, үзен хөр итеп, башкалар белән тигез хокуклы итеп тоя башлады, киләчәккә өмете ныгыды. Салих Сәйдәшев исә нәкъ менә милләтнең ошбу халәтен музыкада чагылдыра алды.

20-30 елларда бик сирәк спектакльләр генә аның музыкасыннан башка куела иде. Әйе, Сәйдәш бу елларда гаҗәеп күп яза. Татар композиторлары иҗатында бу—сирәк очрый торган күренеш. Сәбәп нидә? Беренчедән, дөньяда монарчы булмаган вакыйгалар эчендә кайнау, шунын искитмәле көчле тәэсире, икенчедән, илаһи талант һәм яшьлек дәрт-дәрманы. Гаять чибәр, ихлас, һәм тыйнак булган бу затка табигать тарафыннан да музыкаль сәләт юмарт итеп бирелгән. Ә Сәйдәш үзенең тарихи әһәмиятен башына да китермәгәндер, юкса, әсәрләренең сакланышы хакында кайгыырткан булыр иде. Анын байтак кына музыкаль әсәрләренең партитурасы да сакланмаган, аерым уен коралларының тавышлары гына калган.

Батырлык һәм пәрварлык образларыннан тыш, татар музыкасына Сәйдәш алып килгән яналыклар бик күп: бәйрәм һәм мәхәббәт лирикасы, бай шәрекъ чалымнары... Боларның һәммәсе дә милли музыкабызның офыгын киңәйтте, төсмерләрен

арттырды. Күтәренке рухтагы бәйрәм рәвешләренә композитор бию такмакларын өсти, хәрби марш һәм канкан чалымнарын куша. Лирик җырларында романс һәм опера арияләре исә милли фольклор традицияләре белән табигый рәвештә үрелеп барыла. Шәрекъ җыры һәм биюләре белән ярашуы да яңа образлар хасил итә. Аның музыкасын үзебезнең татар да, башка милләт вәкилләре дә аңлый, тоя, күңеленә сеңдерә. Урта Азия җөмһүриятләрендә Салих Сәйдәшев музыкасының киң таралуы үзе үк моңа зур дәлил.Аның хакында бу якларда бик күп язалар, аны һәммәсе белә, аны таныйлар, аны яраталар! Композитор үзе дә Урта Азия якларыннан, Урал һәм Себердән кайтып керми, һәркайда аңа кадер-хөрмәт күрсәтәләр, олылап озаталар.

Салих Сәйдәшев—һөнәрмәнд инструменталь музыканың нигезен салучы да. Элек җыр-бию фольклорына гына, такмакларга гына яраган уен коралларына ул киң тавыш диапазонына ия булган тантаналы һәм зәвык белән яңгыраган аһәңнәр өсти. Яңа жанрлар—марш, вальс, увертюра, берничә бию көйләреннән төзелгән сюиталарны тудыра һәм үстерә. Мәсәлән, аның «Совет Армиясе маршы» бүген Татарстанның үзенә күрә бер визит карточкасына, эмблемасына әверелде. «Кандыр буе»ндагы «Уңыш бәйрәмендә» сюитасы, «Наемщик»тан «Вальс», «Таһир һәм Зөһрә»дәге «Шәрекъ биюе» һ. б.—моның ачык мисалы.

Тискәре образларны күрсәткәндә дә композитор үз-үзенә тугры: өстен катлау вәкилләренең сурәтләрен музыкада гаять үзенчәлекле алымнар белән гәүдәләндерә. «Зәңгәр шәл» дә, мәсәлән, ишан образы «Бәдавам» мөнәҗәтен көйләгәндә ачыла, пародиягә әверелә. Нәтиҗәдә, надан вә хөсетле зат күз алдына килеп баса. «Наемщик»та да тискәре образлар кызыклы. Икенче бүлегендәге күренештә гаҗәеп зәвыклы биюләр—«Вальс», «Адажио», «Пастораль» һәм «Мазурка» яңгырый. Ясалма затлылык, тәкәбберлек гади халыкның табигый аһәңе белән капма-каршы килә.

Композиторның әсәрләрендә тора-бара аерым халык уен коралларында башкарылган көйләр ансамбль, яисә ханәи (камера) оркестрына (12-15 кеше) кадәр үзгәреш кичерә. Уен коралларында уйнаучыларның саны кайчагында 30 га да җитә.

Салих Сәйдәшев еш кына ни клавир, ни партитураны да кәгазьгә төшереп калдырмаган. Ул партияләрнең тавышларын гына иҗат иткән, хәтер буенча дирижерлык кылган. Шул рәвешле, партитура туганда ук билгеле бер тембрларда яңгыраган. Мөгаен, музыка язу өчен аның вакыты бик кысынкы булгандыр. Мәгълүм ки, ул елларда театр сезонына 10-12 спектакль чыгарган. Болардан тыш композитор әле бик күп концертларда йә башкаручы, йә дирижер буларак катнашкан, радиода эшләгән, күренекле җәмәгать эшлеклесе булган.

Бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең иҗади мирасы әле бүгенге көндә дә тулылана тора. Аның иҗатына мөкиббән аһәнсазларыбыз махсус музыкаль әсәрләр багышладылар. «Музыкаль бүләк» (авторы—А. Монасыйпов), «Сәйдәшстан» сюитасы (Р. Еникеев), фантазия һәм парафразлар (А. Миргородский, Р. Абязов, И. Байтирәк)—әнә шундыйлардан.

Әле күптән түгел генә арабыздан киткән күренекле композиторыбыз Алмаз Монасыйпов кайчандыр Салих Сәйдәшев турында болай дигән иде: «Сәйдәш турындагы фильмга музыка язарга тәкъдим иткәч, мин үзем өчен гаҗәеп зур музыкаль ачышлар ясадым. Бөек Сәйдәшне мин яңадан ачтым».

**Аида АЛМАЗОВА,**
*сәнгать фәннәре кандидаты.*

# АНЫҢ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

Мин Муса Җәлилнең алтмыш еллыгын уздырырга Германия Демократик Республикасына бардым. Күңелдә сәер хис: әгәр, дим, хәзер күзләремне бәйләп, Европа кырларына кертеп җибәрсәләр, Польшаны Шопен моннары буенча, Германияне Бах органының югарыдан, кешелек дөньясы өстеннән яңгыраган тавышы буенча да барыбер табар идем. Ә үз җиремә, Идел буйларына килеп чыгар өчен миңа Сәйдәш маршының бер генә тапкыр яңгырап китүе дә җитә. Мин ул маршны Бөек Ватан сугышы елларында Калинин фронтының бураннары эченнән ишеттем. Кешене үстерә, күтәрә, яшәтә, омтылдыра торган илаһи рухлы музыка...

**Сибгат ХӘКИМ**

Салихны көйләр чишмәсе дип атыйсы килә. Ул көйләрне ничек иҗат итим дип газапланмый, ә күңелендәгесен тизрәк ноталарга салу, язып өлгерү мәсьәләсе генә аны борчый төсле тоела иде. Шуңа күрәдер, әсәрен симфоник оркестр өчен эшләгәндә ул еш кына партитураны язмый иде, ә һәр музыка коралы өчен турыдан-туры партияләр яза иде. Аннан соң театрның ноталар китапханәчесе Мөхәммәт Яушев һәм мин әлеге партияләрнең дубликатларын күчереп яза идек. Мөхәммәт Яушев һәм Мөхәммәт Йосыпов икесе дә скрипкачылар иде. Икесе дә Салихның якын ярдәмчеләре, гомерләре буе аның кульязмаларын—ноталарын күчереп язучылар, аның дуслары иделәр.

**Мансур МОЗАФФАРОВ**

Салих Сәйдәшев—драма спектакльләрен музыкалаштыру, музыкаль оформление эшләүнең соклангыч осталыгына ия булган композитор. Күренекле драматургларыбыздан Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт бу осталыкны тиз күреп алдылар, нык тойдылар һәм үзләренең байтак сәхнә әсәрләрен композиторның талантын күздә тотып яздылар. Салих Сәйдәшев исә алар белән уртак хезмәттә рухи баеды, үткен карашлы художник булып үсте, шул ук вакытта иҗатташ дусларына да күп нәрсә бирде, аларны музыка дөньясына алып керде.

Салих Сәйдәшевнең тормышка дан җырлаучы музыкасы тирән оптимизм, кешеләрнең олы хисләре һәм мөнәсәбәтләре, кешелек дөньясына мәхәббәт, хезмәткә зур ихтирам белән сугарылган. Сәйдәшнең музыкасы яшәргә чакыра. Киң танылу тапкан композиторның бөеклеге дә шунда.

**Нәҗип ҖИҺАНОВ**

Салих Сәйдәшев үзе иҗат иткән эпоханы тоя белде, үз халкы психикасының нигезенә үтеп керә алды һәм иң мөһиме—бу халыкның рухи тойгыларын музыка чаралары белән аңлатып бирде. Аның новаторларча кыю рәвештә яңа формалар, яңача яңгырашлы моңнар эзләвенең тамыры алда әйтелгәннәрдән килеп чыга да инде. Татар халкының музыкаль үсеш дәрәҗәсенә нигез салган Салих Сәйдәшев сәнгатенең бетмәс-төкәнмәс әһәмияте дә шуннан килә.

Композиторның мирасын өйрәнеп утырганда, Салихның музыкасындагы чиксез байлыкка хәйран каласың. Нинди иркен һәм киң колачлы ул! Һәм шул ук вакытта тирән моңлы да! Классик җыйнаклык һәм мәгънәвилек өстенә форма белән шулкадәр иркен эш итү осталыгын гына карагыз сез аның! Бернинди артыклык, ясалмалылык юк, технологиясе бәрелеп торган урыннарын да таба алмыйсың.

**Александр КЛЮЧАРЕВ**

## СӘЙДӘШ ЯДКАРЕ



*Салих Сәйдәшевнең әнисе Мәхүбҗамал. XX гасыр башы.*



*Шәкерт Салих. 1912 ел.*



*Салих укыган мәдрәсә (Хәзерге Тукай урамы, 34 йорт).*



*С. Сәйдәшев—почетлы кызылармеец. 1929 ел.*



*Татар музыкантларыннан бер төркем. Беренче рәттә (сулдан уңга): М. Яушев, Г. Әлмөхәммәтов, Ф. Туишев, С. Сәйдәшев, М. Юсупов. Икенче рәттә: Ф. Биккинин, Х. Әхмәдуллин, И. Һилалов, Һ. Гомәрев, С. Габәши, Г. Сәйфуллин.*




*С. Сәйдәшевнең иҗат концертына багышланган афиша. 1951-52 еллар сезоны.*



*Идел буенда. 1954 ел.*



*С. Сәйдәшев Яңа бистәдәге татар зиратына күмелгән.*



Фәүзия
Бәйрәмова

# ДАЛАДА—ТАТАР КУРГАННАРЫ

## Тамерлан төрбәсе

Далада таулар юк, далада шихан-сыртлар һәм курганнар гына...

Курганнар—гасырлар буе өелгән борынгы каберлекләр, аларга кимендә дүрт мең ел. Тарихта бу курганнарны скиф-сармат, һун-сөн каберлекләре, дип тә йөртәләр, урыслар исә аларны «татар бугорлары», дип атаганнар, борынгы каберлекләрне актарып, алтын-көмеш бизәнү әйберләре тапканнар. Хәзер исә даладагы бу курганнарны татар тарихы белән бәйләмәскә тырышалар, аларны йә индһ-иран халкына, йә билгесез кавемнәргә бирәләр, хәтта төркилекләрен дә яшерәләр. Төркилек мәсьәләсендә дә үзара тарткалаш бара: казахлар ул курганнарны бары тик үзләренеке генә, дип яза, башкортлар башкортныкы, ди, татар галимнәре бу бәхәскә катнашмый.

Минем Курган, Чиләбе, Ырынбур өлкәләренә барып, андагы борынгы курганнар турында шактый язганым булды. XIII гасырга кадәр чит ил һәм урыс галимнәренең скиф-һун-татар милләтен бер итеп караулары турында да мисаллар китереп күп яздым. Аларны кабатлап торасым килми. Әгәр урман-дала татарлары скиф-сарматларның, һуннарның дәвамчысы икән, димәк, алардан калган тарихи истәлекләр, курган-төрбәләр дә татар халкының мәдәни-рухи мирасы булып тора. Хәзер сүзем шундый тарихи мирасларның берсе—Чиләбе өлкәсенең көньягына урнашкан Тамерлан төрбәсе турында барачак.

Аның «Тамерлан башнясы» дип аталуы шартлы рәвештә генә, соңгы гасырда бирелгән исем. Риваятьләр буенча, имеш биредә Аксак Тимернең кызы күмелгән, ул, имеш, бер егет белән атасыннан качып киткән, әмма аны сакчылар Аксак Тимер әмере буенча үтергәннәр. Ата кеше моның өчен соңыннан бик үкенә һәм кызы өчен шушы төрбәне төзетә. Имеш, төрбә өчен кирпечләрне хәзерге Троицки шәһәре булган җирдән, 150 чакрым арадан, ханның гаскәриләре кулдан-кулга биреп торып бирегә хәтле китереп җиткергән. Әмма күпчелек галимнәр бу риваятькә ышанмыйлар, аны әкияткә тиңлиләр. Элек бу төрбә Кәшәнә, дип аталган, ул исә борынгы төркичәдән төрбә, мавзолей, дигәнне аңлата, ягъни, берәр билгеле кеше күмелгән урын. Бу тирәдә исә бер генә түгел, йөзләгән билгеле кеше, дистәләгән татар ханнары күмелгән булып чыкты. Хәер, барысы турында да тәртип белән генә сөйлик.

Иң беренче тапкыр Тамерлан төрбәсе турында мәгълүматка мин Күчем хан

---

Фәүзия БӘЙРӘМОВА—*язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән 20дән артык китап авторы. Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. Чаллыда яши.*

буенча материаллар эзләгәндә юлыктым. Казах язучысы Мурат Абдиров Күчем ханның кабере хәзерге Чиләбе өлкәсенен Варна бистәсе янында, Зур һәм Кечкенә Кәсәнә күлләре арасында, «Тамерлан башнясы» дип аталган төрбә янында булырга мөмкинлеген язган иде. *(Мурат Абдиров. Хан Кучум: известный и неизвестный.— Алматы, 1996, стр.133.)* Ул анда Себер ханнары Шәйбәниләрнен нәсел каберлегe булырга тиешлеген хәбәр итә. Мурат Абдиров бу мәгълүматны Казахстанның башка галимнәреннән алганлыгын әйтә. (*Новожилов Г. Архитектурные памятники Казахстана.—Алма-Ата, 1968, стр.11-14.*), (*Токтабаев Ахмет. Кесене мазары.—Казакъ әдәбияты, 1988, декабрь.*)

Күчем хан турында мондый хәбәр мина шактый сәер тоелды, чөнки ни өчен әле Себер ханын башкаласыннан еракта, су юлы булмаган дала уртасында күмәргә тиешләр, ди? Мин моңа ышанып бетмәдем, алай да күнелемә Чиләбе өлкәсе, Варна, Тамерлан башнясы, дигән атамалар кереп калды. «Күчем хан» романын боларны искә алмыйча гына яздым, чөнки ачыкламаган хәбәрне әсәрләремә кертә торган гадәтем юк. Әмма Варна бистәсе, анын янындагы Тамерлан төрбәсе күнелемнән китмәде, анын буенча шактый материал тупладым, һәм жай чыгу белән шул якларга юл тоттым.

Ул якын ара булып чыкмады—башта Татарстан, Башкортстан, Урал таулары аша 14 сәгать автобуста килдем, аннан жинел машинага күчеп утырып, урый-урый 4-5 сәгать дигәндә Варнага килеп җиттем. «Чиләбе өлкәсенен ин көньяк чигендә урнашкан, биредән 20-30 чакрымда Казахстан башлана»,—диделәр. Килү белән, Тамерлан төрбәсен карарга киттек, ул Варнадан 3-4 чакрым ераклыкта икән. Аны башня дип атап йөртсәләр дә, пирамидага охшатып торгызылган, бераз калкурак урында, кызыл кирпеч белән шакмак рәвешендә тышланган, эчтән түгәрәк булып калган 17 метр биеклектәге бина иде бу.

Тамерлан төрбәсе тыштан—мавзолейны, эчтән шәһри Болгар пулатларын хәтерләтә. Бердәнбер биек ишегe арка сыман итеп эшләнгән һәм көньякка урнашкан, ике озын, тар тәрәзәсе көнчыгышка һәм көнбатышка карый. Түбәсе очлаеп килгән, тишек-фәлән юк. Ишекне атлап керү белән, як-якта ике уенты бар, анда, имеш, хәрби сакчылар торган. Соңыннан ясап куелган тимер ишеккә чүпрәк-чапрак эленгән, монысы инде яна мәжүси гадәт икән. Яна өйләнешкәннәр биргә килеп фотога төшәләр, күпләр бирелә ял итәргә ярата, без барганда да урыс яшьләре бер читтә хәмер эчеп, сыйланып утыралар иде. Югыйсә, бу Россиянен тарихи ядкарьләр исемлегенә кертелгән бина, һәм ул закон белән сакланырга тиеш бит.

Бинаның бик борынгы икәнлеге бәхәссез, аны күпчелек галимнәр XIV гасыр истәлеге, дип яза, төрбәнең төзелешен XII гасыр белән бәйләүчеләр дә бар. Ул элек башка төрлерәк—ике катлы һәм түгәрәк рәвештә булган. Мин анын элеккеге рәсемнәрен һәм узган гасырда төшерелгән фотосын күрдем, алсу кирпечләрнен шул кадәр тыгыз тезелүенә шаккаттым. Аларнын арасына хәтта жеп тә керерлек түгел иде! Моннан 600-700 еллар элек, кул көче белән, ничек шулай камил бина төзергә була?! Әйткәнемчә, элеккеге бинада кирпечләр алсу төстә, яссы рәвешле һәм шактый зурлар булган, мин моны Варна музеенда күрдем. Шундый ук алсу, яссы кирпечләрне Тубылда күреп кайттым, алар Себер татарларынын элеккеге башкаласы Искәр урыныннан табылган иде.

Без әле Тамерлан төрбәсенә янадан әйләнеп кайтырбыз, ә хәзер анын тирә-юнендә ниләр булганлыгын да язып үтик. Бер караганда, бу тирәләр тоташ даладан тора кебек, әмма игътибарлырак булсан, жирнен тигез түгел икәнлеген, урыны-урыны белән өелгән калкулыклардан торганлыгын күрәсен. Болар—борынгы курган-каберлекләр инде, галимнәрнен әйтүенчә, биредә йөзәр чакрым әйләнә-тирә тоташ борынгы каберлекләрдән тора икән. Ерак түгел Бреды районында, Синташ елгасы буенда борынгы металлургия комплексы табылган, күршедәге Чесма (Чишмә) районынын Клинов авылы янында бронза чоры курганы ачылган, янәшәдәге Карталы районында исә атаклы «Курган с усами» бар. Биредән ерак булмаган Кулечи авылы янында, Карталы-Аят һәм Арчаглы-Аят елгалары кушылган урында, кырыктан артык археологик ядкарь табылган, аларнын унысы—таш гасырга, алтысы бронза чорына карый. Карталы-Аят елгасынын сул ярында унсигез курган

табылганлыгы билгеле. *(В.Никитин. «Отступив за даль столетий...» , »Челябинский рабочий», 1979, 3 апреля.)*

Алай гына да түгел, бу урын—борынгы скиф-сармат патшаларын күмә торган махсус урын булганлыгы билгеле. Шуңа күрә биредә таш төрбә-мавзолейлар да, пирамида-курганнар да, алтын-көмеш күмелгән каберлекләр дә һаман очрап тора. Сүзем буш булмасын өчен, Чиләбе галиме, тарих фәннәре докторы Г.Здановичның фикерен китерәм:

«Трудно найти человека в Челябинской области, который бы не видел или не был наслышен о «Башне Кисене». Однако мало кто знает, что мавзолей построен на древнем погребальном поле. Тот участок ковыльной степи, что сохранился вокруг «Кисене», служил кладбищем для многих поколений людей в течении почти четырех тысяч лет—от начало II тыс. до н.э. до XVII-XVIII вв. н.э. И кладбище это нуждается в таком же внимании, как и мавзолей Кисене. Мавзолей и древнее кладбище—это единый уникальный памятник истории народов Южного Урала. Сейчас вокруг мавзолея развалины различных сооружений, переживших века. Это остатки каменных кольцевых конструкций и каменных ящиков бронзового века, почти стертые с поверхности земли пирамиды, сложенные из дерева и дерна в скифосарматовскую эпоху, поверженные каменные «бабы» и ритуальные полощадки тюркского времени.» *(Г.Зданович. «Сохраним для потомков», »Челябинский рабочий», 1982, №93, 7 августа.)*

Бу язмадан күренгәнчә, Тамерлан-Кисәнә төрбәсе дүрт мең еллык борынгы каберлекләр өстендә утыра икән. Автор аларның бронза гасырына, скиф-сармат чорына караганлыгын яза, бу каберлек-курганнарны пирамидалар, дип атый, биредә таш балбаллар булганлыгын һәм боларның барысын да төрки заманнар белән бәйли. Бу—бик мөһим бәяләмә, чөнки еллар үтү белән, төрле сәбәпләр аркасында, бу яклардагы борынгы цивилизацияне төркилек белән бәйләмәскә тырыша башладылар. Беренче планга индо-иран версиясе чыкты, бу исә тамырлары белән фарсы һәм борынгы славянлыкка барып тоташа. Хәзер Аркаимны да бик тырышып шул якка боралар, күрә торып, ялган тарих ясыйлар. Ә безнең өчен Аркаимның да, Тамерлан-Кисәнә төрбәсе янындагы борынгы курган-каберлекләрнең дә төрки цивилизациясе мирасы икәнлеге бәхәссез.

«На основании исследовании ученных Палласа, Сальникова, Стоколова до сооружения мавзолея Кесене на этом месте существовал древний некрополь, насчитывающий несколько сот курганных захоронений,—дип яза икенче бер урыс тарихчысы.—На протяжении четырех тысяч лет возвышенность, расположенная между озерами, служила погребальным полем. В наиболее чтимой, центральной части некрополя был сооружен мавзолей Кесене. В мавзолее хоронили знатных феодалов. По анализу исследований и архитектурных особенностей сделан вывод, что памятник сооружен в XIV веке.» *(С.Загребин. «Башня Тамерлана? Нет—Мавзолей Кесене.» , «Комсомолец», 1983, №59, 17 мая.)*

1960 елны археолог В.С.Стоколов бу некропольне махсус өйрәнә һәм бер борынгы курганны ача. Бу курганнан бронза чоры савытлары чыга, алар галимнәр тарафыннан, безнең эрага кадәр II меңьеллык уртасында ясалган, дип бәяләнә, ягъни, бу табылдыклар Аркаим белән бер чорда эшләнгән була. Шулай ук бу курган янәшәсенә 8 мөселман кабере дә табыла, алары инде соңгырак чорга карый. Шунысын да әйтергә кирәк, Аркаим биредән 70-80 чакрымнарда гына урнашкан, һәм ике арадагы Карталы, Бреды, Кызыл бистәләре туфраклары Варнага кадәр борынгы курган-каберлекләр белән тулы. Бу нәрсә дигәнне анлата? Бу, кайберәүләр язуынча, далада даими зур сугышлар булуын анлатмый, ә биредә халыкның меңнәрчә еллар буе утрак (оседлый) тормыш белән яшәүләрен күрсәтә. Галимнәр язуынча, Чиләбегә кадәр бу арада йөзләрчә шәһәрләр булган, ул хәзер тарих фәнендә «Шәһәрләр иле» («Страна городов») дип атала. Димәк, хәзерге Варна авылы урнашкан Тугызак елгасы буйларында да утрак тормыш белән яшәүче скифлар һәм сарматлар, һуннар һәм төрки-татарлар көн күргән, бу борынгы курган-каберлекләр алардан калган. Әйе, биредә гомер-гомергә кешеләр яшәгән, һәм бу турыда жирле тарихчылар менә нәрсә яза:

«Судя по археологическим находкам, варненская округа была очень популярна у наших земляков с глубокой древности. Напомним о мавзолее Кесенэ, который венчает некрополь древних южноуральцев с каменного века по средневековье—около четырех (!) тысяч лет. Выше Варны по речке у поселка Солнца, где в Нижний Тогузак впадает ручей Кесенэ, обнаружены остатки одной из крепостей всемирно известной Страны городов—Устье. Следы обитания человека каменного века обнаружены на берегах реки на окраинах Варны, а в окрестностях—древние курганы.» *(Александр Моисеев. «Регулярное селение», »Уральский курьер», 2006, 12 марта.)*

Узган гасырның 70-80 елларында, әле Аркаимның исе дә чыкмаган вакытта, Чиләбе галимнәре, шул ук тарихчы Зданович та, Тамерлан-Кисәнә тирәсендәге курганнарны өйрәнеп, биредә тарихи-мәдәни комплекс ачарга уйлыйлар, 100 гектар җирдә 15 борынгы каберлекне торгызырга планлаштыралар. «Кесене будет заповедником погребальной архитектуры. Аналогов в нашей стране нет», диләр алар. 1981-1982 елларда төрбә торгызыла, кызыл кирпеч белән тышлана, курганнар тикшерелә, комплексның проекты эшләнә, ачык һавадагы музей-тыюлык өчен барысы да әзер була. Әмма мондый тарихи комплексны Варнада түгел, Аркаимда ачарга булалар һәм шулай эшлиләр дә. Болай эшләүнең мин берничә сәбәбен күрәм.



*Варна авылы янындагы Тамерлан төрбәсе.*

Әгәр даладагы борынгы цивилизация үзәген Тамерлан төрбәсе янында эшләсәң, аның тамырлары төркилеккә барып чыгар иде, ә бу дөреслек Россия тарихчыларына кирәк түгел ахры. Әле 1972 елда, Тамерлан музей-тыюлыгының эшче проектын эшләгәндә үк, бирегә Казахстан галимнәре килеп, бу тарихи истәлекнең казах мәдәнияте ядкаре икәнлеген язып калдырганнар. Монда төркичелек бөтен яктан да кычкырып тора—скиф-сармат-һун, төрки-татарлар, төрки-казахлар тарихын әйләнеп узып булырлык түгел. Шуңа күрә музей-тыюлыкны абстракт Аркаимга күчерделәр, дип уйлыйм.

Анда күчерүнең икенче сәбәбе—Тамерлан-Кисәнә төрбәсенең Варнага якын булуы, ә ана татарлар нигез салган, хәзер дә менәрләгән милләттәшебез шунда яшәп ята. Телисеңме-теләмисеңме, бу борынгы курган-каберлекләр татарлар исеме белән дә бәйләнәчәк, ә бу кемнәр өчендер кирәкми. Шул сәбәпле монда ачык һавада музей комплексы ачу эше туктатыла. Бер яктан караганда, ул комплексның монда булмавы яхшы, чөнки, проект буенча, биредә мәҗүси ритуаллар башкару күздә тотылган булган. Ягъни, борынгы курган-каберлекләр өстендә корбаннар чалып, кан агызып, мәҗүси иләһәләрне «сыйлау»лар планлаштырылган булган. Борынгы каберлектә мондый куркыныч бидгать гамәлләр кылудан безне Аллаһ Үзе саклап калган булырга тиеш.

Әйе, бу—мазарлык, йөзләрчә еллар ул мөселман зираты да булып торган. Бу хакта мөселманча күмелгән каберлекләр дә сөйләп тора, кайбер тарихчылар да яза. Ә бу яктагы мөселманнар—алар төрки халыклар: казахлар, татарлар, нугайлар, башкортлар... 1768 елда Россия фәннәр Академиясе чакыруы буенча, бу якларның тарихын алман галиме П. С. Паллас килеп өйрәнеп китә һәм ул Тамерлан-Кисәнә төрбәсен «татарский молитвенный дом», дип атый. *(Паллас П. С. Путешествия по разным провинциям Российской империи в 1768-1769 годах. СПб, 1770. Кн.I. Ч. 2., стр.137.)* Моңа тарихчы Сергей Боталов та игътибар итә:

«Побывавший на берегу Кесене в 1770 году академик Петр Симон Паллас, конечно же, осмотрел «Татарскую Кошену», посчитав Башню «молитвенном домом кочевников». *(Сергей Боталов. Номады.—Челябинск, 2000, стр.27.)*

Жирле тарихчы В. Артемьев та бирedә мөселманнар күмелгән булырга тиешлеген яза:

«...Дело еще и в том, что в окружении башни имеются холмы с захоронениями. Кто были умершие: воины или кочевники—вопрос? Но никаких доспехов или стрел здесь не обнаружено. А то, что захоронение мусульманское, не вызывает спора. Потом, надо учитывать, что в поисках клада внутри Башни и за ее пределами не раз вели раскопки «дикие» кладоискатели.» *(В. Артемьев. «Размышления о Башне Тамерлана» ,»Советское село», 2003 г.)*

Далада мондый мавзолей-төрбәләр еш очрый икән, һәм жирле халык аларны мәчет хәрәбәләре, дип атый. Ягъни, жирле халык аларны турыдан-туры мөселманлык билгесе итеп кабул итә. Бу хакта хәтта Мәскәү авторлары да искәртә:

«Тимур (Тамерлан) бывал в этих приуральских краях. Здесь произошла его знаменитая битва с Тохтамышом. В степях Приуралья часто всречаются курганы с кирпичной кладкой, оставшиеся с того времени. Местное население считает их остатками провалившихся мечетей. Но это остатки мавзолеев, построенных без фундамента из необоженного сырцового кирпича и поэтому быстро развалившихся.» *(Г.Н.Матюшин. Яшмовый пояс Урала.—Москва, 1977, стр.161-162.)* Бу китапта Тамерлан төрбәсенең иске рәсеме бирелгән һәм аның астына «Башня Тамерлана. XII-XV вв.» дип язылган. *(Шунда ук.)* Ягъни, бу төрбәгә кимендә мең ел булып чыга, ә ул һаман дала уртасында басып тора! Шулай булгач, авторның бу мавзолей-төрбәләр турында, «тиз жимереләләр», дип әйтүе дөреслеккә туры килми. Ә менә халык хак әйткән булырга тиеш—димәк, бирedә төрбәсе дә, мәчете дә, манарасы да булган!

Әйткәнемчә, Аксак Тимернең бирedә булу-булмавы да, бирedә аның кызының күмелү-күмелмәве дә галимнәр арасында бәхәс уята. Ә ни өчен бу төрбәне хатын-кыз белән бәйлиләр соң алайса? Эш шунда, бирedә 1889 елда Петербург университеты профессоры Э.Ю.Петри казу эшләре алып бара һәм хатын-кыз скелеты таба. Бу скелетның баш сөяге янында ике алтын алка һәм бармакларында фирүзә ташлы ике алтын балдак табыла. Баш сөяге монгол рәвешле була, ә мәет исә мөселманча күмелгән. Петри бу табылдыкларны Эрмитаж музеена тапшыра.

«Был обнаружен женский скелет длиной 2 аршина 6 вершков. Вокруг шеи скелета обмотана шелковая ткань, отдельные ее куски сохранились. У черепа—две золотые серьги с двумя жемчужинами и одним яхонтом на каждой. На пальцах два золотых перстня, гнезда которых украшены золотым арабеском и небольшими зеленовато-голубымими камнями, похожими на бирюзу—датировано XIV веком. Череп монгольского склада, не особенно типичный. Погребение произведено по древнему мусульманскому обряду, украшения и атрибутика соответствует Древнему Востоку»,—дип яза Петри үзенең хисабында. *(Отчет Императорской археологической комиссии за 1889 год. СПб, 1892, стр.55-57.)*

Менә шушы хатын-кыз скелетыннан чыгып, бәлки Аксак Тимер кызы турында риваять тугандыр. Әмма казахлар бирedә Кисәнә исемле казах кызы, башкортлар Мәдинә исемле башкорт кызы күмелгән, дип язалар. Бу тирәдән тагы берничә баш сөяге, каен казыклар һәм бүре суга торган кистән-чукмар да табыла. Шулардан чыгып, бу кешеләр һөҗүм вакытында үтерелгән, дигән нәтиҗәгә килергә дә мөмкин. Әлбәттә, мөселманнар мәетне өс киемнәре һәм бизәнү әйберләре белән күммиләр, әмма кеше сугыш вакытында шәһит китсә, ничек киенгән, шулай күмелә. Бу алка-йөзекләрне шулай гына аңлатырга була. Бу мавзолей тирәсендәге каберләрдә дүрт мең еллык сөякләр ятканын да онытмаска кирәк.

Әйе, бирedә ханнар да, хан кызлары да, патшалар да күмелгән булырга тиеш. Мин эзләгән Күчем хан һәм башка Себер ханнары да шушында күмелгән булырга мөмкин, чөнки башка жирдә аларның каберлекләре юк. Бирedә зур су юллары булмау да каршылык тудырмый, чөнки дала өчен бөтен жирдә—юл... Ул вакытта шактый мул сулы Тугызак елгасының—Уй елгасына, Уйның Тубылга коюын да онытмаска кирәк, ә анда—Себер ханнарының башкаласы. Бу хакта Чиләбедә яшәүче тарихчы, Тамерлан-Кисәнә төрбәсен махсус тикшерүче Сергей Боталов бик ачык итеп әйтә: «...Шибан-хан. Имя которое, безусловно связано с созданием

мавзолея. Можно смело предположить, что мемориал возведен в честь одного из семейных кланов могущественной династии Шибанидов.» *(Сергей Боталов. Номады.—Челябинск, 2000, стр.33-34.)*

Күчем хан Шәйбәниләр нәселеннән булган, димәк, Кисәнә төрбәсе тирәсендә аларның нәсел мазарлыклары булган булырга бик мөмкин. Галимнәр барысы да бер авыздан бу төрбәне Алтын Урда тарихи ядкаре дип билгелиләр, ә Себер ханлыгы Алтын Урданың варисы, дәвамчысы булган, димәк, татар ханнарын кайда һәм ничек күмү йоласын да ул гасырлар буе килгән традиция буенча башкарган. Шул ук Боталов бу турыда бик мәгънәле итеп болай ди: «На месте родовых зимовий в степи выросли города, а над могилами именитых золотоордынцев поднимались мавзолеи-кисене—«дома мертвых». *(Сергей Боталов. Күрсәтелгән хезмәт, 29 бит.)*

Бу тирәләрдән данлыклы Ефәк юлы үтүен дә искә төшерергә кирәк, димәк монда Кәрәван-Сарайлар да, мәчетләр дә, базарлар да булган, дигән сүз. Ә инде бу туфракта кемнәр ятканын хәзер бер Аллаһ кына белә. Шуна күрә бу урыннарга тиешле игътибар һәм анда ятучы әрвахларга дога кирәк. Жирле халыклар шулай эшли дә. Әмма Урал арьягын Рәсәй империясе басып алгач, милләтләргә генә түгел, аларның каберлекләренә дә көн калмаган. Урыслар бу курган-каберләрне актарып, алардан алтын-көмеш эзләгәннәр, бөтен Себер-Уралны сукыр тычкан кебек жырмачлап чыкканнар. Алар махсус төркемнәр оештырып, эшкә йөргән кебек курганнарны актарырга чыгып киткәннәр, бу кабер каракларын «бугорщики» дип йөрткәннәр. Бары тик Петр патшаның махсус фәрманы белән генә талауларны бераз чикли алганнар, әмма курган актарулар барыбер дәвам иткән. Бу хакта 1889 елда Варнада фәнни эзләнүләр алып барган профессор Э.Петри дә язып калдырган:

«Развалины Кисяня представляют собою четырехугольное с надломленным верхом здание, приблизительно в 8 саженей, с двенадцатигранной пирамидальной башней... По мере заселения края переселенцами кирпичи все более и более расхищаются. Киргизы, а равно как и казаки-татары, живущие в Варненской станице, не касались здания, частью из суеверия, частью в том убеждении, что здесь погребено тело магометанского святого.» *(Э.Ю.Петри. Күрсәтелгән хезмәт.)*

XIX-XX гасырларда да Тамерлан төрбәсен талаулар дәвам итә. Бу хакта 1868 елда Варнада булган этнограф Р.Г.Ипатьев та язып калдырган, төп зыянны казаклар(казачье поселение) салганлыгын әйткән. Әмма мөселман-татар казаклары бу вәхшилектә катнашмаган, киресенчә, төрбәне сакларга тырышкан, алар анда барып намазлар укыганнар. Бу хакта тарихчылар менә нәрсә яза: «Поэтому с момента заселения поселка казаки татары взяли мавзолей под свое особое покровительство, тщательно следили за его сохранностью и первое время изредка служили в нем намазы.» *(В.С.Кобзов. Уральская Варна.—Челябинск, 1992, стр.39.)* Бөек Ватан сугышы вакытында урыслар төрбә кирпечләреннән мунчалар салганнар, моржалар чыгарганнар, жирле халык, төрки-мөселманнар бу эшкә катнашмаган. Халык сөйләве буенча, соңыннан бу мунча-моржалар сәер тавыш чыгарып, «елап» утырганнар... Урыннарыннан кузгаткан өчен бәлки шулай рәнжегәннәрдер...

Әйткәнебезчә, кызганычка каршы Тамерлан төрбәсе бүген дә вәхшиләр тарафыннан жәберләнә. Анын эчендә бүгенге вандалларның борынгы диварларга тырнап язган сүзләре, мылтыктан атышкан ядрә эзләре саклана. Мона жирле тарихчылар да игътибар итә һәм борчылуларын белдерәләр:

«Мавзолей и некрополь захоронения вокруг него—это историческая ценность. Этот памятник заслуживает большого внимания и бережного отношения. После реставрационных работ, на которые было потрачено немало сил и средств, на памятнике вновь появились следы вандализма. Кирпичи снова стали царапать, оставляя на них свои инициалы, имена. Совершенно ни к чему привязывать на металлическую ограду ленточки. Что это? Откуда взялась эта традиция? Мне пришлось посетить в Средней Азии много памятников старины, мавзолеев, и никто и никогда не занимался этой дикостью.» *(Галина Золотарева. «Сохранить для потомков.» , «Советское село», 2009, сентябрь.)*

Без дә автор белән тулысынча килешәбез, бу тарихи урыннарда чүпрәк бәйләү кебек кыргый күренешләргә чик куярга вакыт. Бу—мәжүсиләрдән кергән гадәт һәм




*Татар генералы Шәйхелислам Кочуров һәм мөселман-татар казаклары Кочуровлар нәселе.*

аңа безнең милләттә урын булмаска тиеш. Югыйсә, Биләрне чүпрәк басты, Аркаимда шушы хәл, инде Тамерлан төрбәсен чүпрәккә төргәннәр. Зыялылар, дин әһелләре һәм җирле түрәләр моңа каршы төшәргә һәм туктатырга тиешләр.

Тамерлан төрбәсен һәм ул тирәдәге борынгы курганнарны, шәһәрлекләрне җентекләп өйрәнгәннән соң, күңелдә барыбер берничә сорау калырга мөмкин. Биредә кемнәр яшәгән һәм алар кая киткән? Минем үзем өчен бу сорауларга җавап ачык—биредә төрки халыклар яшәгән һәм алар беркая да китмәгән, шушында яшәүләрен дәвам итәләр. Әмма фән дөньясы мәсьәләгә болай карамый, бу зур тарих төркиләргә бирелми, бүгенге төрки халыклар бу тарихның дәвамчылары итеп каралмый. Югыйсә, шушындый ук мавзолей-төрбәләрне бүген Казахстанда, Үзбәкстанда, башка Урта Азия республикаларында, Кавказда, Идел-Уралда да очратырга мөмкин бит!

Икенче төрлерәк фикер дә бар. Тамерлан-Кисәнә төрбәсен беренче булып тикшергән һәм 1762 елда аңа фәнни бәясен биргән тарихчы П.И.Рычков Көньяк Уралда моңа кадәр фәнгә билгесез цивилизация булганлыгын яза, аның фикеренчә, Кисәнә төрбәсе дә шул халыкның изге патшасына куелган булырга тиеш. *(Рычков П.И. Топография Оренбургской губернии.—Оренбург, 1889, стр.242.)* Рычков фикеренчә, бу халык соныннан Кытайга күчеп киткән булырга тиеш. Йөз елдан соң этнограф Р.Игнатьев та, җирле халыктан җыелган материалларга таянып, Тамерлан-Кисәнә төрбәсе турында «...мавзолей построен над прахом святого царя неизвестного народа», дип яза. *(«Оренбургские ведомости», 1868, № 20.)* Ул бу билгесез халыкның утрак тормыш белән яшәвен, соныннан нindидер сәбәпләр аркасында Кытайга качарга мәҗбүр булуын яза. Игнатьев Тамерлан-Кисәнә төрбәсенең саклар тарафыннан салынуын хәбәр итә.

Бу фикерләрнең барысын бергә җыйсак та, барыбер төрки тамырларга килеп чыгабыз. Тарихтан билгеле булганча, бу далаларда яшәгән скиф-сак-сармат халыклары—алар борынгы төркиләрнең бабалары. Ә инде нindидер бер төркем Кытайга китеп барган дип карыйбыз икән, без шул ук төрки уйгырларга килеп чыгабыз, Тибет халкының да бер өлеше төрки тывалылар булуын онытмаска кирәк. Ә урыслар басып алганчы бу далалар нугай татарларының ил-җир биләмәләре була, алар соныннан Төньяк Кавказга күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Ягъни, кайсы гына яктан килеп карасак та, даладагы бу курган-пирамидалар—төрки цивилизация билгесе, безнең байлык, биредә дистәләгән бәйсез дәүләтләр тоткан татар халкының да рухи мирасы. Бүген аны безгә бирергә теләмәсәләр дә, моның шулай икәнлеген үзебез белеп торыйк. Хәер, моны урыс тарихчылары үзләре дә сизенәләр, әмма исемебезне әйтмиләр:

«Кесене» является архитектурным памятником талантливого народа, народа трудолюбивого с высоким моральным и духовным складом, который с большим искусством в те далекие времена смог создать выдающийся памятник народного зодчества из простого кирпича, по который живет вот уже не одно столетие...»,—дип

яза алар. *(«Кесене». «Технорабочийпроект»—Челябинск, 1972, стр. 7. Музей с. Варны.)*

Әйе, бу—безнен турыда, югары әхлаклы, гаять тырыш, мәгърифәтле, гүзәл мәдәнияткә ия булган татар халкына биргән бәя. Вакыт һәм тарих тарафыннан...

...Тамерлан төрбәсеннән ерак түгел, дала уртасындагы ярым кипкән Кәсәнә күлендә ялгыз аккош йөзеп йөри иде...

Әйтерсең лә «Идегәй» дастанында Ку күлендә йөзеп йөргән аккош!

Әйтерсең лә ул безгә Туктамыш, Шаһ Тимер, Идегәйләр чорыннан канат очларында хәбәр алып килгән...

*Били белсәң, ханиям,*
*Икселмәс дәүләт бу иде.*
*Алтын Урда, Ак Урда*
*Алтмыш йортка юл иде.*

*Әй ханиям, ханиям!*
*Җир китәрдә ни калыр?*
*Җиреннән тайган ил калыр;*
*Ил китәрдә ни калыр?*
*Ил киткәндә йорт калыр,*
*Йорт киткәндә сөт калыр,*
*Ак күкрәктән сөт имгән*
*Сүзе татлы тел калыр.*
*Тел китәрдә ни калыр?*
*Язганнан язган хат калыр;*
*Баш китәрдә ни калыр?*
*Буында типкән кан калыр...*

## Татар Варнасы

Тамерлан төрбәсеннән ерак түгел, Түбән Тугызак елгасы буенда, зур гына бер авыл бар. Аны урыслар—Варна дип, татарлар Мача дип атап йөртә. Анық тарихы әллә ни зур түгел—170 еллар тирәсе генә, әмма аңа мөселман-татар казаклары нигез салуы бәхәссез факт. Ни өчен Варна, ни өчен Мача һәм ни өчен татар казаклары—хәзер шуларга тукталып үтик.

XIX гасыр урталары—чукынмаган татарларның җирсез, мал-мөлкәтсез тилмергән вакытлары. Россия империясе татар илен басып алганнан бирле, бары тик чукынган татарларга карата гына мәрхәмәтле булган, аларга җир биргән, дәүләт эшләренә якын җибәргән, мал-мөлкәтле иткән. Ә динен сатмаган татарлар бары тик авыр эшләрдә, җай чыкса—сәүдәдә һәм ялланган хәрби хезмәттә генә азмы-күпме үзләрен күрсәтә алганнар. Империянең көньяк чикләрен, бигрәк тә иксез-чиксез далаларны күчмәннәрнең һөҗүменнән сакларга кирәк булгач, чукынмаган татарлар да эшкә ярап куя—аларны хәзерге Чиләбе һәм Ырынбур өлкәләренә күчереп утырта башлыйлар. Әлбәттә, бу дәүләт сәясәте була, төрки кыргыз-кайсакларга төрки-мөселман татар казакларын каршы куялар, әмма татарлар шулай итеп диннәрен һәм үзләрен өлешчә булса да саклап калалар.

Татарларны бергә 1843 елны, Ырынбур казак гаскәрләре (казачье войска) составында, Самара тирәсеннән күчерәләр, шулай ук алар арасында бүгенге Татарстанның Шөгер, Нурлат якларыннан да милләттәшләребез булган. Татарларны башта Тугызак елгасыннан түбәндәрәк, урыслар белән бергә урнаштыралар, әмма бу ике милләт тыныша алмагач, мөселман-татарларны хәзерге Варна урынына күчерәләр. Шунысын да әйтергә кирәк, ул вакытта ук инде биредә бай татар казакларының—Кочуровларның һәм Усмановларның өч биләмә-хуторлары була. Тарихчылар язуынча, бу станица башта 30нчы номер белән йөртелә, аннан аңа Варна исеме бирелә, 1828-1829 елларда Болгариядә төрекләрне җиңү хөрмәтенә

шундагы крепостьның исеме кушыла. Имеш, бу сугышта Ырынбур казаклары да, шул исәптән, татар казаклары да катнашкан була, татарлар, үз диндәшләре төрекләрне җинеп, Рәсәй империясенә дан китерәләр...

Әмма татарлар бу авылны беркайчан да Варна дип атамыйлар, аңа Мача дигән исем бирәләр, чөнки алар Самара якларыннан шул исемдәге станицадан күчерелгән булалар. Шунысын да әйтергә кирәк, Самара өлкәсендә хәзер дә Мәчәли дип йөртелгән зур татар авылы бар, мондый татар авылларының Түбән Новгород өлкәсендә, шулай ук Татарстанда булуын да әйтеп үтәргә кирәк.

Бөтен тарихи хезмәтләрдә,мөселман-татар казаклары бирегә күчкәндә, буш дала иде, дип язалар, мин үзем моңа бераз шик белән карыйм. Елгасы, күлләре, аз булса да урманы, мал тоту өчен иксез-чиксез далалары булган мондый унайлы җирләр ни өчен кешесез булырга тиеш ди? Без инде Варна янындагы Тамерлан төрбәсе тирәсендә дүрт мең ел буе кешеләр яшәгәнен алдагы бүлектә язып үткән идек. Мина калса, бу тирәләрдә соңгы гасырларда да кешеләр яшәүдән туктамаган, һәм бирегә татар-урыс казаклары күчеп килгәндә дә дала буш булмаган. Татарларның кеше яшәгән җиргә, үз милләттәшләре янына күчә торган гадәтләре бар, аларның урыс казакларыннан аерылып, бирегә күчүләренең сәбәбе шул булмадымы икән, дип уйлыйм. Матбугатта минем фикеремә туры килгән язмалар да күренгәли, кайбер галимнәр бирема урыс-татар казаклары килгәнче дә кешеләр яшәгәнлеген ачыктан-ачык әйтәләр.

«Очевидно и то, что Башня служила каким-то маяком для людей, кочевавших в этих краях, пристанищем в непогоду и местом для отдыха,—дип яза инде безгә таныш булган автор В.Артемьев.—И что, возможно, уже в те века они закладывали поселение, которое ныне именуется Варной и впервые упоминается в циркулярах губернатора Оренбургской губернии в 1843 году как казачье сторожевое поселение.» *(В.Артемьев. Күрсәтелгән хезмәт.)*

Җирле тарихчының бик кызыклы аңлатмасы бу! Димәк, мөселман-татар казаклары килгәнче үк Варнада кешеләр яшәгән, алар күчмән халыклар, ягъни, төркиләр булган дигән сүз. Әмма бу хакта хәзер беркем язмый. Шулай ук Варнага бары тик татар казакларының гына күчеп утыруы да бик буталчык рәвештә, аңлашылмаслык итеп бирелә. Урыс тарихчылары бирегә урыс, татар, калмык казаклары бергә күчкән, дип язсалар, татарлар исә Варнага бары тик татар казаклары гына күчеп утырган, дип баралар. Әйтик, тарихчы В.С.Кобзов Варна тарихына багышлап махсус китап яза һәм анда бу бистәне башлангычыннан ук катнаш торак урыны итеп күрсәтә:

«С самого начало население поселка было интернациональным по своему составу. В это время в Варне проживало около 40% татар, ранее служивших в полках регулярной армии, 39% русских, 11% калмыков, 2% украинцев (малороссов), а также белорусы и несколько казахских семей, не входивших в войсковое сословие.» *(В.С.Кобзов. Уральская Варна.—Челябинск, 1992, стр.13.)*

Татарлар Кобзовның бу сүзләрен ялган дип баралар, аларның әйтүенчә, Варнага нигез салганда монда урыс казаклары да, башкалар да булмаган, ә бары тик мөселман татар казаклары гына күчеп утырган. Билгеле булганча, Кобзов бу китабын Ырынбур архивларында утырып язса да, безгә калса, ул бирема әллә белеп, әллә белмичә ике бистәне бутаган. Хәзер Алексеевски дип аталган бистәгә, чыннан да, татар, урыс, калмык һәм башка милләт казаклары бергә урнашалар, әмма урыслар белән тыныша алмыйча, татарлар алардан аерылып чыга һәм хәзерге Варна урынына килеп тупланә. Архив документларында бу тирәдәге казак станицаларын барысын бер исем астында туплап биргән булырга да мөмкиннәр, әмма бу Варнада урыслар яшәгән дигәнне аңлатмый. Октябрь революциясенә кадәр Варна тоташы белән татар авылы булган, анда нибары ике урыс яшәгән, моны олы кешеләрнең истәлек-хатирәләре дә, архив материаллары да раслый.

1913 елда Варнада туган, 2003 елда 90 яшьлек юбилеен уздырган Өммегөлсем Рәхмиева авыл тарихын бик яхшы белгән. Аның әйтүе буенча, революциягә хәтле Варнада бары тик татарлар гына яшәгән, нибары ике урыс булган, алары да татарча яхшы белгән. Бу хакта җирле газета менә ничек яза: «Она говорит, что Варну до революции населяли одни татары, которые прибыли сюда откуда-то из Оренбурга и

Татарии. Русские селились в соседних селах: Катенино, Бородиновка, Николаевка, Толстых и др. В Варне до 1917 года была всего двое русских. Это русский купец Иван Асоргин, он прекрасно знал татарский язык и общался со всеми жителями на их родном языке. Другой русский был дед Филипп, он тоже знал татарский язык.» («Наше прошлое глазами долгожителя.» Со слов дочери М.Рекуновой, »Советское село», 2003, 22 июля.)

Шушы ук газетаның 2003 елгы 26 июль санында районның мактаулы гражданы, озак еллар буе житәкче урыннарда эшләгән Миннеәхәд Ракаев белән әңгәмә урнаштырылган (аны биредә нигәдер «Михаил» дип атаганнар). Газета хәбәрчесе аннан: «Михаил Шарафович, судя по Вашему упоминанию о трех мечетях, с самого начало Варну населяли татары?» дип сорый. 70 яшьлек Миннеәхәд Ракаев болай дип җавап бирә: «Да, это так. Варну строили татары. Изначально было три семьи русских. Это семья Нечаевых, они были кожевниками. Купцы Осоргины... Еще одним русским был кузнец Кузнецов... Жил еще железнодорожный смотритель Щукин, зять Кочуровых.»

XIX гасыр урталарында Варнада, нигездә, татарлар гына яшәве турында матбугатта язмалар күренгәләп тора. Әйтик, Варна районының 85 еллыгына багышланган мәкаләдә болай диелә: «С 9 сентября 1897 года Варна входила в состав Великопетровского станичного юрта, была населена преимущественна казаками-татарми, в быту именовавшими ее Моча (производное от «Мочинская»). В 1900 году в поселке насчитывалось 290 дворов, имелись 3 деревенских мечети, школа, 3 водяных и 5 ветряных мельниц.» *(«Советское село», 2009, 1 августа.)*

Бу рәсми мәгълүмат. Игътибар итегез—авылда 3 мәчет булган, әмма бер генә чиркәү дә булмаган, чөнки урыслар булмаган! Варнаның башта ук татар бистәсе булганлыгын тагы бер урыс тарихчысы менә болай тасвирлый:

«Объяснит знаток местной истории и почему в Варне так много татар. В районе их около двух тысяч, и большинство проживает в райцентре, где они тоже приметны. Дело в том, что первопоселенцами Варны были татары-казаки, которых немало было в Оренбургском казачьем войске. Входит селение в мемориал славы российского оружия и именовано в честь победы российского флота над турецким при порту Варна. В прошлом татарский облик селения был особенно приметен. Посудите сами: в 1928 году среди 2400 варненцев было около двух тысяч татар.» *(Александр Моисеев. Күрсәтелгән хезмәт.)*

Автор, нигездә, дөрес яза, әмма ул елларда татарлар Варнада ике меңнән дә күп була. Менә минем кулымда тагы бер рус тарихчысының кульязмасы, ул аны 1927-1928 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләренә таянып язган:

«Итак, 1927 год. В с. Варна проживает 2394 человека, в 498 дворах. Все переписываемые именуются едоками. Татар проживает 2312 человек, русских—82 человека.» *(В.Б.Овсянников. «Все остается людям.» Кульязма материал.)*

Бу халык саны алу нәтиҗәләрен Варнада мин күрдем, аны татарлар бик авырлык белән, атналар буе дәфтәргә кулдан күчереп, архивтан алып чыга алганнар. Әлбәттә, бу исемлек төгәл түгел, халык санын исәпкә алганда, нигездә ир-атлар гына хисапланган, хатын-кызлар берничә генә, ә балалар исә, гомумән, йә язылган, йә юк. Әле шулай әштәр-өштәр алынган исәп буенча да татарлар саны ике меңнән артык. Монда иң карт кеше—1815 елда туган Мутаев Кадир бабай икәнлеге күренә, аңа 1927 елда 112 яшь була. Аннан кала да Варнада йөзьяшәр татарлар шактый була. Исемлектә өч мулла—Сабагетдинов Гарифулла, Кинҗәбулатов Мөхәммәт, Усманов Әгъзәм теркәлгән. Ул вакытта әле аларны сөргенгә сөреп өлгермәгән булалар. Шулай ук бу исемлектә ике укытучы—Исаев Рәкыйп һәм Фәткуллин Закирны күрергә була, моннан тыш тимерчеләр, итек тегүчеләр, итек басучылар да теркәлгән, аклар белән качып өлгермәгән кайбер казакларны да язып куйганнар. Шул ук вакытта эре җир биләүчеләр дә аерым хисапка алынган, бу репрессияләр алдыннан бер разведка булмадымы икән, дигән фикер кала.

Мин, филолог-тарихчы буларак, ул вакытта Варнада яшәгән татарларның исем-фамилияләренә дә игътибар иттем. Иң күп таралган фамилияләр—Адамовлар, Әюповлар, Исаевлар, Ишкаевлар, Кочуровлар, Емангуловлар, Мәхмүтовлар,

Рәхмеевлар, Йосыповлар булып чыкты. Шулай ук Абдулловлар, Надрюковлар, Өметбаевлар, Ракаевлар, Шәфиевлар, Таһировлар да шактый иде. Мин биредә шулай ук сирәк очрый торган фамилияләргә дә игътибар иттем—Акировлар, Дамендаровлар, Игметовлар, Макашевлар, Романовлар, Сарантаевлар, Сементеевлар, Субеевлар, Сазанбаевлар, Самурхановлар, Сатаевлар, Саудирәковлар, Текановлар, Күкләшевлар, Сабагетдиновлар... Бу аларның чыккан төбәкләрен, кайсы кавем һәм диннәр белән катнашуларын да күрсәтә ахры.

Варнага нигез салыну белән, аның житәкче-атаманнары да татарлар булган. Дөрес, монда, имеш, 1843 елда башлык булып Бөгелмә ягы кешесе Иван Федоров эшләгән, дип язалар, әмма тагы урыс казакларының мөселман казаклар белән бергә яшәгән вакытларын бутыйлар ахрысы. Безнең фикеребезчә, йә Иван Федоров керәшен татары булган, йә мөселман казаклары өстеннән хорунжий булып Варнага күчкәнче житәкчелек иткән. Соңыннан исә бөтен житәкчеләр дә татарлар, бу факт үзе үк Варнаның саф мөселман-татар авылы булганлыгын күрсәтә, чөнки христиан-урыслар өстеннән атаманлык итәргә татарларны куймаслар иде.

«Поселковыми начальниками и атаманами в 1843-1919 гг. являлись: Зауряд-хорунжий И.Федоров, сотник А.Кочуров, сотник Ш.Кочуров, казак Г.Юсупов, урядник Ш.Надрюков, приказные Адамов и Ш.Гильманов», дип яза бу хакта «Варна. 1843-2003» дип аталган брошюра. *(Күрсәтелгән хезмәт. Еманжиленск, стр.3.)*

Инде тагы урыс мәсьәләсенә килик. Революциягә хәтле Варнада 2 урыс булган, дидек, ә инде 1927-1928 елларда аларның саны—82, бала-чагалары белән, әлбәттә. Сорау туа—Варнада урыслар ни сәбәпле арта башлаган соң? Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, 1924-1926 елларда Варнада район оештырыла, район үзәгенә эшкә читтән урыс житәкчеләре һәм белгечләре китерелә. Икенчедән, бу елларда инде репрессиянең беренче дулкыннары башланган була һәм Варнага да төрле милләт вәкилләрен сөргенгә сөрәләр, алга таба бу процесс тагы да көчәя. Бу хакта жирле газеталар менә нәрсә яза:


«Заселение Варны русскими началось в 1928 году спецпереселенцами. С Украины приехали Березаны, Барбулы, Биденковы, Шпак, Свиридовы, Олейниковы. В 1936 году—Рудницкие, Сарыкины, Вечер, Варивода, Стецко, Усенко. Остальные попали в Варну в период коллективизации из близлежащих сел. Теперь Варна—дружное многонациональное село.» *(«Советское село», 2003, 26 июля.)*

Әйе, хәзер Варна урыс авылы инде, анда яшәүче ун мең кешенең өчтән бере генә татарлар... Ягъни, моннан йөз ел элек тә 2-3 мең татар булган, хәзер дә шулай. Татарлар ни сәбәпле артмый соң, ә киресенчә кимүгә таба гына бара? Моның да үз сәбәпләре бар. 1900 елда Варнада 2785 татар яшәгән, шуның 1396сы хәрби хезмәттәге казак булган. Бу татар казаклары 1904-1905 елгы урыс-япон сугышында да, 1914 елгы Беренче бөтендөнья сугышында да бик актив катнашалар һәм империя өчен корбан булалар. 1917 елгы революция, гражданнар сугышы татар казакларын да икегә бүлә, кемдер совет властен яклап чыга, кемдер империягә биргән антына тугрылыклы булып, аклар ягында сугыша, нәтижәдә, ике яктан да тагы татар кырыла. 1921 елгы ачлыктан һәм тифтән дә авылда күп кеше үлә. Репрессияләр чоры башлангач, Варнаның хәлле татарларын, муллаларын, укытучыларын, элек хәрби хезмәттә булган казакларны сөргенгә сөрәләр, аталар, юк итәләр, гаиләләрен жир куышларына куып чыгаралар, аларның өйләрен көчеп килгән урысларга бирәләр. Варна татарлары тарих тегермәненә салып тартыла, жисми һәм рухи яктан күп жәбер-югалтулар кичерә, әмма имгәнеп булса да, милләт буларак барыбер сакланып кала. Ул хакта алдагы бүлекләрдә язарбыз, иншаллаһ!

Ә хәзер тагы XIX гасыр урталарына, татарларның Варнада милләт булып, мәчет-мәдрәсәләр тотып яшәгән вакытларына кайтыйк әле. Варна (татарча—Мача) башта ук махсус план-проект белән салына, моның өчен хәтта Ырынбурдан жир инспекторын китертәләр, авыл архитектор Мортазин сызымы буенча төзелә. Авылда гаять киң һәм туп-туры өч урам була, алар Тугызак елгасы буйлап, ана параллель рәвештә салыналар. Үзәктәге төп урам Түрә урамы дип атала һәм анда хәлле кешеләр, нәселләре белән Кочуровлар яши. (Кочуровлар нәселенә без әле аерым тукталырбыз, иншаллаһ!) Хәзер бу урам Совет исемен йөртә, анда район

үзәге хакимияте урнашкан. Икенче урам—Урта урам, элек монда базар булган, дөяләр белән кәрәваннар килеп туктаган. Варна-Мачаның өч мәчете дә шушы урамда булган. Хәзер ул урам Октябрски дип атала. Өченче урам—Түбән урам, ул хәзер Магнитка, дип атала.

Хәзер Варнада иллегә якын урам бар, әмма үзәктә иске Мача авылы урамнары калган. Биредә хәзер дә йөз еллык йортлар саклана. Авыл халкы йортларны Карагай урманыннан бүлеп биргән нараттан салган, ә коймалар һәм амбарлар таштан, ак ташны Тугызак ярыннан алганнар. Йортлар бик нык, биек, аларда тирән базлар, идән аслары, ярымподвал бисалары булган. Һәр йортның диярлек ишегалдында кое булган, Тугызак елгасына якын яшәүчеләр суны аннан да алган. 1873 елда Варнада көчле янгын чыга, авылның көньяк өлеше янып диярлек бетә. Шул хәлдән соң ярлы халык жир куышларына күчәргә мәжбүр була, чөнки ул вакытта инде урман кисәргә рөхсәт бирмиләр, сонрак исә саманнан һәм камыштан йортлар сала башлыйлар. Бу йортлар жәен—салкын, кышын жылы булулары белән аерылып торалар икән. 1892 елда Варнаның инде төньяк очы яна, 100 хужалыкка зыян килә, нәтижәдә, халыкның бер өлеше моннан күчеп китәргә мәжбүр була.


*Варна авылы мәчете.*

Әйткәнебезчә, Варнада ир-атларның күпчелеге хәрби хезмәттә булса да, һәр гаиләнең диярлек жир биләмәләре булган, алар иген иккәннәр, мал-туар асраган, һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр, кайберәүләре базарда сату иткән. Авыл халкы үзенә кирәк нәрсәләрнең күпчелеген үзендә житештергән, азык-төлектән тыш, өс-башны да үзенә үзе әзерләгән. Биредә тун тегүчеләр, итек басучылар, итек тегүчеләр яшәгән, хатын-кызлар исә житеннән тукыма тукып, өс-баш текәннәр, шәл бәйләгәннәр, дала жиләкләреннән как койганнар... Дала кин, мал-туар күп булган, көтү-көтү сарык тотканнар, сыер малы да һәр йорта берничә баш булган, ә атлар исә татар казакларының горурлыгы да, таянычы да, ярдәмчесе дә булган. Алар эш атларын—аерым, чабыш атларын—аерым, хәрби атларны аерым тотканнар. Варнадагы һөнәрчелек турында жирле газета менә ничек яза:

«Варна была поселком ремесленников. Плотники, строители домов—Акировы, кузнецы-ковальщики коней—братья Кучербаевы. Кузнецы—Адамовы, Исаевы, Макашевы. Столяры—Аюповы, бондарщики и колесники—Мазеевы, Нигъматуллины, Аюповы. Сапожники-портные—Такановы и Якуповы, шорники—Такановы, сапожники—Бикбаторовы. Они свою продукцию продавали на ярмарках или обменивали на другую продукцию.» *(«Советское село», 2003, 26 июля.)*

Варна татарларында мал-туар да күп булган, бала-чага да ишле булган, һәр йортта 7-8 бала үскән, картлар йөз яшькә житкән. Мона чиста дала һавасы да, яхшы һәм дөрес туклану да ярдәм иткән. Татар казаклары нигездә ат ите ашаганнар, ул хәзер дә шулай. Сөт ризыкларына да зур урын бирелгән. Тиз бозыла торган бу ризыкларны эссе дала жәйләрендә ничек саклаганнар соң? Татарлар монда да жаен тапкан—алар ит-сөт ризыкларын саклау өчен кар базлары-нәүрәбләр ясаганнар һәм тәрәзәсез таш амбарлар төзегәннәр, аларны яз көне елга бозы белән дыңгычлап тутырганнар һәм өстен салам белән каплаганнар. Жәйләрен ризык шунда сакланган, кышларын зур-зур чоланнар азык-төлек белән тулган.

Һәр елны ноябрь башында Варнада көзге ярминкәләр уздырганнар, ул ун көн буе дәвам иткән. Биредә авыл халкы үзе житештергән азык-төлекне, кием-

салымны, йорт җиһазлары саткан, ярминкәгә тирә-күршедәге Троицки, Кустанай, Орски кебек шәһәрләрдән дә сәүдәгәрләр килә торган булган. Бу ярминкәләрдә бер рәттә бодай, арпа, солы, тары, он сатылса, янәшәдә йон-мамык әйберләре, тире һәм тиредән теккән әйберләр торган. Икенче рәтне исә тулысынча ит сатучылар биләгән, итне түшкәсе белән дә, кисәкләргә бүлеп тә сатканнар, бигрәк тә ат ите бик үтемле булган. Биредә шулай ук тал чыбыгыннан үреп ясалган йорт җиһазлары, савыт-саба, агачтан ясалган әйберләр дә алырга мөмкин булган, хатын-кызлар исә мамык шәлләр сатып рәхәтләнгәннәр.

Эшләп ашаган халык күңелле итеп ял да итә белгән. Авылда дини бәйрәмнәр—Ураза гаете, Корбан гаете, Мәүлет бәйрәме зурлап уздырылган. Моннан тыш милли бәйрәмнәр дә читтә калмаган, язгы чәчүләрдән соң уздырылган Сабантуй аеруча үзенчәлекле булган. Мин бу хакта Мәдинә апа Рекунованың истәлекләренә таянып язам, аңа исә 90 яшьлек әнисе Өммегөлсем әби сөйләгән. Кичен чәчү бетәсен белдереп, атка атланган балалар иртән авылга кайтып сөенче алалар. Хатын-кызлар шундук эшкә керешә—алар мунча ягалар, өйдә булган бөтен чиләк-савытны сулар белән тутырып куялар. Ирләр атлы-арбаларга төялеп, кичен авылга кайтып кергәндә, аларны бөтен халык су сибеп каршы ала. Бигрәк тә бала-чагалар тырыша, алар көлә-көлә, такмаклый-такмаклый әтиләрен, абыйларын су белән коендыралар. Суны атларга да, ир-атларга да сибәләр, быел иген мул булсын, яңгырлар явып торсын, дип теләк телиләр. Чыланмаган бер генә кеше дә калмый, әмма моннан барысы да канәгать кала. Кичен исә мунча керәләр, бәйрәмгә әзерләнәләр. Ә иртән—Сабантуй! Далада атлар чаптырып, мәйданда бил алышып, канат тартып, колгага менеп, чүлмәк ватып, катыктан акча эзләп, аулакта кызлар күзләп, татар казаклары бәйрәм итә! Яшьләр җырлый-бии, күңел ача, ә кичләрен исә татарлар бер-берләренә кунакка йөрешәләр... Ырынбур, Самара, Шөгер якларыннан алып килгән матур гадәтләрен, милли бәйрәмнәрен алар монда да дәвам итә. (Ни кызганыч, хәзер Варнада Сабантуйлар уздырылмый икән.)

Инде Варна-Мачадагы мәчетләр турында да бераз мәгълүмат биреп үтик. Беренче мәчет—Җәмигъ мәчет 1870 елда салына, икенчесе—көньяк очтагы мәчет 1873тә, авылның төньяк өлешендәге мәчет—1880 елда салына. Ырынбурдагы документларга таянып, шулай сөйлиләр һәм язалар. Әмма минем күңелемдә бер сорау туды—ничек инде шундый зур, дини авыл 30-40 ел буе мәчетсез торды икән? Мөгаен, авылда мәчет иртәрәк тә булгандыр, әмма теркәлмичә эшләгән булырга мөмкин. Шуңа күрә без хәзергә шушы өч мәчет турында гына сүз алып барырга мәҗбүрбез. Югарыда телгә алган Миннеәхмәт Ракаев үзенең район газетасына биргән әңгәмәсендә Варна мәчетләре турында да сөйли:

«В южной мечети вел службу Усманов Акзам мулла, в центральной мечети—Хасанов Мухамеджан (его зять Юсупов Нури—профессор-востоковед). Преподаватели медресе—Фаткуллин Хальфа, Исаев Ракип. В советское время они преподавали в татарской школе, первым директором которой стал погибший на войне Рахмеев Салих. В северной мечети вел службу род Юсуповых, а последним муллой был Гатаулла.» *(«Советское село», 2003, 26 июля.)*

Ә менә Мәдинә ханым Рекунова үзенең Варна турындагы кульязмасында мәчетләр турында бераз башкачарак мәгълүмат бирә. Ул беренче Җәмигъ мәчетне 1860 елда ачылган дип яза, ә авылның төньяк очындагы мәчет 1870 елда ачылган булырга тиеш. «Первым хазратом мечетей в Варне был Гариф Ягудин,—дип яза ул.—Он женился на Надрюковой Аскаб, которая прожила 105 лет. У них было 6 детей, и своих сыновей он ставил имамами в мечетях.» *(М.Х.Рекунова. «Живительные корни народа.» Кульязма, 23 бит.)* Мәдинә ханымның язуы буенча, икенче мәчеттә имам булып Йосыпов Гатаулла һәм аның улы Хәмзә торган, Усманов Әгъзәм дә имамлык иткән.

Мәдинә ханымның әйткәннәрен Чиләбе тарихчысы В.Кобзов та өлешчә раслый:

«По ведомости о населении Оренбургского казачьего войска за 1862 год, в Варненском поселке уже числилось 1340 человек, в том числе 699 женщин. К этому времени в поселке были возведены одна соборная и одна пятивременная

мечеть, службу в которых вели 2 имама и 2 азанчи. Приход состоял из 613 человек, проживавших в поселках 5-го , 6-го и 7-го полковых округов. Помимо татар, к приходу соборной мечети были причислены башкиры, мещеряки и казахи из близлежащей округи.» *(В.С.Кобзов. Күрсәтелгән хезмәт, 14 бит.)*

Язмадан күренгәнчә, Варнада инде 1862 елда ике мәчет булган икән, димәк, алар иртәрәк салынган булганнар. Ягъни, татар казаклары бергә күчеп утыру белән мәчет салган булырга мөмкиннәр, чөнки мөселман кешесенең тормышын шуннан башка күз алдына китереп булмый. Гает намазлары Җәмигъ мәчеттә укылган, ә көн дә биш вакыт намаз уку өчен кечерәк мәчетләр салынган. Шунысын да әйтергә кирәк, бу мәчетләр каршында мәктәп-мәдрәсәләр дә эшләп килгән, кыз балаларны исә абыстайлар өйдә укыткан.

Бу мәчетләрнең алга таба язмышлары фаҗигале тәмамланган, 1933 елда аларның эшчәнлекләренә мәҗбүри рәвештә чик куелган. Җәмигъ мәчетнең манарасын төшереп, башта клуб ясыйлар, аннан китапханә итәләр. Картларның сөйләве буенча, манараны төшергәндә халык бик елый, кайберәүләр кайгыдан үлә. Манараны төшергән кешеләргә кызыл бантиклар бирәләр, әмма алар да тиз арада үлеп бетә. Көньяк мәчеттә 1938 елдан татар мәктәбе эшли, аннан анда клуб ясыйлар, ә 1949 елда бу мәчетне үгезләр белән тарттырып җимергәннәр, аның бүрәнәләреннән мәктәп салалар. Бу хакта Мәдинә апаның истәлекләрендә менә ничек язылган:

«В 1949 году разобрали южную мечеть. Из ее бревен построили начальную школу рядом с Варненской средней школой по ул. Говорухина, 106. «Бревна возили на волах, книги религиозные сжигали. Мы подбирали некоторые книги и тайком уносили домой» вспоминает моя тетя Минниахметова Минникамал, 1907 г.р.» *(М.Х.Рекунова. Күрсәтелгән хезмәт, 24 бит.)*

Мәчетләр белән бергә мәдрәсә дә юк ителә, бинасына яшәргә урысларны кертәләр, имамнар йортында да алар яши...

1920 елда Варнада татар башлангыч мәктәбе ачалар, аның директоры итеп Уфа мәдрәсәсен тәмамлаган Исаев Рәкыйпне билгелиләр. Әмма бу директор 1938 елга хәтле генә эшли, аннан репрессия корбаны була. Шул ук елны башлангыч татар мәктәбен җидееллык итеп үзгәртәләр, анда 83 бала җыела, мәктәп көньяк мәчет бинасында эшли башлый. Мәктәп яна бинага күчкәч, әйткәнебезчә, башта мәчеттә клуб була, аннан аны җимереп үк ташлыйлар. Ә җидееллык татар мәктәбе 1956 елга хәтле эшли, шул елны исә аны сигезеллык урыс мәктәбенә әйләндерәләр. Шулай итеп, совет чорында Варнада ислам диненә һәм татар мәгарифенә нокта куела, мәктәп һәм мәчетләр ябыла.

Хәзер Варнада һәм казаклар арасында бик билгеле булган нәсел—Кочуровлар (Качуровлар дип тә языла) турында да бераз мәгълүмат биреп үтим. Бу нәсел тарихында милләтнең зурлыгы да, фаҗигасе да чагыла. Нәсел башында торган Абдулваһһаб Кочуров 1845 елдан Варна авылының башлыгы да, мөселман-татар казакларының житәкчесе дә була. Бу нәселнең Тугызак елгасы буенда йөзәр кеше яшәгән ике хуторы һәм кодалары Усмановларның тагы йөздән артык кеше яшәгән бер хуторы булганлыгы билгеле. Аларның тирә-юньдә йөзләгән дисәтин җирләре, болыннары, мал көтүлекләре, елга-сулары, тегермәннәре була.

Әмма Абдулваһһаб Кочуровның иң зур байлыгы—аның биш улы була: Шәйхелислам, Мәрдән (Шәймәрдән), Солтан, Морат (Шәйморат) һәм Шаһгали (Шаһивәли). Алар арасында генерал дәрәҗәсенә житкәннәре дә, Хәрби хөкүмәт әгъзасы булганнары да, империянең иң зур орден-медальләре белән бүләкләнүчеләре дә бар. 1850 елда туган олы уллары Шәйхелислам Кочуров казак гаскәрләренең генерал-майор дәрәҗәсенә хәтле күтәрелә, Ырынбурда яши һәм 1нче Ырынбур казак полкының командиры була. 1891 елда ул Троицки шәһәрендә гаскәр башлыгы буларак Россия императоры Николай II не каршы ала, патша аңа имза белән үз фотопортретын бүләк итә. Татар генералы Шәйхелислам Кочуровны 1918 елда үзенең ишек төбендә атып үтерәләр.

Абдулваһһабның икенче улы Мәрдән (Шәймәрдән)1958 елда туган, ул Варнада яши һәм урман хуҗалыгы өчен җавап бирә. Империя алдында тырышлыклары өчен ул III дәрәҗәдәге Станислав һәм III дәрәҗәдәге Анна орденнары белән бүләкләнә.

1866 елда туган Солтан Абдулваһһаб улы запастагы офицер була, әмма Беренче бөтендөнья сугышы вакытында империяне саклап, зур батырлыклар күрсәтә һәм II дәрәҗәдәге изге Анна ордены белән бүләкләнә. Абдулваһһабның дүртенче улы Морат (Шәймөрат) 1867 елда туган, Петербургта офицерлык-кавалерия уку йортын тәмамлый. Ул большевикларны кабул итми, кул астындагы гаскәре белән кызылларга каршы сугышка күтәрелә, 1918 елны атаман Дутов җитәкчелегендә Троицки шәһәрендә төзелгән Хәрби хөкүмәткә әгъза булып сайлана. Хәрби министр, казак полковнигы Шәймөрат Кочуровның соңгы язмышы билгеле түгел, йә ул аклар һәм кызыллар арасындагы сугышта үлгән, йә исән калып, башка Ырынбур казаклары белән бергә Кытайга, Чүгүчәк шәһәренә барып җиткән. Бу тема өйрәнелмәгән.

Абдулваһһаб Кочуровның төпчек улы Шаһгали (Шәһивәли) 1870 елда туган, ул бигрәк тә 1904-1905 елгы рус-япон сугышында зур батырлыклар күрсәтә. Ул бу сугышта каты яралана һәм соңыннан аны зур пенсия белән ялга озаталар. Япон сугышында күрсәткән батырлыклары өчен татар казагы Шаһгали Кочуров IV дәрәҗәдәге Владимир, II дәрәҗәдәге Станислав, IV дәрәҗәдәге Анна орденнары, исемле корал белән бүләкләнә.

Күрәсез, Кочуровлар барысы да Россия империясенә тәннәре һәм җаннары белән хезмәт итәләр. Әмма Россиядә хакимият алышынгач, аларның ул батырлыклары онытыла, киресенчә, казак булганнары өчен алар эзәрлекләнә башлыйлар һәм репрессияләргә эләгәләр. Кочуровларның иген кырларын, көтүлекләрен, болынлыкларын, йорт-җирләрен, мал-туарларын, тегермәннәрен—бар байлыкларын тартып алалар һәм шуның нигезендә «Варна» совхозы төзиләр. Ә башка татар казакларының мал-мөлкәтләре нигезендә «Үрнәк» колхозы төзелә.

Кызганычка каршы, күп кенә татар-мөселман казакларының, шул исәптән Кочуровларның да документлары, нигездә, сакланмаган, нәсел шәҗәрәләре эшләнмәгән, оныклар төрле фамилияне йөртә. Әмма Варнада Кочуровлар бар. Музейда исә Кочуровларның ике фотографияләре тора. Шуның белән бетте. Варнаның илле урамы кем исемен генә йөртми, әмма империя өчен җаннарын һәм каннарын биргән Кочуровларга монда урын юк. Бәлки ул шулай булырга тиештер дә? Империя башка милләт кешеләрен вакытында файдалана да, мәңгегә оныта. Шуңа күрә төп көченне ул империяне саклауга түгел, үз милләтеңне үстерүгә һәм яклауга бирергә кирәктер! Кочуровлар мисалы бөтен татарларга ачык бер мисалдыр—иң башта үз халкың турында уйла! Аның өчен эшлә! Аның өчен яшә—сине Аллаһ та, милләт тә онытмас...

Инде мөселман-татар казакларының хәрби хезмәтләре турында да бераз мәгълүмат биреп үтик. Россия империясенең көньяк чикләрен саклау белән бергә, алар бу ил уздырган барлык сугышларда да диярлек катнашалар. «Начиная с января 1846 года, варненцы принимали участие практически во всех военных экспедициях и кампаниях XIX века», дип яза без югарыда телгә алган китабында Чиләбе тарихчысы В.Кобзов. *(Күрсәтелгән хезмәт, 46 бит.)*

XIX гасырда гына түгел, XX гасырның башында да мөселман-татар казаклары Россия империясе алып барган бөтен сугышларда катнашалар. Әмма күнелгә иң авыры—бу татарларны Урта Азиядә яшәүче мөселманнарга каршы сугышларда катнашырга мәҗбүр итәләр. Алар 1853-1854 елларда Бохара, Хива, Коканд шәһәрләрен яулауда катнашалар, 1865 елда урысларга Ташкентны басып алырга ярдәм итәләр, 1873 елда урыслар белән бергә бәйсез Хива ханлыгын тар-мар итәләр. Нәтиҗәдә, Коканд, Хива, Бохара ханлыклары үзләрен Россиянең вассаллары дип танырга мәҗбүр булалар. Үз бәйсезлекләре өчен газават игълан иткән Урта Азия мөселманнарына каршы сугышка мөселман-татар казакларын җибәрү—бу үзе җинаять булган. Бу сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен нәсел башы Абдулваһһаб Кочуровка һәм аның улларына империя бүләкләре тапшырыла:

«Известно лишь то, что все чины, принимавшие участие в походе, получили на шапки знак с надписью «За отличие в хивинском походе 1873 года», да в послужном формуляре есаула А.Кочурова записано: «Высочайше удостоен ордена Св.Анны 3 класса с изображением герба империи за Хивинский поход». За этот же поход его старший сын Шейх-Иль—Ислам получил Св.Станислава 3-й степени, а второй сын

Шагимардан участвовал в боях в качестве нижнего чина.» *(В.С.Кобзов. Күрсәтелгән хезмәт, 53 бит.)*

Моннан тыш Варна казакларын урыс-төрек сугышларында файдаланалар. 1863 елда Польшада урысларга каршы кабынып киткән восстаниене татар казаклары кулы белән бастыралар. 1877 елда яна урыс-төрек сугышы башланып киткәч, ут эченә тагы Ырынбур казакларын, Варна татарларын китереп кертәләр. Алар биредә тагы зур батырлыклар эшлиләр, Төркиянең Карс һәм Эрзурм кирмәннәрен штурмлауда катнашканнары өчен «За турецкую войну 1877-1878 гг.» билгеләре белән бүләкләнәләр. Шулай ук төрекләрнең Гөк-Тәпә кирмәнен тар-мар итүдә дә мөселман-татар казаклары зур тырышлык күрсәтә. Кыскасы, бу сугышларда җиңүнең даны—Россиягә, гөнаһысы татарларга була, чөнки алар урыс коралы белән төрки-мөселманнарга каршы сугышалар...

XX гасыр башындагы япон һәм герман сугышларында да татар казаклары күпләп катнаша. Япон сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Варна татарлары Шаһгали Кочуров, Нурәхмәд Исаев, Гатаулла Йосыпов, Исмәгыйль Иштуков, Сөнгатулла Хөсәенов, Мостафа Давытов һәм башкалар орден-медальләр белән бүләкләнәләр. Ә менә Беренче бөтендөнья сугышында Варна авылы күп татар казакларын югалта, 120 кеше яу кырында ятып кала... Шул ук вакытта исән калганнар арасында Георгий тәресе белән бүләкләнүчеләр дә була, әйтик, шундый бүләкләрне Насыйбулла Хәйбуллин, Васил Таймурзин, Ихсан Якупов, Солтан Якупов һәм тагы утыздан артык кеше ала.

Әйткәнебезчә, Гражданнар сугышы казакларны икегә бүлә, берәүләр кызылларны яклый, берәүләр аклар ягына баса. Варнадан 120 татар казагы, есаул Морат (Шәйморат) Кочуров җитәкчелегендә, советларга каршы сугышка күтәрелә. Урыс казакларының күпчелеге кызыл казак Кашириннар кул астына барып керсә, татарлар яңа хакимияткә ышанмыйлар, Варнаны кулга корал тотып большевиклардан саклыйлар. 1919 елның августында Варна кулдан-кулга күчеп йөри, аны әле кызыллар ала, әле аклар... Әмма өстәмә көчләр ярдәмендә кызыллар җиңүгә ирешәләр, аклар, шул исәптән, аларга ияргән йөзләгән Варна татары, гаиләләре белән, Тургай далаларына чигенәләр. Аларның алга таба язмышлары билгесез, әйткәнебезчә, Кытайга аларның бик азлары гына исән-сау барып җитә. Әмма Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, кытайлар бу казакларны совет гаскәрләре кулына тапшыралар, НКВД исә аларның күбесен шунда ук атып үтерә, кайберәүләр, алар кулына төшмәс өчен, гаиләләре белән үз-үзләрен үтерәләр...

Илдә калган Варна татарлары исә күп еллар буе казак булганнарын яшерергә мәҗбүр булалар. Аларга лампаслы казак киемнәре кияргә, корал сакларга рөхсәт ителми, мал-мөлкәтләре тартып алына, үзләре җир куышларына куып кертелә яки юк ителә. 1919 елның гыйнварында ЦК РКПб казакларга каршы яшерен директива кабул итә, ул анда бай казакларны һәм совет хакимиятенә каршы булганнарны рәхимсез рәвештә юкка чыгарырга куша:

«Провести массовый террор против богатых казаков, истребив их поголовно, провести беспощадный массовый террор по отношению ко всем казакам, принимавшим какое-либо прямое или косвенное участие в борьбе с Советской властью», диелә ул яшерен күрсәтмәдә. *(ДОН. 1990, №3.)*

Халыктан бар булган ашлык, ризык запасын тартып алалар, каршы торганнарны атып үтерәләр, бу исә 1921 елгы ачлыкка китерә. Биредә кешеләр кенәнә дистәләп ачлыктан үләләр, эт-мәчеләр ашап бетерелә, далада кеше ашау очраклары да теркәлә. Мөгаен, менә шушы елларда горур Варна татарларының да рухлары сынгандыр, алар бу ерткыч хакимият белән көрәшүнең мәгънәсе юклыгын күреп, үз эчләренә бикләнгәннәрдер, язмышлары белән ризалашканнардыр... Ул арада авылга җыен әтрәк-әләмне китереп тутыралар, район төзелә һәм ул кызу темплар белән урыслаша башлый.

«С целью создания социальной опоры в казачьих областях предлагалось немедленно начать массовое переселение в казачьи районы бедноты из других регионов, уравняв их во всех правах с казаками», диелә партиянең яшерен күрсәтмәсендә. *(В.С.Кобзов. Күрсәтелгән хезмәт, 70 бит.)*

Әмма Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, партиягә тагы туп ите кирәк була, тагы халыкның патриотик хисләре белән уйный башлыйлар. Сугыш башлану белән, Варнада татар мәктәбе каршында митинг була, анда житәкчеләр халыкны Гитлер Германиясенә каршы тәнен һәм жанын аямый көрәшергә чакыралар. Бу сугышта Варнадан өч меңнән артык кеше орден-медальләр белән бүләкләнә, үлүчеләр арасында да, бүләкләнүчеләр арасында да татарлар күп—шул ук Рәхмеевлар, Абсәләмовлар, Йосыповлар, Рахмангуловлар, Якуповлар, Кочуровлар... Варна татарлары бу илгә тугрылыкларын жаннарын биреп раслыйлар. Әллә шуна мәжбүр булалармы? Һәм бу тугрылыктан аларга файда бармы? Милләткә файда бармы? Болар турында алдагы бүлектә сөйләрбез, иншаллаһ!

## Бүгенге Варна

Бүгенге Варнада ун меңгә якын кеше яши, шуның өчтән бере—татарлар. Бер караганда, бу аз сан түгел, әмма бу өч меңгә якын татарның 90 проценты урыслар белән катнаш никахларда торуын белгәч, боларның милләт өчен юкка чыгып баруын аңлыйсың. Әйе, бу гаиләләр урыс телле, күп очракта, урыс динле, урыс гадәтле... Варна татарларының 50 яшьтән түбәннәре татарча укый-яза белми, яшьләрнең, балаларның күпчелеге татарча сөйләшми. Бистә урамнарына карап, монда татарлар яши икән, дип әйтеп булмый, чөнки татарча бер генә язма, бер генә плакат та юк. Хәер, зират янында салынып бетмәгән мәчет бар, бары тик ул гына, биредә мөселманнар яшәгәнен аңлатып, менә ничә ел инде йозакта тора...



*Варна авылының «Чишмә» ансамбле үзешчәннәре.*

Әйе, Варнада мәчет бар, әмма ул эшләми, чөнки стена белән түбәсеннән кала, берни юк—уты-газы-суы кертелмәгән, эче бөтенләй эшләнмәгән. Югыйсә, бу мәчет дип сүз кузгатканга инде 20 ел вакыт үткән, беренче казыгын какканга да инде ун ел була, эченә кереп намаз укырлык түгел. Бу мәсьәлә буенча шактый кешеләр белән очрашып сөйләштем, авылда имам вазыйфасын башкаручы Хөжжәт хәзрәт Мөжипов, мөселман мәхәлләсенең сәркәтибе Галия апа Хәсәнова, зират йортында дин сабаклары укытучы Зимфира Өметбаева, район советында мәхәллә активистлары белән очраштым. Һәм түбәндәгеләр аңлашылды:

Татарлар мәчет сорап йөри торгач, урыслар да Варнада яна чиркәү салу мәсьәләсен кузгаталар, һәрхәлдә, аларның бистәдә инде бер чиркәү-часовнялары булса да. Район хакимият башлыгы Сергей Маклаков халыкка мәчет белән чиркәүне бергә салып бетерергә сүз бирә. Нәтижәдә, хан сараедай чиркәү узган ел күз ачыла, ә мәчет төзелеше биш ел инде урыныннан кузгалмый. Эш шунда, мәчет төзелешенең заказчысы да, башкаручы подрядчигы да—хакимият үзе, шуна күрә, акча хисабы да алар кулында булган. Алар төзелеш эшләренә һәм акча капчыгына имамны да, мәхәллә әһелләрен дә якын жибәрмәгәннәр. Мәчеткә дип миллион сумнан артык акча жыелган, әмма аның нәрсәгә тотылуы турында беркем хисап тотмаган. Халыкның әйтүе буенча, ул акчалар чиркәү төзелешенә дә киткән булырга тиеш, ә мәчеткә дигән кирпечләрдән урыс зиратына өй салганнар. Моны аңлап алгач, мөселман-татарлар үз хисапларын ачканнар, әмма хакимият башлыгы рөхсәтеннән башка мәчет төзелешенә якын килә алмагач, ул акчалардан мәгънә юк. Хакимият

башлыгы хәзер эшләнеп бетмәгән мәчетне архитектура истәлеге итеп, шул килеш калдырырга тәкъдим итә икән, имеш, намаз укырга барыбер кеше юк, ә тыштан туристларга күрсәтергә мөмкин.

Менә шулай татарлар төп башына утырып калганнар...

Һәм бөтен документларда, интернетта, югары даирәләрдә Варна мәчете эшли торган мәчет (действующий), ягъни, намаз укыла торган, дип күрсәтелгән. Бу бит бәндәне генә түгел, Аллаһны да алдарга тырышу! Әмма монда күнелгә ин тигәне—хакимиятнең чираттагы алдавы гына түгел, ә намаз укырга кеше булмавын сәбәп итеп күрсәтү. Чөнки бу сүзләрдә өлешчә булса да дөреслек бар. Мин Хөҗҗәт хәзрәт белән очрашканда да, сүзне шуннан башладым, ни өчен берәр йортта булса да җомга намазлары укымыйсыз, дидем. Ә ул, җәмәгать намазы укырга кеше юк, мин берүзем, диде. Менә монысы мине аяктан екты! Әйтүләре буенча, Варнада мөселманнар саны 3500, монда казах, үзбәк, кыргыз, башкорт милләте вәкилләре дә керә. Шушы хәтле мөселман арасында җәмәгать намазы укырга кеше юкмы? Гаетләрнең кайда укылуы белән кызыксындым, зират өендә укыйлар икән. «Гаетләргә биш йөзләп кеше килә, әмма дүрт-бише генә намазга баса, унбишләп кеше садака сала», диде хәзрәт. Димәк, хакимият башлыгы белеп сөйли—Варнада намаз укырга ир-ат калмаган ?!

Ә мәчет төзелеше турында зурлап сөйләшүне Варна район советында оештырдык. Биредә безне үзебезнең милләттәшебез, район советы депутаты, җирле парламент рәисе урынбасары Ракаев Тәлгать Шәрәф улы кабул итте. Без, дигәнем—мөселман мәхәлләсе әгъзалары һәм мин. Барыбыз да татарлар булсак та, сөйләшү урыс телендә барды, монысы, мөгаен, протокол өчен кирәк булгандыр. Әлбәттә, биредә утыручылар барысы да мәчет төзелешенең яңадан башлануы яклы, әмма ничек итеп? Хакимият башлыгы имамны кабул итми, мәчет төзелеше белән кызыксынмый, ә аның фәрманыннан башка биредә берни эшләмиләр. Беренче эш итеп хакимият башлыгы белән махсус очрашу уздыру каралды, монда Тәлгать әфәнде Ракаев ярдәм итәргә булды. Мәчет төзелешенә бер җаваплы кеше билгеләргә кирәклеге дә сөйләшенде. Шулай ук ярдәм сорап дини һәм милли лидерларга мөрәҗәгать итәргә кирәклеге дә әйтелде. Варна Чиләбе өлкәсенә керсә дә, аннан бирегә татарларнын хәлен белергә беркемнең дә килеп караганы булмаган, шулай ук мәчет теркәлгән Уфа шәһәреннән дә бернинди ярдәм юк. Димәк, аларның ишекләрен кагар вакыт та җиткән. Шулай итеп, монда кадәр файдаланылмаган юллар, алымнар барысы да тикшерелде, иң мөһиме, җомга намазларын укый башлау кирәклеге әйтелде.

Әлбәттә, бер очрашу белән генә мәчет төзелеше башланмас, монда көн саен йөрергә кирәк. Имам Хөҗҗәт хәзрәт мина артык толерант кеше булып күренде, фетнә генә чыга күрмәсен, дип яшәп, ул берүзе утырып калган. Ул үзе бу як кешесе түгел, Башкортстанның Илеш районында туып-үскән, гомере буе төзелештә эшләгән, дин ирege килгәч, Уфага барып, мәдрәсәдә укып кайткан. Дөрес, ул дини йолаларны башкара—бала тугач, сорасалар мөселманча исем куша, никах укый, кеше үлсә, мөселманча күмә, Коръән мәҗлесләренә йөри. Әмма меннәрчә этник мөселман яшәгән җирдә җомга намазларының укылмавы зур гөнаһ бит! Хәзер шуны башка милләтләр, җитәкчеләр дә татарның йөзенә бәреп әйтә башлады. Мин дә моны хәзрәтнең исенә кат-кат төшердем. Һәм—нинди могҗиза! Мин кайтып киткәннең икенче атнасында ук, 4 июнь көнне Варна авылында зират йортында беренче тапкыр җомга намазы укылган! Моны Аллаһның рәхмәте дими, ни дисен?! Болай булгач, Варнада мәчет булачак, иншаллаһ, чөнки аны биредә халык гыйбадәтләр кылып сорый бит! Район җитәкчесе мәчет төзелешенә җаваплы кеше итеп Борнаев Барый Әхмәтҗан улын билгеләгән, ә ул Зимфираның әнисенең ир туганы, атаклы Борнаевлар нәселеннән булырга тиеш.

Ислам дине Варна татарларын бәлки урыслашып бетүдән дә саклап калыр, дигән өмет тә бар. Чөнки хәзер биредә халыкны астан чукындыру бик көчәйгән. Элек Варнага поп итеп чукынган татар яки башкортны җибәрсәләр, хәзер поп та урыс милләтеннән икән, чөнки чукынырга татарча өндисе юк. Барысы да урысча белә. Әйткәнемчә, Варнада 90 процент гаиләләр катнаш никахларда торалар, яшь гаиләләрдә бу сан йөз процент дип әйтергә була. Билгеле булганча, балаларны

чиркәүгә алып барып чукындыралар. Күптән түгел шундый вакыйга булган—катнаш никахтан туган балаларын чукындырырга алып килгән ике татар хатынын поп кире борган, ата-аналары христиан булса гына балаларны чукындырырга мөмкин, дигән. Һәм бу татар хатыннары нишли? Әйе, чиркәүгә барып, башта үзләре чукыналар, аннан инде поп балаларын да чукындыра. Милли һәм дини рухы булмаган башка татарларны да Варнада шушы язмыш көтә...

Варнада милләт һәм дин эшләренең башында Галия апа Хәсәнова тора, ул заманында «Чишмә» ансамблен оештырган, хәзер исә бөтен көчен мәчет төзелешенә бирә. Галия апа үзе дә Кочуровлар нәселеннән, гомер буе күрше урыс авылында укытучы булып эшләгән, ялга чыккач, туган авылы Варнага кайтып, милләтен күтәрү юлына баскан. Ул бу мәчет мәсьәләсендә кая гына керми, кемгә генә язмый, хатлары белән Путинга хәтле барып житә. Аның өендә милли һәм дини эшләрнең архивы саклана, ул татарга кагылышлы һәр кәгазьне бөртекләп жыеп барган, мина да бик булышты. Артык активланып киткәч, аны Варна уртасында машина белән дә бәрдереп китәләр, шул сәбәпле, Галия апа күп тән һәм жан газаплары кичерә, әмма үч алу юлына басмый. Аны бәрдергән урыс үзе машинасы белән бәрелеп үлә...

Варнада милләт тормышы менә шундый фидакарь кешеләрнең эшчәнлегеннән тора, алар олы буында да, яшьләр арасында да бар, шөкер! Минем Варнага баруыма сәбәпче булган һәм Тамерлан төрбәсе буенча күп мәгълүмат биргән яшь мөслимә танышым Зимфира Өметбаева турында аерым язып китәсем килә. Без аның белән интернет аша таныштык, яшь араларыбыз шактый зур булса да, безнең икебезнең дә диндә булуыбыз һәм икебезнең дә татар тарихы, Тамерлан төрбәсе белән кызыксынуыбыз якынайткандыр, мөгаен. Бу сәфәремдә Зимфира мине үзләрендә кабул итте, Тамерлан төрбәсе һәм Варна тарихы буенча күп материаллар бирде, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын! Зимфира шушы Варнада, татар гаиләсендә туып-үскән кыз, ул башта музыкаль юнәлештәге мәктәп, аннан Чиләбедә педагогия институтының урыс филологиясе бүлеген тәмамлый. Чиләбедә укыганда Зимфира дингә килә, Казанга барып, Мөхәммәдия югары дини мәдрәсәсендә белем ала, 2009 елда аны уңышлы тәмамлагач, туган авылы Варнага кайтып, мәктәпләрдә татар теле укыта. Әйе, ярты гасырдан артык татар теле укытылмаган Варнада Зимфира, укыту бүлеге мөдире белән килешеп, ике урта мәктәптә факультатив рәвештә булса да, татар теле укыта башлый! РОНО мөдире булып Вера Михайловна Йосыпова эшли икән, ул заманында Зимфираны урыс теленнән укыткан булган һәм алар арасында бер-берләренә карата зур хөрмәт сакланып калган.

Зимфираның укучылары белән очрашырга мин дә 2нче урта мәктәпкә бардым. Һәр мәктәптә егермегә якын бала йөри икән бу дәресләргә, һәм аларның барысы да диярлек катнаш никахлардан туган балалар. Ягъни, алар татарча укый-яза түгел, хәтта сөйләшә дә белмиләр! Әмма Зимфира бу балалар күңеленә ачкыч таба алган, ул аларда татарлыкка мәхәббәт тәрбияләүне төп максат итеп куйган. Зимфира үзе язган укыту программасы тарихи-мәдәни факультатив, дип атала һәм аны жирле тарихка яраклаштырып, Россиянең теләсә кайсы төбәгендә укытырга мөмкин. Биредә балаларда тарих һәм мәдәният аша татар милләтенә мәхәббәт уяту, татарлыкны кузгату максаты куелган. Зимфира моңа төрле чаралар белән ирешә—ул дәрескә ноутбук күтәреп кереп, интернет аша балаларны татар тарихы, Казан, Болгар, Алтын Урда тарихи ядкарьләре, Тамерлан төрбәсе, борынгы курганнар белән таныштыра. Шулай ук башлангыч музыкаль белем алган кеше буларак, синтезаторын алып кереп, балалар белән «Туган тел» һәм башка милли жырларны башкара, мең еллык татар әдәбияты турында мәгълүмат бирә, милли ризыклар һәм татар киемнәрен күрсәтеп, дәресләр оештыра, балаларны үз нәсел тарихлары белән кызыксынырга өйрәтә, бергәләп шәжәрәләр төзиләр. Әлбәттә, хәзергә балалар да, хәтта аларның укытучысы да иркенләп татарча сөйләшә белмиләр, әмма алар инде рухлары белән татар!

Зимфира Өметбаева—фән һәм диннең, мәдәният һәм милли тарихның бергә үрелгән яңа мөселман-татар үрнәге ул. Ул дөньяви һәм дини югары белеме булган яшь белгеч, дин кануннарын да саклый, фәнгә дә ишекләрне ябып куймый. Ул әле Чиләбе педагогия институтында укыганда ук Көньяк Уралда жир-су атамаларының

төркилеген исбатлап, курс эшләре яза, әмма ана кайда укуын онытмаска исенә төшерәләр. Мона карап Зимфира төрки тарих белән кызыксынуын туктатмый, ул хәтта Казанның Мөхәммәдия мәдрәсәсендә дә гаҗәеп кызыклы темага диплом эше яза. «Татары—в калейдоскопе имен» дип аталган бу фәнни хезмәт борынгы төрки-татарлар тарихына бик үзенчәлекле, тирән анализ һәм бәя ул. Кайбер мөселманнар кебек, ул борынгы төрки тарихтан баш тартмый, киресенчә, төрки телнең дөнья яратылганда ук төп тел—праязык икәнлегенә чын күңелдән ышана һәм шуны башкаларга да дәлилли ала. Әйткәнемчә, бу анын дини инануларына зыян китерми, киресенчә, офыкларын тагы да киңәйтә.

Мәктәптә укыту өстенә, Зимфира Өметбаева Варнада дини дәресләр дә алып бара, зират йортында хатын-кызларны укыта. Бу орлыклар да җимеш бирер әле. Варна урамнарында яулыклы бер Зимфира гына булмас, аның төшенә кергәнчә, авылның бөтен урамнары мөселманча киенгән хатын-кызлар белән тулыр, иншаллаһ! Тагы шунысына игътибар иттем—Зимфира чын мәгънәсендә дала кызы... Ул үзенең туган якларын өзелеп ярата, аны берни белән дә алыштырмый. Ул башкалар кебек ничек тә Казанда калу ягын карамаган, ә үз халкын агартырга дип, туган даласына кайткан... Әйе, ул дала ярата, ат итен ярата, бишбармак ярата, самоварын алып, сахрага чәй эчәргә чыгарга ярата... Ул татар тормышын өзелеп ярата. Шунысын да әйтергә кирәк, Зимфиранын әнисе Тәнзилә ханым нәселе белән Троицкиның атаклы ишаны Расүлов хәзрәткә барып тоташа.

Зимфира белән без Варнаның крайны өйрәнү музеенда да булдык, көне буе биредә Тамерлан төрбәсе һәм татар тарихы белән бәйле материалларны өйрәндек. Хәер, монда татар тормышына кагылышлы әллә ни юк—Кочуровларның ике фотосы, ике трактористканың исеме һәм Тукай белән Җәлил рәсемнәре куелган калфаклы «татар почмагы»... Югыйсә, ике катлы музейда татарларга күбрәк урын бирергә дә булыр иде, чөнки, ни әйтсән дә, Варнага нигез салучылар бит алар! Әмма биредә ул турыда бер сүз дә юк, бөтен җирдә урыслар, урыслар, урыслар... Варнада туып-үскән, Казанда татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнаган күренекле артист Гали Надрюковны да белмиләр монда. Муллаларыбызны да белмиләр. Музейда мине бердәнбер гаҗәпләндергән нәрсә—ишек түбәнә сөяп куйган таш балбал булды. Әмма анын да төрки тарих ядкаре икәнлеге язылмаган иде. Гомумән, биредә төрки, Алтын Урда, татар сүзләрен кулланмаска тырышалар кебек, әйтерсең лә, дала тормышы урыслардан башланган... Мин музейда эшләүче рус ханымнарына Тамерлан төрбәсенең дә, таш балбалның да төрки цивилизация билгесе икәнлеген аңлаттым, ә алар туристлар юклыкка зарландылар. Ә кем килсен—урыслар өчен болар кызык та түгел, кадерле дә түгел, ә Себер һәм Казан татарлары биредә ханнары күмелгәнлеген белми дә...

Варна белән танышуыбызны дәвам итәбез. Биредә ике милли ансамбль эшли икән—«Чишмә» һәм «Мирас». Мин район мәдәният йортында бу ансамбль әгъзалары белән дә очраштым, Татарстандагы һәм татар милләтендәге хәлләр турында сөйләдем, китапларымны, Чаллыдан алып килгән газеталарны бүләк иттем. Бу ансамбльләр инде 8 ел эшлиләр икән, аларга нигезне Галия апа Хәсәнова салган булган, хәзер Рауза Абидуллина һәм Мәдинә Рекунова җитәкчелек итә. Үзләренә бик матур милли киемнәр тектергәннәр, репертуарларында җирле җырлар да бар, бергәләп җырлап та күрсәттеләр. Алар Варнада гына түгел, тирә-юньдә, Магнитогорски, Чиләбе шәһәрләрендә узган милли чараларда да бик актив катнашалар икән, төрле бәйгеләрдә мактаулы урыннар да алганнар. Дөрес, бу ансамбльләргә, нигездә, олы яшьтәге апалар йөри, әмма аларның милли йөзләре, саф татар телләре барысын да онытгыра. «Мирас» ансамбле музейда мәктәп балалары алдында да татар халкынын сәнгате турында чыгышлар ясаган, ул видеога төшерелеп, җирле телевидениедән дә күрсәтелгән. Варнада бердәнбер милли учак, татарлык билгесе алар!

«Мирас» ансамблен җитәкләүче Мәдинә апа Рекунова турында аерым әйтәсем килә. Мәдинә апа бик актив, милли җанлы кеше, ул Варна тарихын өйрәнеп, кульъязма китап та язган, моннан тыш та авыл тарихы турында мәкаләләре район газетасында даими басылып тора. Мәдинә апа шулай ук Варнадагы халык авыз иҗатын, мәкальләрне, җыр-такмакларны, догаларны туплаган, әмма аларның

күпчелеге безнен яктагы фольклорга бик туры килә. Моңа бер дә гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки татар халкының, кайда гына яшәсә дә, тамырлары, нигезе бер бит, шуңа күрә, иҗаты да уртак. Алай да, Варна-Мачаның үзенә генә хас берничә мәкаль-әйтемен дә ишеттем һәм язып алдым—«Ил куәте—ирдә, җир куәте—диндә.» «»Картлык кылган өстеннән йөрми, адәм өстеннән йөри.» «Күләгәле күл корымас.» «Болганчык су тирән булмый.» Тагы менә шундый җыру истә калды:

*Биек кенә тауның башларында*
*Бакыр чәйнек кайный җил белән.*
*Уфтанмаек, дустым, кайгырмаек,*
*Бер без генә түгел, ил белән...*

*Биек кенә тауның башларында*
*Йөгереп кенә йөри бер бәрән.*
*Әллә инде бәрән, әллә адәм,*
*Үтә гомеркәйләрем әрәм...*


*Варна авылының 2нче урта мәктәбендә укучы татар балалары.*

Соңыннан Мәдинә апа безгә Варнаны күрсәтеп йөрде, үз машиналары белән ярдәмгә мәктәп китапханәсендә эшләүче Рәмзия ханым Нагорная һәм аның ире алынды. Варна, чыннан да, хәзер бик зурайган, аны җәяү генә йөреп чыгарлык түгел. Дөрес, бистәдә эре промышленность объектлары юк, Варна авыл хуҗалыгы районы, ит, сөт, икмәк, яшелчә кебек азык-төлекне үзләрендә үстерәләр һәм эшкәртәләр. Район үзәгендә зур элеватор һәм тимер юл станциясе бар, соңгысы 1892 елда ук ачылган булган һәм бүген дә «Тамерлан» исемен йөртә. Бу тимер юл белән төньякка таба китсәң—Троицкига һәм Чиләбегә барып җитәргә мөмкин, көньякка китсәң—тимер юл Орски, Ырынбурларга кадәр барып чыга. Якын-тирәгә электричкалар да йөри икән.

Варнада шәхси йортлар күбрәк булып чыкты, алар агачтан, кирпечтән, саманнан һәм камыштан салынган. Бистәдә шулай ук ике-өч катлы кирпеч йортлар да бар, шуннан биеген күрмәдем. Татар Мачасы уртада калган, элеккеге Җәмигъ мәчет бинасында хәзер китапханә, икенче мәчет урынында—Дан аллеясы... Варнаның иске өлешеннән барганда, үзеңне нәкъ йөз элек яшәгән кебек хис итәсең—биредә генә күрергә мөмкин булган таш коймалар, тәрәзәсез амбарлар, акшарланган камыш йортлар... Мәдинә апа кайда, кем яшәгәнен барысын да белә һәм сөйләп бара, Зимфирада болар слайдларга да төшерелгән.

Варнаның төньягында, калкурак урында, мәһабәт чиркәү кукраеп утыра. Ул Елан тавына салынган. Халыкның сөйләве буенча, элек анда еланнар мыжлап торган, бу урын мәҗүсиләрнең табыну урыны булган. Варна музеенда торучы таш балбалны да шушы Елан тавыннан тапканнар, имеш, элек ул 5 метрлы стеллага урнаштырылган булган... Чиркәү сала башлагач, аннан кеше сөякләре чыккан, элеккеге мәдәният бүлеге мөдире Савин кеше сөякләре өстендә берни төземәскә кушкан, әмма ул үлгәч, урыс гыйбадәтханәсен барыбер шушында салганнар. Белгән кешеләрнең

әйтүенчә, Елан тау тирәсендә гел курганнар икән, әмма аларны өйрәнүче юк. Хәер, кайбер рус тарихчылары моны белә, әмма бу хәтле зур тарих аерым кешеләр генә күтәрерлек эш түгел:

«Мавзолей, по сути своей, вершина айсберга, выступающего из океана веков,— дип яза инде безгә таныш тарихчы Сергей Боталов.—Весь озерный перешеек вокруг Варны занят гигантским погребальным полем различных эпох—от бронзового века до начала прошлого века—конца кочевий в этих местах. Здесь покоятся останки наших земляков почти четырех тысячелетий.» *(Сергей Боталов. Күрсәтелгән хезмәт, 32 бит.)*

Авылның икенче башында—зур татар зираты, ул бик борынгыга охшаган, аның эчендә дә төрбә сыман корылмалар һәм гарәпчә язылган кабер ташлары бар. Бу ташларны беркем укымаган һәм өйрәнмәгән. Зират янында гына—салынып бетмәгән мәчет, зират эчендә—Зимфира дин дәресләре укыта торган йорт. Бу зираттан җанга ниндидер монсу тынычлык инә, дөнья ыгы-зыгысы онытыла, дала жиленен кылганнар белән сөйләшүен тын гына тынлап торасың... Үләннәр кыштырдавына догаларыбыз кушыла, без кыйблага карап, бу зиратта яткан әрвахлар рухына дога кылабыз, аларга мәңгелек тынычлык телибез... Һәм күңелгә шушы авылда туып-үскән хәрби журналист Мансур Хәсәновнын Мачага багышланган шигъри юллары килә:

*Мин Мачага кайтсам, китә алмыйм,*
*Чакырып мине хатлар салмагыз.*
*Кыр казлары көньягына таба*
*Очмый, мине килеп алмагыз.*

*Ничә еллар читтә җаным туңды,*
*Моң-зар булдым җылы кояшка.*
*Чакырмагыз мине, чакырмагыз,*
*Сулышыма җиңел бу якта.*

*Бик күрәсем килә шул кырларны,*
*Кисәнәне, Уба буйларын.*
*Анда калды минем бала чагым,*
*Шунда тарта мине уйларым.*

*Бер дә элек мин моңаймый идем,*
*Хәзер җылыйм инде көн саен.*
*Әллә мин Мачаны актык күрәм,*
*Әллә күңел йомшый ел саен.*

*Әй син, Мача, әй син, яшел Мача!*
*Ник саргайттың мине вакытсыз?*
*Бик яшисем килә бу дөньяда,*
*Булсам да мин яшьтән бәхетсез.*

*«Бәхил», димә миңа,бер кайтырмын,*
*Ак каеннар яфрак ярганда.*
*Зират буен яшел үлән каплап,*
*Кырлар чәчәк белән тулганда.*

*Шундый вәгъдә бирдем мин зиратта.*
*Үзем өчен урын алганда...*

Әйе, Варна татарлары, кайда гына китсәләр дә, мәңгелеккә шушында кайтып яталар икән... Кисәнә-Тугызак буйларына, татар далаларына, Мача зиратына...

Авылнын тирә-юненә дә чыгып керәбез. Тугызак суы буйлары ямь-яшел агач,

дала уртасындагы урын димәссең! Югыйсә, биредә җәйләрен эсселек кырык градуска җитә икән, кышларын да шундый дәрәҗәдә салкынлык. Ә Тугызак буйларында һәрчак яшеллек һәм күләгә, таллары да нәкъ бездәге кебек, су өстенә иелгән... Авыл тирәсендә эреле-ваклы берничә күл дә бар, әйтик, Тамерлан станциясе янында—Акчарлак күле, далада Мулла күле, Кисәнә, Чикатай күлләре... Төп елга—Тугызак, аннан тыш Карталы—Аят, Таеткан елгалары бар. Ерактан Уба тавы күренеп тора, бәлки ул да борынгы кургандыр... Тугызак атамасының да тамыры бик борынгы булырга тиеш, тугыз татар кавеме турында 8 гасыр таш-стеллаларына ук язып калдырылган бит! Шулай ук Себердә Токуз авылының булуы да борынгы төркилеккә ишарә. Муса Җәлил үзенең «Алтынчәч» либреттосында Тугызак образын биргән, ул илне баскынчыларга каршы көрәшкә өндәүче Ана образы.

Варна районында моннан тыш та төрки тамырлы җир-су атамалары шактый икән, бу хакта махсус ккитаплар да басылып чыккан. Әйтик, Чиләбе галиме Н.Шуваловның «От Парижа до Берлина» дип аталган кечкенә ике томлыгы, ул биредә нугайбәк керәшеннәренең Париж һәм Берлин дип аталган авылларын күздә тоткан. Әмма бу китапларда Чиләбе өлкәсендәге, шул исәптән, Варна районындагы бөтен төрки җир-су атамалары йә—казахныкы, йә башкортныкы итеп күрсәтелгән. Югыйсә, тау—татарча да тау, елга—татарча да елга бит! Инде татарчасы ярылып яткан атамаларны «тюркский», ягъни, төрки дип кенә күрсәтергә тырышканнар. Бу да татарны оныттырырга тырышуның бер алымы булып тора.

Шушы китаптан алып, Варна районында булган күл атамаларын биреп үтәбез:

Акчарлак, Алаком, Алтынкүл, Ачысор, Байтак, Бакан-жул (юл) , Баран-жулун, Джигай, Жидекүл, Исәннелде, Карабай, Карамыс, Каратай, Кинҗәтим, Салырбай, Үтәмеш, Чикатай һәм елгалар—Тугызак Арчаглы-Аят. *(Шувалов Н. И. От Парижа до Берлина по карте Челябинской области.—Челябинск, 1999.)* Моннан тыш картада Акман, Сарыкамыш, Карауб, Түләк, Шыганак, Алтыр күлләре, Алакуп, Култай, Каработак, Җабагы сазлыклары күрсәтелгән. Йә, әйтегез, боларның кайсысы татарча анлашылмый? Шунысын да әйтергә кирәк, башкорт галимнәре Уфада һәм Чиләбедә Урал аръягын үзләштерү буенча зур эш алып баралар, урыс галимнәренең бу өлкәдә китаплары да алар күзәтүендә һәм алар ярдәмендә дөнья күрә. Ә без Варнаның да татарныкы икәнлеген исбат итә алмыйбыз!

## Йомгаклау сүзе

Менә безнең Варнага сәяхәтебез тәмам. Мин үзем өчен күп яна нәрсәләр белдем, шуны башкалар белән дә уртаклашырга булдым. Минем өчен беренче ачыш—Тамерлан төрбәсе янындагы далада Алтын Урда ханнарының, бигрәк тә Шәйбәниләрнең некрополе—патша мазарлыгы булу. Моның шулай икәнлеген урыс һәм казах галимнәре дә таный, бу хакта югарыда әйтелде инде. Ул гына да түгел, бу мазарлыкның борынгы скиф-сармат-сак-һун курганнары өстендә урнашуы. Бу исә традицияләрнең дәвамлы булуын күрсәтә, ягъни, төрки-татарлар да шул ук җирләрдә яшиләр, шунда күмеләләр, шул ук гореф-гадәтләрне дәвам итәләр, дигән сүз. Бу кыпчак далалары—төрки цивилизациянең үзәге, шәһәрләр иленең уртасы, төрки дәүләтләрнең нигезе, татарларның Ана-Ватаны. Кызганыч, даладагы бу скиф пирамидалары, татар курганнары әле татар күзлегеннән өйрәнелә дә башланмаган, тарихи хезмәтләр язылмаган, данлы үткәнебез турында әдәби әсәрләр тумаган, фильмнар төшерелмәгән. Бу изге эш—бездән соң киләсе буыннарга амәнәт.

Үзем өчен икенче яңалык—шушы көнгә хәтле Казаннан Варнага, Тамерлан төрбәсен, татар тарихын өйрәнергә бер генә татар галиме дә, бер генә татар язучысы да килмәгән булып чыкты. Шулай ук Татарстаннан дин әһелләре һәм сәнгатькәрләр дә бирегә аяк басмаган. Варна татарларының да күпчелеге гомерләрендә дә Казанны күрмәгәннәр... Инде моннан соң, иншаллаһ, гасырларга сузылган бу өзеклек бетерелер, Зимфира кебек яшь мөселман-татарлар аша даладан Казанга күпер салыныр, биредә фәнни конференцияләр, Сабантуйлар, очрашулар уздырылыр, дип өметләнәм.

Соңгы ачышым—Варна-Мачадагы мөселман-татар казакларының язмышы

булды. Мона кадәр бу турыда әллә ни язылмады һәм сөйләнмәде, христиан-татар казаклары—нугайбәкләр турында бераз хезмәтләр булса да, мөселман казаклары турында белмәдек. Ә алар булган, далаларда ил-авыл булып яшәп яткан, үзен басып алган империя өчен кан түккән, гомерен биргән һәм шул империя «ярдәмендә» тарих мәйданыннан юкка чыга язган. Әмма юкка чыкмаган. Бу—бик гыйбрәтле язмыш. Аны өйрәнергә һәм сабак алырга кирәк. Варна татарларының Тамерлан төрбәсе янына килеп урнашулары да үзенә күрә бер ишарә-билге, чөнки бу бөек цивилизациянең дәвамчылары итеп язмыш нәкъ менә татарларны сайлаган, һәм бу бер дә юкка түгел... Далада татардан башланган төрки тормыш бүген дә татарлар белән дәвам итә. Һәм ул мәңге шулай булыр, иншаллаһ!

Килгән юлым буйлап кайтырга кузгалам. Варнадан—дала буйлап Магнитогорскига, аннан Урал тауларын кисеп үтеп, Чаллыга кадәр Башкортстан аша тәүлеккә якын машина юлы... Атилла хан һәм аның уллары, Чыңгыз хан оныклары, татар яугирләре атка атланып гасырлар буе үткән Татар Юлы... Як-якта—сибелеп калган татар авыллары, татар шәһәрләре, татар атамалы Җаек һәм Агыйдел, Кама сулары, татар тарихын саклап торган Урал таулары... Җир астында һәм өстендә—5 мең еллык скиф-татар курганнары, мәңгелеккә күмелгән бөек татар тарихы... Ул әле ачылмаган, ул әле өйрәнелмәгән, әмма хак сүз, барыбер, әйтеләчәк, дөнья татар тарихын әрҗәнадан ачачак әле, иншаллаһ!

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Әтрәч авыллары

Олы Әтрәч һәм Кече Әтрәч исемле авыллар Тәтеш районында, Зөя бассейнындагы Олы Үләмә елгасының уң кушылдыгы—Әтрәч суы ярына утырганнар. Олы Әтрәч район үзәге Тәтештән—17, Кече Әтрәч 19 чакрым ераклыкта урнашкан. Жирле үзидарә советы Олы Әтрәч авылында, бу ике авыл бер-берсенә бик якын, янәшәдә генә, кушылып урнашканнар.

Әтрәч атамасы Казан ханлыгы чорындагы тарихи документларда телгә алына. «Әтрәч пустошы» атамасы XVI йөзнең икенче яртысыннан XVII йөз урталарына кадәр вакытны алган тарихи чыганакта теркәлгән. Д. А. Корсаков (XVIII йөз) белешмәсендә Олы Әтрәч авылы Әтрәч, Иске Шонгат (Иске Әтрәч, Тенеш) төрдәшләре белән телгә алына. Авылда 101 ясаклы татар һәм 90 керәшен көн иткән, ә Миртөбәк (Кече Әтрәч) авылында 84 йомышлы татар һәм 9 керәшен исәпләнгән.

Элек бу тирәләрдә калын урман үскән. Халык урман кисеп ышналар, басулар ясаган. Кыяр, Шалкан, Наратлык, Дуңгыз, Яна, Олы, Иске, Морзалар ышна-басулары шул турыда сөйли.

Әтрәч суы һәм авыллар атамасы XIV йөз кабер ташы язмаларында очрый торган Әтрәч исеменә мөнәсәбәтле. Кабер ташларының саны 50гә якын һәм шуннан чыгып, бу урында шактый зур феодаль үзәк булган дигән нәтиҗәгә киленә. Жирле халык бу зиратны, кайчандыр монда булган Болгар шәһәре Шонгатыга мөнәсәбәтле рәвештә, «Шонгаты өсте» дип атый. Әлеге авыллар янында соңгы болгар чорларына караган ике авыл хәрабәсе, акча хәзинәләре, табылдык әйберләр жыелмасы билгеләнгән.

Әтрәч авылы атамасы Казан ханлыгы чоры чыганакларында искә алына, һәр ике Әтрәч халкы үзләреннән якында гына урнашкан Олы Болгаер һәм Кече Болгаер авыллары халкы белән дус яшәгән. Казан ханлыгы чоры авыллары теркәлгән чыганакта Болгояр—Болгар Кривой авылларының янәшә китерелүе дә игътибарны жәлеп итә. Авылларның дуслыгы борынгы заманнардан килә икән. Кече Болгаер авылы басуында Әтрәч борылышы дигән микротопономик атама да бар.

Әтрәч халкы күрше авыллар белән бергә Чабыр жыенын бәйрәм иткән.

Олы Әтрәч һәм Кече Әтрәч авылларының икесендә дә географик берәмлекләр һәм тарихи урыннар күп. Олы Әтрәч авылында Изге зират бар. Наратлык дигән урында халыкның ак тавык яисә сарык суя торган йоласы сакланган. Бу тирәгә сыерлар килсә, алар үзләреннән-үзләре дерелди башлый һәм сөтләре бетә икән.

Әтрәч атамасы Казан арты төбәгендә дә очрый. Питрәч районында Әтрәч авылы һәм шул ук исемдәге елга бар. Бу авыл исеме һәм гидроним Казан өязе авыллары белән бәйләнешле тарихи документларда очрый. Әтрәч авылы Казан ханлыгы чорында булган. Апас районындагы Кошман авылының бер урамы да Әтрәч исемен йөртә.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

## Әшнәк авыллары

Исемнәренә «Әшнәк» берәмлеге катнашкан авыллар Балык Бистәсе районында урнашкан. Олы Әшнәк авылы район үзәге Балык Бистәсеннән—19, Казаннан 109 чакрымда; Югары Әшнәк район үзәге Балык Бистәсеннән—20, жирле үзидарә советы үзәге Олы Әшнәктән—6, Казаннан—108 чакрымда; Кече Әшнәк Балык Бистәсеннән 14 чакрымда урнашкан.

Әшнәк атамасы шактый күп тарихи чыганакларда очрый.

Нугай юлы өстенә утырган Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авыллары Казан ханлыгы авыллары тупланган исемлеккә кергән. Олы Әшнәк авылы зиратында археологлар соңгы болгар (Алтын Урда) чоры кабер ташларын һәм авыл хәрабәләрен билгеләгәннәр.

Әшнәк суы Казан өязе теркәү кенәгәсендә (1602—03 еллар) искә алына.

Д.А.Корсаков бастырып чыгарган белешмәдә язылганча, Кече Әшнәктә—147, Олы Әшнәктә 236 йомышлы татар яшәгән.

Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк халкы күршедәге Олы Елга, Кече Елга, Олы Солтан, Янтык, Чирмешән авыллары белән бергәләшеп, июнь башында Жөзән жыены бәйрәм иткән.

Олылар сөйләве буенча, Әшнәк атамасы болай килеп чыккан.

Монгол яулары вакытында Кама буеннан ике гаилә Әшнәк елгасы буена килеп утырган. Бу вакытта әле елганың исеме булмый. Алар бик дус һәм тату яшәгәннәр. Дусларны «әшнә» дип йөртәләр бит. Шушы сүздән Әшнәк авылы атамасы барлыкка килгән. Елга да шундый исем йөртә башлаган.

Икенче фикер мондый. Кайсыдыр яудан качып хәзерге Әшнәк елгасы һәм аның тармаклары буйларына төрле милләт кешеләре килеп урнашкан. Алар соныннан күбесе татарлашканнар, бик дус яшәгәннәр. Аларны әшнәләр дип йөрткәннәр. Авылның өлкән кешеләре хәзер дә кулланыла торган «чуаш», «чегән» кебек кушаматлы гаиләләрнең шәжәрә башы шул елларга барып тоташа, дип аңлаталар.

Олы Әшнәк авылында чишмәләрдән Урсай чишмәсе, Чукрак чишмә, Шири чишмәсе, Аракы чишмәсе һ.б.ны атарга мөмкин. Басуда Кәрәкә күле бар. Кәрәкә дигән балык күп үрчегәнгә күл шулай аталган.

Авыл тирәсендә зур урманнар юк. Офыкта күренеп торганнары да кечерәк кенә. Ләкин шул кечерәк кенә урманнар да авыл халкын ягулык утын, жиләк-жимеш, чикләвек һ.б. белән тәэмин итеп тора. Авылның умарталыгы да шунда.

Авылларның үзара аралаша торган үз юллары бар. Авыл халкы телендә Пулат юлы, Балыкчы юлы, Илбакчы юлы, Елга юлы (Елга авылына бара торган), Лашман юллары атамалары сакланып калган.

Олы Әшнәк авылы мәктәбе гомер-гомергә зур һәм көчле мәктәпләрдән саналган. Элегрәк ул сигезьеллык булган, ә хәзер урта мәктәп. Тарих кабинетында авыл тарихына кагылышлы мәгълүматларны шактый табарга мөмкин.

Авылда элек ике мәхәллә, ике мәчет булган. Ил өстеннән узган динсезлек шаукымы авылны әйләнеп үтмәгән. Ямanaты чыккан елларда мәчетләр ябылган, манаралары киселгән. Мәчетнең берсеннән мәктәп интернаты төзегәннәр.

1994 елда авыл халкы өчен онытылмаслык вакыйга—мәчет ачу тантанасы була. Авылга иман, дин кире кайта.

Авыл өчен изге урыннарның берсе—зират. Аны чиста, төзек итеп тоту—авыл халкының изге бурычы, намус эше. Авылның хәзерге вакытта инде мәрхүм мулласы Галимжан абый зират йортын, мәрхүмнәрне жирли торган кирәкле әсбапларны, жиһазларны тәртипкә салган, булмаганын булдырган. Ел саен язның бер көнендә авыл халкы зиратны чистарта, чүп-чардан арындыра, жимерелгән киртә-чардуганнарны яңартып буйый.

Авылда олы кешеләр күп. Арада ялгыз яшәүчеләр дә бар, ләкин берсе дә картлар йортына бирелмәгән. Аларга колхоз идарәсе дә, жирле үзидарә советы да ярдәм итеп тора. Укучы балалар да булыша.

***

Кече Әшнәк авылы Олы Әшнәктән 3 чакрым ераклыкта.

Авылда язучы Әхәт Гаффар, журналистлар Рәкыйп һәм Ринат Гаффарлар туып-үскәннәр.

Кече Әшнәк авылы тип-тигез рәт булып салынган 4 урамнан тора. Бер урам таулы җиргә урнашкан. Анысы Тау башы дип атала.

Авылны икегә бүлеп Әшнәк суы ага. Артык зур булмаса да, елга матур, яр буйларында агачлар, куак һәм әрәмәләр үсә. Малайларга кармак белән тотар өчен балык та җитәрлек.

Авылда өч зур чишмә бар. Иң зур чишмә Үзәк урамда, су буенда. Аның исеме дә Олы чишмә. Олы чишмә—тау чишмәсе, аның суы үзенә юлны ташлар арасыннан яра. Чишмәгә улак куелган, суы бик мул. Өстенә бура буралган, ул матурлап бизәлгән. Янында тагын кечерәк чишмәләр челтерәп ага. Аларны да авыл халкы кадерләп тора, һәрберсенә улаклар куелган.

Чишмәнең икенчесе Түбән очта. Анысы гади чишмә генә түгел, аны Изгеләр чишмәсе дип йөртәләр. Бу чишмә элек хәзерге урында булмаган, берничә тапкыр урынын алмаштырган. Борын-борыннан Түбән оч әбиләре чишмә янына чүмеч, комган куялар. Бу традиция, гадәт шулай дәвам итә. Изгеләр чишмәсенең суы җир астыннан ургып чыга, ул салкын һәм каты су.

Чишмәнең өченчесе Югары очта. Аны ун еллар элек авылның Фәсхетдин исемле кешесе казыган. Хәзер чишмә аның исеме белән йөртелә.

Авылда өч күл бар. Берсе Кәрәкә күле исемен йөртә. Ул алма бакчасына якын гына урында, бик матур, аны камышлар, су үләннәре чорнап алган. Күл буендагы камышлар арасына җәй көне кыр үрдәкләре, торналар оялый һәм шунда бала чыгаралар. Кәрәкә күлендә балыклар, бигрәк тә кәрәкә балыгы күп.

Икенче күл, гаҗәпкә каршы, тау башында, урман кырыенда. Бу күл дә бик ямьле. Анда ел саен бер пар кыр үрдәге оя кора.

Өченче күл авыл кырыенда гына, Түбән очта булган. Ләкин аның хәзер инде суы кипкән.

Авылның ике ягында урман. Аның берсе Авыл урманы дип йөртелә. Бу урманда җиләк, гөмбәләр бик күп була. Үрнәк урманында чикләвек үсә. Авыл халкы монда чикләвеккә йөри. Үрнәк урманы эчендә матур алан бар. Аны халык Чүннек дип атый.

Кече Әшнәк авылы тирәсендә коры елгалар күп. Иң зурысының берсе—Озын елга. Ул авыл урамын урталайга бүлә. Үзе бик тирән һәм озын (бер чакрымга кадәр). Түбән очта Козгын елгасы бар. Аның кырыенда үләксә базы казылган. Бирегә козгыннар җыелганга күрә, бәлки, елга шулай аталгандыр.

Олы Әшнәк белән Кече Әшнәк арасында Шайтан елгасы бар. Бу елга, имеш, җенле икән. Әгәр дә шушы ике авыл арасындагы юлдан төнге уникеләр тирәсендә үтсән, ак атка атланган кешеләр чыгып, сине утыртып алып китәләр икән, дип сөйлиләр.

Ел саен, сабан туйларына бер атна кала, авыл халкы Зират ашы яисә Изгеләр ашы уздыра. Бу бәйрәм болай башлана. Җомга көнне иртүк, кем нәрсә булдыра ала, зират кырыендагы аланлыкка ашау әйберләре алып килә. Күп кешеләр корбан чала. Ипи, бәрәңге, күкәй h.б. әйберләр китерәләр. Авылның берничә хатын-кызы бу әйберләрдән шунда берничә зур казанда аш пешерә. Җомга вакыты җиткәч, бабайлар җомга намазы укый. Олылар зираттагы туганнары каберләре янына барып дога кыла. Соныннан бөтен авыл халкы бергә табынлашып утырып кырда пешкән ашны ашый. Уныш теләп балаларга печенье, конфет h.б. тәм-том өләшәләр, яңгыр теләп су сибешәләр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Фирдәвес Хуҗин

# КҮКЛӘР ШАҺИТ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## «Батырлык өчен» медале

Егерме алтынчы июнь көнне, төшке аштан соң дивизия күләмендә сафларга тезелергә боерык булды. Дивизиянең барлык очучылар составы штаб каршындагы мәйданга тезелеп басты. Таралган чыш-пыштан сугышчан йөкләмәләрдә аеруча батырлыклар күрсәткән экипажларны орденнар белән бүләкләү булачагы турында ишеткән идек. Хәбәр дөрес булып чыкты. Полковник Лебедев дивизия сугышчылары белән исәнләшеп:

—Исәнмесез, бөркетләр!—дип, киң яланга оран салды.

—Сәламәтлек телибез, иптәш полковник!—сәламләү җавабы йөзләгән күкрәкләрдән ургылып тирә-юньне дер селкетте. Дивизия командирының дулкынлануын кулындагы исемлек язылган кәгазьнең чак кына калтыравы күрсәтә. Аңа якын торганлыктан мин моны ачык күрәм. Күкрәгенең ике ягын да күп сандагы орден-медальләр бизәгән ир уртасы полковник тамагын кырып алганнан соң исемлеккә күз төшереп беренче фамилияне кычкырды. Фамилиясе яңгыраган очучы сафтан чыгып, пичәтле адымнар белән командир каршына килеп басты. Кулын чигәсенә якынайтып, честь биргәннән соң, сул кулы белән орденны алды һәм:

—Советлар Союзына хезмәт итәм!—дип, баскан урынында йөз сиксән градуска борылып, кабат сафтагы урынына кереп басты.

Ниһаять, дивизия күләмендәге бүләкләүгә кагылышлы боерыклар укылып бетте. Һәр полкка үз штабы урнашкан якка атларга әмер бирелде. Безнең полкның штаб башлыгы подполковник Иванченко:—«Үрә кат!» «Уңга борыл! Атлап кит!»—кебек әмерләр белән полк сугышчыларын артыннан ияртте. Бүләкләүләр полкларда да үткәреләсе икән, анысы, кагыйдә буларак, медальләр белән. Штаб каршындагы кызыл постау җәелгән өстәл янында полк командиры подполковник Ударцев инде көтеп тора иде. Арттарак эленгән полк байрагы тантанага тагын да житдирәк төс өсти. Ударцев белән тигезләшкәч, штаб башлыгы туктарга боерды. Сулга борылып үрә катканнан соң «Вольно!» әмере яңгырады. Подполковник «Батырлык өчен» медаленә лаек булучылар фамилиясен атап кычкыра, ә мин: «кырык өченче елда мин дә бу медальне алган идем бит», дип уйланып басып торам. Шулчак: «Күпсанлы хәрби йөкләмәләрне уңышлы үтәүгә керткән өлеше, инициативасы һәм кыюлыгы өчен Хак Хәлилович Хәлиловны «Батырлык өчен» медале белән бүләкләргә!»—дигән тавыш ишеттем. Юк, бу

*Ахыры. Башы 8 санда*

минем хыялым җимеше генәдер, колагыма ялгыш ишетелгәндер. Фамилияне полк командиры янә кабатлады. Янәшәмдә сафта торучы: «Бар инде!»—дип җиңемнән тартты. Димәк, дөрес! Димәк, фашизмны җиңүгә керткән тыйнак өлешемне полк командованиесе югары бәяләгән. Дулкынланудан башыма кан йөгерде. Каушап-кабаланып сафтан алга чыктым, шулай да үземне тиз кулга алдым, устав таләп иткәнчә кырт борылып пичәтле адымнар белән полк командирына таба атлап киттем. Подполковник Ударцев аталарча киң елмаеп, килеп җиткәнне көтә, бер кулына медальне тоткан, икенчесен күрешергә миңа суза. Яхшы кеше ул безнең командир, әнә ич, әсирлектә булуыбызга карап тормаганнар, штаб башлыгы белән бергәләп бүләкләнүчеләр исемлегенә керткәннәр. Рәхмәт инде. Тамагыма төер утырды. Хыянәтче күз яше керфегемә эленергә җыена. Булмый гына торсын әле, Түбән Барыш малае—Хак Хәлил улы диләр мине! Безнең нәселдә ирләр еламый, безнең нәселдә авырлык килгәндә дә ирләр елмая гына. Ничек итеп Ударцев кулыннан медальне алуымны һәм әйтелә торган сүзләрне кабатлаганнан соң кабат сафка килеп басуымны төштә кебек кенә хәтерлим.

Исемлек укылып, бүләкләр тапшырылып беткәч, полк командиры кыр сумкасыннан янә ниндидер кәгазь чыгарды. Бусы ни булыр тагын дигән сүзсез сорау белән шул якка текәлдек.

—Игътибар!—диде подполковник тавышына тантаналы төсмер бирел.—Кырык бишенче елның егерме алтынчы июненнән уникенче номерлы һава дивизиясе Германиядәге оккупацион зонадан алынып, Советлар Союзының Чита шәһәренә күчерелә. Боерыкны укылган көннән гамәлгә кергән дип санарга! Уникенче һава армиясе командующие генерал-лейтенант...—Ударцев командующийның фамилиясен атады.

—Ура!—дип кычкырдык барыбыз да. Чөнки күп айлар буена чит җирләрдә йөреп зарыккан идек. Туган ил туфрагы, туган йорт булмаса да, барыбер җанга якын шул.

Ике көн ерак юлга хәзерләнүләр белән үтте. Инде чемоданнар тутырылган, тимер юл белән барачак полк җиһазлары эшелонга төялгән. Һава ачылу белән эскадрильялар да күккә күтәрелергә әзер.

Егерме сигезенче июнь, безнең өчен атап диярсең, болытларын таратып, юмарт кояш нурларын сипте. Күңелләр күтәренке. Һәр экипаж үз самолеты тирәсендә кайнаша. Бүген очабыз! Адәм баласына үзен бәхетле тояр өчен күп кирәкмени. Янәшәдә яхшы кешеләр, дуслары булса, атлаган саен намусына үрелмәсәләр, шул җиткән. Мин дә акрынлап элекке кысага кереп барам, хәрби хезмәтем көйләнеп килә. Хәер, бөтенесе алай көйле булмаган икән шул. Мин бу турыда полк очып китәргә өч сәгать кала белдем. Шул өч сәгать язмышымны кинәт бөтенләй икенче якка борды да куйды.

## Берлин—Мәскәү

Кояш җылысында рәхәт изрәп, татлы уйларга чумып утырганда, штабтан чыккан берәүнең нидер кычкырып аэродромга ашыкканлыгы күренде. Бу—полк командиры ординарецы иде. Әле аның сүзләре аермачык ишетелми. Тик бу кабалануның яхшыга түгеллеген сиздереп, йөрәк чәнчешеп куйды. Бер дә бүтән булмас, безнең үткәнгә бәйләнеше бардыр! Шулай булып чыкты да. Бондаренко, Мителкин фамилияләреннән соң ординарец минем фамилияне атады, полк штабына чакыруларын әйтте. Матур башланган иртәнең бөтен матурлыгы бетте, кәеф кырылып, күңел сүрәнләнеп калды. Штабта безне подполковниклар Ударцев һәм Иванченко җитди йөз белән каршылады. Күренеп тора: өлкән офицерларның да кәефләре төшкән. Армия штабының махсус бүлегенә чакыруларын, әлегә Читага очмыйча, Берлиннан егерме биш чакрым көнчыгышта

урнашкан штабка барырга кирәк булачагын әйттеләр. Юлда тоткарлыксыз хәрәкәтләнер өчен тиешле кәгазьләр тутырылган, ике атналык азык запасы һәм автомашина бирелгән.

—Ну, егетләр, кайгырмагыз ул кадәрле. Күрәсенне күрмичә, гүргә кереп булмый ди. Анда да тишек башлар утырмый торгандыр,—подполковник ияге белән Берлин ягына ымлады,—тикшерерләр, әсирлеккә үзегез теләп төшмәгәнне ачыклаганнан соң, кабат хезмәт урыныгызга кайтарырлар. Яхшыга өметләник, ә хәзер барыгыз, юлга кузгалыгыз.

Командирлар өчебезне дә берәм-берәм кысып кочаклап, штаб бинасыннан машинага кадәр озата чыктылар. Аларның аталарча кайгыртуын тою китек күңелләргә нindидер юаныч бирде. Машина безнең өчен генә түгел, дивизиянең башка полкындагы элекке әсирләр өчен дә бирелгән иде. Юл унаенда алар да утырды. Тоткынлыктан котылгач, машинада полкны эзләп Польша ягына чапкан асфальт юлдан кабат Көнбатышка жилдерәбез. «Алда тагын ниләр күрәсе бар икән?» дигән уй баш миенә кереп оялаган да, агач корты кебек эчтән кимерә. Әнә инде шактый артта калган аэродромнан эскадрильялар бер-бер артлы һавага күтәрелә башлады. Алар тиешле биеклеккә күтәрелгәннән соң канатларын чайкап аэродром өстеннән бер әйләнеп узалар да, Көнчыгышка, озын-озак һава сәфәренә кузгалалар. Дистә меңләп чакрым ераклыктагы яна хезмәт урынына барып житкәнче юлда бензобакларына ягулык тутыру һәм ял итеп алу өчен алар әллә ничә аэродромга төшәрләр әле, аннары янадан очарлар. Тик болар һәммәсе бездән башка гына башкарылыр, полкташларның күбесе араларында өч очучының юклыгын сизмәс тә. Алар гадәттәгечә ашый-эчәр, шатланыр-көләр, вакыты белән кайгырыр да, тик безнең турыда гына уйламас. Нишлисең, кеше психологиясе шулай яратылган инде, беркемгә үпкәләп булмый. Башкалар ничектер, һәрхәлдә, мин сезгә үпкә сакламыйм, туганнар. Күрешә алмасак, мин сезгә риза-бәхил.

Көндезге сәгать өчкә армия штабына барып життек. Иванченко белән Бондаренко штабка кереп китте. Без урамда калдык. Штаб бинасы каршында төрле типтагы самолетлар тезелеп тора. Бусы гаҗәбрәк иде. Очкычларның янына ук барып карарга керештек. Һәрберсенең алдында язулы такта урнаштырылган. Анда кайсы очкычның ничә хәрби йөкләмәгә очуы, ничә фашист самолетын бәреп төшерүе язылган. Сталинградтан һәм хәтта Мәскәү яныннан Берлинга кадәр килеп житкән машиналар бар, бу инде легендага тиң. Бер читтә зенит орудиеләре урын алган. Аларга да ничә дошман самолетын бәреп төшерүләрен язганнар, расчет командирының исем-фамилиясе күрсәтелгән. Хәйран калып, тамаша кылып йөргәндә Иванченко белән Бондаренконың чыкканнары күренде. Штабтан Уфа шәһәре янәшәсендәге Алкино станциясенә кайтырга кирәклекне әйтеп чыгарганнар. Алкино фашист тоткынлыгында булганнар өчен фильтрацион лагерь урнашкан һәм элекке әсирләрне жиз иләктән үткәрәләр һәм кайсын кая жибәрәләр, имеш. Кем ГУЛАГ лагерьларына озатыла, кемдер төрмәгә ябыла, ә кемнәрдер ирекка чыгарылырга мөмкин. Өч категориягә бүленеп хөкемгә тартылучыларның кайсына эләгәсең бит, анысы гаебеңә карап. Иванченко үзләренең полкындагы, ә Бондаренко безнең полктагыларга командировка кәгазьләрен аерым тутырткannар иде.

Берлин урамында очраган хәрбиләрдән Мәскәүгә китүче поезд вокзалының кайда урнашканын сорашып белдек. Тик вокзалга баргач, комендант безгә Мәскәү поездының иртәгә көндез генә буласын әйтте. Вокзал каршындагы кунакханәдә төн кунарга туры килде. Иртәнге чәйдән соң су буе чиратка билет алырга бастык. Чират акрынлык белән кыймылдый, болай дәвам иткәндә монда тагын бер-ике төн кунарга туры килмәгәе. Борчулы уйлар белән чиратлап кизүлек иткәндә яныбызга Бондаренко белән Кожинцов килеп басты, үзләренең авызлары ерык. Иванченко һәм мин аптырап аларга карыйбыз, шатланырлык

нәрсә күренми шикелле.

—Килегез әле, кил,—дип кул изи тегеләр.—Ташлагыз чиратыгызны!

Һаман берни анламыйча, теләр-теләмәс чираттан чыктык. Чөнки бер чыксаң, башка кертмәячәкләрен белә идек.

—Әйдәгез, кунакханәгә кайтыйк. Билет мәсьәләсе хәл ителде! Кайтып, бүлмәбезгә керсәк, өстәл артында очучылар курткасы кигән таныш түгел бер капитан утыра.

—Мисляк,—дип таныштырды үзе белән. Иванченколар полкында хезмәт иткән Советлар Союзы Герое капитан Мисляк Иванченконың якын танышы булып чыкты. Отпуск ялына кайтып барышы икән, эшнең нидә икәнлеген белгәч, безнең барыбызга да чиратсыз гына билетлар алып биргән. Менә бит ул ничек: язмыш бер яктан адәм баласын төрле авырлыклар биреп сынаса, икенче яктан һич уйламаганда җинеллек тә китерә. Шулай итеп зур проблемадан—билет юнәтү матавыгыннан ансат котылдык. Ул арада кесәләренә икешәр шешә аракы тыккан Метелкин белән Кожинцов кайтып керде. Стаканнарга эчемлекләр салынды, шау-гөр килеп кечкенә мәҗлес ясап алдык.

Поезд Берлин вокзалыннан төнге сәгать унбердә кузгалды. Вагон тәрәзәсеннән сугыш афәтеннән зыян күргән урманнар, җимерелгән шәһәр, авыллар күзгә чалынып кала. Эшелон кечкенә разъездларда тигезлеген акрынайтып, бары олырак станцияләрдә генә берничә минутка туктала. Польша чиген чыкканда документларны җентекләп тикшерделәр, аның башкаласы Варшавада ике сәгать торылды. Ниһаять, СССР чиген үттек. Минскида минем белән Бондаренко арасында Смоленскига житкәч төшеп калу турында сүз башланды. Чөнки бүген июльнең икесе генә әле, ә безнең кәгазьләрдә Алкинода унөченче июльдә булырга диелгән. Вакыт артыгы белән житәрлек һәм Бондаренко мине үзенең туган җирендә берничә көн кунак булып китәргә кыстый. Ахырда ризалаштым. Өченче июль көнне башка иптәшләр белән вакытлыча саубуллашып, Смоленск вокзалында төшеп калдык. Моннан Спас-Диминск юнәлешендә поезд белән шактый барасы икән. Ә поездлар ул якка сирәк йөри. Хәтсез генә көткәннән соң запас юлга паровоз-теплушка килеп туктаганы күренде.

—Исемем Иван булмасын, бу теплушка, мөгаен, безнең якка,—дип кычкырды Бондаренко һәм сикереп атлап паровоз машинисты янына ашыкты. Әнә инде кул изи.—Хак, бирегә кил!—дип кычкырды ул.—Әйтәм бит безнең якка дип.

Машинист рөхсәте белән депога ремонтка ашыккан теплушканың күмер төялгән өлешенә менеп кунакладык. Җил күмер тузанын бөтереп битләргә сылый, чәч, теш араларына тутыра. Анысына гына түзәр идең, салкын вак янгыр яварга кереште, ул тора-бара бозлыга әйләнде. Тундырса да, янгырның бер унай ягы бар: ташкүмер тузаны буранлаудан туктады, өсләрдәге кара тузан юылып төште.

Спас-Диминскига караңгы төшкәндә генә килеп життек. Ярый әле Сухиничка бара торган товар поезды туры килде, аның алгы тамбурына басып Сутук дигән станциягә кадәр сәяхәт кылдык. Бу вакытта инде таң атып килә иде. Сутуктан Бондаренколар авылы Филинога нибары бер чакрым. Арылган, ачыккан һәм нык тунган булсак та, якындагы елгада бит-кулларны юганнан соң авыл ягына атладык. Ныклап ашаганнан соң, чиста урын-жирдә туйганчы йокы симертү хыялы безне алга куалады. Филино әле тирән йокыда иде, Бондаренколарның капкасы да бикле. Иван шакып ачтырды. Тик аның хатыны Валентина станциядә дежурлыкта икән, өйдә Валяның сеңлесе Нина гына. Ул безгә чәйләр кайнатып, ашарга тегесен-монысын хәстәрләп биргәч, апасына хәбәр итәргә чыгып чапты. Йоклап кына киткән идек, Валентина кайтып керде. Ике елдан артык күрешмәгән ир белән хатын кулга-кул тотынышып дөньяларын онытып сөйләшергә кереште. Мин монда артык идем. Шуңа күрә кырык өченче елның көзеннән кырык дүртнең язына кадәр безнең авиаполк торган

Спасскига барып кайтырга карар кылдым.

—Кая барасың инде, ятып ял итәр иден?—диештеләр ирле-хатынлы Бондаренколар итагать өчен.

—Барам әле, күптәннән Нюраны да күрәсем килә,—дидем мин дә сер бирмичә. Күренеп тора, Бондаренколар җаваптан канәгать калды. Тиз генә җыенып Нюралар авылына юл тоттым. Бәхеткә, Нюра өйдә булып чыкты. Ул мине исән күрүенә бик шатланды.

—Кайберәүләрдән ишетеп белүемчә, сине сугышчан йөкләмә үтәгәндә, самолетыгыз янып һәлак булды дип сөйләделәр,—диде ул үз күзләренә ышанмыйча.

—Сугышта маҗара белән дә исән каласың икән аны,—дип җавапладым мин. Сөйләшеп утыра торгач кич җиткәнен дә сизмәгәнбез. Нюраныкылар кайтып йөрмәскә, үзләрендә генә кунарга кыстадылар. Юньләп ял күрмәгәнлектән, соңгы ике тәүлектә нык алҗыткан иде—ризалаштым.

Бондаренколар куркуга калганнар. Икенче көнне иртә белән Филиногa кайтып керүгә, Иван мине:

—Ну, парин, көттерәсең үзең дә, кайда йөрисең син?—дип каршылады.

—Әй, Нюраларны очраттым ла,—дигән булдым сөйләшүне шаян тонга борырга тырышып.

—Беләм мин сез очучы халкын, күктә—ялкын, җирдә—алкын!—дип шаяртты уен-көлкене күтәреп алган Валя да бармак селкеп. Ул көнне тәмле ризыклар пешереп кунак иттеләр. Иртәгәсен юлга җыендык. Валяга эшкә иде. Сеңлесе белән икәүләп Сутук станциясенә кадәр озата килделәр. Сутуктан Сухуничка бардык. Анда вагоннан перронга төшүгә, ун минут үтмәгәндер, Мәскәү поезды килеп туктады. Икенче көнне, көндезге сәгать өчләр тирәсендә Бондаренко белән мин инде башкаланың Курск вокзалында идек.

## Мәскәү—Казан—Алкино

Мәскәүдә озак тоткарланмыйча, ничек тә Казанга баручы поездга эләгергә кирәк иде. Ә анда поезд Казан вокзалыннан кузгала. Гомеремдә беренче мәртәбә метрога төштем. Менә нинди икән син, метро! Халык җир өстендә дә, аста да күп. Бөтенесе каядыр ашыга. Казан вокзалындагы кассаның кайсына гына килеп бәрелсәк тә, бөтенесендә бер җавап ишеттек: билетлар сатылып бетте. Четерекле хәлдән чыгуның нинди юлын табарга? Уйлана торгач, билетсыз гына поездга утырырга дигән карарга килдек. Кеше аз йөри торган урында, караңгырак почмакны сайлап, поезд кузгалган уңайга вагон баскычына сикереп мендек. Вагон эченә узарга ашыкмадык, чөнки монда проводниклар очрап куып төшерүләре бар. Берничә станцияне тамбурда басып үткәннән соң, вагон тулы халык арасына кереп кысылдык. «Күңелең киң булса, урын табыла», диләр бит, утырып кайтырга да мөмкинлек чыкты тагын. Юлда билет-фәлән тикшерүче булмады.

Казанга кайтып җиткәндә иртәнге сәгать жиделәр иде. Көн кояшлы, матур. Таныш урамнар, җанга якын таныш йортлар, аның юмарт нурларына коенып күзне иркәли. Аларга карап, сөенечле уйларга күмелеп Бауман урамына таба атлыйм, янәшәмнән Иван Бондаренко бара. Аның әле Казанны беренче күрүе. Шәһәрне ошаткан булса кирәк, әсәрләнүе йөзенә чыккан. Җәяүлеләрнең үз иткән урамы Бауманда, мин сугышка кадәр күп мәртәбәләр өсләренә басып үткән урам ташлары: «Исән йөреп, сау кайттыңмы, Габделхак, без сине көткән идек!»—дип эндәшәләр сыман. Мин хыялга чумып атлый торгач, банк урнашкан бинаны уза язганбыз. Кабыргама Бондаренко «шушымы?» дип төрткәнгә сискәнеп башымны күтәрдем.

—Әйе, шушы.

Банкка кереп, немец маркаларын совет акчаларына алыштырдык. Инде көн кызуланып килә. Шунда башыма бер шәп уй килде.

—Әйдә, мин сиңа Казанның күрке саналган Кабан күлен күрсәтәм, шунда бер уңайдан су да коенырбыз,—дидем Иванга. Дустым бик теләп ризалашты. Кабан күленә Бауман урамыннан күп булса җәяүләп ун минутлык юл, аны үткәч, чишенеп ташлап, күңелләр булганчы су коендык. Туганнарга, танышбелешләргә барганчы төс-кыяфәтләрне рәткә китерү өчен чәчтарашка кердек. Чемоданнарны вокзалдагы саклау камерасында калдырган идек, аларны барып алгач, трамвайга утырып, кода абыйларга киттек. Без барып кергәндә, кода абый эштә, өйдә аның җәмәгате Нәсимә апа гына иде. Аның белән озак кына сөйләшеп утырдык. Шуннан соң бергә эшләгән кайбер иптәшләрне күреп булмас микән дигән уй белән аларның яши торган урыннарына бардык. Тик алар да эштә иде. Авылдагы элекке күршебез Ганибай абыйларны күреп чыктык, Мингалимов Нуретдин агайларга сугылдык. Анда фатир ишеген Ниса апа ачты. Бер уңайдан кызлары Сәхияне дә очратып сөйләшәсе килгән иде, тик аны отпуск ялына авылга кайтып китте, диделәр. Ниса апа мине башта танымыйча торды. Аннары гына:—Габделхак наныем, син түгелме соң бу?—дип күз яшьләренә буылып, кочаклап алды.—Үзгәргәнсең, балакай, олыгаеп киткәнсең дип әйтимме?—Аннары үзе үк соравына җавап биргәндәй,—И-и, бу каһәр төшкере сугыш дигәннәре, күпме кешенең башын ашады да, күпме баланы ятим итте,—дип сөйләнде. Инде кич җиткән иде, кайтырга кирәк. Ниса апа белән саубуллашып, беренче тукталган урыныбыз—Нәсимә апаларга кайтып киттек. Ул әле йокларга ятмыйча безне көтә, хәзинәдә барын өстәлгә тезеп сый-хөрмәт әзерләгән. Сугыш һәм тормыш хәлләрен сөйләшеп, озаклап чәй эчкәннән соң йокларга яттык.

Икенче көннең иртәсендә Ульян шәһәренә баручы пароходлар турында белешергә төшеп киттек. Ульянга пароход төнге сәгать унберләдә генә буласы икән. Көн озын, тамак ягын да кайгыртырга кирәк. Ваня белән икебезгә ашханәдә туклану өчен җитәрлек итеп талоннар сатып алдык. Әле күрәсе килгән кешеләрем күп, вакытым була торып һәм Казан кадәр Казанга килеп тә Кәримәне күрмичә китсәм, мин үземне гафу итә алмаячакмын. Кәримә—Түбән Барыш кызы, безгә чыбык очы туган тиеш, аның белән башлангыч сыйныфларда бергә укыдык. Әле шушы араларда авылга кайтып килгән дип ишеттем. Димәк, авыл хәбәрләрен аннан да яхшы белүче юк. Күрәсе килүемнең тагын бер сәбәбе: мин бу кызга карата битараф та түгел, армиягә китәр алдыннан, аны күргән саен йөрәгемнең татлы сулкылдап куюын сизә идем. Тик Кәримә, сылу кыз, бик сабыр һәм тыйнак, ул хисләрен берничек тә тышка чыгармый. Шунлыктан, мин дә ничектер тыелып кала идем. Ә менә аны күрергә хәзер җай чыкты. Бондаренконы ял итәргә калдырып, әүвәл бергә эшләгән иптәшләр янына сугылдым. Алар белән озаклап гәпләшкәннән соң Кәримә яши торган Совнарком урамына мендем. Кәримәне өйдә туры китерә алмадым, фатир хуҗабикәсе:

—Әле яңарак эшкә җыенып чыгып китте, урамда очрамадымени?—дип каршылады. Хуҗабикәнең кызы: «Хәзер алып кайтам мин аны»,—дип чыгып йөгерсә дә, куып җитә алмаган. Ахырда, аның белән бергә эшләүче бер кыз артыннан: «Абыең килде, өйдә сине көтеп утыра»,—дип әйтергә кушып җибәргән. Фатир хуҗасы Разия апа белән хәтсез озак сөйләшеп утырсам да, Кәримә кайтмады. Мин күңелсез генә саубуллашып кайтырга кузгалдым. Краснококшайск урамыннан төшеп барганда «Габделхак!» дип эндәшүгә артыма борылсам, Кәримә басып тора. Зифа буйлы, сылу йөзле кызны күргәч, йөрәгем дөпелдәп тибәргә кереште, кинәт кенә авызым кипте. Минем инде Кәримәне күрмәвемә биш елдан арткан иде. Ул вакыт эчендә кыз тагын да гүзәлләнгән, тулып пешкән алма кебек җитешкән иде. Янына барып, бер кулым белән аның кулын, икенчесе белән нечкә биленнән эләктереп кысуымны сизми дә

калдым. Кәримә минем әрсезлегемне сизмәгәнгә сабышты, кыргый үҗәтлек белән ычкынырга талпынмады..

—Әйдә, Габделхак, урамда болай басып тору килешмәс, Разия апаларга кайтыйк,—диде ул тыенкы гына. Мин берсүзсез килешеп ана иярдем. Үткәннәрне, бүгенге хәлләрне һәм авыл яналыклары турында сөйләшеп утыра торгач, кичке алтыны житкергәнбез. Пристаньга төшәсе барлыкны уйлап китәргә ашыктым. Бондаренко мине көтеп зарыккан, сонга калмасак ярый инде дип кайгыра ук башлаган.

—Ну, Хак, йөреп тә күрсәтәсен үзен,—дип жинелчә шелтәләп тә алды. Тиз генә чәйләп алганнан сон пристаньга киттек. Юлда кайчагында төрле хәлләр килеп чыга, шуна, пароход китәргә бер-ике сәгать алданрак төшүен хәерлерәк иде.

Пристаньда билетка чират торучы авылдашым Сатира апаны күрдем, Ул сенлесе Илһамияне озатырга төшкән. Сатира апа белән әнгәмәбез дәвамлы булды, сәгать унберенчеләр киткәч кенә трамвайга утырып кайтып китте. Унбердә буласы пароход иртәнге дүртләрдә килде. Ваня Бондаренко белән анын килгәнен көтеп пристаньнын көтү залында тик канғырап утырдык.

Менә инде мин әтигә ияреп Казанга беренче барган һәм аннан сон Татарстан башкаласында яшәгән чагында, әллә ничә мәртәбәләр Тәмтегә кайтып-китеп йөргән су юлы буйлап чираттагы тапкыр кайтып киләм. Тик бу юлы өйгә түгел шул, аннан ераккарак—тикшерү-чистарту лагерена. Таныш яр буйлары, андагы урманнар, күз күреме житкән кинлектә болыннар, кечкенә шәһәр һәм авыллар күренеп кала. Аларны танысам да, алар мине таныйлар да, танымыйлар да бугай. Пароход тирәли бер зур акчарлак очып әйләнә. Ул мина «кыйк» дип түгел, «Габделхак!» дип эндәшәдер кебек тоела. Мөгаен, «Габделхак, берничә еллар элек син бу пароходта еш йөри иден, ул чагында йөзен үсмерләрнеке кебек бик яшь, шома иде. Тирә-юньне янгыратып шаркылдап көлә, башкалар белән шаяртып сөйләшә иден, күзләрен дә очкынланып тора иде. Ә аларны хәзер мон, сагыш баскан, ике ирен читенә сизелер-сизелмәс булып буразналар сызылган. Ни булды сина, Габделхак?!» диюедер. Әллә бу мина гына шулай тоеламы? Акчарлакнын башка ишләре дә очып килде, алар «кыйк» диеп чыелдашып үзара ни турындадыр хәбәрләшеп алдылар да, су өстеннән балык күзләп, читкә очтылар. Тәмтедә төшеп калып, Түбән Барышка бик кереп чыгар идек, унөченче июльдә безгә Алкинода булырга кирәк, ә бүген айнын унберенче көне. Вакыт тар, ашыкмыйча булмый.

Пароход Ульяновскига төгәл унсигез сәгать барды. Пристаньнан поезд вокзалына жәяүләп кенә киттек. Әле ярый житештек. Уфа ягына баручы поезд янарак килеп туктаган. Тик гадәттәгечә, билетлар сатылып беткән. Инде безнен бу яктан тәжрибә житәрлек иде, бу юлы да «куяннар» булып, билетсыз барырга булдык. Алкино Уфадан егерме биш чакрым бередәрәк икән. Икенче көнне иртәнге тугызда анын вокзалында төшеп калдык. Янәшәдә Дим елгасы ага, анын суына чумып чыкмыйча түзеп була димени—озаклап су коендык.

Командировка кәгазьләрендә күрсәтелгән көнгә без тиешле урынга килеп життек. Юлда ук: «Сез бара торган жир—уникенче номерлы укчы дивизия урнашкан урын» дип анлатканнар иде. Сорашып, анын кайдалыгын белдек. Дивизия штабы урман каплаган калкулыкта урнашкан. Анда Бондаренконын да, минем дә командировкаларны һәм «шәхси эш»ләрне алып калдылар, кулларыбызга егерме сигезенче укчы полкка билгеләнүебез турында белешмә тоттырдылар. Бер кызылармияче озата барды. Полк торган урын концлагерьдагы кебек чәнечкеле тимерчыбыклар белән әйләндереп алынган, бу инде мондагы тәртипләрнен гадәти частьлардагы режимнан үзгә булуын күрсәтеп тора. «Анлашыла»,—дип уйладым үзалдыма, күнелсезләнеп. Хәер, без инде мона психологик яктан алдан ук әзер идек, кая жибәргәннәрен белеп килдек. Полк шта-

бында дүртенче ротага билгеләделәр. Рота урнашкан землянканы күрсәттеләр. Самолетта сугышчан йөкләмәләргә очкан, якты казармаларда яки аэродром янәшәсендәге торак пункттагы йортларда яшәгән вакытларны сагынырсың. Ни дисәң дә, землянка—землянка инде, исеме үк «җиргә казып кергән» дигәнне аңлата. Землянка киң һәм озын, урын-җир хәрбиләрнекечә булса да, аның эчен электр лампочкалары түгел, керәчин салынган лампалар яктырта. Кеше өстенә кеше, суларга һава җитми. Анысына да түзәр идең, урынга ятуга канэчкеч кандалалар талый башлый. Йокын—йокы түгел. Монда дәрәҗәләргә карау да юк, офицерлар, сержантлар һәм рядовойлар барысы бер рангка куелган. Ярый әле дүртенче ротадагы бу газаплар озакка бармады, «шәхси эш»ләребезне карагач, безне тимерчыбыклы зонадан чыгарылуга лаек дип тапканнар. Инде унсигезенче ротага билгеләнәсез, дип, үлчәмнәре ягыннан баштагысына охшаш, әмма кандаласыз землянкага күчерделәр.

Алкинога килеп, ун көннәр чамасы үткәч, Пилаудагы әсирлектә гаупвахтаның янәшә камерасында тотылган полковник Аверьяновны очраттык. Ничек әсирлектән котылгандыр, анысы Бондаренко белән минем өчен сер булып калды, тик ул безнең «эш»ләрне карауны тизләтергә булышачагын вәгъдә итеп шатландырды. Күңелдә өмет уянды, һәркөнне үзебезнең элек хезмәт иткән полкка җибәрүне көтәбез. Тик көннәр үтә тора, үзгәреш кенә юк. Ул да түгел, унсигезенче ротаны дивизия карамагына күчереп, урман эшләренә җибәрделәр. Монда йорт түбәләрен ябар өчен дранкалар ясыйбыз. Ашау яклары яхшырды анысы. Безнең артельдә егерме биш кеше, шуларга өч пешекче хезмәт күрсәтә. Ләкин күңел тыныч булмагач, ашаганың—аш, эчкәнең—су түгел, дип белеп әйткәннәр.

Унсигезенче ротадан да яше ягыннан өлкәнрәк булып, «гаебе» буенча беренче категориягә эләгүчеләрне демобилизацияләп, өйләренә кайтара башладылар. Икенче категориягә туры килгәннәр алты айга, бер һәм хәтта икешәр елга мәҗбүри эшкә озатылды. Әсирлеккә сугышның башы белән яисә кырык икенче елда төшкәннәрнең «гаебе» аеруча зур дип табылып, андыйларны җир читендәге Колымага, төрле срокка алтын приискларына озаттылар. Инде безнең яшьтәге беренче категориядәгеләргә чират җитте. Мәскәүдән тулы белешмә килгәннәргә элек хезмәт иткән полкларына, ә кайберәүләргә хәрби округ штабына барырга куштылар. Башкаладан, ниһаять, минем исемгә ясалган запроска да җавап кайтты. Бу—мең тугыз йөз кырык бишенче елның унынчы ноябрь көне иде. Командировка кәгазендә: «Читада урнашкан өч йөз егерме алтынчы авиадивизиянең унсигезенче сигез йөз кырыгынчы авиаполкына унсигезенче декабрьгә барып айдан артык җитәргә!» дип язылган. Аңа кадәр әле айдан артык вакыт бар. Ә Алкино Татарстан күршесендә генә, нигә әле туган якны күреп китмәскә ди. Һәм мин литер кәгазенә «Казан аша» дигән сүзне өстәттем. Тик туры Казанга кайтып булмады, шунлыктан, башта Ульяновскига, ә аннан шулай ук тимер юл белән Татарстанның Җиде Кизләү станциясенә кадәр поездда кайттым. Бу вакытта көннәр суыткан, җир өстенә юка кар япмасы яткан, төньяктан искән җил битне чеметтерә иде.

Поездда н төшкәч ялгызыма гына тәпиләргә туры килмәде, Шунгаты авылыннан бер егет отпуск ялына кайтып килә икән, аның белән сөйләшә-сөйләшә Капрый авылына кадәр араны кыскарттык. Ул анда туганнарына кереп калды, мин Кече Күккүз балалары мәктәпкә йөри торган сукмактан Зөя бозы өсләтеп, Зур Күккүзгә таба юл тоттым. Шулай да Зур Күккүзгә кермәдем, Кала Тавы аслап юлны кыскарттым. Юлда Настя очрады. Аның Зур Күккүзгә баруы икән. Әтисе Антон дәдәйнең вафатына кырык көн булган, христиан гадәте буенча шуны билгеләп үтәр өчен аракы алып кайтырга баруы. Елга өсләтеп кенә, җизниләрнең арткы капкалары аша керергә ниятләдем. Апаларда өс-баш киемнәремне беркадәр рәткә китереп, кырынып-чистарынып аласым килде.

Яр өстенә күтәрелүгә апаларның күршесе Шәфыйкъ карт мине жизнигә охшатып, сөенеч алырга ашыккан. Башына да кимәгән, яланөс, аягына галуш кына эләктергән апам каршыма йөгереп чыкты. Сенлем Рәйсә аларда булган, аның артыннан ул күренде. Апа—мескен, кызганып та куйдым үзен, нәүмизләнүе йөзенә чыккан: күзләреннән яшьләре ага, үзе елмаерга итенә. Күрәсен, ул, әллә кайчан хәбәрсез югалган абыйны «исән» дип кереп әйткәч, шатлыгыннан дөньясын онытып, шул секундта аны күрергә омтылган. Тик ул—юк! Аның урынында—мин! Мине күрү дә шатлык әлбәттә. Апа хәзер кайгысын да, шатлыгын да бергә кичерә, йөрәге генә түзсен.

Мин апаларның өйләренә кереп тиз-тиз кырынырга керештем. Рәйсә, өстемнән салган курткамны эләктереп, өйгә энидән сөенче алырга чыгып чапкан. Өне-тыны бетеп янадан килеп керде, шатлыгыннан бер урында басып тора алмый: әле кулларын чәбәкләп сикергәли, әле мине муенымнан килеп кочаклый. Аңа ияреп туган нигезнең капка төбенә житкәндә әни карчык чыкты.

—Улым, алты айдан артык кайда булдың син, хатын да, хәбәрең дә юк?—дип, иннәремә килеп сарылды. Хатын-кызның күнеле йомшак инде аның, әниләрнеке бигрәк тә—әни тавышсыз гына елый иде. Өйгә кереп чишенергә дә өлгермәдек, олы абыйның хатыны Бибижиһан жинги улы Газизулла белән кызлары Нажия һәм Кафияләрне ияртеп килеп житте. Күрше-күлән, әллә каян гына ишетеп Лотфи, Әхәт, Ибрай дуслар хәл белергә жыелды. Йорт эче күнелле шау-шу белән тулды. Кеше керә-чыга, һәрберсе белән сөйләшеп утыра торгач, кич житте. Әнинең самавыры әллә ничә тапкыр суынып, әллә ничә тапкыр янартылырга өлгерде. Йокларга төн уртасы житкәндә генә яттык.

## Аулак өй

Иртәгесен мин уянганчы ук Лотфи белән Ибрай килеп житте.

—Фронтовик, бу вакытта йоклап яталар димени?—дип шау-гәр килделәр дусларым. Фронттагыча тиз генә сикереп торып, әнинең:

—Бәбкәм, үзем жыештырырмын, хатын-кыз эше бит ул,—диюенә карамыйча, тиз генә урынны жыеп куйдым. Әнинең самавыры күнелле чажылдап күптән минем торганны көтә, өй эченә тәмле коймак исләре таралган иде. Өч ир-егет өстәл артына утырып, кайнар коймак белән, булары чыгып торган чынаякларга өрә-өрә озаклап чәй эчтек. Армия хезмәтенә алынганчы кигән киемнәрем бераз кысанрак булсалар да, башкасы булмагач аларны кидем. Хәрби форма тәмам туйдырган иде. Бергәләп кәнсәләр ягына юнәлдек. Урамда очраучылар, танып, исәнләшәләр. Тегесен-монысын сораштырырга керешәләр. Уллары сугышта һәлак булганнарның күнелләре нечкәреп, күзләреннән яшьләре тәгәри. Равил абый очрады. Мин инде кырык дүртенче елны отпускка кайткач, аның белән кич утырып төрле темаларга иркенләп сөйләшүебез турында язган идем. Равил абый бу юлы да ачылып елмаеп:

—Кайттыңмы, солдат, бөтенләйгәме, әллә отпуск ялына гынамы?—дип сорады.

—Бөтенләйгә түгел әле, Равил абый, Читага китеп барышлый, авылдашларның хәлен белеп китим дидем.

—Шәп булган, Габделхак энекәш, авылдашларыңны, туганнарыңны һәм әниеңне онытырга ярамый. Туган туфрак дигән нәрсә дә бар бит әле, чит жирләрдә йөргәндә ул гел искә төшеп, үзенә тарта, төшләргә кереп йөдәтә. Аннары сиңа күптәннән әйтәсем килеп йөри идем: маладис, туганай, авылыбыздан беренче очучы булып китеп, аның данын күтәрден. Түбән Барышта гына түгел, әлегә районда беренчесе синдер дип уйлыйм, зәңгәр киңлекләрне иңләүче лачын. Киләчәктә дә маркаңны төшерә күрмә,—дип, уртанчы абыемның яшьтәше безнең белән саубуллашты. «И-их, Равил абый, син күп нәрсәне белеп бетермисең

шул,—дип уйладым эчтән өзгәләнеп.—Әйтергә ярамаган, безнең теләк-ихтыярдан гына тормаган күп нәрсәләр бар шул бу дөньяда!»

Авылның кайбер өлкәнрәк агайлары мине танып та бетермиләр, уртанчы абыйның исемен әйтеп: «Гариф»,—дип исәнләшәләр. «Гариф түгел әле бу—Габделхак»,—дип төзәтергә туры килә. Көнозын урамда йөреп, кичкырын өйгә ачыгып кайттым. Өйдә мине әнинең токмачлы ашы көтә иде. Дәүләтша Бәнатларында кичке аулак өй икәнен Лотфидан ишетеп белгән идем. Ибрай белән Лотфи кабат мине алмага керделәр һәм без аулак өйдә күңел ачарга киттек. Гармунчылары булмаса да, аулак өй күңелле үтте.

Икенче көнне, унҗиденче ноябрьдә, Лотфиның безгә килүе булгандырмы, аның белән кәнсәләргә киттек. Анда Балтайга, Тәскиягә шалтыратырга керештем. Ләкин аны мәктәптә диделәр. Лотфи үзләренә дәште. «Әти белән әнинең сине күрәселәре килә»,—диде ул. Өлкәннәр бик җылы каршы алды. Мин Лотфи белән кечкенәдән уйнап үскәнлек белән, алар мине үз балаларыдай якын күрәләр иде. Кара Вафаларның суганнарына кереп тотылганны, Дәвеш авылында пионер лагеренда булган чакларны, «Осенний» совхозына эшкә йөрүләрне искә алып утыра торгач, төшке аш вакыты җиткән. Кыстый-кыстый ашарга утырттылар. Төштән соң кабат кәнсәләргә төштек. Анда авыл советы секретаре Талия үзе генә утыра иде. Без анардан кәгазь, каләм сорап алдык та, бүгенге аулак өйгә чакыру билетлары яза башладык. Мин әнидән, аның кодагыйларга ашка җыенуын ишеткән идем. Ул анда төн кунарга да калмакчы. Моннан да җайлы форсатның булуы мөмкин түгел. Шуннан файдаланып, Лотфи белән аулак өйне бездә оештырырга ниятләдек. Чакыру билетларын болайрак дип яздык:

*«Татарстан АССРның Апас районы Түбән Барыш авылының Кавказ урамы утыз беренче йортында кичә үткәрелә. Мостафина Гөлсылу, сезнең кичәгә килүегезне сорап:*

*Закиров Лотфи,*
*Хәлилов Габделхак.*
*17.11.1945 ел.»*

Чакыру билетларын яза башлаганчы авылдагы кызларның исәбен алдык. Алар барлыгы кырык дүрт икән. Тик шуларның төгәл яртысы, егерме икесе генә аулак өйләргә йөри. Калганнары өйдә утыра, имеш. Гөлсылудан соң Мәрзия, Фатыйма, Бибиҗамал, Зәйнәп һәм башкалар исеменә чакыру кәгазьләре яздык. Кәнсәләрдән безгә кайтып, Рәйсә сеңелкәшне һәм апаның кызы Нәҗияне билетларны ияләренә тапшырырга күндердек. Кызларның берсе авылның бер башыннан, икенчесе икенче башыннан аулак өйгә чакыру билетларын таратырга керешә. Дулкынланып кич җиткәнен көттек, кызлар безнең болай «кылану»ны көлкегә алмаслармы, килерләрме кич утырырга. Гасабилануыбыз юкка булган, исемлеккә кергән барлык кызлар да диярлек утырмага килгәннәр иде. Өйләнгән, үзе авыл Советы рәисе булуга карамастан, безнең сүзне аяк астына салып таптамыйча Хәлил Зәйнуллин да гармунын култык астына кыстырып килде. Кичә бик күңелле үтте, арыганчы биедек тә, җырладык та. Шешә тәгәрәтү, күз бәйләп уйнау уеннары да онытылмады. Ике дистәләп кыз, берничә егет төн урталары авышкач кына өйләренә таралышты.

Егерменче ноябрь көнне сугыш башыннан бирле хәбәре булмаган, уртанчы апамның иренең абыйсы—Габдулла кода кайтып төште. Менә бит ул тормышта ничек тә була. Безнең сөйләшкәнне апа йотлыгып тыңлый, күзләре очкынланган. Күреп торам: апаның күңелендә янә җизнине исән килеш күрүгә өмет уянган. Уянсын, әйдә, кешене өмет яшәтә, диләр бит.

Көн саен диярлек кемнәрдә дә булса аулак өйләр ясап, көннәр бер-бер артлы үтә торды. Мин көн саен диярлек Урта Балтайга телефоннан шалтыраттым. Тик ничә тапкырлар шалтыратып та, Тәскияне туры китереп сөйләшә алмадым. Үзен күрмәсәм дә, тавышын булса да ишетәсем килгән иде. Хатлар аша гына

сөйләшә башлавыбызга бүген алтмыш өч ай тулды, бу—1890 көнгә, сәгатькә әйләндерсәң, 45360 сәгатькә тигез. Кеше гомере өчен күп тә түгел кебек, икенче яктан уйласаң, аз вакыт түгел. Соңгы тапкыр мин бит аны кырыгынчы елның августында ук күргән идем. Арада—армиягә алынган вакыт, озын сугыш юллары ята, сугыш беткәнгә дә ярты елдан артты. Шуларны уйлап, йөрәгем өзгәләнә, күңелне сагыш баса.

Иртәгә китәсе дигән көнне, 29 ноябрьдә, Шәфыйкъ агай кызы Мәрзия, әтиләренең өйдә юклыгыннан файдаланып, үзләрендә аулак өйгә кызлар җыйды. Без дә чакырулы. Уеннар төнге бергә кадәр сузылды. Җырлап-биеп арыгач, ниһаять, таралдылар. Мин авызыма папиросымны кабып, кабызмыйча гына чыгу ягына юнәлдем. Шулчак Лотфи «ашыкма», дигән мәгънәдә күз кысты. Папиросны аннан-моннан суырып ташладым да, өйгә әйләнеп кердем. Мәрзия белән Гөлсылу өстәл янында утыралар, Лотфи янәшәдә басып тора.

—Егетләр, сөйләгез әле безгә үзегезнең сугышта күргәннәрегезне, югыйсә газеталарда язганнардан, кемнәрдәндер ишетүләр буенча гына беләбез андагы хәлләрне, ә чын дөресен беркемнән ишеткәнебез юк. Чамалавыбызча, хакыйкать тирәндәрәк ята,—диештеләр кызлар күзләрендә кызыксыну очкыннары уйнатып. Без Лотфи белән бер-беребезгә карашып алдык. Ул да, мин дә баштан кичкәннәрне тулысынча авылдаш дус кызларга да сөйли алмый идек. Аларга түгел, Лотфига да әсирлеккә эләгүемне әйтмәгән идем. Чөнки бу хакта сүз кузгатып йөрәк яраларымны яңартасым килми, вакыты җиткәч ул хәлләр барыбер беленер анысы, тик әлегә вакыты җитмәгән. Лотфи үзе дә чак кына штрафбатка эләкмичә калган кеше, үзе сөйләмәгәч, мин аны сораштырып бимазаламадым. Кызларга аннан башка да сөйләр нәрсәләребез күп иде. Мин—күктәге, Лотфи җирдәге фашистлар белән бәрелешләр турында аеруча хәтергә сеңеп калган эпизодларны тетрәндерерлек итеп тасвирладык. Сугышта хатын-кызлар да күп катнашты. Санитар, снайпер, очучы кызларның күрсәткән батырлыклары турында сөйләдек. Ирләр белән чуалып, ялгыш юлга кереп киткән кызлар да аз булмады. Андыйларның күбесе яшьли генә үз бәхетләрен үзләре югалтты. Инде кияүгә чыгу яшенә җитсәләр дә, мона кадәр Түбән Барыштан беркая чыгып йөрмәгән Мәрзия белән Гөлсылу авызларын ачып тыңладылар. Алар өчен барысы кызыклы, бу кызларга бар да яңалык иде. Лотфи белән Мәрзияләрдән иртәнге дүртенче яртыда кайтып киттек. Икенче көнне озынколаклар аркылы безнең Шәфыйкъ агайларда озаклап утыруыбыз турында сүз төрләндерүләр күп булуы ишетелде.

## Ерак юлга

Көндез кода абый белән колхоз идарәсеннән мине станциягә илтергә ат сорап куйдык. Иртәнге сәгать биштәге поездга житешергә кирәк иде, шуңа төнге уникедә үк юлга кузгалдык. Олы абыйның улы Газизулла белән Рәйсә сеңелкәш станциягә кадәр озатырга алынды. Тик бар да без уйлаганча җинел генә барып чыкмады, поездны икенче көннең шушы вакытында гына була, диделәр. Станциядән ерак булмаган Дәүләки авылына барып атны ял иттерергә уйладык. Газизулланың Галия исемле апаларда булганы бар икән, туры аларга кердек. Галия апа күптәнге танышларыдай якын күреп бик җылы каршы алды. Икенче көнне Рәйсә белән Газизулла кайтып киттеләр, икесенең дә аерылышу сагышыннан керфекләре яшькә чыланган иде. Бигрәк тә Газизулла күзгә тутырып карап:

—Әй, нәни абый, без тагын кайчан күрешә алырбыз икән инде,—дип өзгәләнде. Болай да хискә бирелүчән унҗиде яшен тутырган егетне аңларга була иде, чөнки тагын бер елдан көзге чакырылышта аны хәрби хезмәткә алачаклар. Ә минем кайчан демобилизациягә эләгәсем әлегә билгеле түгел. Үземнең дә

күңелем нечкәрде. Тамак төбенә утырган төерне йотып:

—Ярый, балалар, юл кешесенең юлда булуы хәерле, барыгыз кайтыгыз инде,—дип бер читтә мине көтеп торган кода абый янына ашыктым. Дәүләкидән станциягә җәяүләп кенә киттек. Вокзалда кеше күп түгел, поездга тагын ярты сәгать вакыт бар иде. Поезд вакытында килде. Ниһаять, мин вагонда. Кузгалып киттек.

Казанда таныш-белешләрне, дус кызларны, туганнарны күргәннән һәм өч көн кунак булганнан соң, Мәскәү—Владивосток поездына утырып, ерак Чита якларына кузгалдым. Эшелон тулысы белән диярлек дембельләрдән тора, кеч-кенә станцияләрдә дә озаклап туктала. «Болай акрын кыймылдасак, Яңа елны юлда каршылавың бар»,—дигән уй күңелгә тынгы бирми. Көнчыгышка барган саен декабрь салкынлыгы да арта, вагонның ачык тишекләре аркылы салкын җилләр сызгыра. Минем хәлләр мөшкелләнде, чөнки өстемдә юка, аякларда да кирза итекләр. Юлга дип әни-карчык биштәремә тутырган ашамлыклар салкында бозланып катты, станцияләрдә туктагач алып менгән кайнар суда аларны җебетеп ашагач кына тәнгә бераз җылылык кергән кебек тоела. Шундый шартларда Себер капкасы дип аталучы Свердловск каласына җиттек. Анда кайбер иптәшләр белән җылырак пассажир поездына көчеп утыру уе бар иде. Вокзалдагы кеше өстенә кешене күреп һәм бериш гавамның унар-унбишәр көн инде поезд көтеп ятуын ишеткәч, тизрәк үзебезнең составка утырып китү җаен карадык. Свердловскида чак кына үзгәреш булып алды. Ул да булса, 504 нче номерлы Мәскәү—Владивосток поездының номерын 502гә алыштырдылар һәм сөендергәне—һәр вагонга ягып җылытыр өчен ташкүмер белән тимер мич бирделәр. Вагон эче сизелерлек җылынды, безнең дә кәефләр күтәрелде. Тик бу куанычлар озакка бармады, Төмән шәһәрен үтеп Ишимгә җитеп килгәндә мичнең кызулыгы гына бөтен вагон эчен дә җылытып бетерә алмый башлады. Омскига якынлашканда һава сындырып җибәрде, вагон тәрәзәсеннән тышта ябалак кар яуганы күренде. Омск вокзалында тукталыш өч сәгатьлек булудан файдаланып, талоннарга юлда кирәкле азык-төлек сатып алдык. Минем белән тагын өч сержант бергәләп ашыйбыз. Безнең запаста тозлаган балык бар иде, аны сатып җибәрдек, чөнки ул су эчәсене китерә, ә станцияләрдә кайнаган су табу җинелләрдән түгел.

Татарски дигән шәһәргә житкәч, составның паровозын алмаштылар. Без шуннан файдаланып, вокзал янәшәсендәге ашханәгә барып, туйганчы кайнар аш ашадык. Маңгайлардан борчак-борчак тир бәреп чыкты, яңаклар алсуланып, кәефләр күтәрелеп китте. Новосибирск тирәләрендә коры салкыннар башланды. Барасы юл ерак, озак вакыт мондый хәлгә чыдап булмаячак иде. Һәм без Новосибирск вокзалында биш йөз икенче номерлы поездан төшеп калдык. Тәннәр дә керләнгән, мунча сорый. Мунча кереп, кырынып-чистарынып бу калада өч көн ял иткәннән соң, 18 декабрь көнне, санитар вагоннардан торган биш йөз беренче номерлы поездга утырып кабат сәфәребезне дәвам иттек. Вагоннары нибары егерме кешегә исәпләнгән бу поезд бик уңайлы булып чыкты, үзе—җылы һәм чиста, аның пассажирлары да тулысы белән демобилизацияләнгән солдатлардан тора. Тик менә вокзалларда ашамлык сатып алу өчен чыгып йөрүләре генә кыенлашты, Красноярскида һава температурасы минус 63 градуска житте. Һавада кошлар очмый, урамнарда адәм заты күренми. Вагон тәрәзәләре калын боз катламы белән капланды. Байкал күле тирәсенә житкәндә генә җылыта башлады, тәрәзәдәге бозлар эреде. Тик диңгезгә охшаган бу күл өсте куе томан белән капланганлыктан, дулкыннар шавы гына ишетелә, ә зур су үзе күренми. Паровоз, торбасыннан куе төтен чыгарып, составны алга ашыктыра. Вагоннар астында рельслар тукы-тукы килеп чакрым арты чакрымнарны саный. Урыны белән җир өстенә кар төшмәгән районнар очраштыра, күк йөзен кара болыт басып, коеп янгыр яуган җирләр дә бар. Иксез-чиксез

Себер кинлекләре шул, мона артык гаҗәпләнәсе юк. Минем командировка кәгазендә күрсәтелгән Чита шәһәренә житкәндә тагын салкыннар башланды, минус илле градус диделәр. Тиздән полкташларым белән очрашасымны уйлау күнелгә жинеллек бирде. Инде дус булып беткән яна танышларым белән саубуллашып вагоннан чыктым. Таныш түгел урамнар буйлап 326 нчы дивизия штабын эзләп киттем. Очучы киемендәге хәрбиләр еш очрасалар да, берсе дә безнен дивизия турында ишетеп белми иде. Бу хәл мина гажәп тоелды. Үзәк комендатураны эзләп табарга карар иттем. Суык аяклардан үтеп, бөтен гәүдәгә тарала. Жылыныр өчен йөгереп тә карыйм, әмма биш-алты адым атлауга, салкынлык энәләре үпкәгә кадалып, тынны кыса. Комендатурага барып житкәндә өшер хәлгә житкән идем. Коридорга кергәч, бераз ипкә килер өчен стенага сөяләп тордым, чөнки бу килеш берничә сүздән жөмлә төзеп әйтү дә кодрәтемнән килмәс иде. «Комендант ярдәмчесе» дигән язулы бүлмәнен ишеген шакыдым. Эчтән: «Керегез!»—дигән аваз ишетелде. Тик комендант ярдәмчесенен хәбәре куандырырлык түгел иде. Ул хәтта безнен дивизиянен номерын да белмәвен, ә уникенче һава армиясенен хәзерге вакытта Хабаровскида икәнлеген әйтте. Мин анардан рөхсәт сорап, кабат Читага хәтле утырып килгән поездга житешү уе белән вокзалга ашыктым. Бәхетемә, биш йөз беренче номерлы поезд әле китмәгән, мин вагонга кереп элекке урыныма урнашканнан сон, егерме минутлап үткәч кенә ул кузгалып китте. Минем юлламада һәм билет алыр өчен бирелгән хәрби литерда Читага кадәр генә дип күрсәтелгән. Килеп житү вакыты унсигезенче декабрь дип язылган булса да, бүген инде айнын егерме дүрте һәм кайчан тәмамланасы билгесез сәфәрем әле һаман дәвам итә. Хәерле булсын. Кәеф ташка үлчим. Дивизияне таба алмасам, нишләрмен? Сораулар күп, аларга җавап бирүче генә юк. Уйлый-уйлый да башым катты. «Жә, ярар,—дип тынычландырырга тырыштым үземне,—Чита комендатурасында уникенче һава армиясе штабынын Хабаровскида урнашканын әйттеләр бит. Бәлки, өч йөз егерме алтынчы дивизия дә шундадыр».

Хабаровскига поезд беренче гыйнвар иртәсендә генә килеп житте. Жирле вакыт белән сәгать жиделәр генә. Штаблар да, үзәк комендатура да эшли башларга иртәрәк. Сәгать тугызлар тулганчы вокзал бинасында көтеп утырдым. Аннан станция дежурныеннан үзәк комендатуранын кайда икәнлеген сорашып, ул күрсәткән якка таба киттем. Урамда очраган хәрбиләрдән сорашып бара торгач, ниһаять, таптым. Комендант ярдәмчесе минем уникенче һава армиясе штабынын кайдалыгы белән кызыксынуыма, «кем сез, кайдан килүегез, ул сезгә нигә кирәк?» динән сораулар белән күмеп ташлады. Бөтенесен тәфсилле анлатып биргәч кенә, тәрәзә янына чакырып, «әнә—ул»,—дип, илле метрлар чамасы ераклыкта гына урнашкан кызыл кирпеч бинага төртеп күрсәтте. Тик ул йортка керү ансат булмады, пропуск алганчы, штабнын оператив бүлеге хезмәткәренә телефон аша анлатма бирергә туры килде. Оператив хезмәткәр мин хезмәт иткән дивизиянен инде күздән үк уникенче армиядән аерылып башка жиргә киткәнен, анын турында хәбәрдар түгеллеген ирештерде. Минем өчен сөенечле хәбәрләр түгел иде болар. Телефон трубкасын куеп, аптырап торганда, янәшәмдә басып торган өлкән лейтенант:

—Сез, иптәш сержант, үзәк аэродромга барып карагыз. Хәтерем ялгышмаса, анда 326 нчы дивизиядән бер офицер хезмәт итә кебек,—дип, кинәшен бирде. Күнел эчкәресендә чак кына өмет чаткысы баш калкытты. Кабат вокзалга барып, ашханәдә ашап чыкканнан сон аэродромга киттем. Өч чакрымнар чамасы юл үтүгә аякларым авырта башлап, кире борылдым. Кышкы көн кыска шул, ул арада кич житте. Төнне тимер юл вокзалынын көтү залында уздырырга туры килде. Икенче көнне иртәнге чәйне эчкәч, хәрби округ штабына киттем. Анда да мине канәгатьләндергән жавап алып булмады.

## Яңа полкта

Округныкыннан кайтышлый кабат уникенче һава армиясе штабына кагылдым. Пропуск яздырып, оператив бүлек башлыгының үзе янына кердем. Ул минем командировка кәгазенә күз төшергәч, нниндидер калын журнал актарырга керешге һәм:—Ә менә алар кайда икән,—дип кычкырып җибәрде,—сина, сержант, Воздвиженское станциясенә кадәр барырга кирәк булыр,—диде командировочныемның артына тиешле язуын язып, пичәт басканнан соң. Ул янадан комендант янына керергә, аннан да, инструкция таләп иткәнчә, кайбер формаль билгеләнүне үтәргә кушты. «Анысын гына үтибез инде анын»,—дип уйладым эчемә җылы кереп. Бер тәүлектән мине иптәшләрем, командирлар белән очрашу көтә. Бу—өченче гыйнвар, минем туган көн булачак. Комендант юлламаны үзгәртеп язды, билет сатып алырга яңа литер бирде.

Икенче көнне иртәнге алтыда Владивостокка баручы поездга утырып, кабат юлга кузгалдым. Ворошилов шәһәрендә икенче поездга күчеп утырырга туры килде, чөнки Воздвиженское төп тимер юл магистраленнән бераз читтәрәк. Поезд белән ике сәгать ярымлык юл. Мин үземне начар хис итә башладым: башым авырта, хәлсезлек басты. Воздвиженское станциясендә вокзал буенча дежурный бүлмәсенә кереп, көн яктырганны көттем. Кояш офыктан күтәрелә башлауга хәрби шәһәрчеккә таба юнәлдем. Аэродром аша чыкканда андагы самолетларның безнең дивизия самолетларына охшамаганлыгына игътибар иттем. Моны күреп эчем пошты. Шәһәрчеккә барып җиткәч, иртәнге чәйгә баручы очучыларның бөтенләй таныш түгеллекләрен күрдем. Димәк, безнекеләр монда түгел! Штаб янында торган часовойдан сорашкач, өметем бөтенләй өзелде—тугызынчы һава армиясенең 251 нче дивизиясенә кергән җитмеш сигезенче полк аэродромында икәнмен. Тик миңа инде барыбер, тизрәк нинди дә булса җылы бүлмәдәге унайлы урынга ятып, онытыласым килде. Көчле авыру мине аяктан егып килә. Беренче көнем аерым бүлмәдә карантинда үтте. Икенче көнне, устав кушканча мунча кертеп өс-башны алыштырганнан сон, казармага урнаштырдылар. Менә инде мин хәзер яңа җирдә, яңа хезмәттәшләр арасында, алар белән бертигез хокукта. Ләкин монда озак яшәргә туры килмәде, тән температурам кырыкка күтәрелеп, мине лазаретка салдылар.

Лазареттан унбишенче гыйнварда гына савыгып чыктым. Хәрби хезмәтем башланды. Ләкин элекке полкташлар һич истән чыкмады. Өч йөз егерме алтынчы дивизиянең кыр почтасы номерын белешеп, Кураев, Лаптев, Муравьев кебек иске дуслар белән хатлар алыша башладым. Читләтеп язулардан сигез йөз кырыгынчы авиаполкның Көньяк Сахалинда икәнен белдем. Ләкин аннан ни файда?! Авылдагылар, Тәския һәм Сәхияләр белән дә хатлар алышу башланып китте. Тәския бер хатында шигъри юллар белән болай дип язды:

*«Яшьлек көннәр шундый кыска була,*
*Үткәч алар, кире кайтмыйлар.*
*Сахраларда шиңгән чәчәк кебек*
*Яңадан да чәчәк атмыйлар.*
*Син дустымны өзелеп сагынганга,*
*«Уел» көен сузып җырлыймын.*
*Биек таудан аккан чишмәләрдән*
*Сине кайда диеп сорыймын.*
*Сиңа булсын шашкын йөрәгемнән*
*Ургып чыккан сөю хисләре.*
*Хәтеремдә саклансыннар җәйнең*
*Бергә үткән ямьле кичләре...*

*Сөекле дустым, бүген 1.03.46 ел. Алты сәгать укытып чыктым да, ял итәргә*

*уйладым. Ләкин никтер эчем поша, йөрәгем яна. Аптырагач, тынычлык тапмам-мы дип, синең хатларыңны тагын бер тапкыр карап чыктым. Әле февральнен уналтысында гына язган булсам да, тагын хат язарга уйладым. Ике тапкыр кайтып китүеңдә дә күрешә алмадык. Инде мәнге күрешә алмабыздыр кебек сизелә. Хуш, сау бул, дустым. Күрешүләргә өметләнеп. Тәския.»*

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. Инде яз башы булса да, чынлап җылыт-мый әле. Һавалар монда тиз үзгәрүчән, иртәнге якта кояшлы матур көн булса, төштән соң кинәт давыл кубып, кар-бураннар уйнау табигый күренеш. Март урталарында миңа полкның ягулык-майлау материаллары складына каравылга басарга туры килде. Кичтән һава җылы булганга өстемә шинель генә кидем, аякта киез итек. Бер-ике сәгать үтүгә, күк йөзен кара болытлар басты, яңгыр сибәләргә керешге. Яңгыр түгел, таш яуса да, постыңны ташларга ярамый. Түзәргә туры килә. Түзүен түзәсең дә, лычма юешләнгән киез итекләрдәге аякларны авызга кабарлык булдым. Үземә билгеләнгән вакытны үткәргәнче алар берни сизмәслек хәлгә җиттеләр. Өзлегеп, кабат лазаретка эләктем. Бу юлы урамга чыгарга да рөхсәт юк. Атналар буе лазарет ятагында аунау тәмам ялыктырды. Ярый әле эскадрильядагы кайбер якын танышлар хәл белергә килә. Алар үзләре белән газета, минем адреска килгән хатларны алып киләләр.

## Сөенечле хәбәр

Кичтән йоклап китә алмыйча озак яттым. Иртә белән кеше вакытында тор-мыйча, урынымда бөкләнеп ятканымны күреп, кабыргама шәфкать туташы Верканың:

—Тор, Хәлилов, шундый чакта йоклап яталар димени?—дип төртүенә уя-нып, күземне ачтым.

—Ә, нәрсә? Ни булды?—дип сөйләндем мин чибәр марҗа кызының кинәт эндәшүеннән куркуга калып.

—Булды, солдат, булды,—диде Вера кин елмаеп.—Менә укы!—ул минем кулыма газета тоттырды.—Сезнең чакырылышны беренче майдан беренче сен-тябрьгә кадәр дембельгә озатачаклар!

—Ур-ра!—мин ничек урынымнан сикереп торып, кызның нечкә биленнән эләктереп, әйләндерергә керешкәнемне сизмичә дә калдым.—Рәхмәт сиңа, чибәркәй, яхшы хәбәрең өчен,—дидем һаман Вераның биленнән ычкындыр-мыйча. Туташ этенгән була.—Җибәр инде, башкалардан яхшы түгел,—дип сөй-ләнә. Аның болай әдәп өчен генә әйткәне сизелеп тора, чөнки ул миңа һаман саен ныграк сылана иде. Палатадагы башка авырулар да безнең янга ашыкты, һәркемнең Верховный башкомандующийның әмерен үз күзләре белән күрәсе килә иде. Анда чыннан да акка кара белән: «Өченче чират демобилизацияләүне 1946 елның беренче маеннан беренче сентябренә кадәр үткәрергә!» дип языл-ган иде. Шул көннән башлап зур түземсезлек белән беренче май җиткәнне көтә башладык.

Мин, 28 март көнне сәламәтләнеп, эскадрильяга кайттым. Бу вакытта эскад-рильяда интенсив рәвештә очу күнекмәләре бара иде. Икенче көнне үк үземә дә һавага күтәрелергә туры килде. Мондагы ИЛ-10 дигән самолетлар мин элек очкан ТУ-2 түгел шул инде. Һәрхәлдә, әлләияләнмәгәнлектән, мондый типтагы очкычлар миңа уңайсызрак тоелды. Штурмовик, бомбардировщиктан шактый аерыла. Һавадан төшкәндә гәүдәмдә нык арыганлык сиздем.

Егерме дүртенче апрель көнне кызылармияче кенәгәләребезне җыеп алдылар. Моны кемнең кайда яшәвен һәм кая кайтачагын белү өчен мәгълүмат тупларга кирәклеге белән аңлаттылар. Димәк, демобилизация өчен кирәк булган доку-ментларны туплый башладылар. Унбишенче майдан башлап безнең полктан да кайтара башлаячаклар икән, дигән хәбәрләр таралды. Инде бары дембельгә китү

уе белән генә яшибез. Көннәрне, сәгатьләрне санап үткәрәбез. Беренче май, аның арты тугызынчы май бәйрәмнәре шаулап үтте. Аларны полкта да зурлап үткәрделәр. Бигрәк тә тугызынчы май тантаналары колачлы булды. Хәер, аның шулай узуы табигый да, чөнки бөтен полк сугышчылары диярлек уннарча һава бәрелешләрендә катнашкан, үлем белән күзгә-күз очрашкан кешеләр, тәннәренә сугыш җәрәхәте алмаганнары сирәктер. Ахыр чиктә дошманны җиңеп, исән калу үзе зур бәхет. Алар өчен бу бәйрәмнең әйтеп бетергесез кадерле булуы аңлашыла. Минем өчен дә кадерле Җиңү көне. Шулай да күңелдә төер бар. Ул һәрдаим үзен сиздереп, эчтән «игәүләп» тора. Сугышның башыннан ахырына кадәр ут эчендә йөреп, беренче «Батырлык өчен медале»нең эзсез югалуы, «Берлинны алган өчен», «Кенигсбергны алган өчен» медальләреннән мәхрүм калу, 151 мәртәбә! парашюттан сикерүне раслаучы белешмәнең юкка чыгуы—болар һәммәсе аянычлы язмышның ачы җимешләрен татуга дучар итә. Демобилизацияләнеп кайткач, туганнарга һәм авылдашларга, таныш-белешләргә «син сугышта кайда йөрдең?» дип сорасалар, ни диярмен. Элек хезмәт иткән сигез йөз кырыгынчы полк командирына әллә ничә тапкыр запрос ясатуның да бернинди нәтиҗәсе булмады. Гади «пушка ите» булган миллионнарның берсе, Апас районы Түбән Барыш авылы егете—Хәлилов Габделхак Хәлиулла улына нишләргә соң, җә, әйтегезче? Ни хәл итим!? «Өлешемә тигән көмешем»,—дип, башны аска иеп, язмыш сынавына түзәргәме? Күрәсең, тәкъдирдә шулай язылгандыр.

## Һәлакәтле очыш

Майның матур көннәренең берсе иде. Полк командиры майор Галкин личный составка аэродромда булырга әмер биреп, командный пунктка кереп китте. Бүген полк күләмендә күрсәтмә очышлар булырга тиеш. Әлегә кайсы эскадрильялардан нинди звенолар катнашырга тиешлеге билгеле түгел, анысын полк командованиесе хәл итә. Әлегә без, бөтен полк экипажлары, төркем-төркем яшел үләнгә сузылып ятып, дөнья хәлләре, ил-көн вакыйгалары, үзебезнең көндәлек тормыш турында сүз алып барабыз, тәмәке көйрәтәбез. Кемнәрдер әңгәмәгә катышмыйча тыңлап кына ята, кайберәүләр яткан көйгә йокыга оеган. Полк командирының сәясәт буенча урынбасары майор Гусев озатуында КПдан чыгып аэродромга таба атлаганы күренде. Эскадрилья командирлары экипажларга бер рәткә тезелергә боерып, аның каршына басып рапорт бирергә ашыктылар. Безнең экипаж исемлеккә кермәгән иде. Димәк, без җирдән генә тамаша кылачакбыз. Майор Галкин звеноларга аерым-аерым очу тәртибенең ничек башкарылырга тиешлеген төшендерде. Һәм менә күккә күтәрелергә күрсәтмә алган экипажларның очкычлары һавада төрле маневрлар башкарырга кереште. Пикегә төшү, кыска арада тулы әйләнеш ясау, бочка һәм кискен спираль фигуралары күрсәтү аларга бурыч итеп куелган. Звенолардан торган эскадрильяларның синхрон рәвештә башкарган трюклары астан күзәткәндә бигрәк сокландыргыч күренә, дистәләгән очкыч моторларының бердәм гүелдәве гигант умарта кортларының бер кучкә җыелып безелдәвен хәтерләтә. Шулчак кинәт умарта күченә таяк тыгып болгаткандагыга охшап, бергә хәрәкәтләнүче очкычларның сихри бергәлеге бозылды—арадан бер самолет аерылып читкәрәк чыкты һәм инструкция буенча тыелган маневрлар ясый башлады. Бу күренешкә башкалар белән бергә майор Галкин да игътибар итте. Ул кичекмәстән һавада гайре табигый хәрәкәтләр ясаучы экипаж белән автомобильгә урнаштырылган радиостанция аша бәйләнешкә керде. Федоров экипажы никтер полк командирының әмеренә дә әһәмият итмичә, билгесез юнәлештә очып, күздән югалды. Командирның борчылуы йөзенә чыккан, үзе туктаусыз Федоров һәм Лебедев экипажының шартлы позывнойларын әйтеп, рация аша полкта ин яхшылардан саналган экипажга эндәшә—җавап кына юк. Очкычлар бер-бер артлы аэрод-

ромга төшеп, урыннарына тезелделәр. Федоров экипажы күренмәде. Ни булыр бу? Һәркемне шул сорау борчый. Ашханәдә төшке аш ашаганда авыр тынлык хөкем сөрде. Башка чакларда мутрак очучылар официанткалар белән шаяртып сөйләшә, кеше-кара күрмәгәндә йомшак җирләренә шапылдатып алырга да күп сорамыйлар иде, бүген күнелле гөрелдәү дә, сүз озайтулар да күренмәде.

Төшке аштан соң полк командиры безнең экипажга эзләү эшләре башлап җибәрергә боерды. Фотоаппаратны җайлап урнаштырып, ашыгыч рәвештә һавага күтәрелдек. Федоров самолеты киткән юнәлешне чамалап, шул якка очабыз. Аста ташлы таулыклар, ерганаклар белән ермачланган урманлыклар җәелеп киткән. Тауның һәр ягын җентекләп күздән кичереп, объективка алабыз. Сазлыклар да очрый. Аларда самолет төшеп кадалган эз юкмы икән дип, төрле билгеләргә игътибар итәбез. Шактый зур мәйданны инләп, озак вакыт очсак та, нәтиҗә—нуль! Югарырак менеп карарга булдык. Алай иткәндә, күзәтү мәйданы арта. Әмма болай эшләүнең дә файдасы тимәде, ике сәгатьтән артык очыш ясап та, Федоров очкычының скелетен да шәйли алмадык. Кая китеп югалдылар икән болар, җир йотмагандыр ич! Инде өметне өзеп, кайтыр якка борылгач, бер тау битендә нидер ялтырап киткәндәй тоелды. Мин сөйләшү аппараты аша:

—Командир, күрәсеңме, тегендә нидер бар!—дип эндәштем.

Лейтенант Кузнецов кояш нурында чагылып алган әлеге ялтыравыкны шулай ук абайлаган икән:

—Күрәм, өлкән сержант, хәзер шунда борылабыз,—дип, очкычны тау ягына турылады.—Менә кая эләккәннәр икән алар,—диде экипаж командиры сүзләрен теш арасыннан кысып чыгарып. Инде бу вакытта безнең штурмовик җир өстендә койрыгы гына күренеп торган самолет калдыгына тәмам якынайган, мин аны фотообъективка алырга керешкән идем. Кузнецов төшерергә җайлырак булсын өчен тау битенә дүрт яклап килде. Мин унайлы мизгелне кулдан ычкындырмадым.

Аэродромга төшеп утырып, самолет моторларының шавы тынырга өлгермәде, янибызга полк командиры килеп җитте. Әле ул, күрәсең, нәрсәгәдер һаман өметләнгән, безнең сүзләр аны бөтенләй чарасыз итте. Бер көн эчендә берничә яшькә картайган майорны хәтта кызганып куйдым. Командирларның да ирешкән дәрәҗәсенә кызыгышлы түгел, алар өстенә никадәр зур җаваплылык йөкләнгән. Майор безне командный пунктка алып керде, катастрофага очраган самолетның координатларын җентекләп сорашты. Озак та үтмәде, пленкадан төшереп ясалган фотографияләрне керттеләр. Авариягә юлыккан очкыч калдыкларын фотода кабат күрү авыр тәэсир калдырды.

Икенче көнне Федоров белән Лебедевның гәүдә калдыкларын табутка салып, полк күләмендә зурлап күмделәр. Һавага залплар ясалды, майор Галкин үлгәннәрне искә алып нотык тотты. Тик ул сүзләрен әйтеп бетерә алмады, артык дулкынланудан тавышы калтыранды. Аның нотыгын урынбасары майор Гусев тәгәлләде. Шулай итеп, сугышта гына түгел, тыныч хәрби хезмәттә дә корбаннар булуын үз күзләребез белән күрдек.

## Сау бул, Армия. Исәнме, туган як!

Полкта демобилизация турындагы сүзләрнең тынып торганы юк. Берәүләр тәүге озатуны егерме икенче майда башланачак, ди. Икенчеләр—егерме алтысында, дип сүз озайта. Белмәссең, юраганнарның юш китерүе дә ихтимал. Шуна күрә, кайбер иптәшләр белән беррәттән юл капчыгы хәстәрләп куюны кирәк таптым. «И-их, әйткәннәре чынга ашсын иде!»—дип теләк телим. Теләрсең дә, инде алты ел хәрби хезмәттә ич, шунын дүрт елы кан, үлем белән янәшә. Тик менә май ае узып, июньгә кердек, армиягә кырыгынчы елны чакырылганнарны

түгел, утыз тугызынчы елда мобилизациягә эләккәннәрне дә кайтарганнары күренми. Алай гына да түгел, дивизия буенча хәрби белгечләрне беренче сентябрьгә кадәр калдырырга дигән боерык укыдылар. Чөнки сугыш елларында егерме биш, егерме алты һәм хәтта егерме җиденче елда туган үсмерләрне дә фронтка алып бетергәннәр, хәзер безнең ише «картларны» алыштырырга кеше запасы юк, имеш. Аннары Корея якларында хәлләр имин түгел, дигән хәбәрләр бар. Иптәш Сталин Ерак Көнчыгыштагы Кораллы Көчләрнең көчсезләнүен теләми торгандыр. Ничек кенә булмасын, бу хәбәрләр күңелләргә шатлык өстәми, инде туган җирләр сагындырды, өйгә кайтасы килә.

Түземсезләнеп, сентябрь җиткәнне көтәбез. Шулай да алтынчы июль көнне 1938-39 елларда алынган солдатларны демобилизацияләү турында боерык укыдылар. Ул елгыларны күмәк фотога да төшерделәр. Шуның артыннан ук безнең авиадивизияне Кореяга күчерү әмерен белгерттеләр. Кореяга ук китәргә туры килер микәнни?! Туган яклардан һаман ераклашабыз болай булса...

Шулай да сентябрьнең беренә кадәр көтәргә туры килмәде. Якын арада дембельгә эләгәселәрне Кореяга җибәрмичә күрше полкка күчерә башладылар. Анда татар һәм башкорт егетләре дә байтак иде. Мин Фәрит Вәлиев атлы егет белән дуслашып киттем. Ул миннән яшьрәк булса да, сәламәтлеге буенча демобилизациягә эләгә иде. Инде июль ае ахырына якынлашып килгәндә, безнең төркемнәрне дә туган якларга кайтарып җибәрә башладылар. Чират миңа да житте. Июльнең егерме сигезе көнне мин Владивосток—Мәскәү поездына утырып кайтыр юлга чыктым. Юл өчен литер тутырганда миңа туклану талоннарын егерме жиде көнгә исәпләп бирделәр, командировка кәгазенә дә: «Владивосток—Мәскәү—Казан» дип язылган иде. Югыйсә, поездан мин Мәскәүгә житкәнче үк төшеп калам. Хәер, юл хәлен белеп булмый, запас көннәр булып, артык талоннар белән тәэмин ителү комачау итмәс.

Инде юлларда кырык бишенче елдагы кебек кеше өстенә кеше, этеш-төртеш юк, табигатьтә ямьле җәй тантана иткәнлектән, вагоннарда катып-калтырап утырасы юк. Кәеф яхшы, күңелләр күтәренке.

Мин өч атна дәвамында Казанның тимер юл вокзалына кадәр кайтканны, анда кайткач, беренче номерлы трамвайга утырып Бишбалтага барганымны, туганнарда, дусларда, таныш-белешләрдә кунак булганымны тәфсилләп язып тормыйм. Казан пристаненнан Тәмтегә, ә аннан авылга кайтуымны да әйтеп кенә китәм. Мин әле бу вакытта үземнең тагын утыз өч ел ярымнан фанилыктан бакыйлыкка күчәсемне белмим, бу турыда башыма да китерми идем. Мин туган ягыма кайтып килүем белән, әлегә якты дөньяда яшәвем, сөя-сөелә белүем белән бәхетле идем.

Саумы, туган авылым—Түбән Барышым?! Мин, синең гади бер улың, күп еллар чит җирләрдә сират күпере кичкән кебек, үлемнән бер карышта гына йөргәндә дә, бер генә мизгелгә дә сине исемнән чыгармадым, сиңа хыянәт итмәдем. Моңа Күкләр шаһит!

# 2011 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1432-1433 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

**5 гыйнвар**—Сәфәр ае башланган көн.

**30 гыйнвар**—Һиҗрәт кичәсе көне. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

**15 февраль**—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**3 июнь**—мөселман календарендa изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**9 июнь**—Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич—Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**29 июнь**—Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**2 июль**—дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбан ае башлану көне.

**15 июль**—Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**1 август**—чират изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**29 август**—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**5 ноябрь**—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**6 ноябрь**—Гайдел-Әдхьә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**7, 8, 9 ноябрь**—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**26 ноябрь**—1433 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**5 декабрь**—Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**11 декабрь**—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

*Төзүче-мөхәррир*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН**



*Ял вакытында. Сулдан уңга: Кави Нәҗми, Фатих Мөсәгыйт, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Сәрвәр Әдһәмова, Галимҗан Мөхәммәтшин. Үткән гасырның 30нчы еллары.*



*Рәссам Рәшит Имашев шагыйрьне менә шулай сурәтләгән. 1974 ел.*



*Сабада очрашудан соң. Нәби Дәүли (сулда), Сибгат Хәким, Хәсән Туфан. 1958 ел.*



*Замандашлар—фикердәшләр. Гомәр Бәширов һәм Хәсән Туфан. 1973 ел.*




*Хәсән Туфан трибунада. Өстәл янында утырганнар (сулда) Нәкый Исәнбәт һәм Мөхәммәт Гайнуллин. 1975 ел.*



*Шагыйрь иҗат итә. Кайчак тәмәке дә кирәк булгалый. 1973 ел.*

# ЕВРОПАНЫ АРКЫЛЫГА-БУЙГА

СӘЯХӘТНАМӘ

2006 елның җәендә мин автомобильдә Казаннан алып Анталиягә кадәр юл уздым. Амстердам (Голландия) һәм Салоники (Греция) шәһәрләре аша. Ә инде 2008 елның көзендә Париж һәм Рим аша Лиссабонга бардым. Маршрутларымның берсе—Европаны буйга, икенчесе аркылыга кичте, мәкаләмнең исеме әнә шунардан килеп чыкты да инде.

Анталиягә без танылган музыкант Арион Рәхмәтуллинның «Рено-Меган» дигән машинасында бардык. Испания консуллыгыннан безгә бер айлык виза бирелгән иде. Бер-ике атнаны иң әүвәле Барселонада уткәрергә дигән нияттән үзебез белән гитара һәм аккордеон алдык.

Кузгалдык, хәерле юл була күрсен! Беренче төн кунуыбыз Минск шоссесындагы «Таверна» (Казаныбыздан 1020 чакрым) кунакханәсендә узды. Икенче төнебез—Белорусия-Польша чигендә. Ул чакта бу ике ил арасында «челноклар» (бүтәнчәрәк әйтсәк, «алыпсатарлар») кырмыскадай кайнаша иде. Чират зурдан. Үземнең дә машина шундый булганга күрәдер, «Фольксваген Пассат»ларның күплегенә игътибар иттем. Икенче көнне Польшаны кичеп чыкканнан соң, ниһаять, Берлинга барып җиттек. Машинага бензин салырга кирәк иде. Бензоколонкада бер нәрсәгә гаҗәпләндек: бакны тутырып ягулык салырга мөмкин, тик кайда-ничек түләсенә һич төшенә алмадык. Аптырагач, якындагы кафега кердек, тик анда ни хуҗалар, ни кергән кешеләр күренми. Шакыйбыз, эндәшеп карыйбыз, аннары гына эчкәрге ишектә повар-ашчы күренде. Кассасына карады, бездән тиешле акчаны алды, кая таба ничек барырга икәнлеген дә тәфсилләп аңлатып бирде. Бездә мондый хәлләр төшенә дә кермәс иде, дип хәйраннарга калдык.

Безнең каршыга полицейскийлар килеп туктады. Без, Россия номерлы машина хуҗалары, куркып-каушап калдык. Алар исә бездән: нинди ярдәм кирәк дип сорадылар һәм кая-ничек барасын аңлатып бирделәр.

Берлин картасына карый-карый бара торгач, «Беролина» дигән кунакханәне эзләп таптык. Буш номерлар бар булып чыкты, ике кешелек бүлмә 45 евро тора. Иртән Берлин урамнарын гизәбез, истәлекле урыннарда тукталабыз. Рейхстагның шунысы гаҗәп иде—җир өсте, җир асты һәм һава коммуникацияләре бик тә заманча, янәшәдә генә Шпрее елгасы ага. Берлин шәһәре үзе иркен, парк, мәйдан, автопарклар күп, урамнары киң.

Гамбург автострадасына эләгүләр бер дә җиңелдән булмады. Чөнки Берлин божрасыннан чикләнмәгән тизлек белән (130 сәг./км. рәсми рөхсәт ителгән) машиналар ташкыны чаба. Өченче тапкырында гына үзебезгә тиешле юлга эләктек һәм Гамбургта Арионның дусты Ришат белән очраштык. Алар СССРдагы хәрби дирижерлар әзерли торган (Уфа) бердәнбер балалар мәктәбендә бергә укыганнар икән. Дачасына кунакка чакыруына карамастан, без тизрәк Амстердамга ашыктык.

Машинабызны трамвай тукталышында калдырып, үзәккә уздык, кызыл «квартал»га да кердек. Анда эшлекле һәм чиста атмосфера. Чибәр кызлар—50 доллар «тора». Без—комсомол һәм партия тәрбиясен алган кешеләр буларак, бу гөнаһтан

баш тарттык. Әй, бездә булса иде бу!.. дибез.

Биредә теләсә кайсы шәһәрнен үзәгенә үтеп керү ансат, чөнки төп транспорт агымы сине үзеннән-үзе шунда илтә. Ә менә машина куяр урын (автостоянка) табу ансат булмады. Машинабызны Казандагыча итеп бер почмакта калдырдык та атаклы башкала урамнарына чумдык. Өч сәгать буе тамаша кылып йөргәннән сон, борчылып, машинабыз янына әйләнеп кайттык. Борчылуыбыз юкка булмаган икән: күрәбез—мангай тәрәзәсенә 50 евро штраф квитанциясе чәпәлгән иде! Аны почтага түләргә кирәклеген ачыкладык. (Түләү срогынын 2 ай иканлеген без әле белми идек). Эзләп карасак та почта бүлекчәсен тапмадык һәм... күршедәге чит илгә—Бельгиягә томырылдык. Көлешәбез: янәсе, шушы вак-төяк өчен генә компьютерлар безне «эләктермәс», Интерпол да ике як чикне бикләмәс. Ни булса булды, төн уртасында утлары янып торган Бельгия автострадасына кердек. Люксембургнын бер читенәрәк урнашып, машинада төн йокладык.



Париж—Брюссельдән ерак түгел, ләкин Люксембург аша әйләнеп узсаң, юл озыная. Арион дустыма Буада үскәндә Роза Люксембург урамында яшәвемне һәм балачактан ук шушы шәһәрне күрергә хыяллануымны аңлатам. Килеште. Ләкин Люксембург Амстердамнан да «хәтәррәк» булып чыкты: тукталырга дисән, буш урыннар юк, урамда тукталыш ясау һич мөмкин түгел! Өстәвенә, шәһәрдә томан һәм яңгыр иде, йөрдек-йөрдек тә Парижга юл тоттык.

Арионның Казан дусты, музыкант Толя Байдаров Парижда күптәннән яши. Француз хатыны белән ул ел саен туганнарына—Питрәч районына кайта. Машинабызны куйдык та Парижны «йотарга» чыгып киттек. «Йоту» дигәнебез—1 долларга Елисей кырларында, агач эскәмиядә бер банка сыра чөмерү һәм көнбагыш чиртү иде.

Байдаровларның өч катлы йортында ике көн кунак булганнан соң Урта диңгезгә юнәлдек. Париж-Марсель автострадасыннан файдаланган өчен (770 км) 28 евро түләдек. Юлда шулай да кечкенә бер «ЧП» булып алды. Лионга житәрәк, кирәкле юл чатын узып киткәнбез икән. Юлда машиналар күренми, бер чакрым чамасы арт белән барырга кирәк. Өч йөз метр ара узуыбыз кая... эвакуатор килеп житте! Россиядә без бит шулай өйрәтелгән—хәтәр нәрсәкәй бу... Куркып-каушап калдык, документларны әзерлибез, акланырга берәр сәбәп тә табарга кирәк. Руль артыннан сикереп төшә автомеханик, менә сиңа мә: нинди ярдәм кирәк, ди... һәм хәерле юл теләп калды. Россия кинлекләрендәге ГАИ инспекторлары, радарлар, эвакуаторлар «көлке» тоелды безгә.

Арион дустыбыз Канныга ашыга иде, чөнки анда кинофестиваль бара. Төн кунарга кирәк иде, юлда ниндидер бер кунакханәне эзләп таптык. Гажәп: ни утлары, ни кешесе юк, ишекләре бикле, һич кенә дә кереп урнашыр чама күренми. Ирле-хатынлы ике француз килеп чыктылар да аңлаттылар: банкоматка кереп иң әүвәле 44 евро кредит акчасы түләргә кирәк икән. Рәхмәт, киң күңеллелек күрсәтеп, булышты болар безгә. Кердек. Вестибюльдә автомат безгә су эчемлекләре һәм бутерброд тәкъдим итә. Персонал юк, алар көн уртасында гына киләләр, күрәсең.

Канн фестивалена сонга калдык. Тан атканчы диярлек атаклы Англия бульвары буйлап хисләнеп йөрдек. Һәм аннары Анталиягә барырга карар кылдык.

Монако—бик кечкенә дәүләт. Минем анда булганым бар иде инде. Монте-Карлоны азмы-күпме карап өлгергән идем ул чакта. Бу юлы без машинабызны жир асты гаражында калдырдык та, лифтта турыдан-туры кенәзлек сараенын мәйданчыгына күтәрелдек.

Монте-Карлода «Формула-1» трассасынын катлаулы, классик үрнәгенә тап булдык. Анардан зур тизлектә бару хәтәр тоела. Аны исән-аман узып чыкканнан

соң без үзебезне «җинүчеләр» сыйфатында тойдык.

Италиягә килеп кергәч тә андагы тоннельләрнең күплегенә таң калдык. Римга керү юллары—түләүле. Кунакханәләр күренми. Алар 15 чакрым читтәге шәһәрчеккә урнашкан икән. Өч йолдызлы кунакханәләр—80 евро, безнең кесәләр өчен бик кыйммәт. Без кире борылдык һәм караңгыда адаштык. Бер яклы юлдан барганда полиция патруленә килеп каптык! Әлеге дә баягы, мескенгә салышып, алардан кая барырга кирәген сорашып җинелчә котылдык.




Римда трамвайга күчеп утырдык, автоматтан билет сатып алдык. Аны компостер аша үткәрергә кирәк икән (белмәдек), контролерлар кереп 50 евро штраф салдылар.

Алдагы юлыбыз—Греция аша Төркиягә. «Полярис» дигән паромда (2 пассажир һәм 1 машина—150 евро) 14 сәгать буе Әдрән диңгезне кичеп, (Салих Сәйдәшевнең «Әдрән диңгез» җыры гел колакта яңгырап торды.) Игуменица дигән грек портына тукталдык. Тау юлларыннан бара торгач, атаклы Олимп тавын күреп сокландык.

Төрек таможнясына килеп житкәч, безне «сюрприз» көтеп тора икән: компьютерлар күрсәткәнчә, безнең машина... Төркиядән бөтенләй «чыкмаган» икән! Бактың исә узган ел Арион дустым шушы машинасы белән Төркиядә булган, паром белән Сочига чыкканда машинаны теркәргә ничектер «онытканнар»... Таможня вәкилләре әллә кайларга шалтыратып, двигатель-шасси номерларын күчергән булып бик озак иза чиктеләр. Көтә торгач, машина эчендә йоклап киткәнбез. Төрекләр, биредә йоклау тыела дип, безне, ниһаять, куалап җибәрделәр. Безгә шул гына кирәк тә иде—шатланып китеп бардык...

Тарихи урыннарны гиздек. Иң истә калганы—Троя атының «карыны»на кердек. Ул шулкадәр зур: аның эченә бер рота солдатлар сыя ала, диделәр. Атнаун көннән соң мин Истанбулдан самолет белән Мәскәүгә очтым, аннары поезд белән—Казаныма...

***

Өйдәгеләр үпкәләмәсен өчен, 2007 елның җәендә мин гаиләмне Сочига һәм Кырымга сәфәргә алып чыктым. Паромда барулар миңа шулкадәр ошады, Керчь бугазы аша Сочидан Кырымга юл тоттык. Дәрьяны кичүләр 16 сәгать вакытны алды. Керчь бугазы хәтәрләрдән санала икән, бер айдан соң анда берничә судноның батканын ишетеп хәйраннар калдык...

***

2008 ел. Дүрт көн дигәндә машинабыз белән 4000 чакрым араны узып, хатыным Фирдәвес белән Парижга килеп життек. Өч көн эчендә без Эйфель башнясын, Елисей кырларын, XII гасырның Нотр-дам соборын, Лувр музеен, Пигаль мәйданын, Латин кварталын, Люксембург бакчасын карап өлгердек.

Метро станцияләренең берсендә миңа коллегам—болгар аккордеончысы очрады. Аның ялга туктавыннан файдаланып, аккордеонын сорап алдым да бер-ике мелодия уйнап күрсәттем. Узгынчылар миңа акча салмады, аның каруы үзем хуҗаның тартмасына евро салдым. Карышкан булса да, безнең очрашудан ул бик шат иде.

Парижда өч көн йөргәннән соң иртән таулардан төшеп, Испания тигезлекләре аша узганнан соң, кичкә Португалиягә барып кердек. Ни өчен нәкъ менә Португалиягә? Ул бит Көнбатыш Европада иң ярлы илләрдән санала. Хикмәт

шунда ки, бу ил бик күп географик ачышлар, шул исәптән Робинзон Крузо исеме белән дә бәйле. Дөрес анысы, дөнья тирәли беренче сәяхәтне Испания оештыра, ләкин бу экспедицияне португалчы Магеллан житәкли. Европадагы иң озын күпер—Лиссабонда: озынлыгы 17 чакрым, 10 чакрымы Тежу елгасы өстеннән уза. Бирედә безнең опера театрының «Аида» афишасын күргәч, гажәпләндем, билгеле. Театр директоры Рәүфәл Мөхәммәтжанов һәм оркестр житәкчесе Николай Андреев искә төште... Рәүфәл белән 1973 елны без Франциядә бергә булган идек, Рәүфәл ул чакта музыкант, пианист буларак барды.

Лиссабон белән Мадрид арасы 650 километр. Мадридка төн уртасында барып кердек. Бу—төнге тормыш белән яшәүче шәһәр. Ул Казан һәм Мәскәү калаларыннан шул ягы белән нык аерылып тора. Биредәге күп кенә клуб һәм дискотекалар төн уртасында гына эшли башлый. Король сарае—Европадагы иң зур корылмаларның берсе, 2000 бүлмәдән тора ул (Эрмитажда 1060 бүлмә). Бу олуг музейдагы Кораллар палатасын исләрең китеп карыйсың.

Пиреней тауларын кичеп, янадан Франциягә кайтабыз. Шаулап яуган янгыр пәрдәсен ерып, Канн һәм Ницца арасындагы Антиб култыгына тукталабыз. Кунакханә хезмәткәре бирედән ерак түгел миллиардер Абрамовичның вилласы урнашканын рәхәтләнеп сөйләп бирде безгә.

Менә без хәзер Италиядә. Римнан дусларга шылтыратып, Ровиго шәһәрчегенә килдек. Искиткеч жылы каршыладылар. Галина белән, ул Италиягә китеп барганнан соң, унбиш еллап инде очрашкан юк. Безнең үз машинабыз белән Мәскәүдән түгел, Лиссабоннан килеп чыгуыбыз алар өчен көтелмәгән хәл иде. Әлеге рус-итальян гаиләсе мәктәп яшендәге уллары белән бакчалы, хәлле йортта яшәп яталар икән. Бакчаларында исә помидор-виноград түгел, татлы жимеш—киви үсә. Австралиядән килгән бу жимеш Италия жирлегендә дә әйбәт тернәкләнеп киткән.

Күргән шәһәрләребездән хатыныма иң ошаганы Вена шәһәре булды, чөнки ул күп кенә яклары белән Казанны хәтерләтә иде.

Кайтыр вакытлар житте. Польша, Белоруссия чикләрен узып, Смоленск өлкәсенә аяк бастык. Түбән Новгород, аннары Чабаксар. Бирედән инде Казаныбызга кул сузымы ара. Бер тәүлек эчендә 1300 чакрым араны узганбыз. (Бернинди радарлар каравылламый, хәтта «Дакар»чылар да тәүлегенә нибары 700 чакрым ара узалар). Ә барлык йөргән юлыбыз 13 мең чакрымга жыелган иде. Мәскәү өлкәсе аша узулар бигрәк тә авыр булды: радар, бөкеләр, тизлекне тыючы саннар-тамгалар...

2008 елның 25 декабрендә Россия Президенты үзенең указы белән «Универсиада-2013» бәйгесен закон көченә кертте. Үземнең шәхсән «Дакар-2008» сәфәрен мин 2013 елда Казанда узачак Универсиадага багышладым. Һәм мона хакым бар дип саныйм. Чөнки гомеремнең 20 елы Казан университеты белән бәйле: 7 ел укыдым (2 елы физфак, 5 елы тарих-филология факультетының роман-герман бүлеге), аннары инде 11 ел буе шунда инглиз телен укыттым.

Таң белән Казанга кайтып төшкәч, хатыным әйтә: арыдым, бүтән беркайчан машинага утырмыйм, ди. Әмма бер көн узды микән... хатыным белән шул ук машинада «Буинск-Айрес»—ягъни минем туган якларым Буага, аның «Люксембург-стрит»ына кайтып киттек.

**Сәйдәш ГАРИФУЛЛИН,**
*филология фәннәре кандидаты, автосәяхәтче.*

# КОМАЧ ХАТИРӘЛӘР

## Урынсыз сорау

1975 ел. Партия өлкә комитетының киңәйтелгән утырышы бара. Проблемалар күп. Нефтен дә чыгарасы, «КамАЗ»ын да төзисе бар, игенен, яшелчәсен дә үстерергә кирәк. Беренче секретарь Фикрәт Табеев һәммәсе буенча да кискен таләпләр куя, кичектергесез бурычлар билгеләп, сүзен төгәлли. Ахырдан залга: «нинди сораулар булыр?»—дип мөрәҗәгать итә.

Урта рәтләрдән бер карт коммунист кыюсыз гына урынынннан тора:

—Нишләп республикада ит бетте, иптәш секретарь?

Чыннан да базарларның, кибет киштәләренең бушап калган чагы иде бу. Хәлнең житдилеге югары түрәләргә дә билгеле булгандыр, әлбәттә. Ләкин берсенең дә чаң сугарга кыюлыгы житми. Катырак сораулар бирә башласаң, «кызыл билетыңны сал!» дип кенә куркыталар. Кәнәфиеннән «выжт!» дигәнне дә аңлата инде бу. Ә өлкән агайның куркыр туны тузгандыр, күрәмсең.

Әмма Табеевның теләсә нинди судан коры чыга алуы да күпләргә мәгълүм иде:

—Ягез, кем бүген ит ашамады, кул күтәрсен?!—диде ул, үтергеч карашын залга юнәлтеп.

Бер мәлгә тып-тын калды халык.

—Барыгыз да тук икән бит! Шулай булгач, нигә мондый юләр сорау бирәсез?

Утырышта катнашучылар дәррәү көлеп жибәрде.

—Ит дигәннән, аны күп ашауның зарарлы икәнлеген беләсезме сез?—дип дәвам итте секретарь.—Бервакыт мин Лондон кунакханәсендә миллионер-капиталистны очраттым. Номерларыбыз янәшә иде, ашханәгә дә бергә йөрдек. Мин аның бер генә дә ит ашаганын күрмәдем.

—Ә нәрсә генә ашый иде соң миллионер?—дигән сорау бирергә батырчылык итте кемдер.

—...Ботка, карабодай боткасы!

—Акчасын җәлләгәндер ул капиталист!...—диде шул ук тавыш иясе.

—Карабодаен да байлар гына ашый икән,—дип көлешеп алды залдагылар.

Хәзер ите-мае да, азык-төлеге дә мул кебек үзе. Ләкин базарларга чыккан саен һаман да Фикрәт аганың шул сүзләре искә төшә.

## Парад һәм чәчәкләр

1977 елның ноябре. Бөтен ил Бөек октябрь түнтәрелешенең 60 еллыгын билгеләп үтә. Казанның Ирек мәйданы да халык белән шыгрым тулы. Тиздән бәйрәм парады башланып китәргә тиеш. Тыныч, салкынча һава. Жиргә тәүге ак кар бөртекләре төшә. Ленин һәйкәле янындагы трибунага республикабызның Ф. Ә. Табеев, С. Г. Батыев, Г. И. Усманов кебек зур түрәләре менеп кунаклаган.

Көчле, сизгер микрофоннан сәгать текелдәве ишетелә башлады. Трибунадагылар да кыймылдашып алды. Татарстан Югары Советы Президиумы рәисе Салих Батыев микрофон янына килеп басты һәм кесәсеннән зур ак кульъяулык тартып чыгарып, шуңа каты итеп борынын сенгереп куйды. Микрофон бөтен мәйданга ишеттерде бу дәү борын тавышын. Сәгать текелдәве дә тынып калды һәм шул минутта ук фанфаралар уйнап жибәрде. Бу хәлне күреп-ишетеп торган янәшәдәгеләр: «Парадны башларга әмер булды бугай»,—дип көлешеп алды.

Инде демонстрантларга бәйрәм котлавы укылды. Шуннан соң балалар төркеме трибунадагы түрәләргә революция символы булган кызыл канәфер чәчәкләре менгереп бирде (аны коммунизмның баш көрәшчесе Маркс та яраткан диләр бит). Житәкчеләр исә аларга тартмалы конфетлар бүләк итте. Йомшак кар бөртекләре исә талгын гына ява да ява. Трибунаның мәрмәр плитәләрен каплый, биткә, борын очларына кунып кытыклый.

Салих аганың да эчен пошырды бугай ул кар бөртекләре. Балалар биргән чәчәк бәйләмен алды да җәһәт кенә таш плитә өстендәге карны себереп-жилләтеп төшерде.

Күпләр мона игътибар да итмәде шикелле. Кеше күрер, нәрсә уйларлар дип, үзе дә башына китермәгәндер Салих ага. Ләкин була шул зур түрәләрнең һәр адымын, һәр кыланмышын күзәтеп торучылар. Трибуна янәшәсендәгеләр арасында да ыгыр-мыгыр, чыш-пыш китте:

—Революция символын мәсхәрәли бит бу!.. Житмәсә, шундый бәйрәм көнне...

—Башындагы мех бүреге белән саберсә ярамый микәнни?..

## Корылык сәбәбе

1975 ел. Яшьләр диннән читләшкән, без—атеист дип күкрәк суга. Татарстанда нибары 12 мәчет исән калган. Әллә инде шул гөнаһлар өченме, чәчүләр тәмамланганнан бирле тамчы да янгыр төшкәне юк. Кояш көннән-көн ныграк кыздыра. Корылык яный.

Әнә шундый эссе көннәрнең берсендә ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе Салих ага Батыев Декабристлар урамындагы нәшрият йортына журналистлар белән очрашуга килде. Олы житәкченең беренче сүзләрендә үк һава шартларының рәхимсезлегенә тирән борчылу сизелеп тора.

—Игеннәр күтәрелеп китә алмый, айдан артык янгыр көтәбез,—дип башлады ул, авыр гына сулап.—Ниһаять, бүген иртәнге якларда Чистай, Аксубай, Октябрь районнарында яртышар сәгать чамасы явып үткән дип хәбәр иттеләр. Сорый белеп сораганнар димәк Ходайдан... (Исән калган мәчетләрнең яртысы шул районнарга туры килә иде).

Батыев авызыннан Ходай сүзен ишеткән кайбер журналистлар авызларын ачып, сагаеп калды, шикләнеп бер-берсенә карады. Салих ага исә тирән генә тамак кырып алды да сүзен дәвам итте:

—Ә менә көнчыгыш районнарга таба бер генә болыт кисәге дә бармады, бер генә тамчы да таммады... Чөнки анда Алладан ялварып сораучылар юк, мәчетләр юк.

Шуннан соң, ни хикмәттер, матбугат битләрендә дингә, муллаларга, мәчеткә йөрүчеләргә караш үзгәрде, тәнкыйть язмалары да сирәгрәк күренә башлады.

## Сыңар оек

Туксанынчы еллар башы иде бугай. Татарстан белән Башкортстан арасында мөнәсәбәтләр жылы иде. Ел саен әле бер, әле икенче якта әдәби очрашулар, гастрольләр, мәдәният чаралары үткәрелә. Шундый чараларның берсен газетада яктырту өчен кулга командировка кәгазе тоттырдылар. Камал театры артистлары, жырчылар, әдәбият әһелләре пароходка утырып киткән. Мин икенче көнне самолет белән очарга булдым. Кичке бишләр тирәсендәге рейска билет юллап, аэропортка йөгердем.

Теркәлү башланасы урында халык жыелган. Күрәм, арада кулына зур гына портфелен тоткан—Илдар Юзеев басып тора. Ялда икән. Берәр атнага туган ягына да кайтып килергә уйлаган. Мәдәният көннәре чараларында катнашуын да үтенгәннәр. Кәефе шәп, хәл-әхвәл сорашабыз.

Шулвакыт диктор тавышы янгырый: Уфага очу 2 сәгатькә кичектерелә! Техник сәбәпләр аркасында...

Нишлисең, була торган хәл, көтәргә туры килә инде. Урам әйләнеп, дөнья хәлләре, әдәбият турында сөйләшеп, вакыт узганы сизелмәде дә. Ләкин янәдән әлеге дикторның ялкау тавышы янгырый:—Фәлән-фәләненче рейс белән Уфага очучылар игътибарына! Сезнең рейс якынча иртәнге алтыга күчерелә...

—Синең аяк авыр булды, ахрысы,—ди Илдар абый.—Нишлибез инде хәзер? Билетны кире тапшырып китсән, иртәгә Уфада көтәләр. Өйгә кайтып кунсаң—рейска килеп житәлмәвең бар. Иртүк торып такси ялларга кирәк, үзе самолет бәясенә төшәчәк инде...

Нишләргә кинәш итәсез, дигәндәй, стойка артында утырган сары чәчле, зәңгәр киемле кызый янына киләбез. Безнең алдан гына берничә пассажир сүгенә-сукрана билетларын тапшырып китеп барды. Язмышка буйсынып, көтәргә калучылар да бар, әлбәттә. Алар зур аэропорт залының бер почмагына кереп урнашты.

—Ихтыярыгыз,—диде битараф кына, кассада утыручы кызый.—Уфа аэропортында метеоусловие начар, көчле томан.—Газета хезмәткәрләре икәнлегебезне белгәч, маржабыз тавышын бераз йомшарта төште.—Транзит пассажирлар өчен бездә кечкенә генә кунакханә бар, шунда йоклап чыгарга мөмкин, бәясе кыйммәт түгел.

Теләсәгез юллама кәгазе язып бирәм.

—Ах бу матьеё условия дигәннәре... (Шагыйрь рифмасын да тиз таба шул).

Кунакханә дигәннәре аэропорт янында гына бер катлы иске йорт. Тулай торак бүлмәләрендәге кебек, өч-дүрт тимер карават, иске урындыклар һәм уртада бер шып-шыр агач өстәл. Башка берни дә юк. Буфет-мазары да күренми. Бишәр тәңкә түләп мендәр тышлыгы, одеал һәм башкаларын алып җәйдек тә йокларга яттык.

Төн уртасы булдымы, таң алдымы, нидер кыштырдаган тавышка уянып киттем. Туфли табаны да тыпырдап куйды бугай. Ләкин күз ачылмый. Илдар абый туалетка чыгарга җыенадыр дип уйладым һәм, икенче янга борылып, янәдән йоклап киттем.

Иртәнге бишләр тирәсендә Илдар абый уята:

—Тор, шәкерт, киттек Уфага... ди, Тукайчалап.

Мин солдат кебек тиз генә киендем, юыну бүлмәсенә дә барып килдем. Ә Илдар абый һаман мыштырдый, нидер эзли кебек, караваt асларына да иелеп карый. Костюм-чалбарын кигән, тик яланаяк йөри идәндә.

—Бер оекбашны табалмыйм,—ди бу.

—Өеңнән киеп чыккан идеңме соң?

—Бөтенләй юләргә санама инде абзаңны, Хөсәен...

—Туфлиенә эләгеп, бәдрәф юлында төшеп калдымы әллә?

—Ә кайда соң ул бәдрәф дигәннәре? Минем анда чыкканым юк ич.

—Ничек инде? Төн уртасында кем кыштырдап йөрде соң?

—Билләһи дим, чыкмадым...

—Әллә тычкан, күсе-мазар йөрде микән? Ишек тә ачылмады кебек, ул чакырылмаган кунаклар ишектән түгел, тишектән йөрер дип сөйләнә-сөйләнә, караватларны шудыра-шудыра, без стена буйларыннан идән ярыгын эзлибез. Бер почмакта бармак сыярлык кына тишеккә юлыктык, плинтус очлары да кимерелгән кебек. Тик монда оекбаш кадәр оек сыяр микән. Резина кебек сузыла торган ефәк булса бер хәл. Гап-гади «хыбы» бит.

—Яланаяк килдем дөньяга, шулай гына бәлки китәрмен...—дип, Туфан шигырен искә төшерәм.

—Шаяртыр вакыт бетте, Хөсәен, самолеттан калуыбыз бар,—ди Илдар абый, җитдиләнеп,—бир оекны!

—Сыңар оекбаш белән мин нишлим? Коллекция җыймыйм ич...

Юлда йөрүченең һәрвакыт запасы булырга тиеш. Минем портфель төбендә дә бер пар ята иде. Шуны алып Илдар абыйга сузам.

—Ничә сум тора?—ди абзый.

—Юкны сөйләмәче, Илдар абый, ки әйдә, рейска соңга калабыз!..

Чыннан да, без аэропортка йөгереп барып кергәндә, самолетка утырту тәгәлләнеп килә иде инде.

Шуннан соң бер айлап вакыт үткәндер. Оек маҗарасы да күптән онытылган. Беркөнне редакциягә Илдар абый килеп керә. Портфеленнән кечкенә кәгазь төргәк чыгарып миңа суза бу. Ачсам—минем оеклар. Юылган, үтүкләнгән.

—Акчалата бирим дигән идем, хатын шикләнә. Хөсәеннеке диюең хак булса, үзенә илтеп тапшыр, ди. Күсе урлады, дип әйтеп карыйм, аңа да ышанмый. «Берәр ана күседә онытып калдыргансыңдыр әле»—дип тәмам теңкәгә тиде...

Кызык та, сәер дә кебек күренде Илдар абый бу минутларда. Кем уйлаган бит сыңар оекбашның шундый кәмитләр китереп чыгарасын. Әле һаман да аңлый алмыйм, кая югалды соң ул оек? Күсе урлаган дисәң—аның нигә кирәге булды икән дүрт аяклы кимерүчегә?

**Хөсәен ӘХМӘТ-ВӘЛИ**

**Редакциядән:**

*Бу көннәрдә Хөсәен Әхмәт-Вәлигә (Хөсәен Хәсән улы Вәлиәхмәтов) 60 яшь тула. Без каләмдәш дустыбызны юбилее белән котлыйбыз, аңа саулык, яңа иҗади уңышлар телибез!*

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!



## Ләйсән Исхакова

### *Әбиләр чуагы.Көз.Кояш...*

**Әбиләр чуагы.Көз.Кояш...**
**Җилләрдә пәрәвез талпына...**
**Моң белән талпынган җепләрнең**
**Барсы да мәхәббәт хакына.**
**Ягалы җаннарны ялгызлык**
**Күбәләк шикелле очырган.**
**Ә Кояш нурларын тамчылар,**
**Сәйләннәр күзеннән качырган.**
**Җилләре дә җылы,тик нигә**
**Көз исе җаннарны яралый?**
**Әбиләр чуагы. Көз. Күңел**
**Сөюнең җепләрен аралый...**

### *Күзләрдә калам.*

**Буш йөзләрдән торган рәсем ясыйм,**
**Буш сүзләрдән торган җыр язам.**
**Язларыма юллар ерак әле...**
**Мин күзләрдә калам,күздә калам.**
**Кыскартылган вакыт йомгакларым**
**Сүтәмен дә,кире җыямын.**
**Җәйләр үтте.Бары сурәт булып**
**Мин күзләрдә калам,каламын.**
**Кышларның күңеле ак,диләр,**
**Югалган бизәкләр-эзләрдә.**
**Мизгелләр елларга әйләнде-**
**Мин калдым күзләрдә,күзләрдә.**

### *Унҗиденче кышым.*

Унҗиденче кышым салкыны
Җилгәрә уйларым, хисләрем.
Тик көзнең ямансу карашы
Һаман да хәтердә, истә әле.
Кыш йолдыз чүпләргә дәшкәндә
Син миңа җәйләрне юрама.
Күптәннән кышларга гашыйк мин,
Кыш моңы күңелгә урала.
Ябалак карларның сурәтен
Кадрлап сеңдерәм җаныма.
Тырыштым. Төшендем. Аңладым–
Бүгеннән мин язны сагынам.

### *Таң иде...*

Иртәләр үзәге—таң җиле
Офыктан офыкка түгелә.
Бер төннең сулышы туктады–
Җем дә җем йолдызлар сүрелә.
Өзелгән төннәргә бер дәва–
Төнге шәм уйлана һаман да.
Төнге шәм сөрәне чакыра:
«Син дәшмә, син тыңла, тик тыңла!..»
Бу сөрән әй җиңел, әй гамьсез–
Тыңгысыз күңелгә таң инде.
Сибелде кадерсез төн гаме.
Күк иде... Тын иде... Таң иде...

### *Хыялга алданып...*

Төсмерләр төсләргә әйләнгәч,
Күкләргә тартыла кыялар.
Адәмгә бер өмет өрегез,
Дәшегез тик бер сүз, хыяллар!
Хыяллар! Кагынган җаннарга
Сез—канат! Канатлар чыдаммы?!
Әллә соң күңелгә җыелган
Күз яшен берүзем сыгаммы?!
Дәшмисез, хыяллар... Беләсез
Мин кабат ялгызым калганны.
Төсмерләр төсләргә әйләнгән,
Хыяллар, тик сезгә алданып...

***

Сөю җырлары—күбәләк,
Алып менә күкләргә.
Дәшә гел бәхет мәленә,
Йолдыз-сәйлән чүпләргә.
Йолдызларга дәшкән саен
Сиңа дәшкәндәй булам.

Җавабыңны ишетмәгәч,
Җиргә төшкәндәй булам.

Хәтердәге сөю җырын
Йөрәгем отты инде.
Тик язда калган хәтерне
Күкләр онытты инде...

*Бәләкәйләр*

## БӘЛӘКӘЙ ЗИЛӘ

### Кайда икән ул бәхет?

Их, Каратау түбәсенә менеп йолдызлар жыясы иде. Алар бит аннан кул сузымы гына—үрелсәң тотып буладыр. Карангы төндә куркыныч шул. Ай яктыртса бер хәл. Бүреләр бар, ялгыз йөрергә ярамый. Күптән түгел генә колхоз малларына да зыян салганнар ди. Үскәч менеп жыярмын әле ул йолдызларны күп итеп. Әти-әниемне сөендерермен. Йолдызларны жепкә тезеп әниемнен түшенә муенса итеп тагармын, жемелдәп торырлар. Әтием дә әнине бик ярата, ана һәрвакыт болын чәчәкләре бүләк итә. Оялып тормыйлар, безнен алда үбешәләр. Безгә дә куаныч. Бераз уңайсызланабыз, билгеле, бишебез дә хихылдашкан булабыз. Исән генә яшәсеннәр инде. Әтиебез авырый шул. Йолдызлар, әйтегезче, әтиемә нинди дәва сихәт? Эндәшмиләр. Караңгы төн уртасында абага чәчәге күрсәң бәхетле буласын диләр. Минем бәхетем—әтием саулыгы! Әй, абага, күрсәт чәчәгенне! Бигрәк куе шул бездә урманнар. Куркыныч. Кара урманнарның иң карасы да безнең яктадыр. Нихәтле эзләсәм дә табалмадым мин абага чәчәкләрен. Урманнарның кердем уртасына, адашканнарым булды. Әтигә саулык эзләп, үзем югала яздым. Авырган килеш әтием мине үзе эзләп тапты.

Табалмадык әтиебезгә дәва, табалмадык... Иртә китте ул якты дөньядан, бәгырькәй. Кырык сигез яшьтә... Мина, аның кызы Зиләгә, унике тулып калды.

### Авылымда

Авылым Нәсибаш Каратау итәгенә урнашкан. Матур бездә табигать! Башкортстан бит! Аның яме—Урал таулары гына түгел, елгалары да, урманнары да. Тау очларына эленеп торган болытлары да, жир куеныннан шарлап чыккан чишмәләре дә. Шул гүзәллекнең бер кырыена бас та тынла: тынлыгында—бал кортлары скрипка уйный, гөрелтесендә—тракторлар волторна калтыраталар. Гомумән, зур бер оркестр симфония башкара, күл һәм тугай камышларында курай моң жилен уйната. Күз алдына китерегез: шул тирәлектә кечкенә кыз дөньясын онытып жырлый да жырлый. Ул мин, хыялый кызчык—Зиләгез. Каратауга менәм. Тавышым каршы тауларга бәрелеп, янадан кайта. Кызык. Ничек алай икән ул? Кайтаваз диләр. Инешкә төшәм, суы шулкадәр жылы. Әти-әниемнән качып су коенам. Ачуланырлар. Батармын дип куркалар. Һи, сай бит ул, муеннан гына. Ә менә Юрүзәндә коену куркыныч, тирән ул, катырак та ага. Әле йөзә дә белмим. Әти карап торганда мин кыюрак. Суга чүгәләп чумам да, бик озак чыкмый торам. Күземне ачып су дөньясын күзәтәм. Белсәгез икән, шундый матур балыклар яныма килеп ялт-йолт уйныйлар!.. Рәхәт тә инде шуларны карап утыруы. Өстә борчылып кычкыра башлыйлар. Мине батты дип уйлыйлар. Шуны сизеп мин судан чөелеп чыгам. Кызык ич үзең турында кайгыруларын тоюы.

## Җырлы балачагымда

Әтием белән әнием—укымышлы кешеләр. Әти Даян исемле. Бигрәк матур яңгырый, әйеме? Әниемнеке—Нәсимә. Шул хәтле искиткеч исем, килешәсездер? Минем өчен аларның исемнәреннән дә назлырак исем юктыр сыман дөньяда. Әтием ике белемле: укытучы да, юрист та. Әни дә гомере буе укытучы булып эшләде, мине дә укытты. Өстәвенә әле әти баянда уйный иде, әни—мандолина чиртә. Нинди генә телләрдә җырламый иде әти, хәтта бер тапкыр Осетиягә баргач, аларча да җырларга өйрәнеп кайткан иде. Безнең бөтен гаиләбез музыкага мөкиббән булды: өйдә гаилә хоры да, гаилә филармониясе дә бар иде дисәң ярый. Ләкин мин бик оялчан үстем. Тауларга менеп кычкырып җырлап йөрсәм йөрдем, ә менә өйдә сорасалар..., ишек артына качып, кешегә күренмичә генә җырлыйм. Янәмәсе, радиодан тыңлагыз, ягъни ишек артында радио бар. Соңрак кыюланыбрак киттем. Теләсә кайда, теләсә кайчан җырлый башладым. Өйдә дә, ишегалдында да, урамда да, урманда да... Кунаклар килгәнне гел көтеп торам инде. Чөнки алар килгәч законно җырлыйм. Әти үзе дә куша, кунаклар да сорый. Минем гел шулай җырлап йөрүемнең сәбәбе дә бар. Безнең өйдә һәрвакыт классик музыка яңгырап торды. Пластинкаларда дисеңме, радиодамы, соңрак магнитофоннан уйнаттык. Русланова, Поль-Робсон җырлары белән җенләнеп бетә идек. Колакка гел музыка кереп торгач, җырламый хәлең юк. Мин катгый рәвештә үземә җырчы булам дип сүз бирдем. Әйткәнемчә, көн-төн җырлыйм. Өйдәгеләр интегеп беттеләр. «Житәр, үкермә, улама!»—диләр. Ә мин һаман—иртәдән кичкә кадәр сайрыйм. Өйдә—мич чикерткәсе, урамда—чыпчык, бакчада—сандугач! Аптырагач, мине бәрәңге бакчасына терәлеп үскән каенлыкка куып чыгардылар. Анда каен башына менеп җырлыйм. Инде миңа бәрәңге төбенә өяргә дә кушмыйлар. Олаксын әнә урманына, сайрасын шунда тончыкканчы!



Беркөн шулай апаларга бәрәңге алырга бардык. Тамагым җырлап аңкауга ябышкач су эчәсем килеп бер савыттан әчерәк, компот эчкән идем. Әллә нәрсә булып чыкты ул... Кәефем күтәрелде. Өйгә кайтышлый урамда бертуктамый җырлаганмын. Апа:

—Җырлама, адәм хурына калдырасың бит, әнә, көләләр,—дип тә әйтеп карый икән, ә мин аның саен катырак җырлыйм икән.

Инде бу җырлауларымнан, соңрак, әтиемнең дә саруы кайный башлады бугай. Чамасын югалтканмын ахры, әти:

—Минем башыма җырлый бу,—дип әйтә торган иде.

Шулай бервакыт әтиемнең бик матур көзгесе каршында җырлыйм. Кырыйлары бизәкле. Киноларда гына күргәнем бар иде андый затлы әйберне. Әй, артистланам, әй, көязләнәм, кулларымны күкрәкләремә җәеп җибәреп... Кулларымны айкап җибәргән идем, көзгем өстәлдән очты да төште идәнгә. Тәмам чәлпәрәмә килде! Ах, ни әйтерләр инде?.. Ачуланып тормадылар тагы. Әти: «Бәхеткә булсын!»—диде.

Саташып җырлап йөри торгач, бер мәлне урманда адаштым. Дөньямны онытып әллә кая кереп киткәнмен. Көчкә эзләп таптылар. Караңгылар төшеп беткән иде инде.

## Минем бабам шундый булган...

Әйткәнемчә, безнең өйдә гел музыка яңгырап торды. Итальянча җырлап, төрле халык җырларын өйрәнеп үстек. Радиодан берөзлексез «Маяк» радиосы сөйләп торды. Әбием Фәхрибану да классик музыканы бик ярата иде. Бабам Мәхмүт шулай ук үз чорының алдынгы кешесе булган. Зур укытучы иде, диләр аны. Ул Габдулла Тукай

кинәше белән Башкортстанга килгән. Тукай ана: «Мәхмүт, бар син ул якларга, халыкка аң-белем тарат!»—дигән. Бабамның белеме чыннан да тирән булган—Казан укытучылар семинариясен рус теле, әдәбияты белгечлеге буенча тәмамлаган. Хезмәтләре өчен аны Калинин үз кулы белән «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләгән. Тирә-якта авторитеты зур, абруйлы кеше икәнлеге аның авылдашыбыз, булачак бөек язучыбыз Нәкый Исәнбәтне үлем җәзасыннан коткаруында да чагыла. Нәкыйга аклар армиясенә хезмәттәшлек күрсәтүдә гаеп тагыла. Моны белеп бабам Кызыл Армия командирына бара һәм аны фаҗигадан коткара. Үзенең язмышын куркыныч астына куеп, менә шундый батырлык эшли бабам.

## Әниемнең бер сабагы



Башлангыч мәктәптә, әни классында укыган чак. Дәресне начар әзерләп килгәнгәме, әни миңа «икеле» куйды. Шулхәтле кәефем китте. Хурлык. Үз әнием бит, үз әнием, үз баласына!... Өйгә кайткач урын өстендә яткан әтием:

—Нәрсә булды, кызым?—дип сорады.

—Әни икеле куйды.

Әти икеле алуымның сәбәбен сорап тормады, әни кайткач беренче сүзе шул булды:

—Нәсимә Мәхмүтовна, нишләп син Зиләгә түбән билге куясың? Рус кызларына югары билге куюыңны беләм. Бүтән Зиләбезне кимсетмә, яме!—диде.

Мин читкәрәк киткәч, әниемнең әтигә үз балабызга мәктәптә корырак булырга кирәк, яклау-мазар булырга тиеш түгел дип сөйләгәнен ишетеп тордым.

Әтием бик ярата иде шул үземне.

## Чишмә башым—Сәнгатьтә

Әтием үз хәлен анлапмы, әллә чыннан да музыка белеме бирү нияте беләнме, күп балалы гаилә булуыбызны исәпкә алып, мине район үзәгендәге интернатка бирделәр. Монда хор дәресләре, фортепиано, вокал күнегүләре үткәрелә иде. Башта мине баянда уйнарга өйрәтеп маташтылар. Баян авыр, зур. Мехын бер якка тартып төшерәм дә, шул арада көйне уйнап куерга өлгерәм. Аннан пышылдатып мехын җыям. Гел шулай интегеп өйрәнәм. Карап-карап тордылар да, булмый бу дип балетка өйрәтмәк булдылар. Әти, аягынны тегеләй ит, болай ит, ди. Мин, балетка бармыйм, дим. Карыша торгач, күнделәр. Котылдым балеттан.

Әти барысына да өйрәтә инде. Ноталарны да белә бит. Русча җырлар да өйрәндек.

*«Ты, синичка, где была?*
*Где ты гнездочко свила?*
*..........................*

Интернатта режим. Эксперименталь тәрбия биреләләр. Иҗат төрле яклап тәкъдим ителә. Анда мал-туарларыбыз да бар, бакчабыз да. Үзебез карыйбыз, тәрбиялибез, үстерәбез.

Авылга кайткач, апама урыс җырларын ике тавышка җырларга өйрәтәм. Бер концертта шулай җырлап халыкны шаккатырырга булдык. Тамашачы көлә генә: «Бәй, болар җырлый белми бит, икесе ике якка аерылып киттеләр ич,—диләр.

Сонрак ике тавышка җырлауның матурлыгын авылдашларыбыз да аңлый башладылар.

## Әтием васыяте

Мин жиденче класста укый идем. Әтием урын өстендә. Хәле авыр. Мине чакырып алды да:

—Кызым, шифоньер өстендә бер тартма бар, шуның астында сиңа кирәкле адрес ята. Бер елдан соң шул адрес белән Уфага барырсың, яме!—диде.

Бер елдан соң әтиемнең шул сүзләре искә төште. Адресны алып Уфага бардым, музыка училищесына укырга кердем. Әнигә дә әйтеп тормаган идем. Авылга хат килеп төшкән. Почтальон: «Сөенче, Нәсимә, сөенче! Кызың укырга кергән!—дигән хәбәрне әнигә житкергән. Әни: «Нишләп әйтмәдең, кызым, укырга керүеңне?—ди. Үзенең сөенече йөзендә, күзләрендә.

—Әни,—мин әйтәм,—әгәр керә алмаган булсам, сиңа нинди борчулар китерер идем. Менә хәзер икебез дә шатланабыз.

Шулай итеп, унбиш яшьтә училищега кердем.

## Шаянлыгым

Бер кызык хәл сөйлим әле. Аны сөйләү бераз оят та инде. Ярар, сүз башлагач, туктап калмыйм. Резеда апам белән кәжә сөте эчәсебез килеп китте (ул миннән ике яшькә олы). Без бит урлап эчәргә маташабыз. Бер зур кәжәбезне тоттык та, саумак булабыз. Тик тормый, нәгаләт, сөзә. Тр-р, хайван! Ул тыпырчына бирә, апа тегене астан кармалый. «Кая соң моның имчәге?»—ди.

Тәкә булып чыкты бу. Хур булдык. Ярый әле берәү дә күрмәде. Сөйләмәгән булсам, сез дә белми идегез.

**Зилә СӨНГАТУЛЛИНА**

---

# ДАЧАДА, БАЛЫК ТОТКАНДА

Бер заман ике профессорның гәпләшүен бик кызыксынып тыңлаган идем. Хужа, дача хужасы, балык кармакларга ярата, ә кунак өчен бу шөгыльнең бер кызыгы да юк иде шикелле. Ул хуждан болай дип сорады:

—Әйтегез әле, Николай Григорьевич, сез шушы калкавычларга текәлеп карап утырганданиләр турында уйлыйсыз?

Тегесе, бераз уйланып утыргач, ашыкмый гына бөтен гәүдәсе белән кунагы ягына борылды да, кулларын ике якка жәеп, болай диде:

—Үзем дә шаккатам, Виктор Васильевич, шушы калкавычларга карап утырганда минем берни хакында да уйлаганым булмый.


—Мин ахмакны, зинһар дим, гафу иттегез инде, Николай Григорьевич!

—Монысы ни өчен тагын?

—Соң, шулай рәхәтләнеп берни дә уйламый утырган чагыгызда тузга язмаган соравым белән уйланырга мәжбүр иттем бит!

**Ким ШАКИРОВ**

# РӘСЕМЛЕ КРОССВОРД




Рәсемнәргә карап, кроссвордны чишегез. Ачкыч сүз 7 нче санда.
*(Җавабы киләсе санда.)*

**Зөфәр ХИСАМОВ** *төзеде.*

# К

**«КЫЙССАИ СӘКАМ»**, («Сәкам турында хикәйят»), төрки-татар әдәбиятының шигъри ядкәре; героик дастан. Авторы билгесез. Касыйм ханлыгында 17 йөзнең 1 нче яртысында язылган. 377 строфадан тора. Эчтәлеге һәм теле б-н татар әдәбияты ядкәре «Дәфтәре Чыңгызнамә» (17 йөз) б-н аваздаш. Әсәрнең исеме төп герой баһадир Мәкам исеменнән алынган. Аны мәҗүси Хуранның Җиһаншаһы Мәккәгә Али хәлиф б-н сугышырга җибәрә. Җиңгән очракта ана үзенең кызын кияүгә бирергә вәгъдә итә. Ләкин баһадир үзе җиңелә һәм ислам динен кабул итә. Җиңеп чыгучы Сәкамга данлыклы Золфокар кылыч, могҗизалы ат Дөлдөл, Малик баһадирнең чукмар таягын бүләк итә һәм кире Хуранга ислам таратырга кайтарып җибәрә. Җиһаншаһ янына кайтып, Сәкам аны дошманны җиңдем дип алдый һәм кызына өйләнә. Гөрләп туй итеп яткан вакытта кунак кыяфәтендә үзенең сугышчылары б-н Али килеп керә, һәм Дөлдөлгә атланып, кулына Зольфокар кылычын һәм Малик чукмар таягын алып, Җиһаншаһны җиңә. Хуран халкы мөселманлыкка чыгып, гомерләрен саклап кала.

«К.С.» киная формасында Касыйм ханлыгында Шаһгали хан хакимлек иткәндәге сәяси вәзгыятьне тасвирлый, Мәскәү яклы хакимнәрдән котылу юлларын күрсәтә, мөселман җитәкчеләр тирәсендә берләшергә чакыра. Әсәр 19 йөзнең 5 күчерелмәсендә сакланган (Казан, С.-Петербург, Уфа архивлары һәм китапханәләрендә саклана).

Әд.: Дмитриева Л.В. Описание тюркских рукописей Института востоковедения. М., 1980. Т.3; Родин Н.А. Касимов-Городец Мещерский. Рязань, 2004; Госманов М. Каурый каләм эзеннән. К., 1994.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«КЫЙССЕЛ—ӘНБИЯ»** («Пәйгамбәрләр турында хикәяләр»), төрки (чыгытай) әдәбияты ядкәре (1310—11). «К.—Ә.» авторы Насреддин Рабгузи тарафыннан исламны беренчеләрдән булып кабул иткән чыгатай хөкемдары Тармаширин ханга (1326-34) багышланган. Әсәр ул заманда традицион булган «пәйгамбәрләр турында хикәяләр» жанрында төзелгән. Әсәрне язганда Рабгузи Коръән тәфсирләрен, пәйгамбәрләр турындагы гарәп һәм фарсы кыйссаларын файдаланган. 33 пәйгамбәр турындагы кыйссалардан тыш (Мөхәммәдне дә исәпләп) «К.-Ә.» үз эченә борынгы төрки риваятьләрен дә алган. Кайбер пәйгамбәрләрнең тормышы версияләре, аерым алганда Ибраһимныкы, мөселманга караганда, христиан күзаллавына якынрак. Шул ук вакытта Ииуд (Шамун) вакыйгасы һәм христиан, һәм мөселман версияләреннән аерылып тора: Ииуд Гайсаны сатмый, ә аның тарафыннан Кече Азиягә ислам таратырга җибәрелә һәм соңыннан пәйгамбәрлеккә ирешә. Сөләйман (Соломон), Әюб (Иов), Даниял пәйгамбәрләр турындагы хикәяләр автор версиясендә бирелә. Төрки мөселманнар арасында «К.—Ә.» популяр дини әсәрләрнең берсе (20 гә якын литография, ш.у. Казанда (1859 дан) һәм Анкарада берничә басма китап чыкканы билгеле). Әсәрнең берникадәре В.В.Радловның борынгы «Төрки телләр сүзлеге тәҗрибәсе» («Опыт словаря тюркских наречий», т.1-4, 1888-1911) сүзлегенә нигез булып тора.

Әд.: Катанов Н.Ф. Мусульманские легенды: Тексты и переводы. СПб., 1894; Малов С.Е. Мусульманские сказания о пророках по Рабгузи // Зап. Коллегии востоковедов при Азиатском музее АН СССР. 1930. Т.5; аныкы ук. Памятники древнетюркской письменности: Тексты и исслед. М.—Л., 1951; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 2001. Вып.3; Emilogli Ed. Kissas-i Enbiya. Ankara, 1994.

**КЫЙТГА** (гарәп.), профессиональ каллиграф тарафыннан эшләнгән, аның кулы куелган сәнгати бизәлгән чәчмә яки тезмә текст; каллиграфия сәнгате төре. К.ны диварларга элгәннәр, алардан каллиграфия үрнәкләре альбомнары төзегәннәр. Татар сәнгатендә К. шәмаилнең бер төре буларак яши, кәгазьгә каләм һәм тушь б-н төшерелә, кайвакыт басыла.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

К. үрнәкләре фарсы телендәге поэтик тексттан өзек (авторы М.—Г.Мәхмүдев), гарәп телендәге икеюллык (авторы Йосыф Йасәри хәзрәт), Мөхәммәд әл-Бусыйри касыйдәсе кыяфәтендә Казан ун-ты Фәнни китапханәсе Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, ТРның Милли музеендә саклана.

Әд.: Шамсутов Р.М. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003.

*Р.И.Шамсутов.*

**КЫЗЫЛ АРМИЯ ҺӘМ ФЛОТ ӘДӘБИ ОЕШМАСЫНЫҢ ТАТАР СЕКЦИЯСЕ** (ТатЛОКАФ), Казандагы татар язучыларының иҗтимагый берләшмәсе (1930-32). Максаты: хәрби темага язучыларны берләштерү, Кызыл Армия һәм флотта хезмәт итүче каләмле яшьләрдән язучылар тәрбияләү. Оештыручылары: К.Нәҗми, Г.Иделле, М.Әмир. Татар телендә 4 җыентык чыгара: «Штурм» (1931), «Манёвр» (1932), «Кызыл Армия ударниклары», «Сакта» (1933).

*Н.Г.Гыйззәтуллин.*

# Л

**ЛАЖЕЧНИКОВ** Иван Иванович (14.9.1792, Коломна ш.—26.6.1869, Мәскәү), язучы, рус тарихи романына нигез салучыларның берсе. «Соңгы Новик» («Последник Новик», 1931—33), «Боз йорт» («Ледяной дом», 1835), «Мөселман» («Басурман», 1838), «Опричник» (1843) һәм «Матери—соперницы» («Көндәш әниләр», 1867) тарихи драмалар, повестьлар авторы. 1824 тән Казанда яши. 1825 нең сентябрь-декабрендә Казан ун-ты студентлары инспекторы, 1827 гә кадәр—Казандагы ир балалар гимназиясе һәм Казан губ. халык училищелары директоры, соңыннан Мәскәүгә күчә. Казан чоры «М.Л.Магницкийны мин ничек белә идем» («Как я знал М.Л.Магницкого», 1866) очеркында чагылган. Анда Л. ун-тагы иҗтимагый атмосфера турында яза, Казан аристократларын, шәһәрнең мәдәни тормышын тасвирлый.

Әсәр.: Полн. собр. соч.: В 12 т. СПб.—М., 1899—1900.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ЛАИСОВ** Наип Хәбибназар улы (10.8.1935, Актаныш р-ны, Түбән Яхшый а.), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1970), проф. (1996), ТРның атказ. укытучысы (1993). 1962 дә Алабуга пед. ин-тын (2003 тән Алабуга пед. ун—ты) тәмамлагач, ш.у укыта. 1971-80 декан урынбасары, филол. факультеты деканы, 1980-89 проректор, 1989-2000 ректор, берүк вакытта, 1994 тән татар филология кафедрасы мөдире, 2000 нән әдәбият кафедрасы мөдире. Хәзмәтләре Г.Тукай иҗатына, 20 йөз башы татар поэзиясе, рус-татар әдәби багланышлар, Г.Тукай әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Теория литературы. К., 1974 (авторлдаш.); Лирика Тукая (вопросы метода и жанра). К., 1976.

**ЛАТЫЙП** (Латыйпов) Галимҗан Шакир улы (20.1.1912, Уфа губ. Яна Дөмәй ав.—4.11.1986, Казан), шагыйрь. Казан финанс-экономия ин-тын тәмамлый (1939). Фин сугышында катнаша. 1941-51 елларда республиканың тикшерү-финанс оешмаларында инспектор булып эшли. 1951-60 та «Пионер» ж-лы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире. Беренче шигырь җыентыгы («Юл буйлап») 1939да басылып чыга. Л.ның «Хезмәт иртәсе» (1950), «Кыр чәчәге» (1958), «Шигырьләр» (1962), «Чын күңелдән» (1964), «Адымнар» (1967), «Кояшлы яңгыр» (1971), «Свет над Волгой» «Идел нуры» (1973) «Жир жыры» (1983) исемле җыентыкларына туган илгә багышланган, халыклар дуслыгын чагылдырган, авыл тормышы, гаилә бәхете турындагы лирик һәм шаян шигырьләре, җырлары, балладалары, поэмалары тупланган. Ул шулай ук Е.Исаев, Д.Бедный, С.Михалков, А.Твардовский, П.Неруда, Н.Вапцоров шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итүче; популяр җыр текстлары авторы да.

Әд.: Нуруллин И. Галимҗан Латыйп шигырьләре // Совет әдәбияты. 1949. №12; Сәхапов Ә. Тынгысыз хисләр җырчысы // Мирас. 2002. №1.

**ЛАТЫЙП** (Латыйпов) Кави Таһир улы (1.5.1927, Чуваш АССРның Батыр р-ны Кызыл Чишмә ав.—13.4.2008, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Бөек ватан сугышында катнаша. А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1971). 1955-57 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә к-ты инструкторы, 1957-59 да ТАССР Мәгариф министрлыгы инспекторы, 1959-62 та Казан телестудиясе редакторы, 1962-78 дә Казан дары з-дының күп тиражлы «Ленинчы» газетасы редакторы, 1978-82 дә СССР ПФАнең проф.-техн. педа-

гогика Казан ФТИ өлкән фәнни хезмәткәре. Әдәбияткә фронт көндәлеген чагылдырган «Солдат эзләре» (1960) дигән шигырь җыентыгы белән килеп керә. Бөек Ватан сугышы темасы, туган илне дошманнардан саклаучы геройлар турындагы шигырьләре «Умырзая» (1966), «Краски жизни» («Тормышның төсләре» М., 1973) җыентыкларында да дәвам итә. Л. поэзиясенә кыскалык, тирән эмоциональлек хас. 1980 елларда Л. ирекле шигырь—верлибрга мөрәҗәгать итә, аның шигырьләрендә көтелмәгән кыю рифма, кинәт кенә ритм үзгәреше күзәтелә: «Вакыт канатында» (1983), «Хәтер йомгагы» (1986), «Иркен сулыш» (1991), «Иман кәрваны» (1997), «Утлы күмер» (2005) җыентыклары шундыйлардан. Л. прозаик буларак та билгеле. Л.ның «Мизгел» (1972), «Ефәк әрем» (2002) җыентыкларына кергән хикәя һәм повестьларында Бөек Ватан сугышы вакыйгалары кабат истә яңартыла. «Йолдыз тапкан егет» (1964; чувашчага тәрҗемәдә «Шылтыр тупны качча», Чабаксар, 1972) док. повесте космонавт А.Н.Николаевка багышлана. Ул И.Я.Яковлев исем. Чуваш милли пр. лауреаты. 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнгән; Чуваш АССРның, ТРның Почёт грамоталарына ия (1984, 2002).

Әд.: Юзеев И. Кави Латыйп // Казан утлары. 1983. №1; Юмарт Г. Голос поэта // Ялав. 1983. №5; Әхмәтҗанов М. Күңеле һаман унҗидедә // Килер бер көн. К., 1988; Гатауллин Р. Үҗәт яугир, самими шагыйрә // Казан утлары. 2002. №5.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЛАТЫЙФИ** (Латыйпов) Флүс Фатыйх улы (3.6.1943, Мөслим р-ны Мөслим ав.—16.2.2010, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, публицист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1967-68 елларда «Кооператор Татарстана» («Татарстан кооператоры») газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1968 дән Телевидение һәм радиотапшырулар буенча ТАССР Дәүләт к-тында башта хәбәрче, мөхәррир, сонрак яшьләр тапшырулары редакциясе мөдире. 1985 тән «Социалистик Татарстан» газетасы хәбәрчесе, 1986 дан (өзеклек белән) «Казан утлары» ж-лы (1997 дән баш мөхәррир урынбасары) , 1993-97 дә «Татарстан» ж-лы баш мөхәррир урынбасары. Хикәяләр һәм лирик повестьне үз эченә алган беренче «Кырагай» исемле җыентыгы 1988 дә басыла. «Вөҗданыңнан сора» (1988) дигән очерклар һәм публицистик мәкаләләр җыентыгы Х.Ямашев премиясенә лаек булды. Катлаулы сюжетка корылган тарихи-мавыктыргыч «Хыянәт» романы (1993; русчага тәрҗемәдә «Измена», 2004) Казан ханлыгының соңгы берничә ел вакыйгаларын чагылдыра, ике яшь кешенең мәхәббәт тарихын тасвирлый. Л. татар язучылары арасында беренчеләрдән булып румын татарларының халык авыз иҗатына игътибар итте, тарихи «Чурабатыр» эпосын (1993) хәзерге татар теленә тәрҗемәдә бастырып чыгарды. Аның «Тамга—След» (1993), «Соңгы кисәтү» (1995), «Игезәкләр» (1996) повестьлары фәнни-фантастик жанрда язылган. «Әманәт» хикәяләр җыентыгы, «Ишелеп төшкән бәхет» (2001) һәм «Бәйсез этләрне атарга» (2002) романнары яшьләр тормышыннан алып язылган.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 2001.

Әд.: Галиуллин Т. Тарихыңны оныткан—киләчәгең юк // Замана балалары. К., 1993; Сафин Ф. Хыянәтсез иҗат // Казан утлары. 2001. №6; Заһидуллина Д. Милли реализм юлыннан // Казан утлары. 2003. №6.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЛӘТЫЙФӘ**, мөселман Көнчыгышы халыклары фольклоры һәм әдәбиятында, ш.и. татар сүз сәнгатендә кече эпик жанр. Гарәп, фарсы һәм төрки-татар телләрендә мәзәк һәм хикәят жанрлары б-н беррәттән кулланган. Л.кә кыскалык, юмористик яки сатирик яңгыраш, көтелмәгән азаккы өлеш хас; омонимия, ирония, алогизм, күпмәгънәлек, гипербола һ.б. сәнгати чаралар, телнең стилистик алымнары киң файдаланыла. Л. жанрында язылган әсәрләр тематика һәм персонажлар (Хуҗа Насреддин, Бирбал) тирәсендә тупланалар; төрки-татар шагыйре Сәйф Сараи һ.б. иҗатында очрыйлар. 19 йөздә берничә Л. җыентыклары басыла («Ләтаифе Хуҗа Насретдин» һ.б.).

Әд.: Миңнегулов Х. Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты. К., 1976.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ЛЕБЕДЕВ** Константин Валильевич (18.8.1921, Чуваш АССРның Алатырь р-ны, Сутяжное а.—1.7.2000, Казан), язучы, медицина фән. канд. (1952). Сов.-фин сугышында катнаша. Казан медицина ин-тын тәмамлагач (1945), ш.у. укыта (1946-77). Бөек Ватан сугышы елларында зыялылар тормышыннан «Сынау көннәре» («Дни испытаний», 1949), медицина ин—ты укытучылары һәм студентлары тормышыннан «Кешеләр һәм дәрәҗәләр» («Люди и степени», 1956) романнар, Н.А.Миславский, Н.О.Ковалевский тормышы һәм эшчәнлеге турындагы очерклар авторы.

Әд.: Гиниятуллина А.К. Писатели

Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ЛЕБЕДЕВА** Ольга Сергеевна, к. Гөлнар ханым.

**ЛЕВАДНАЯ** (чын фам. Измайлова) Ольга Георгиевна (2.6.1958, Украина ССР, Сумы ш.), шагыйрә. 1971 дән Казанда яши. 1978 дән ВЛКСМның Мәскәү райкомында статистик, 1981 дән кибет администраторы, 1988 дән Мәскәү р-ны ЗАГСында эшли. «Кар көтеп яшим» («В ожидании снега живу», 1992), «Сихер аша узу» («Пройти заколдованный круг», 1998), «Канат җилпешем» (2003), «Уйлар баскычыннан меңгәндә» («Поднимаясь по лестнице раздумий», 2005), «Кошлар тавышыннан истәлекләр туа» («Из крика птиц растут воспоминания», 2005). Л. поэзиясенә лирик һәм фәлсәфи янгыраш, ритмлык һәм музыкальлек хас.

Әд.: Кутуй Р. И гнёзда, сохранившие тепло... // Казань. 2003.№1.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ЛЕОНОВ** Леонид Максимович (19.5.1899, Мәскәү—7.8.1994, ш.у.), язучы, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1972), Соц. Хезмәт Герое (1967). «Бурсыклар» («Барсуки», 1924), «Карак» («Вор», 1927), «Океанга юл» («Дорога на океан», 1935), «Рус урманы» («Русский лес», 1953; Лен. бүләге 1957), «Пирамида» (1994) романнары, повестьлаәр, пьесалар, публицистик мәкаләләр һ.б. авторы. 1941 нең октябреннән 1942 нең мае ахырына кадәр Чистайда яши. Кабат 1942 нең октябрь-ноябрендә һәм 1943 нең июнендә була. Чистай чорында «Ябырылу» («Нашествие», 1942; СССР ның дәүләт бүләге 1943), «Безнең Мәскәү» («Наша Москва», 1941), «Язучылар фронтта» («Писатели на фронте», 1942) мәкаләләре языла, «Ленушка» (1942-43), «Алтын карета» («Золотая карета», 1946) пьесалары языла башлый. Л. шәһәрнең мәдәни тормышында актив катнаша, аерым битләре Алабуга һәм Камага багышланган булган «Океанга юл» романыннан өзекләр укый.1942 нең октябрендә «Ябырылу» пьесасын сәхнәләштерүдә катнаша (премьерасы 1942 нең ноябрендә була). 1943 нең мартында пьеса Казан зур драма театрында, 1980 дә Казан академия театры сәхнәләрендә куела. Л.ның күп кенә әсәрләрендә («Ябырылу», «Алтын карета», «Рус урманы», «Великошумскны алу»—«Взятие Великошумска» повесте) Чистай һәм Казанда алган тәэсирләре чагылыш тапкан. СССРның Дәүләт бүләге (1977) лауреаты. 1946—70 тә СССР ЮС депутаты.

Әдә.: Давыдов И.В. С думой о фронте. К., 1984.

*Г.С.Муханов.*

**ЛЕРОН** Ләбиб (псевд., чын исем-фам. Леронов Лемон Лерон улы) (11.11.1961, Мөслим р-ны Иске Карамалы ав. туа), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый(1984). 1983-89 елларда (өзеклек белән) «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли (1988-89 да әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире), 1986-88 дә ТР язучылары Әдәби фондынын директоры, 1989 дан «Салават күпере» ж-лы мөхәррире. Балалар өчен язылган «Янгырның ял көне» (1988), «Транзистор үч ала» (1989), «Тәгәрмәчле чана, яки Әкият боткасы» (1993), «Шүрәле шаяруы» (1996), «Таһир мажаралары» (1999), «Кояшны кочкан малай» (2004) китаплары юморга һәм фантазиягә бай. Ул шулай ук «Сине генә сөям» (1997) исемле лирик-публицистик шигырьләр җыентыгы һәм татар язучыларына пародиялар һәм эпиграммалар тупланган «Күрше тавыгы» (1990) «Сөяксез тел» (2008) кебек җыентыклар авторы да. Әлмәт татар драма т-ры Л.ның «Чәпәләй белән Тәпәләй» (1995), «Ангыра сарык җүләре» (1996) пьесаларын сәхнәләштерде.

Әд.: Әдипләребез: библиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**ЛИБРЕТТО** (итал. libretto—кечкенә китап), 1) опера, оперетта, оратория өчен язылган әдәби текст (М.Җәлилнең «Алтынчәч» операсы, Ә.Фәйзинең «Ильдар», «Шагыйрь», Ә.Исхакның Г.Бәширов романы буенча язылган «Намус», Х.Вахитнең «Самат», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик», һ.б. оперлар; Р.Хариснын «Кеше» поэмасы буенча язылган ораториясе, Т.Гыйззәтнең Х.Ибраһимов пьесасы буенча язылган «Башмагым» муз. комедиясе Л.лары); 2) балет, пантомиманың әдәби сценарие (Ә.Фәйзи һәм Л.Якобсонның «Шүрәле» балеты, Ә.Фәйзинең Г.Тукайның «Печән базары, яхут Яна Кисекбаш» поэмасы буенча язылган «Кисекбаш» балеты Л.лары); 3) театр программасына яки аерым китапчыкка язылган опера һәм балетның эчтәлеге (М.Җәлилнең «Дулкыннар» («Балыкчы кыз») һәм «Хәмидә» оперлары); 4) кинофильм сценариенең сюжет планы яки схемасы (Гәрәй Рәхимнең «Борынгы Болгарны сагыну» Л.сы).

*Н.Г.Ханзафаров.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА ТАТАРГА КЕМ ТИЯ УЛ?

Әүхәди агай Бәйрәмов фин сугышыннан инвалид булып кайта. Әгәр бөтенләй дә кайта алмаса? Ул чакта Фәүзия Бәйрәмова дигән татар кызы дөньяга килмәс иде бит. Нинди кимәлдәге югалту булыр иде икән бу?

Фәүзиябез нәкъ алтмыш ел элек, 5 декабрьдә килә безнең бу бимазалы дөньяга. Һәм әти-әнисенә генә түгел, башкаларга да кирәклеген бик тиз сизеп ала. Сигезенче классны тәмамлауга ук аны Саба район газетасына эшкә дәшәләр! Вакытның кадерен белеп, ашыгып яши Фәүзия. Урта мәктәптә һәм университетның татар теле, әдәбияты бүлегендә читтән торып кына укый.

Тормыш вариантлары күп була аның. Алтмыш еллыгын пенсиядәге журналист булып та каршылый алыр иде. Саба газетасыннан тыш тагын безнең «Казан утлары»нда, «Татарстан яшьләре»ндә, «Социалистик Татарстан»да (хәзерге «Ватаным Татарстан») һәм Татарстан китап нәшриятында (җәмгысе 12 ел) эшли ул. Күңелен шуңа гына салса, хәзер тәгаен олуг язучыларыбызның берсе булыр иде. Күпләгән проза китаплары (шул җөмләдән алты роман), бер пьеса китабы чыгарды, иҗатын Ә. Еники, А. Гыйләҗев кебек бөекләребез дә хуплады («Фәүзия бик тә талантлы һәм таланты аның гаять үзенчәлекле»—Әмирхан ага сүзе). Театр училищесының режиссерлык бүлеген тәмамлаган кеше буларак, сәхнәдә дә азмы-күпме уңыш казана алыр иде. Ләкин барын да узып бүтән хис, бүтән дәрт, бүтән омтылыш алга чыга. Фәүзия җитмеш ел өзеклектән соң беренче милли оешмабызны—Татар иҗтимагый үзәген оештыручыларның берсе. Аннан ул «Иттифак»ны бар итте. Максатының җегәрен исеме үк әйтеп тора: милли бәйсезлек партиясе. Ләкин Фәүзияне әйдәр (лидер) иткән нәрсә, оештыру эшчәнлегеннән дә алда, аның туры сүзле, ачы телле шәп оратор булуы. Беркадәр милли анга ия зыялырак катлауларны гына түгел, гап-гади әби-бабайларны да авызына карата алды ул. Халыкны шактый дәрәҗәдә Фәүзия уятты. 1990 елда Сабадан Татарстан Югары Советына депутат булып сайлануы—район башлыгын да җинеп—тикмәгә түгел, әлбәттә.

Депутат булгач, Бәйрәмованың ялкынлы сүзе тагын да зуррак егәр алды. 1995 елны исә, бу юлы Тукай районыннан, депутатлыкка үтмәде. Фәүзия шуннан соң татар халкына үпкә сүзләре дә әйтте әле. Ләкин халык дигәнебез (кешеләр суммасы?) шаукымга бирелүчән бит ул. Шактый көчәйгән һәм популярлашкан Татарстан җитәкчеләренә ул чорда милли хәрәкәт кирәкми иде шул инде. Һәм «административ ресурс» дигән озын кул сайлау бюллетеньнәренә дә житә башлаган иде кебек. Астыртын көчләрнең кулы да уйнады бугай. Ирек (Азатлык?) мәйданында үткән манифестация вакытында әле бер, әле икенче кеше янына килеп нәрсәдер әйтеп йөргән хатынга игътибар иткән идем. Менә ул минем каршыга килеп басты да, «А вы знаете, что Байрамова призывает уничтожить детей от межнационального брака?» диде. Мин мондый сүзне әйткән кешене күрсәтергә яки исемен атарга кушкач, ул шундук юкка чыкты.

Ләкин гаеп беркадәр Фәүзиядә дә бар иде түгелме. Ул үзен татар Жанна д'Аркы, һәр сүзе һәм гамәле 150 процент дөрес булган илаһи зат сыманрак хис итә башлады кебек тоела иде миңа.

Хәер, Фәүзия генәме? Сиксәненче елларның икенче яртысын искә төшерик әле. Татар файдасына да беркадәр үзгәрешләр булмас микән дип либераль табыннан сөяк ыргытканны көтсәк тә, тулы бер милли хәрәкәт пәйда булыр дип уйлый ала

идекме соң? Аны әйдәрлек затлар шәйләнми кебек иде чөнки. Ләкин шунда, шөкер, могҗиза булды. Бер-бер артлы калыктылар: Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова, Рафаэль Хәким, Фәндәс Сафиуллин, Зәки Зәйнуллин, Рашат Сафин (соңгы өчесе запастагы полковниклар), Рафаил Мөхәммәтдинов, Разил Вәлиев, Айдар Хәлим, Марсель Мусин, Батулла, Туфан Миннуллин, Мөхәммәт Миначев (Мәскәү), Илдус Әмирхан, Зиннур Әһлиуллин, Индус Таһиров, Гаял Мортазин, Фәрит Уразаев, Илдус Садыйков, Тәлгат Абдуллин, Наил Мансуров, Азат Зыятдинов, Рәшит Ягъфәров, Әмир Мәхмүдов, Вафирә Гыйззәтуллина, Әзһәр Шакиров, Дамир Исхаков, Рахмай Хисмәтуллин, Фәрит Хәбибуллин[1]...

«Могҗиза»ны тудырган сәбәпләр бар иде, әлбәттә. Бу—исән калган милли ан орлыкларының алтмышынчы елларда бүртә башлавы һәм аерым шәхесләребезнең тәгаен эшләре: Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» романы, «Кол Гали» драмасы, Әмирхан Еникиның «Әйтелмәгән васыять», Миргазиян Юнысның «Безнең өй өянке астында иде» хикәяләре, Әбрар Кәримуллинның татар китабын тикшергән хезмәтләре, әдәбиятка алтмышынчы елларда килгән шагыйрьләребез иҗаты... Һәм—яңа тарихи вәзгыять.

Ләкин ошбу «могҗиза»ның чиге-чамасы бар иде шул. Сыйфат ягы турында әйтүем. Нишләмәк кирәк, хәзинәдә бары инде. Татарның милли әйдәре, юл башчысы булырлык зат табылмады (гәрчә «бердәнберләр»—«Жанна» һәм «Жан»нарыбыз шактый булса да). Әйдәрләребезнең төп өлеше күп яки бик күп эш башкарды. Олы эшләр эшләүчеләр булды. Ләкин әлеге гамәлләр кайчакта үзара бетерешеп, нәтиҗә нульгә тигез була торган иде. Спорт теле белән әйтсәк, уртак җиңү хакына кертелгән голларның үзең керткәне генә кадерле булса, шәбрәкне керткән командадашыңа акаеп карасаң, җиңү тәтеми шул инде ул. Кызганыч ки, без дә җинелдек. Дәүләти җиңелүнең (сәбәпләре турында язган бар) бер өлеше булган милли хәрәкәтнең җиңелүен әйтәм... (Үзгә фикергә ихтирам белән карый белмәү татарның бер үзенчәлегедер инде ул. Ләкин, исән калыйк дисәк, безгә аннан арынырга кирәк. Адашканда юлны кем табуы түгел, юлның табылуы мөһим.)

Кайда ул хәзер безнең әйдәрләребез, һәм ниләр майтаралар? Арада инде бу дөньядан киткәннәре дә бар. Урыннары җәннәттә булсын! Татар хакын яклаудан читләшүчеләр бар. Эчүгә сабышучылар да бар кебек. Әкренрәк, салмаграк булса да, шул юлдан бара бирүчеләр дә бар, шөкер.

Фәүзиябез нишләде соң? 1995 елгы хәл аның өчен җан газабына әверелгән, шуңа тән газабы да өстәлгән: авыр операция кичергән. Һәм шул газаплар аша ул дингә килгән. Башкасын белмәсәк тә, яулык бәйли башлавын искәрдек бит. Берәүләр ошатмады. Ни гаҗәп, үзебезнең татар зыялылары арасыннан да яулык бәйләү турында гаепләп, нәфрәтләнеп диярлек сөйләүчеләр булды. Ярымшәрә йөрүләргә бер дә нәфрәтләнмибез юкса. Аннан, яулык татарның милли киеменә дә әйләнгән бит инде...

Һәм Фәүзиябез җигелеп эшкә тотынды. Рәсәйнең татарлар яшәгән бөтен төбәкләрен дә йөреп чыгып килә инде ул. Быел гына да 15 җиргә барган. Үзен-үзе командировкага җибәреп, бөтен мәшәкатьләрне үз өстенә алып, акчасын да үзе табып (башта Татар конгрессы да биргәләгән юкса). Баргач, шул як татарларының үткәнен һәм бүгенге хәлен җентекләп өйрәнә,—галим буларак та, милләтпәрвәр буларак та. Төрле җирдә, 10ар, 15әр тапкыр, халык алдында чыгыш ясый. Соңыннан бу сәяхәтләр мәкаләләр, китапларга әйләнде. Йөргән аякка җимнең төрлесе ияр. Чиләбе ягына баргач, атом сынавының агулы эзе сакланган зонадагы авылларның күчерелүен, Мөслим һәм Татар Караболагы дигән татар авылларының гына торып калганлыгын белә. Бу якларга унлап тапкыр килеп, хәлне кат-кат өйрәнә. «Ябылган тема, кагыла күрмә!» дип кисәтүләргә дә карамыйча, кабат-кабат чаң суга. Чыннан да, файдасы тими. 2006 елны аның «Атом-төш архипелагы яки татарга каршы геноцид» дигән китабы Германиядә немец телендә басылып чыга. Шул китабы белән 2007 елны Берлинда үткән халыкара китап ярминкәсендә катнаша. Шуннан соң Германия Бундестагының «яшел» (табигатьне яклаучы) депутатлары да шау-шу

[1] Бу — минем вариант. Исемлеккә кертмәгәнсең дип яки керткәнсең дип (замана үзгәрде!) тотып кыйнамасалар ярый инде.

күтәрә. Һәм, ниһаять, Мөслим авылы күчерелә.

Беләбез бит инде(шул белүдән әллә ни узмасак та!), милли эшчәнлегенә бәйле рәвештә Фәүзиягә җинаять эше ачылган иде. Бәләкәй генә күнелсезлек чыкканда да адәм баласының төн йокылары кача. Ике елга сузылган тикшерү һәм хөкем эшләре вакытында инде болай да күп ыгы-зыгылар кичергән кешенең, хатын-кызның нервылары ничек чыдагандыр да, йөрәге ничек түзгәндер? Әгәр дә бирешсә, көчсезлек, мескенлек галәмәте сизелсә, моның калтыраулы кара шәүләсе бөтен милли хәрәкәтебезнең киләчәгенә төшәчәк иде. Әмма, шөкер, Фәүзия нык торган. Шартлы рәвештә бер елга хөкем иткәннәр, соңыннан җәза җиде айга калдырылган. Бу вакыт үтте инде. Фәүзия һәм аның адвокаты, хөкем карары белән килешмичә, эшне Страсбурдагы халыкара судка җибәрәләр. Кабул ителә.

Шул ике ел эчендә Фәүзияне шаккатырган нәрсә була: берәүләрнең аны күргәч урамның икенче ягына чыгулары, исәнләшмәүләре, «танымаулары». Бәладән башаяк, янәсе. 1944 елда без татарлар Кырым татарларын да танымый башлаганбыз әнә. Имеш, алар безгә беркем дә тими. Халкыбызның Фәүзиягә мөнәсәбәте элек тә каршылыклырак иде. Йә, уйлап бетерик инде: кем тия икән татарга Фәүзия Бәйрәмова?

Кемнең кемлеге хәлиткеч мәлләрдә беленә ул. 1991 ел августының өч көнен онытмагансыздыр, шәт. ГКЧПга каршы Казанда үткән демонстрациядә Татарстан хакимиятеннән һәм татар милли хәрәкәтеннән бердәнбер Фәүзия Бәйрәмова катнашты. (Сталин конституциясе көнендә туган кеше!) Шул өч көннең соңгысында мин гомеремдә беренче тапкыр кулыма чын листовка алдым. Фәүзиядән. Эш урынында (Китап нәшрияты) ябыштыр дип бирде. ГКЧПга каршы листовка!

Шул елның асфальт эретерлек эссе май көннәре дә истән чыкмаячак. Татарстан Югары Советы депутаты Бәйрәмова ачлык игълан итте—Россия президентын сайлауны Татарстанда үткәрмәүне таләп итеп. Бу сәяси ачлыкка кушылучылар тагын да булды. Ләкин ул хакимият өчен дә, халык өчен дә иң әүвәл ул чакта үтә популяр Ф. Бәйрәмова акциясе иде. Җиңү дә (Югары Советыбыз Россия президентын сайлау Татарстанда рәсми төстә үткәрелми дигән карар кабул итте) иң әүвәл, әлбәттә инде, аныкы иде. Барысыннан да озаграк ач торды Фәүзия— 14 көн. Бик кадерле җиңү бу, ул яуланмаса, Татарстан үзеннән-үзе Россия составында булып килеп чыгасы иде.

«Фәүз» гарәпчә җинеп чыгу дигән сүз. Хәер, аның тагын бер мәгънәсе бар әле: бәладән котылып исән калу. Фәүзиягә моны искә төшерер җай чыккалап тора. 1994 елны аларның подъездында шартлау була, ике кеше үлә... 1999 елны биш кеше, Фәүзиядән тыш мөфти Габдулла хәзрәт, Айдар Хәлим, Милли Мәҗлес сәркәтибе Зөһрә Айсина, һәм алар белән тагын, «Независимая газета» хәбәрчесе буларак, Вера Постнова, Уфага баралар һәм татар телен дә Башкортстанның дәүләт теле итүне таләп итеп көндез пикет үткәрәләр. Шунда аларны милиция бүлегенә алып китеп, төнге уникегә кадәр тоталар. Кайтканда машиналары капланып, аздан гына үлми калалар. Алла саклады, ди Фәүзия. Аның кулы сына, умыртка сөяге зыян күрә. НТВ каналы соңыннан шушы хакта зур гына тапшыру бирә, бу махсус оештырылган автокатастрофа дип раслый.

Сүземнең азагында Фәүзияне кәнәфигә утыртып калдырасым килә. Моның өчен янә 1991 елга әйләнеп кайтыйк әле. Сәяси ачлыкта көннәр буе каты урындыкта утыру читен буласын уйлап, Китап нәшрияты егетләре Фәүзиягә йомшак кәнәфи алып килделәр. (Кайда икән хәзер бу Дәүләт музееның түрендә торырга тиешле экспонат?) Яшьләр Югары Советта чыгыш ясарга депутатны әнә шул кәнәфидә күтәреп алып кереп киттеләр. Шунда мин Фәүзиябезне рухи тәхеттә утырган итеп хәтерләп калдым.

**Рәфикъ ЮНЫС**




# «РУХИ ТОРМЫШЫБЫЗ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ»

*«Казан утлары»ның меңенче саны чыгу уңаеннан «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китабыбыз нәшер ителүгә (2006 ел, декабрь) дүрт ел тулды. Бу вакыт эчендә китап Татарстан һәм Россиянең барлык төбәкләренә дә диярлек барып иреште, Төркия, Англия, Америка, Австралия, Кытай кебек илләргә дә юл тапты. Аның турында матбугатта бик матур фикерләр әйтелде. Менә аларның кайберләре.*

**Айдар ХӘЛИМ,** *язучы:*

—Үткән һәм килгән еллар чигендә төрки-татар халкы тарихында, юк, бөтен дөньяның мәдәни харитәсендәдер, чын-чынлап кабатланмас, гаҗәеп вакыйга булды: бик шәп проза, новеллистика, поэзия, публицистика, фотоиллюстрацияләрнең һәм иҗади фикер документларының яраткан журналыбыз «Казан утлары»ның меңенче саны чыгу уңаеннан бер түбә астында берләштерелгән бик зур, 90 табаклы томы дөнья күрде... Бу уникаль басма турында тагын ни әйтим? Аны күрергә кирәк. Аны тоярга кирәк. Һәм сезнең алда соңгы йөзьеллыкның бөтен әдәби-рухи тарихы ачылачак.

*Звезда Поволжья.*
*2007, 7 март.*

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,** *филология фәннәре докторы, профессор:*

—Китапларның төрлесен күргән, «Казан утлары»ын да бик күптәннән укып барган кеше буларак, бу басманы мин, йә, ни майтардылар икән дигәндәй, скептик рәвештәрәк кулга алдым һәм... исләрем-акылларым китте. Чын мәгънәсендә бер хәзинә бу...

Журналның гына түгел, ә гомумән татар рухи тормышының, милли яшәешенең бер белешмәсе, чыганагы, энциклопедиясе, хрестоматиясе кебек тә ул.

*Мәдәни җомга.*
*2007, 2 март.*

**Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,** *публицист, тәнкыйтьче:*

—Җыентык, һичшиксез, халкыбызның үзаңын үстерүгә өлеш кертәчәк!.. Бу җыентыкта берничә докторлык диссертациясе өчен «азык» бар.

*Мәгърифәт.*
*2007, 14 апрель.*

**Рәис ДАУТОВ,** *тәрҗемәче, әдәбият белгече:*

—Үткәндәге мәдәни-иҗтимагый тормышыбызның куанычлы һәм аянычлы этапларын язма әдәби материаллар мисалында объектив рәвештә яктырткан уникаль китап-антология... Тарихи әһәмияткә ия зур бер яңалык, казаныш.

*Балачак әдипләре. Дүртенче китап.*
*2008, 230 б.*

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,** *язучы:*

—Укучылар кулына инде «Татар энциклопедиясе», «Татар тарихы» дигән олуг хезмәтләрнең кайбер томнары килеп иреште. Һичшиксез, «Сүнмәс утлар балкышы»

дип аталган китап та киштәбездә шулар янәшәсендә урын алырлык.

*Идел.*
*2007, № 4.*

**Рафаэль МОСТАФИН,** *әдәбият белгече, тәнкыйтьче:*

—Татар әдәбиятының бу үзенчәлекле антологиясен укыганда тулы бер дәверне яшәп чыккан кебек буласың, еш кына катлаулы һәм авыр, кайчакта исә фаҗигале дә булган вакыт сулышын тоясың.

*Звезда Поволжья.*
*2007, 31 май.*

**Адлер ТИМЕРГАЛИН,** *язучы:*

—Уртакул американ төрмә бинасына тартым «хрущоба»ның кысан фатирмәгарәсендә, һава житмәгәндә тәрәзә ачкалап утырам. Теземдә кызыл мәрмәрдәй саллы том—үзе бер китапханәгә бәрабәр «Сүнмәс утлар балкышы». Мин бу утларның саллы җылысын тизләрем белән дә, күңелем белән дә тоям...

Әгәр дә мәгәр бер мәлне мине адәм заты яшәми торган утрауга озатасы булып, үзем белән ун китап алырга рөхсәт итсәләр, шуларның берсе һичшиксез «Сүнмәс утлар балкышы» булыр иде. Алай-болай ерак йолдызлара сәяхәткә чыгып китсәм дә үзем белән алыр идем мин аны...

*Казан утлары.*
*2008, № 1.*

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,** *язучы, тәнкыйтьче:*

—Язучыларның гына түгел, үзен зыялы санаган, күңелендә милләт язмышы хакында аз-маз уй-фикер, милли хис йөрткән һәр татарның өендә бу китап булырга тиеш ләбаса. Чөнки әлеге җыентык чын мәгънәсендә уникаль, кабатланмас басма, татар халкының хәзерге буыны андыйны бүтән күрә алмаячак...

*Мәдәни җомга.*
*2007, 13 апрель.*

**Булат СОЛТАНБӘКОВ,** *тарихчы:*

—Дәвер тарихы—бу уникаль басманы шулай дип атыйсы килә... Аның гомере озын буласына һич шикләнмим. Татар мәдәниятенең үзенчәлекле бер энциклопедиясе булган ошбу китап бөтен уку йортларыбызда һәм китапханәләребездә булырга тиеш.

*Республика Татарстан.*
*2007, 29 май.*

**Язилә ШӘРИФУЛЛИНА,** *журналист:*

—«Сүнмәс утлар балкышы»н карап, укып чыккач ук күңелгә энциклопедик характердагы бу китапны, һичшиксез, дусларыма бүләк итәчәкмен дигән уй туды. Чынлап та, рухи бөтенлектәге кеше өчен бүген шушыннан да зур бүләк бармы соң?

*Татар иле.*
*2007, № 9.*

**Китап редакциядә бар әле (сатуга чыгарылмады).**
***Адресыбыз:* Казан, Декабристлар ур., 2. «Казан утлары». 10нчы кат.**
***Белешү өчен телефоннар:* 562-10-62, 292-93-16.**

# 2010 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2010 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. № 6

**ТАТАРСТАН АССР ТӨЗЕЛҮГӘ 90 ЕЛ**

Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы турында декрет. № 5

Таһиров И. Татарлар дәүләт төзү юлында. *(Татарстан АССР төзелүгә 90 ел).* № 4

**МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Юныс Р. «Бу—төкәнмәс көрәш!» № 1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Бәйрәмова Г. Син һаман шул сандугач. *Кыска бәян.* № 6

Габделхакова Р. Тау артында кояш бар. *Роман.* №№ 4-7

Гыйматдинова Н. Эзләмәгез җирдән... *Бәян.* № 6

Гыйсметдин Д. Божра буйлап. *Бәян.* № 11

Җамалетдинова Ф. Исемнәре Искәндәр... *Хикәя.* № 3

Зәйнуллин З. Лотфулла солдат. *Бәян.* №№ 11-12

Камалов Х. Үлем куа килә. *Фронт истәлекләреннән.* № 5

Кәримов К. Күрше авыл кызы. *Бәян.* №№ 1, 2

Кәримов К. Игезәкләр йолдызлыгы. *Роман-фарс.* №№ 9, 10

Маликова М. Юкә чәчәк аткан чак иде. *Роман.* №№3-6

Мирхәйдәров Р. Җәяүле сәйран. *Роман.* №№ 1-3

Мушинский Ә. Һаваларда—ак күгәрчен... *Роман.* № 12

Мөхәммәдиев Р. Кыргый атауга сәяхәт. *Хикәя.* № 9

Низами Р. Сәйдәшнең соңгы елы. *Кыйсса.* №№ 1, 2

Рахман Р. *Хикәяләр.* № 3

Тимергалин А. Карурман аша... *Хыялый кыйсса.* № 8

Хәмзин А. Кырык сигез кило. *Хикәя.* № 2

Хәсәнов А. Данәгөл. *Роман.* №№ 7, 8

Хәсәнов Ә. Әҗәт. *Хикәя.* № 7

**ШИГЪРИЯТ**

Әхмәдиев Н. Шәм кабызам. *Шигырьләр.* № 8

Әхмәтҗан Роб. Тукай катламы. *Шигырь.* № 4

Әхмәтшина М. Язмышлар ярда кавыша. *Шигырьләр.* № 5

Баян Ә. Гөмбәзеннән төшми сөю-ай. *Шигырьләр.* № 3

Булатова К. Сәфәр чыккан кешегә. *Шигырьләр.* № 9

Вәлиева Р. Татар кызына. *Шигырьләр.* № 5

Гадел Ә. Табигатькә—сөю җырым... *Шигырьләр.* № 2

Гыйззәтуллина Ф. Ватан көзгесе. *Шигъри дастан.* № 4

Гыйләҗев И. Фикердәшләр, бергә берләшик тә... *Шигырьләр.* № 1

Дәрзаман Ж. Ап-ак карлар ява... *Поэма.* № 10

Җиһангирова Ш. Дөнья буйлап. *Шигырьләр.* №12

Зәйдулла Р. Татар булып калыйк! *Шигырь.* № 10

Иделбикә. Гомер симфониясе. *Шигырьләр.* № 8

Идиятуллин Р. Гомер—кыска кыйсса гына... *Шигырьләр.* № 2

Кәрим Ф. Ант. *Шигырь.* № 5

Майорова Р. Кая болай ярсый әле күңел?.. *Шигырьләр.* № 2

Мингалим Р. Юллар... юллар. *Шигырьләр.* № 5

Миңнеруй. Гөмбәз бишегендә. *Шигырьләр.* № 3

Миңнуллин Р. Татар киңлекләрендә. *Шигырьләр*. № 8

Мирза М. *Газәлләр, робагыйлар*. № 2

Морат Г. Яңа елда—ак карлар. *Шигырь*. № 1

Мөҗәһит. Матур кешеләр бар. *Шигырьләр*. №12

Мөхияр Р. Уян, халкым!.. *Шигырьләр*. № 3

Мөхәммәтшин Р. Нәтиҗәләр чыгарыр чак җитте. *Шигырьләр*. № 10

Мөхәммәтшин Г. Көт кенә гомер язымда... *Шигырьләр*. № 10

Низами Р. Вакыт эргәсендә. *Шигырьләр*. № 7

Рахман Р. Әзер калыпларга сыймас хис бу... *Шигырьләр*. № 1

Рәхим Г. Менә шундый хәлләр... *Шигырьләр*. №12

Рәхимова Б. Дөнья тынып калган ак тында. *Шигырьләр*. № 10

Рәшит Ә. Йолдыз белән йолдыз арасы. *Шигырьләр*. № 6

Сафина Н. Күңел фасыллары. *Шигырьләр*. № 11

Сөләйман. Кыйбла. *Биләр дастаны. (Г. Рәхимнең кереш сүзе белән)*. №7

Ситдикова Ә. Иңнәремдә өмет—канат. *Шигырьләр*. № 3

Суфиянов А. Тормыш йөрәгенә—чәчәк. *Шигырьләр*. № 8

Туфан Х. Ә йолдызлар дәшми. *Шигырьләр*. №12

Фәйзуллин Р. Булган инде гамәлләрнең төрлесе. *Шигырьләр*. № 9

Хәлим А. Онытылган агач. *Шигырьләр*. № 11

Шагыйрьҗан Л. «Шигъри тамчылар» циклыннан. *Афоризмнар һәм хикмәтле фәлсәфи сүзләр*. № 6

Шаһи Р. Шигърият—тереклек суы... *Шигырьләр*. №12

Шәех Л. Бер көләчәк әле кояш та. *Шигырьләр*. № 2

Шәрипов Р. Ике шигырь. *Шигырьләр*. № 5

Якупова С. Сүзгә төреп, җыр-сер иттем. *Шигырьләр*. № 6

Яруллин Ф. Чиксезлекләрнең мин чигендә. *Шигырьләр*. № 1

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Лерон Л. Кычыткан чыпчыгы. *Моңсу комедия*. №12

Миңнуллин Т. Мулла. *Ике пәрдәле драма*. № 8

Хәким З. Кайда син, Аттила?! *Тарихи драма-роман*. № 10

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Вәлиулла И. Аллаһ боерса, мәчет тавына ап-ак карлар явар... № 11

Зарипов Р. Кояшка каршы һөҗүм. №№ 6,7

Мушинский Ә. «Сүздән олы берни юк!» № 4

Юныс Р. Татар батырмы? № 5

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әхмәдуллин А. Әдәбиятыбыз тарихы төрек телендә. № 7

Вәли Р. Батыр йөрәк шигърияте. № 3

Галиуллин Т. Илһам учагың сүрелмәсен. № 3

Закирҗанов Ә. Татар трагедиясе. № 3

Мостафин Р. Белешмәлек кенә түгел, фәнни хезмәт. № 9

Низаметдинова Г. «... Ат уйнаклый һаман шигыремдә». № 9

Таҗетдинова М. Коръәннең Такташка тәэсире. № 1

Тимергалин А. Ике сандык йакут. № 2

Фазлетдинов И. Тетрәнүләр шигърияте. № 2

Ханнанов Р. Шартлы дөнья. № 7

Хәсәнова Ф. Шигърияттә—яңалык. № 4

Шәех Л. Шигъри трагедия остасы. № 4

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Ахунов М. Кычыткан телне сүз кашыр. №12

Әмирханов М. Их, мать якасын, Черчилегезнең сатыйм каргасын... № 10

Батулла. Төнге мәҗлес. № 11

**ФӘН**

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №№ 1-12

Исхаков Д. Татар юлы такыр түгел... *(Татарның этник тарихы, халыкны исәпкә алу һәм сәясәт)*. №№ 9-11

Хисамов Н. Үлемсез «Кыйссаи Йосыф». № 7

ТАРИХ

Бәйрәмова Ф. Далада—татар курганнары. №12

Миңнегулов Х. Халкыбызның зыялы улы. № 3

Халиков А. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. №№ 2,4,5

СӘНГАТЬ

«Әни...» күп театрларга килде. *(СССРның халык артисты Ш. Биктимеров белән Р. Юсупова әңгәмәсе).* №12

Бәйрәмова Г. Кыйммәтле хәзинә остасы. № 5

Вахитов Р. Әниләр-апалар турында. № 3

Иске Аракчиноның күккә ашуы *(Р. Низаминың И. Ханов белән әңгәмәсе).* № 11

Мәһдиев Р. Татар ядкаре. № 10

Мулюков Б. Халыкның моңлы улы. № 1

Шакиров Ә. Тарих сәхнәсендә—без эзлебез... *Артист монологы.* № 2

Шакиров Ә. Булмас димә, дөнья бу! № 11,12

ХӘТЕР

Вәлиди Җ. Милли мәктәп вә милли тел. № 6

Вәлиев М. Тынгысыз җан иде... *(Нәби Дәүлинең туувына 100 ел).* № 6

Галиев М. Ике урман чигендә. № 3

Галимуллин Ф. Халыкка багышланган гомер *(Мансур Хәсәновның туувына 80 ел).* № 6

Госманов М. Уйландыра торган уйлар. № 6

Госманов М. Аксакаллар мәҗлесеннән. № 11

«Мин йолдыз түгел, җырчы гына» *(Ф. Фәтхинең мәшһүр җырчы Ф. Кудашева белән әңгәмәсе).* № 11

Мөдәрисова Х. Рәхмәт сиңа, дустым! № 7

Рахмани Р. Борылыш чорында *(Г. Толымбайның туувына 110 ел).* № 7

Фронтовик язучыларның хатлары. № 4

Шамов А.—Бәширов Г.: фронт һәм тыл хатлары. №№ 5, 7

Хуҗин Ф. Күкләр шаһит. Документаль бәян. №№ 8-12

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре. №№ 3-7

Журналыбыз—Бөек Ватан сугышы елларында. № 4

ЮБИЛЕЙЛАР

МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Миңнегулов Х. Татарның бөек бер моңчысы. № 8

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Бөеклек баскычлары. №№ 8-12

ХАЛИКЪ САДРИНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ. № 8

ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Туфан Х. Ә йолдызлар дәшми. *Шигырьләр.* № 10

САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Алмазова А. Кабатланмас Сәйдәш. №12

Аның турында замандашлары. №12

ХӘСӘН ХӘЙРИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 2

ЗАҺИТ ХӘБИБУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 9

ӘНӘС ГАЛИЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ. № 4

ҖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ. № 7

МАРАТ МӨЛЕКОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Бәйрәмова Ф. Ул гел беренче рәттә булды... № 2

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Әдипләребез фикерләре. № 3

ДИЛӘРӘ ЗӨБӘЕРОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 4

ТАҺИР НУРМӨХӘММӘТОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 4

МӘГЪСУМ ХУҖИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 5

ВАХИТ ЮНЫСНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 10

ТӘУФИКЪ КАМАЛИЕВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ. № 2

КОТЛЫЙБЫЗ!

ФӘРИТ ХАТИПОВКА 80 ЯШЬ

Нәҗипова—Зиннәтуллина Ә. Гомер заяга узмаган. № 2

МӘРЗИЯ ФӘЙЗУЛЛИНАГА 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 6

ӘСГАТЬ САЛАХКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 1

ВАКЫЙФ НУРУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 5

ИЛЬҺАМ ШАКИРОВКА 75 ЯШЬ

Бөек җырчы турында сүз әйтәләр: Гәрәй Рәхим, Полад Бюль-Бюль Оглы, Юлай Шамил Углы, Рабин Сәфәргалиев, Бибигөл Теләгәнова, Михаил Львов. №2

МӘГЪСҮМ ГӘРӘЕВКӘ 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 3

ДАМИР ШӘРӘФЕТДИНОВКА 70 ЯШЬ

Без бит көрәшчеләр затыннан... *(Р. Низаминың «Гасырлар авазы» журналы баш мөхәррире Д. Шәрәфетдинов белән әңгәмәсе).* № 10

МӘХМҮТ ГАЗИЗОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 2

ЗӨФӘР ФӘТХЕТДИНОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 3

ХӘЛИМ ҖӘЛӘЙГӘ 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 4

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВАГА 60 ЯШЬ

Юныс Р. Фәүзия Бәйрәмова татарга кем тия ул? №12

КАМИЛ КӘРИМОВКА 60 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Алтыдагы алтмышта... № 7

ХӨСӘЕН ВӘЛИӘХМӘТОВКА 60 ЯШЬ

Әхмәт-Вәли Х. Комач хатирәләр. №12

ЗАҺИД МӘХМҮДИГӘ 50 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 7

НУРИЯ ИЗМАЙЛОВАГА 50 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Күңеленә дөнья сыйган. № 1

**«ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ»НӘ 90 ЕЛ**

Р. Низаминың «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире И. Шәрәфиев белән әңгәмәсе. № 1

**Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНА 70 ЕЛ**

Миңнуллин К. Гыйлем йортыбыз бәйрәме. № 5

**ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ИГЪЛАН ИТЕЛҮГӘ 20 ЕЛ**

Батулла Р. Азатлыкка таба. № 8

**«ШӘҺРИ КАЗАН» ГАЗЕТАСЫНА 20 ЯШЬ**

Р. Низаминың «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире М. Мортазин белән әңгәмәсе. № 10

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Әхмәтгалиева А. Тугрылык. № 2

Мостафин Р. Туфанның кайтуы. № 1

Фазлыев Р. Шаян талант. № 1

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Думави Н. Талак. № 9

Камалов Б. Гомер кичендә. Хикәя. № 1

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Сабиров И. Елау егет эшемени. № 4

**ҖАНИСӘП**

Без—татарлар! *(Ф. Фәтхинең И. Габдрафыйков белән әңгәмәсе).* № 3

Бердәм булыйк! № 6

Менә шундый исемлек... № 10

**ЮМОР-САТИРА**

Гобәй Р. Мамадыш мәзәкләре. № 4

Морат Г. Ике икең биш була. № 1

Миңнуллин Т. Минһаж мажаралары. № 2

**АК ҖИЛКӘН**

Абзалова Г. Исемеңне дога кебек кабатлап туеп булмый. № 7

Вәлиев Д. Парчалар. № 16

Габделхакова А. «Белмәү яхшырак...» *Фантастик хикәя.* № 4

Зарипова А. Бер телефон тарихы. № 5

Зарипова А. Бәхет бияләйләре. № 10

Исхакова Л. Әбиләр чуагы. Көз. Кояш... *Шигырьләр.* №12

Камалова А. *Шигырьләр.* № 7

Нургатина А. *Шигырьләр.* № 1

Нургатина А. Мин сине яратам.

*Фантастик хикәя.* № 9

Сәйфуллин И. Сәяхәт. *Шаян хикәя.* № 10

Сәлахова А. Өмет сүнмәде. *Шигырьләр.* № 4

Фәтхетдинова Л. Су елмайгач... *Хикәя.* № 11

Усманова Э. Кылый. *Хикәя.* № 10

Хәмзин А. Безнең дуслар мәктәптә. № 1

Хужин И. Яңа робинзоннар. *Хикәят.* № 1, 3

Шакиров К. Ньютон башына алма төшкәнме? № 2

Шакиров К. Ачышлар һәм ябышлар. № 4

Шакиров К. Ялгышлык бүләк иткән ачыш.№ 5

Шакиров К. Үсмер чактагы «ачышым». № 6

Шакиров К. Орбиталар җимерелеп бетмәгәнмени?№ 7

Шакиров К. Үҗәт шәкертләрдән кемнәр чыга? № 9

Шакиров К. Галилейның беренче ачышы. № 10

Шакиров К. Дачада, балык тотканда. № 12


### БӘЛӘКӘЙЛӘР

Вәлиев Р. Бәләкәй Разил. № 11

Миңнуллин Т. Бәләкәй Туфан. № 5

Низами Р. Бәләкәй Рашат. № 3

Нуруллина Д. Бәләкәй Дания. № 8

Сәхәбиев Р. Бәләкәй Сәхәби. № 7

Солтанова Г. Бәләкәй Гөлфия. № 10

Сөнгатуллина З. Бәләкәй Зилә. №12

Хәмзин А. Бәләкәй Алмаз. № 3

Шакиров И. Бәләкәй Илһам. № 4

Шәрәфиев Р. Бәләкәй Шәрәфи. № 6


### ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ

Ширмән Х. Хәл итәсе иде. № 10


### ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Вәлиева Л. Әй, болыт, кояшны каплама. *Шигырьләр.* № 11

Зарипова А. Күбәләккә тимәгез сез... *Шигырьләр.* № 3

Ибраһим Б. Яшәү рәхәт. *Шигырьләр.* № 9

Һадиева Э. Минем йола. *Шигырьләр.* № 6


### ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

Гомәр Г. Кол Галигә—«табу»! № 2

Гомәр Г. Шигырь—тәмаке түгел! № 8


### БОЛГАРЫБЫЗ

Болгар тарихына багышланган махсус сәхифә. № 9


### ТӨРЛЕСЕННӘН

Гарифуллин С. Европаны аркылыга-буйга. Сәяхәтнамә. №12


### ГОМЕР ИТМЕШ, ДӨНЬЯ КӨТМЕШ...

Нәҗмиев Т. Парчалар. № 3


### БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Әхмәтгалиева А. № 2

Әхмәтшина М. № 6

Диндаров И. № 1

Җамал А. № 11

Нәбиуллина Г. № 7

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№ 1-12

Укучы сүзе. №№ 2, 10

«Казан утлары»—интернетта. №№ 2-8

«Казан утлары» архивыннан. №№ 1-12

Безнең күргәзмә. № 7

Хушлашу сүзе. №№ 2, 3, 4, 8, 11

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№ 1-12

### КАЗАННЫ ҮЗ ИТӘЛӘР

Финляндия Президенты Тарья Халонен, Россиягә эшлекле сәфәре вакытында, Татарстан Республикасына да килде.

Ул, Илбашы Рөстәм Миңнеханов белән очрашу барышында, сәүдә-икътисадый, фәнни һәм мәдәни хезмәттәшлек урнаштыру турында сүз алып барды. Ә Казан (Идел буе) федераль университетының кинәйтелгән гыйльми советы утырышында Россия һәм Финляндия арасындагы фәнни бәйләнешләр турында лекция укыды.

Ике ил мәдәниятен баетуга зур өлеш керткәне өчен, Тарья Халоненга «Казан университетының Мактаулы докторы» исеме бирелде.

### ЮНЕСКОДА ДА СҮЗЕБЕЗ ҮТӘ

Октябрь аенда Парижда ЮНЕСКО башкарма советының 185нче сессиясе булып узды. Анда «Культуралар арасында диалог: тынычлык культурасы сәясәтенә яңача караш» дигән тема буенча дискуссиядә Татарстанның беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев чыгыш ясады. Чыгышның тулы тексты республикабыз газеталарында басылып чыкты.

### АЛЖИР ДА ЯКЫН БУЛЫР

Казан һәм Тлемсен (Алжирның шул исемдәге провинциясе башкаласы) тугандаш шәһәрләр булачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Алжирның Россиядәге илчесе Смәил Шерги белән очрашуы вакытында әнә шундый карар кабул ителде.

«Соңгы вакытта без Ислам дөньясына аерым игътибар бирәбез»,—диде республика башлыгы. Әлеге очрашу ике яклы хезмәттәшлекне ныгытуга хезмәт итәчәк. Хәзергә исә бу мөнәсәбәтләр без теләгән дәрәҗәдә түгел. Шуңа күрә Татарстан Президенты Алжир делегациясен Казанга чакырды. Аның составына Тлемсен провинциясе губернаторы һәм Тлемсен шәһәре мэры, югары уку йортлары җитәкчеләре керәчәк. Тлемсен үзе 2011 елда Ислам мәдәнияте башкаласына әвереләчәк.

### ТАТАР ТАРИХЫ—ИНГЛИЗ ТЕЛЕНДӘ

Казан университетында татарлар һәм Татарстан турында инглиз телендә басылган киң колачлы тәүге хезмәтне тәкъдим итү булды.

«Татар тарихы һәм цивилизациясе» дигән өч томлы хезмәт бу. Аны профессор Миркасыйм Госманов һәм республика Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов җитәкчелегендә Казан галимнәре эшләгән.

Тантананы ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев ачып, инглиз телендә шундый җитди басманың дөнья күрүе—татарларның катлаулы, шул ук вакытта бай мәдәниятен бөтен дөньяга танытуга ярдәм итәчәк, дип билгеләрде. Татарстанда планлаштырыла торган зур халыкара чаралар алдыннан бигрәк тә мөһим бу, диде ул.

Дәүләт Киңәшчесе фикеренчә, Россия тарихын илебез территориясендә (бүген гадәттә татарлар һәм борынгы Болгар дәүләте белән бәйләп аңлатыла) ислам дине барлыкка килүдән башка күз алдына да китереп булмый. «Әлеге китапны укыганнан соң шундый төп йомгак ясарга була: татарлар күп еллар узганнан соң да милли-мәдәни үзенчәлекләрен саклап калган һәм, элеккечә үк, Россияне бердәм дәүләт буларак үстерүдә мөһим роль уйный»,—дип басым ясап әйтте Татарстанның беренче Президенты.

### АКСАКАЛ ӘДИП ЮБИЛЕЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле әдип, җәмәгать эшлеклесе, ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинга 75 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә үтте. Юбилярны котларга Татарстанның беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы депутатлары, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, драматургның якыннары, туганнары, якташлары һәм каләмдәшләре килгән иде. «Миңа бәхетле язмыш бүләк иткән Ходай—иҗат

юлын сайларга ирек биргән. Театр, әдәбият юлыннан киләчәккә атлаганда киртәләр очратмадым, янәшәмдә яхшы кешеләр күп булды. Вак-төяк абынулар, сөртенүләр булган икән, адәм баласын күзен ачыбрак йөрергә өйрәтү өчен алары да кирәк»,—дип язган иде Туфан Миңнуллин.

—Мин үземне бәхетле кеше дип саныйм,—диде тәбрикләү чыгышында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.—Чөнки миңа шундый бөек шәхесләр белән аралашып яшәргә, алар белән бергә республикага хезмәт итәргә туры килде. Ә Туфан ага турында аерым әйтәсем килә. СССР заманында ук инде аның үз сүзе, үз фикере, үз кыйбласы бар иде. Һәм ул гомере буе үзе сызган туры юлдан барды да. 90нчы елларда Туфан Миңнуллин безнең халыкны яклап мәйданнарга чыкты, көндәлек матбугат аша халыкка үзенең фикерләрен ирештерде, пьесаларында бу болгавыр елларны тасвирларга тырышты. Ул бүген дә Дәүләт Советы утырышларында юк-бар сүз белән чыгыш ясамый, аның һәрбер сүзе уйланган булыр.

Аннары Фәрит Мөхәммәтшин юбилярга Татарстан Президентының Рәхмәт хатын һәм республика җитәкчелеге исеменнән җиңел автомобиль ачкычын тапшырды.

Юбилярны котларга килүчеләр күп иде: күрше республика һәм үзебезнең театр эшлеклеләре, якташлары, тамашачылар... Каләмдәшләре исеменнән Туфан Миңнуллинны Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Илфак Ибраһимовлар тәбрик итте.

Ә тантана ахырында юбиляр Туфан Миңнуллинның чыгышы аеруча тәэсирле булды.

—Мин дә гомер көземә якынлашам. Мәңгелек сәфәргә җыенырга вакыт,—диде ул, Әлмәндәр карттай ямансулап.—Әмма Ходай каршына буш кул белән барып булмый. Беләсезме, бер танышым минем әсәрләрне күпме тамашачы караганын исәпләп чыгарды. Уртача алсак, мин язган пьесалар буенча куелган спектакльләрне миллион ярым тамашачы караган булып чыкты. Залда җыелган халык бер минут кына кул чапса да, шуның өчтән икесе театрларга, ә калган өчтән бере минем өчен алкышлаган дип исәпләдек. Менә шул миллион ярым тамашачы 40 сәгать буе ашамыйча, эчмичә мина кул чапкан икән, җәмәгать. Мәңгелек сәфәргә чыкканда да шул алкышларны алып барырмындыр...

### КИТАПЛАР ОЧРАШТЫРДЫ

Моннан 15 ел элек Татарстан китап нәшрияты белән Башкортстанның З. Бишева исемендәге «Китап» нәшрияты арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү төзелгән иде. Шулай бергәләшеп уртак фикергә килү нәтиҗәсендә әлеге нәшриятларда «Каләмнәр туганлыгы» һәм «Кардәшлек киштәсе» дигән серияләр булдырылды, башкорт язучыларының китаплары бездә татар телендә, ә татар язучыларыныкы күрше республикада башкортча чыгарыла башлады. Бүгенге көндә, һәр ике якта да 30ар китап дөнья күрде. Җәмгысе 60 китап! Тугандаш республикаларда, төгәлрәк әйткәндә, Илештә һәм Актанышта үткәрелгән китап бәйрәмнәрендә нәкъ менә шушы игелекле хезмәт, ике нәшрият арасында төзелгән килешүнең күркәм нәтиҗәсе үзәккә алынды.

Галиҗәнап китап бер төркем нәширләрне һәм каләм әһелләрен дуслык сәфәренә дәште. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, шулай ук әдипләр Мөсәгыйт Хәбибуллин, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Марсель Гали, Фоат Садриев, Зиннур Мансуров алдан ниятләнелгән очрашуга юл тотты. Ә Уфадан икенче делегация сәфәргә чыкты. Аның составында Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Равил Бикбаев, Башкортстан «Китап» нәшрияты директоры Зәфәр Тимербулатов, шагыйрь һем прозаиклар Кадим Аралбай, Ирек Кинъябулатов, Гөлфия Юнысова, Галим Хисамов, Марсель Сәлимов, Әнисә Таһирова, Факиһә Тугызбаева, Сабир Шәрипов, Ринат Камал, нәшрият директоры урынбасары Галия Галимова бар иде. Санап үтелгән каләм ияләре очраклы гына сайланмаган—аларның әлеге нәшриятларда китаплары басылып чыккан.

Тантанада чыгыш ясаучылар—район җитәкчеләре дә, нәширләр, язучылар да—һәммәсе вакыт сынауларын кичкән ике халыкның кардәшлеге, алар арасындагы күпкырлы мәдәни бәйләнешләр, әлеге кавемнәрнең яшәешендә китапның бинһая зур вазифа башкаруы, каләм ияләренең илкөн алдындагы җаваплылыгы һәм башка шундый мөһим мәсьәләләр турында бик тәэсирле итеп сөйләделәр.

Бу очрашулар тугандаш ике республика арасында дустанә мөнәсәбәтләр тагын да яхшырачагына ышаныч тудыра.

### ИМАНЛЫ ӘДӘБИЯТ КИРӘК

Мәгълүм булганча, быел апрель аенда, Г. Тукайның юбилее алдыннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте талантлы яшьләр арасында «Таян Аллага» дип аталган әдәби бәйге игълан иткән иде. Бәйгенең максаты—яшь авторларны рухи проблемаларга мөрәҗәгать иттерү иде. Яшь язучыларның эшләренә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, язучы Вакыйф Нуриев, Г. Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Ркаил Зәйдулла, филология фәннәре кандидаты Зәфәр Гыйләҗев һәм журналист Рузилә Мөхәммәтова бәя бирде.

Нәтиҗәдә, поэзия жанрында гран-прига Рүзәл Мөхәммәтшин лаек булды. 1нче урын Ләйсән Фәтхетдиновага, 2нче урын Рифат Сәлахка, 3нче урын Йолдыз Миннуллинага бирелде.

Конкурста катнашкан 15 авторның әсәрләре «Таян Аллага» дигән җыентыкта бастырып чыгарылды. Проза жанрында исә 2нче урынга Гөлнирә Хөсәенова, 3нче урынга Ләйсән Фәтхетдинова лаек булды. Барлык җиңүчеләргә дә акчалата бүләк бирелде. Моннан тыш, Рифат Сәлах Хаҗ сәфәренә юллама белән бүләкләнде. Конкурсны оештыручылар Рүзәл Әхмәдиевнең шигырьләрен аерым китап итеп тә бастырып чыгарды.

Әлеге башлангычның дәвамлы булуы аеруча куанычлы. Икенче «Таян Аллага» әдәби бәйгесе 1 ноябрьдә игълан ителде, ул Г. Тукайның 125 еллыгына багышлап үткәреләчәк.

### КАН КАРДӘШЛӘР БӘЙРӘМЕ

29 октябрь Төркиядә республика оешу көне буларак зурлап билгеләп үтелә. 87 ел элек булган бу вакыйганы башкалабызда эшләп килүче Төркия генераль консуллыгы да бик күркәм билгеләп узды.

Узган елгы кебек, Төркия Республикасын үз итүчеләрне канкардәшләребез быел да «Корстон» тамаша-күңел ачу үзәгенә җыйды. Төркия Республикасының Татарстандагы генераль консуллыгы башлыгы Әхмәт Туга белән ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова җыелган халыкны бәйрәм белән котлады, соңгы елларда Төркия белән Россия, шул исәптән Татарстан арасында җылы мөгамәлә урнашуга шатлануларын, киләчәктә тагын да тыгызрак хезмәттәшлек итәчәгебезгә ышануларын җиткерде.

Мондый кичәләр ярымрәсми очрашу буларак оештырылганга, сәясәтчеләребез, галимнәребез, дин, дәүләт әһелләребез белән аралашу, фикерләшү өчен яхшы форсат ул.

### ПРЕМЬЕР—ТАТАРЛАР КУНАГЫ

Төркия Премьер-министры Рәҗәп Тайип Эрдоган Хельсинкида Финляндия татарлары белән очрашкан. «Исламия» җәмгыяте рәисе Окан Дахер сүзләренә караганда, очрашуда 70ләп милләттәшебез катнашкан. Эрдоган Финляндиядә яшәүче татарларның ана телләрен, гореф-гадәтләрен саклап калуына соклануын белдергән. «Бу тарихи очрашу булды, чөнки Төркия Премьер-министрының безгә кунакка килүе нәкъ бәйрәм елына туры килде. Быел мәхәлләбезнең рәсми оешуына 85 ел тулды. Хельсинкидагы мәхәллә йортыбыз төзелүгә дә декабрьдә 50 ел була. Моннан тыш, мәдәни оешмабызга 75 ел»,—дигән О. Дахер. Алар бу хакта Төркия кунакларына да сөйләгәннәр.

### КИРӘКЛЕ ГАМӘЛ

Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребез кызыксынулары, һөнәрләре буенча махсус берләшмәләр төзергә җыена. Бу хакта Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин башкаладагы татар иҗтимагый оешмалары лидерлары белән очрашу вакытында сөйләште. Әлеге эшне татар журналистлары башлап җибәрмәкче. Табиблар клубын җитәкләргә исә танылган кардиолог Ренат Акчурин ризалык биргән. Язучылар, сәнгать әһелләре дә үз берләшмәләрен төзергә ниятли икән. Бу оешмалар татар милләтен ныгытырга булышыр иде, ди алар. Очрашу барышында тагын бер сөенечле яңалык мәгълүм булды. Киләсе елның 26 апрелендә Мәскәүдә Габдулла Тукай истәлегенә һәйкәл ачылачак диләр.

### ТАТАРЛАР ТУРЫНДА ДИСК

Күптән түгел «Татарлар. Милли мәдәният» дигән диск сатуга чыкты. Анда милләтебез турында бик күп мәгълүмат тупланган. Дискның авторы Айдар Мәрдәншин әйтүенчә, бирелә тарих, дин, милли кием, музыка, аш-су, Сабантуй бәйрәме дигән бүлекләр бар. Ул, бер яктан, өлкәннәргә мәгълүмати ярдәм бирсә, икенче яктан, кызыклы анимация белән сабыйларны да үзенә җәлеп итә.

### ЯҢА ҺӘЙКӘЛЛӘР БУЛАЧАК

Татарстанның мәдәният министрлыгы Рудольф Нуриев, Һади Такташ һәм Рөстәм Яхинга куелачак һәйкәлләрнең иң матур эскиз проектына һәм кую урынына республикакүләм ачык конкурс игълан итте. Анда катнашу өчен гаризалар 8 ноябрьдән 22 декабрьгә кадәр кабул ителә.

### КАЗАНЫБЫЗ БОРЫНГЫ РӘСЕМНӘРДӘ

ТР һәм татар халкының дәүләтчелеге музеенда үзенчәлекле күргәзмә ачылды. Ул Казан күренешләрен беренче тапкыр фоторәсемгә төшерүнең 230 еллыгына багышлана һәм 2011 елның 15 февраленә кадәр дәвам итә.

Моның тарихына килгәндә, борынгы чорларда калабызның еш кабатлана торган янгыннарда бик күп зыян күрүен яхшы беләбез. Шундый коточкыч янгыннарның берсе 1774 елның җәй урталарында була. Императрица Екатерина IIнең (Әби патша) махсус боерыгы белән шәһәрне төзекләндерү өчен шактый күләмдә акча бүлеп бирелә.

Казна акчасының әрәм-шәрәм ителмәвен дәлилләү, төзелгән йортларның, каланың күренешләрен мәңгеләштерү өчен утызлап фотодан тупланган аерым бер рәсемнәр сериясе булдырыла. Шулардан 24 фото бүгенге көнгә кадәр сакланган.

Фотосурәтләрне Казан гимназияләре башлыкларының берсе Юлий Каниц һәм аның ярдәмчеләре эшләгән.

Күргәзмәне ачу тантанасында Казан Кремле музей-саклагычы директоры Рамил Хәйретдинов, баш архитектор Рөстәм Зәбиров, экспозициянең авторы Сергей Саначин чыгыш ясадылар.

### «МИН ТОРМЫШНЫ ЯРАТАМ»

10 ноябрьдә Милли музейда халык язучысы Фәнис Яруллинның тормышы һәм иҗатына багышланган «Мин тормышны яратам» дигән кичә узды. Анда студентлар һәм мәктәп укучылары катнашты. Кичәгә шулай ук язучының туган ягыннан да килделәр. Шунысын да әйтергә кирәк, ике ай элек Баулы районының Кызылъяр авылында Фәнис Яруллин исемендәге музей да ачылган иде.

Әлеге кичәдә әдип сүзләренә иҗат ителгән җырлар яңгырады. Аларны 2нче татар гимназиясе һәм 103нче мәктәп укучылары башкарды. Шагыйрь яшьләрнең бик күп сорауларына да җавап бирде.

### ИСЛАМ УНИВЕРСИТЕТЫНДА ОЧРАШУ

Язучыларыбыз матур әдәбият ятучылар, студентлар, мәктәп укучылары белән еш очрашып тора. Чираттагы очрашуларның берсе Россия Ислам университетында булды. Студентлар белән әңгәмәләшергә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, халык шагыйре Р. Фәйзуллин, халык язучысы, драматург Р. Батулла, язучы-галим Т. Галиуллин, шагыйрә Г. Бәйрәмова килгән иде. Университет ректоры Р. Мөхәммәтшин белән берлектә уздырылган әлеге очрашуда студентлар борынгы һәм бүгенге әдәбият, тормыш-яшәеш турында үзләрен кызыксындырган күпсанлы сорауларына җаваплар алдылар, журналлар, китаплар белән бүләкләнделәр. Сөйләшүдә дин һәм әдәбиятнең берлеге, татар телен саклауда динчеләребезнең дә роле зур булырга тиешлеге әйтелде.

### ЯЗУЧЫ-ДИПЛОМАТНЫ ЯД ИТҮ

Баулы районы Исергәп авылы—күренекле язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Миргазиян Юныс белән аның бертуган энесе, заманында атаклы Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтын тәмамлаган, Гыйрак, Мисыр, Әфганстан, Сүрия кебек илләрдә СССР илчелегендә эшләгән шәхес, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, публицист, Вахит Юныснын туган авылы. Быел Вахит Юныснын тууына 80 ел тулды. Шул уңайдан Исергәптә һәм Баулы мәдәният йортында язучы-дипломатны искә алу кичәсе үткәрелде. Анда Миргазиян һәм Вахит Юнысларның каләмдәшләре—күренекле язучылар Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев һәм Татарстан Милли китапханәсе директоры Наил Камбеев катнашты. Кунаклар Вахит Юныснын Исергәп авылы зиратындагы каберен зыярәт кылды, Юнысовларның туган нигезендә, алар укыган мәктәптә, район китапханәсендә булды. Алар шулай ук Кызыл Яр авылында туып-үскән Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинның әле күптән түгел генә ачылган музей-фатирын да карады.

### АЛИШ ПРЕМИЯСЕ ИЯЛӘРЕН ТАПТЫ

Татарстан мәдәният министрлыгы һәм язучыларның А. Алиш исемендәге премиясе әдәбият өлкәсендә уңышларга ирешкән шагыйрьләргә, әдипләргә бирелә. 1996 елда аңа беренче мәртәбә Ләбибә Ихсанова лаек булган иде. Быел бертөркем язучылар А. Алишның туган ягында булып кайтты. Иң элек алар Көек авылында язучының бюстына чәчәкләр салды. Аннары Спаста зур тантана узды. Анда А. Алиш исемендәге бүләкләр Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Дания Гайнетдиновага һәм Мөслимдә яшәүче язучы Мөҗәһит Әхмәтҗановка тапшырылды.

### ШӘЛЕ ЕГЕТЕ ҮРЛӘР ЯУЛЫЙ

Язучы Камил Кәримовка 60 яшь тулу уңаеннан, Питрәч районының Шәле авылы мәдәният йортында зур иҗат кичәсе үткәрелде. Юбилярны барлык якташлары исеменнән Питрәч муниципаль районы хакимият башлыгы Ш. Г. Насыйбуллин, мәктәп директоры М. Г. Хәсәнова, хезмәт ветераны И. Б. Бәйрәмов, язучының беренче укытучысы С. М. Вафина, шулай ук хезмәттәшләре—«Казан утлары» журналы коллективы һ. б. котлады.

«Ком сәгате», «Сакау күке», «Уен», «Игезәкләр йолдызлыгы» романнары һәм дистәләгән китап авторы Камил Кәримовның иҗат бәйрәме 25 октябрь көнне К. Тинчурин исемендәге театр бинасында дәвам итте. Юбиляр кичәсенә халык шыгрым тулып килгән иде.

Тантанада республиканың Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге һәм Татарстан—Яңа Гасыр телерадиокомпаниясе катнашты.

Юбилярны каләмдәш дуслары Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Илфак Ибраһимов, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Алмаз Хәмзин, Газинур Морат һ. б. котлады. Бәйрәм уңаеннан туган ягыннан да зур делегация килгән иде.

Кичәдә күренекле язучы, танылган юмор остасының байтак популяр әсәрләре яңгырады. Аларны ул үзе дә укыды, сүз осталары да башкарды.

Җырчылар Рәсим Низамов, Азат Ти-

мершәех, Айгөл Бариева, Рамай белән Назлыгөл һәм Гүзәл Нурмөхәммәтова чыгышлары тамашачылар күнелен яулады.

Шунысын да өстәп әйтик: хезмәттәшебезнең укучыларда зур кызыксыну уяткан «Игезәкләр йолдызлыгы» романы «Казан утлары»ның быелгы 9-10 саннарында басылып чыккан иде.

### ИЛДАР ХАНОВ БӘЙРӘМЕ

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында сынчы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Хановның 70 яшьлек юбилее уңаеннан күргәзмә ачылды.

Ярты гасырлык иҗат эшчәнлеге дәверендә Илдар Ханов 70тән артык скульптура һәм монументаль-декоратив әсәрләр иҗат итә. Аларның күбесе Татарстан җирендә: Чаллыда «Ватан-Ана», «Кәрәш», Энтузиастлар бульварында «Уяну» скульптура комплексы, «Эволюция», «Тормыш агачы»; Казанның Арча зиратында «Ату» рельефы; Тукай-Кырлайда «Шигърият агачы» монументаль композициясе h. б. Аракчинодагы «Галәм әхрамы» Илдар Хановны сынчырәссам һәм архитектор буларак бөтен дөньяга танытты.

Илдар Ханов тормышындагы иң җете мизгелләр; сынчы-рәссамның әти-әнисе яшәгән нигездә калкып чыккан әхрам ничек яши, ничек итеп көннән-көн яна төсләргә байый бара—«Хәзинә» милли сәнгать галереясындагы фотокүргәзмә әнә шулар турында сөйли. Шунда ук рәссам иҗатына багышланган фильмнарны да карарга мөмкин.

### АЛСУ ИҖАТЫНА БАГЫШЛАП

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында Алсу Тимергалинаның илле яшьлек юбилее уңаеннан шәхси күргәзмәсе ачылды. Рәссам сәнгать сөючеләргә «Иске Казан. Печән базары», «Актүбә атлар», шулай ук күпсанлы этюдлары буенча билгеле. Алсу Тимергалина (мәшһүр әдип Адлер Тимергалинның кызы) акварель, графика һәм рәсем сәнгатенең башка алымнары буенча эшли. Ун еллап иҗади гомерен Иске Казан һәм Казан буенча тарихи цикллар иҗат итүгә багышлады. Ул шулай ук күп кенә китапларга иллюстрацияләр ясавы белән дә күпләргә билгеле. Ә менә кадәр Алсу ханымның картиналарын Төркиянең Истанбул шәһәрендә үткән күргәзмәдә дә җылы кабул иткәннәр иде.

### ЧАЛЛЫДА ӘДӘБИ КИЧӘ

Чаллының Сара Садыйкова исемендәге концертлар залында шагыйрь Мирһади Разовның 50 яшьлек юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә үтте. Юбилярны тәбрикләргә күренекле мәдәният хезмәткәрләре, язучылар, гаммәви мәгълүмат чараларында эшләүчеләр, шигърият-җыр сөюче милләттәшләребез җыелган иде.

Мирһади Разов—1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Шагыйрьне каләмдәшләре һәм якташлары исеменнән Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире Вахит Имамов котлады.

Кичәдә күптән түгел генә Мирһади Разовка «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында да игълан ителде.

***

Хәзерге татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен «Инновация» студиясе сценарий авторы, режиссеры, язучы **Юзеев Салават Илдар улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

2010 елның 31 октябрендә 73нче яшендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты, драматург, прозаик һәм философ **Диас Назыйх улы Вәлиев** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Кышкы урман.

*Дүртенче биттә:* шагыйрь **Мөҗәһит Әхмәтҗанов**.


# Яңа китаплар




**Мөхәммәт Мирза.** Адәм баласы. Шигырьләр.— Казан: «Мәгариф» нәшр., 2009.—448 б. Тиражы 1000 данә.

Мөхәммәт Мирзаның бу китабы бишьюллыклардан тора. Әлеге шигырьләр үзләренең бердәм композицион төзелеше белән аерылып торалар. Шагыйрь үз иҗатында табигатьнең бихисап күренешләрен, халык әйтемнәре-гыйбарәләрен кулланып, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, кешелекнең рухи тазалыгына кагылышлы мәсьәләләрне яңача тасвирлый.

Китап дүрт телдә басылган. Аларны русчага А. Кәримова һәм Т. Шәрәфиева, төрекчәгә Ч. Зариф һәм Ф. Кутлу, инглизчәгә Р. Маккейн тәрҗемә иткән.




Беренче намаз: төрек һәм төрки шигырьләр, хикәятләр-хикмәтләр, хикәяләр.—Казан: «Ихлас» нәшр., 2010.—143 б. Тиражы—500 данә.

Бу җыентыкта татар вакытлы матбугатында—«Казан утлары» һәм «Сөембикә» журналларында,«Мәдәни җомга», «Заман—Татарстан» газеталарында дөнья күргән төрек һәм төрки әдипләрнең гүзәл әсәрләре урын алган. Аларны күренекле шагыйрә Бикә Рәхимова тәрҗемә иткән. Китапның башында Әкрәм Каланның кереш мәкаләләре дә урын алган.



Мөҗәһит Әхмәтҗанов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)